www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Җәүдәт СӨЛӘЙМАН. Кояш нурларына сыена. *Шигырьләр.* ........................................3
Рабит БАТУЛЛА. Китек күңел. *Бәян.* ........................................7
Айрат СУФИЯНОВ. Өзелмәсме милли шәҗәрә? *Шигырьләр.* ........................................38
Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Ак читек. *Бәян.* ........................................42
*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ........................................77
Гөлүсә БАТТАЛОВА. Рәшә иде ерак дәвердән. *Шигырьләр.* ........................................79
Ринат МӨХӘММӘДИЕВ. Аязучан болытлы һава... *Хикәя.* ........................................128

МАКСИМ ГОРЬКИЙНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Марсель ГАЛИЕВ. Бөек әдип. ........................................83
Максим ГОРЬКИЙ. Лев Толстой. *Язмалар. (М.Галиев тәрҗемәсе.)* ........................................91
*100нче бит:* Рабит БАТУЛЛА. ...биздергән дә тел! ........................................100
*Яңа исемнәр.* Алинә ХИСАМИЕВА. Кайтаваз кабатлый үткәннән. *Шигырьләр.* ........................................125

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Зөлфәт ХӘКИМ. Тәрәзәдә һаман ут яна. *Бер пәрдәле драма.* ........................................136

ДӨНЬЯ ХАЛЫКЛАРЫ ӘДӘБИЯТЫ

Арпад ГАЛГОЦИ. Язга таба. *Хикәя. (Р.Зәйдулла тәрҗемәсе.)*........................................155

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕНӘ КАНДИДАТЛАР

Рамил ХАННАНОВ. «Яшәлгәнен яза торам...» ........................................158

РӘФИКЪ ЮНЫСКА 75 ЯШЬ

Рәфикъ ЮНЫС. Җитәрбез иң ерак чорларга. *Шигырьләр.* ........................................164
*Язмыш мизгелләре.* Рәфикъ Юныс фотоархивыннан. ........................................166

РАБИТ БАТУЛЛАГА 80 ЯШЬ

Саимә ИБРАҺИМОВА. Сокланам! Шаклар катам! ........................................168

РӘИС ДАУТОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Флёра ТАРХАНОВА. Мин аларга мең-мең рәхмәтле! ........................................172

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. «Бүркем икәү...». ........................................174
*Мөгаллим мөнбәре.* Алёна ФӘХРЕТДИНОВА. Халык авыз иҗаты – миллилекнең башы. ...179
*Безнең календарь:*Дәрҗия АППАКОВА, Әнәс КАМАЛ, Нәҗип МАДЬЯРОВ. ........................................182
*Куен дәфтәреннән:* Рәшит МИНҺАҖ. Ышанычлы иләк. ........................................185
*Печән базары:* Нәсих ТАҖИ. Мин. *Мәсәл.* Габделхак ӘХМӘТ. Кайткан! *Памфлет.* .........187
*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ........................................188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........................................190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Илсур Һадиуллин**
**Рәфикъ Юныс**

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер).

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266).*
: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*

: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 28.02.2018, график буенча 28.02.2018.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Е-453. Тираж 4200.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2018 ел



Җәүдәт
Сөләйман

# КОЯШ НУРЛАРЫНА СЫЕНА

***

Дөнья – тәмуг...
Әзме сызлау, бәргәләнү...
Тоя шуны тәнең, җаның, аңың булсын...
Кайтып-кайтып, үзәгеңне телеп ала
Шарт-шорт килгән кыллы нәфес чыбыркысы...

Дөнья – оҗмах...
Тән-өрфия өчен әзер
шифа сулы кизләүләре, саф һавасы,
нурлы кояш, татлы ризык-нигъмәтләре.
Хур иясе бишектәге һәр нарасый...
Күңел өчен меңләп төсләр, меңләп һуш-ис,
Кошлар сайрый, моңлы-җырлы фани дөнья.
Аң чигендә акыл үтмәс тибрәнешләр.
Зиһен үтми моңа. Моны күңел тоя...

...Җәннәт-тәмуг – ике халәт бер дөньяда.
Бер гөлчәчәк. Чәчәге һәм энәләре...
Бер киселә, бер тырнала, бер сыйпала –
шулдыр җанның күк катларын үтүләре.
Сиңа, адәм, бердәнбер ул, ул бер дөнья,
Җәннәте дә, тәмугы да бергә шунда.
Башка җәннәт, башка тәмуг сиңа түгел,
Син адәмнән күккә ашкан бакый җанга...

## Талпыну

Бер талпынам күккә карап, бер сүреләм,
Бер тагам да, бер салам канатларны,
Күңел һаман тынычланмый, и талпына,
Һаман тарта, тарта әле күк катлары.

---

Җәүдәт СӨЛӘЙМАН (1955) – *галим, ТР Фәннәр академиясе академигы, шагыйрь; «Ямаулыклар», «Мин-минсез дөньяда», «Күләгәләр» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт, М.Җәлил һәм Г.Исхакый исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

Әмма шунда сүреләм дә тынычланам,
Ә соң җирдә әзме серләр, тукта, кара,
Оныкларым, минем серле йомгакларым,
Үзләре бер дөнья булып үсеп бара.

Шул дөньялар хәзер минем җирем, күгем,
Шул дөньялар илтә мине еракларга,
Канатларны салып куеп, каурыйлардан
Тырыша-тырыша канат сиплим оныкларга.

***

Артларыннан кемдер куа, булыр,
Диңгез дулкыннары килә ургып.
Кая ыргылуың, диңгез, кызып,
Кая ашкынуың күзең йомып?
Бер-бер артлы, үрә басып, гүя,
килә Рум гаскәре, диңгез тулы.
Кыя-ташлар күкрәкләрен куя,
Кургаш дулкыннарга киртә булып.
Нидер даулый диңгез, кыя-ташка
бәрә-бәрә кургаш йодрыкларын.
Әллә диңгез искә төшерәме
Ил йотылган котсыз вакытларны?
Кая барып бәрелергә белми,
Дулкын ярга бәрә, кайта-кайта...
...Дулкын-дулкын минем хисләр тузгый,
Тамырларны, күңелемне айкап...

***

Бу гади бер коан, шуны күз алдына китер:
Ике төпсез упкын арасында чиксез күпер.
Бер җавабы шундый (тик соңгысы түгел):
Упкыннар – Кичә-Иртәгә, ә күпере – Бүген.

Кичәге көн һәм иртәгәсе – ике рәшә яр,
Ике ярны тоташтыручы – бары син бар.
Бүгенге көн – ике арадагы упкын-дәрья.
Шул дәрьяда вакыт ятьмәсендә синең дөньяң...

Упкын-дәрья үзе вакыт ятьмәсендә булса,
Дөньяң – дәрья. Хәзер һәм биредә – Күк сүрәсе.
Биредә һәм хәзер мәңге яшәгәндә генә,
Мәңгелеккә дәгъва кешелекнең Фәлсәфәсе...

***

*Әнигә*

Тиз йөрешле поезд. Оча Нарбоннага[1].
Бордо[2] төбәгеннән юл үтә.
Бордо, дигәч, телдә кызыл шәраб тәме...
Хатирәләр тирән, ә ...истә.

[1] Франциядәге шәһәр.
[2] Франциядәге төбәк исеме.

Уңнан-сулдан очып үтә тоташ таулар,
Поезд тәрәзенә сыланып,
Мин авылда сыман, әни белән бергә,
Очып кайттым, хискә чолганып...
...Поезд тәрәзендә – зәйтүн агачлары,
Күңел тәрәзендә – наратлар,
Истә, әни, истә, чиләк тулы җиләк,
Үзең кара җиләк, ул чаклар...
Поезд оча гына! Чит-ят дөнья оча!
Бәдән фәкыйрь шунда, вагонда.
Ә мин үзем йөрим шәүрин[3] буйларында,
Күңелем белән әни янында.
Мин поездда. Юлда. Әмма әни белән.
Шундый халәт: бер – төш, бер – өнем.
Юкка гына түгел, саташу да түгел –
...Туган көне бүген әнинең.

## Диңгез

Учларыңда, диңгез, ташлар уйнатасың,
Син дулыйсың, гүя ачулы,
Әйдә, дула, диңгез, миңа шуннан рәхәт,
Дулкын баса йөрәк ярсуын.

Бер карасаң, дәһшәт, диңгез үрә баскан,
Күк йөзе дә кара, куркыныч.
Син улыйсың, диңгез, әйдә, ула шулай –
Син улаган саен ...мин тыныч.

Үзенә бер сихри рәхәт бар давылда,
Кайный дөнья, җанда – тантана!
Тәңре кодрәтендә ике халәт бергә,
Диңгез дулый – күңел шатлана...

***

Яши-яши күнегәсең табигатькә,
Диңгез-таулар урман-кырлар кебек якын,
Булсын Париж, Барселона йә Лиссабон,
Безнең белән бер калыптан, шул ук халкы.
Әйтмәс идем, монда ирек, ни теләсәң,
Шуны эшлә, күкләр, диеп, чиксез.
Монда да шул – дәүләт булгач, шул ук читлек,
...Әмма иркен читлекләре, эчтән биксез...

## Тирән күлдә әбиләр чуагы

Купшы яфраклардан алтын җәймә.
Шәмнәр булып рәт-рәт каеннар.
Ефәк пәрдә булып, каен яфраклары
Кояш нурларына сыена.

[3] Яшел чирәмле елга буе.

Тирән күлнең вак-вак дулкыннары,
Бер фирүзә төсле, бер сапфир,
Тирән күлдән күзем алмый торам,
Табигатькә гашыйк – мин, фәкыйрь...

Күк йөзенең ачык, көләч мәле,
Зәңгәр гөмбәз – күлгә кайтаваз.
Әмма... күзләр күпме елмайса да,
Җәйләр инде кире кайталмас...

***

Аяктагы тышау әле коллык түгел,
Бәйләсә дә аякларны бергә.
Һәм казык та шулай, әле коллык түгел,
Бәйләсә дә баш-аяктан җиргә.

Казыкларны җирдән давыл йолкып ала,
Тышауларны үткер кылыч кисә,
Җуелмасын гына, канга-җанга сеңгән
Кылычлардан үткер дала исе...
Давыллардан көчле ирек хисе...

***


Әле син бер яшел кыяк идең,
Тәүге тапкыр сине күргән чакта,
Әмма тылсым инде иңгән иде
Балкып торган серле кыл-кыякка.

Серле кыяк – бүген гүзәл чәчкә,
Таҗларында уйный көмеш рәшә,
Янар чәчкә, синең балкыш аша
Сихри гөлләр иле мине дәшә...

***

Бармы бер-бер мәңге дәвам иткән
Җисем, фикерме йә бер күренеш...
Бармы җирдә, күктә йә кайдадыр,
Бакый җан иясе йә яшәеш?

Без белмибез, хәтта беләлмибез,
Мәңгелек сер хәтта фани дөнья.
Бер Тәңрегә мәгълүмдер чишелеш,
Бер Тәңрегә бакый җиһан сыя...



Рабит
Батулла

# КИТЕК КҮҢЕЛ

БӘЯН

Шәһәр йоклый. Биш катлы йортның бер тәрәзәсендә ут һаман сүнми дә сүнми. Яшь кенә ир белән яшь кенә бер ханым сөйләшә-чөкердәшә таң аттыра.

– Исемең ничек синең? – диде ханым.

– Мостаңгир! – диде ир кеше.

– Мостаңгир? – диде ханым, гаҗәпләнүен яшермичә. – Ул нинди исем тагын? «Мустаң» кайсыдыр бер телдә «ат көтүчесе» дигән сүз түгелме соң?

Мостаңгирның көлгәне ишетелде.

– Хак әйттегез, сөйкемле туташ!

– Ханым! – дип төзәтте хуҗабикә.

– Кичерегез! – диде ир кеше. – Хак әйттегез, ханым! Сабый чагымда мин җәй буе җылкы саклап тамак туйдыра идем... «Мустаң» – «Ат» дигән сүз, дөрес. Әмма минем исем «Му»дан башланмый, татарча «о» белән әйтелә: Мос-таң-гир!

– Гаҗәп, татарда андый исем ишеткәнем булмады. Мос-таң-гир!

– Бабам Мостафа, атам Җиһангир... Менә сиңа – Мостаңгир! Әти шулай хыялый булган, дип сөйлиләр.

– Матур исем килеп чыккан. Мостаңгир...

Мостаңгир Сәлимәне үбеп алды. Тышта әкренләп яктыра.

– Ә син кемне үпкәнеңне беләсеңме, Мостаңгир?

– Беләм... Сәлимә исемле тол хатынны үптем.

Сәлимәнең йөзендә гаҗәпләнү чаткылары уйнап алды. Кызыксынуын яшерә алмыйча, Сәлимә Мостаңгирга текәлеп карады. Аның башында уй бөтерелә иде.

«Менә сиңа – мә! Каян килеп минем исемне белә бу иптәш Мостаңгир?»

– Каян белдең? – дип сорады хуҗабикә.

Мостаңгир серне тиз генә ачарга теләмәде, Сәлимәне бераз тилмертте, Сәлимәнең кызыксынуы артканнан арта; Мостаңгир моны сизеп тора, үзе хәйләкәр елмая, вакытны озаграк сузар өчен, үрелеп шырпы алды да тәмәке кабызды.

---

Рабит БАТУЛЛА (1938) – *Татарстанның халык язучысы; иллегә якын китап авторы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

«Тәмәкене дә әллә ничек, матур итеп тарта бу Мостаңгир», – дип уйлады Сәлимә.

– Әйт инде, Мостаңгир, каян белдең? – дип сорады ул тагын.

– Мин сихерче бит, – диде егет.

– Әйт әле, сихер иясе, миңа ничә яшь?

– Әйтмим!

– Тотылдың, алайса, монысын белә алмыйсың.

– Беләм.

– Белсәң, әйт!

– Егермедә, дисәм – ялган. Утызга җитеп киләсең, дисәм – яратмассың.

– Кара, нинди дипломат син.

– Шулай да, ике яшькә киметеп булса да әйтим: сиңа егерме дүрт яшь!

Сәлимә тагын уйлый.

«Каян беләсең син барысын да? Берәрсе яллап җибәрмәгәндер бит? Юк, син сатлык кешегә охшамагансың...»

– Бозау икәнсең, – диде ханым. – Нәкъ өстенә бастың. Миңа егерме алты тулды... Мөгаен, син юристтыр!

Мостаңгир, тәмәке төтенен авызында тотып:

– Мъ! – дип башын чайкады.

– Алайса, син язучы яки журналист!

– Мъ!

– Алайса, артист яки режиссёр!

Мостаңгир, ниһаять, төтенен эчкә алды да әйтте:

– Юк! Син күзәтә белмисең икән, Сәлимә. Мин – инженер!

– Менә сиңа – мә!

– Әле, җитмәсә, цех башлыгы, белдеңме?

– Син профессияңне ялгыш сайлагансың...

– Нигә, Сәлимә-җан?

– Һәр премьера саен син театрда, һәрвакыт синең кесәңдә яңа китаплар, газеталар була... Синең эштән соңгы вакытың сәнгатькә бирелә.

– Юк, Сәлимә, сәнгать миңа бирелә, – диде кунак.

– Син сәнгать кешесе, Мостаңгир! – диде хуҗабикә.

– Бу юлы да син хаклы түгел! Мин сәнгатьне сөюче генә... Беркайчан да артист яки музыкант булырга хыялланмадым.

– Мостаңгир, син барысын да каян белдең? Гәҗит теле белән әйткәндә: сиңа минем турыдагы мәгълүматны кем тапшырды? Безнең уртак танышыбыз да юк шикелле.

– Һич нәрсәдән шикләнмәгез, ханым! Бу минем мантыйкый фикерләү ысулы!

– Сез бик борынгы китаплар теле белән сөйлисез, бәлки, төшендереп бирерсез, ә?

– Фикер эзлеклелеге һәм күзәтүчәнлек! Логика! Мантыйк!.. «Зәңгәр шәл» тамашасын карарга без – фәкыйрегез дә барган иде. Менә шул тамашаны карарга театрга ике кыз килде. Алар һәрвакыт премьераның беренче көненә йөри. Аларның берсе чем-кара, икенчесе сап-сары чәчле иде. Тәкъдир шулай кушкандыр инде: бу ике кыз без – фәкыйрегез утырган рәтнең алгысына туры килде. Колак дигәнең бик сак нәмәрсә бит, ишетә. Кара чәчлесе сары чәчлесенә «Фирая» дип, сары чәчлесе кара чәчлесенә «Сәлимә» дип эндәшә...

Сәлимә көлә башлады.

– Очлы колак! – дип, Мостаңгирның колагын тартты.

– Аннан соң, синең тол хатын икәнлегеңне альбомдагы рәсемнәр сөйләде. Синең ирең офицер булган.

– Очлы күз!

– Җә инде, Сәлимә! Аннан башка да кушаматларым күп минем – Аллага шөкер.

– Нинди кушаматларың бар тагын? Әйтеп бир!

– Кыярбаш!

– Ни өчен Кыярбаш?

– Баш түбәм ике бөтерчекле минем.

Сәлимә Мостаңгирның чәчен актарырга тотынды:

– Каяле, кая!.. Чынлап та ике галактика!

– Әнә шул ике галактика минем башны озынча итә дә инде.

Тынлык урнашты. Икесе дә җитди уйда иде. Мостаңгир фотоальбомны янә кулына алды да Сәлимәнең ире белән парлап төшкән рәсемне җентекләбрәк тикшерә башлады.

– Сез шундый пар килгәнсез, – диде Мостаңгир, шактый утыргач. – Капитан! Икегез дә бәхетле. Нигә аерылыштыгыз, дип сорасам, атлаган саен бу турыда синнән сорый торганнардыр инде...

Сәлимә җитди иде. Ул, авыр уйларыннан арынырга теләптер ахрысы, тирән көрсенеп куйды.

– Тормыш гаять кызыклы икән ул, Мостаңгир.

– Катлаулы дип әйтергә теләгән идеңме?

– Кызык та, катлаулы да... Без аның белән озак йөреп кавыштык. Бала чактан ук безне «Таһир белән Зөһрә» дип йөртәләр иде. Әни дә, апам да аны гел мактап кына торды. Өйләнештек. Бер ел да тора алмадык... Өйләнешкәнче яратыштык, яратмадык түгел, һәрхәлдә, без бер-беребезне яратабыз, дип уйлый идек. Бергә яши башлагач, мин котчыккыч хата эшләгәнемне аңладым. Әгәр мин аңа чыга алмасам – бу котчыккыч үкенеч, хәтта бәхетсезлек булып күренер иде. Шушы хатамны аңлау өчен, аңа чыгарга, шушы хатаны эшләргә кирәк булгандыр...

Тагын тынлык урнашты, тагын алар үз уйларына батты.

– Эчә идеме? – дип, Мостаңгир тынлыкны бозды.

Сәлимәгә Мостаңгирның бу соравы ошамады, хәтта аны чыгырыннан чыгара язды.

– Кызык кына бу кешеләр... – Сәлимә канәгать түгел иде. – Бөтен кеше, начар идеме, ямьсез идеме, эчә идеме, дип теңкәмә тиеп беттеләр инде. Эш начарлыктамыни? Эш ямьсезлектәмени? Эш эчүдә дә түгел! Апам, җизнәм, туганнарым фикеренчә, дус кызларым уенча ул – алтын ир. Барча танышбелешләрем, дус-ишләрем аннан аерылганга аптырый. Апам мине гомере буе аңламаячак... Хәзер, Мостаңгир, шундый замана, ана – кызын, кыз анасын аңламый. Хәтта мин үземне үзем дә аңламыйм кайчак. Ул ямьсез түгел иде, мәһабәт ир. Эчми дә иде... белмим, белмим... Аңа кияүгә чыгуны бер ялгыш дип карасаң, аның белән торуны мең ялгыш итеп карарга кирәктер... беләсеңме, дустым, сәбәбен һич әйтә алмыйм... Элеккеге яратышып йөргәннәрне искә төшереп, мин аны яратырга тырышып карадым. Юк!.. Нигә аны да, үземне дә тилмертергә?

Сәлимә тынып калды.

Мостаңгир кыюсыз гына әйтеп куйды:

– Альбомыңда саклыйсың... – диде.

Сәлимә авыр уйларыннан аерылмыйча гына дәвам итте.

– Альбом – ул кеше тарихы, Мостаңгир. Кечкенә генә бер адәмчекнең

бәләкәй генә тарихы ул... Замана үзгәргән саен, альбомдагы, дивардагы рәсемнәрне утка якмыйм мин... Рәсемен ертып кына кешене тарихтан юып булса икән. Яхшымы, яманмы, ул булган...

Сәлимә үзе сөйли, үзе болай уйлый:

«Язмыш безне ни өчен очраштырды икән, Мостаңгир? Нигә болай бик тиз, бик җиңел ияләшеп киттек соң әле без?»

Сәгать кыңгыравы чылтырарга тотынды. Мостаңгир, сикереп торып, киенә башлады. Сәлимә тиз генә халатын бөркәнде.

– Сәлимә, сәгать җиде икән бит инде! – диде Мостаңгир, каударланып.

– Чәй эчеп кит, ичмасам, – диде Сәлимә, аш бүлмәсенә узышлый.

– Соңга калам, юлга вакыт күп китә... – диде Мостаңгир, киенә-киенә.

Сәлимә аны ишеккә чаклы озатты.

– Килерсеңме? – диде ул.

– Килермен, Сәлимә, килермен! – диде Мостаңгир.

Сәлимә аңа күн янчык бирде.

– Менә ачкычлар. Син бу ишекне теләсәң кайвакытта ачып керә аласың!

Мостаңгир Сәлимәне кочаклап үпте дә бусагадан атлады.

– Туңасың, яп ишекне! Җә, хуш, Сәлимә! – дип, Мостаңгир, лифтны да көтмичә, йөгереп аска төшеп китте.

***

Тышта буран тагын да ныграк котыра. Бүлмәдә салкынча. Сәлимә бөрешеп утыра. Ул җәймә бөркәнеп уйга талган.

Сәлимәнең уйлары да буранның рәхимсез улавын арттыра кебек.

«Әгәр килмәсә? Ихласлыгымны аңламаса? Көтәргә кирәк. Вакыт хәл итәр. Бер көн, өч көн көтәргә. Әгәр дә мин аңа бер кич юаныр өчен генә кирәк булганмын икән – фаҗига. Әгәр дә ул мине үз итеп ярата икән – җаным-тәнем, барлык хисем, бөтен тырышлыгым белән мин аныкы!.. Көн дә үтте, төн дә үтте... Шимбә көн башланды бит инде... Ул һаман юк...»

Шулчак ишек артында тавыш ишетелде.

– Сәлимә сеңлем, газета-журналларыңны ал! – диде гәзит-журнал ташучы хатын.

Сәлимә, ишекне ачып, бер кочак газета-журналлар күтәреп керде. Тагын ишек шакыдылар. Сәлимә дерт итеп китте дә ишек катына йөгерде.

Тышта тагын тавыш яңгырды.

– Сәлимә апа, сөт китердем, чыгып ал, – диде сөт ташучы кыз.

Сәлимә бер шешә сөт күтәреп өстәл янына килде. Аннан соң көзгедәге үз сурәтенә бакты. Радионы борып җибәрде. Ләкин бу эшләр аңа кирәк түгел. Ул эче пошканнан гына, вакыт уздыру өчен генә эшли иде боларны.

Сәлимәнең эчке тавышы үз-үзен битәрли иде.

«Җүләр дә инде син, Сәлимә. Тинтәк хатын син... Килер димсең?»

Сәлимә эчке тавышына үзе җавап кайтарды.

– Белмим, өздереп кенә әйтә алмыйм. Күңелем ышана.

Сәлимәнең эчке тавышы:

«Күңел, күңел! Китек күңелле хатын син, Сәлимә», диде.

– Күңеле тулган хатын мин. Җылыйсым килә.

Сәлимәнең эчке тавышы:

«Тулган күңел – китек күңел. Килмәсә Мостаңгирың?»

– Килмәсә – яман булыр... Күңелем һаман тулган булыр...

Сәлимә тагын урынына барып утырды. Ул инде Мостаңгирның килүенә ышанмый иде. Сәлимәне йокымсырау томаны басты. Сәлимә төш күрә иде. Әллә каян гына Хамис килеп чыкты.

Хамис ни өчендер артык кычкыра иде:

– Сәлимә, харап итмә мине дә, үзеңне дә... Ни булды соң сиңа? Ни булды соң миңа?

Сәлимә дә ни өчендер каты тавыш белән сөйләшә.

– Безгә аерылышырга кирәк, Хамис! – дип кычкыра.

– Аңламыйм мин сине, Сәлимәкәй, аңламыйм, – диде Хамис, аны иңбашларыннан каты тотып. – Кире кайт, кире кайт!

Сәлимә ачыргаланып кычкыра:

– Кайтмыйм, кайтмыйм...

– Мин сине бәйләп алып кайтачакмын! – диде Хамис.

– Кит, Хамис, кит, җибәр мине.

Хамис юк булды, томан эченнән Идрис килеп чыкты. Ни өчендер Идрис Сәлимәгә туры карамыйча гына, гаепле кеше сыман сөйли иде.

– Гафу ит, Сәлимә, мин синең ирең була алмыйм! Мин сиңа өйләнә алмыйм.

Сәлимә Идрисне кызганды шикелле, ул аны юаткан сыман әйтте.

– Нигә гаепле кеше сыман син йөзеңне миннән яшерәсең, Идрис? Минем алда синең гаебең юк бит, Идрис... Мин сине өйлән, дип кыстамыйм да... Нигә туры карамыйсың, Идрис?

Идрис ике учы белән битен каплады.

– Син бит, Сәлимә, миннән дүрт яшькә олы... Әниләр риза булмас...

Сәлимә, үгетче апа сыман, егеткә эндәште:

– Идрис, син бит мине яратасың. Юк, син миңа яратам дип әйтмәдең. Хатын-кыз үзен яраткан кешенең карашын укый белә ул... Мин бит сиңа бик тә ошыйм, олырак булсам да ошыйм бит мин сиңа... Мине дусларың белән таныштырганда, синең күзеңдә һәрвакыт горурлык, мактану чаткылары күренә торган иде... Синең карашың: күрәсезме, Идрис абзагыз нинди кызлар белән генә йөри, ди иде бит... Син мине сөясең бит...

Идрис аянычтан, ачынудан җанын кая куярга белми иде:

– Сөям, Сәлимә! – дип кычкырды ул. – Син күңелемнең буш урынын тутырдың. Ләкин мин сиңа өйләнә алмыйм...

– Ихтыярың, Идрис... – диде Сәлимә. – Мин сиңа тагылмыйм. Син начар кеше түгел... Мин сиңа тугры хатын була алыр идем. Үзеңне яраткан кешенең тормышын бизәү үзе бәхет булыр иде. Син мәхәббәтеңнән качасың... Кире кайтырсың, ләкин соң булыр.

Идрис Сәлимәдән ояла иде булса кирәк; ул ханымга яны белән торган килеш:

– Сәлимә... – диде. – Сине бит миңа кадәр кемнәрдер сөйгән, кемнәрдер үпкән, ләззәтләнгән, син дә алардан ләззәт кичкәнсең... Хуш! Беләм, тегеләй дә, болай да миңа газап.

Идрис юкка чыкты. Аның урынында тагын бер шәүлә пәйда булды.

– Кем син? – диде ханым.

Шәүлә әйтте:

– Бу мин, Сергей, – диде.

– Ә-ә, Серёжа, синмени? – диде ул, томан эчендәге шәүлә ачыклана төшкәч. – Нигә килдең? Мин сиңа әйттем, кабат күрешмәбез, дидем.

– Өйләнгәнемне әйтергә килдем, – диде шәүлә.

– Ишеттем.

– Матур яшибез болай.

– Теге чакта: синнән башка яши алмыйм, язылышыйк, дип ялварган идең.

– Хәтта еладым да... Ләкин боларның берсе дә ялган түгел иде.

– Ышанам, Серёжа. Син эчкерсез кеше, син хатын-кызның кадерен беләсең...

– Соң, нигә миңа чыкмадың?

– Бераз гына күңелем тартса да, мин синеке идем. Ләкин мин башка өчен, син башка өчен яралтылган.

– Соң бит, ни... әйтсәң дә, без бит...

– Ятак мөнәсәбәтләребез безне бәйли алмый, бары тик аера гына, Серёжа.

– Соң бит, Сәлимә...

– Йә Аллам, син дә бичара кеше икәнсең, Сергей. Синең белән минем өчен ни әһәмияте бар аның? Үткән ялгышларга салават.

– Ни өчен соң?

– Белмим! Белмим!

Сергей юкка чыкты. Суыткыч гүли. Гүелдәү дөньяны тутыра. Галәмне гарасат тавышы каплый. Таулар ишелә. Йортлар, манаралар упкынга җимерелеп төшә. Җир шары урталай ярыла. Котылгысыз, дәһшәтле Кыямәт башлана. Сәлимә шушы дәһшәт арасында берүзе.

– Кая соң кешеләр? Кешеләр кайда-а? – дип илерә. – Нишләп мин ялгызым гына? Ичмасам, Идрис, Сергей да юк... Идри-ис... Серёжа-а...

Тузан, төтен, томан давылында талгын гына булып чырайлар, йөзләр күренеп-күренеп китә. Кайсылары айгылдый-айгылдый көлә. Кемнәрдер үкереп елый. Кемдер Сәлимәгә бармагы белән төртә дә оятсыз сүзләр кычкыра:

– Син әхлаксыз хатын, бер төнең ничә доллар тора-а? Ха-ха-ха... Син бозык хатын! – дип үкерә.

Сәлимә, җанын кая куярга белми, ары ыргыла, бире ыргыла.

– Син минем ирем Хамис бит... Хамис, син нигә мине мыскыллыйсың? Ха-ами-ис... Хамис та китте... Берәү дә мине килеп коткармасмы икәнни? Упкынга очам... Коткарыгы-ыз... Аста җәһәннәм, коточкыч тәмуг... Төш бит бу... Төш кенә бит бу... Уяныргa кирәк, уяныргa... Мин ялгыш ятканмын, шуңа күрә бастырылам, саташам гына мин... Уяныргa кирәк, берәрсе төртеп уятсын иде. Мин уянам, кычкырам, кычкырам да үз тавышыма уяна-ам... А-а-а... Кем бар анда-а? Кем ба-ар?

Мостаңгир керде. Сәлимә Мостаңгирны да төшемдә күрәм, дип уйлый иде.

– Мостаңгир! Син мине алдамадыңмыни? Нигә болай озак көттердең соң? – дип сөеклесен сораулар белән күмеп ташлады.

Мостаңгир ханымны кочты, күкрәгенә кысты да:

– Сәлимә, саташасың, – диде. – Саташасың, Сәлимә.

Мостаңгир Сәлимәне селкетергә тотынды. Сәлимә күзен уды. Ул Мостаңгирны шытырдатып кочаклады, аннан үкси башлады. Куркыныч төшнең бетүенә сөенеп елыймы, көткән кешесенең килүенә куаныпмы, Сәлимә үзе дә белми. Ул Мостаңгирны шытырдатып кыскан да сулкылдап елый, Мостаңгир аны иркәләп юата:

– Булды... булды... мин монда бит... Тынычлан, Сәлимә... Менә шулай...

Эфирда музыка. Сәлимә тынычлана төште, төзәтенде, чәй әзерли башлады. Сөйләшмичә генә чәй эчәләр.

– Син мине гафу ит, Сәлимә, килә алмадым... Эштәге хәлләр... Бүген дә көнозын шуның белән йөрдем.

Сәлимә Мостаңгирны тагын кочаклады. Бу – аларның бәхетле мизгелләре иде.

Мөнәсәбәтләр ачыкланды, бергә тора башладылар.

Аларның мөнәсәбәте чыннан да ихлас иде. Икесе дә эчкерсез, икесе дә кешелекле...

Шулай көннәр уза торды.

***

Мостаңгир кайтып керде. Өйдә хәрәкәт күренмәде.

– Күкү... – дип күкелдәде Мостаңгир. – Бу нинди игътибарсызлык? Берәү дә мине каршы алмый.

Мостаңгир хатынын эзли башлады. Күзе өстәлдәге язуга төште. «Мостаңгир, чәй куя тор, мин кибеткә киттем, хәзер кайтам. Сәлимәң!..» диелгән иде анда.

Мостаңгир чәйнеккә су алып, утка куйды. Ут аның уйларын кузгатты:

«Мәхәббәтемне болай табармын, дип уйламаган идем. Әкияттәге кебек, мин суга бата башлаган бер чибәр кызны коткарам, аннан соң ул кыз миңа гашыйк була. Яки караңгы почмакта юлбасарлар тырнагыннан бер кызны коткарам, ул кыз зур гына кешенең кызы булып чыга, ул кыз миңа гашыйк була. Мин дә аны яратам, тормыш ал да гөл бара... Бу әллә ничек булды шунда».

Ишектән Сәлимә керде дә кычкырды:

– Мостаңгир, азык-төлекне кабул итеп ал!

Мостаңгир, йөгереп килеп, Сәлимә кулындагы әйберләрне алды.

– Менә мин яраткан сыр! – диде ул, товарларны карый-карый. – Рәхмәт!

Сәлимә, өс киемнәрен сала-сала:

– Карының ачкандыр инде синең, балакай, – диде.

Мостаңгир ашамлыкларны аш бүлмәсенә алып китте:

– Тук дип ялганламас идем, – диде ул. – Син пешергән аштан соң завод ашханәсендәге ризыкны кабасы да килми.

– Көнозын ач йөрдеңме? – диде ханым.

– Тук йөрдем дип ялганламас идем.

– Җүләр баш! Түзәр хәлең калмаса, чәй эчеп алыйк булмаса.

– Сәлимә! – диде Мостаңгир, серле итеп.

– Әү! – диде Сәлимә.

– Мин фатир алдым бит бүген, – диде Мостаңгир.

– Нинди фатир? – диде Сәлимә.

– Законный фатир, яңа йорттан, бер бүлмә.

– Котлыйм. Кайчан күченергә уйлыйсың?

– Нигә мин генә? Кайчан күченәбез, диген.

– Сүзеңне уйлап сөйлә, Мостаңгир, соңыннан үкенерлек булмасын.

– Үткәннәргә үкенгән кеше – арты белән күлгә чумган үрдәк. Бу якшәмбе машинага заказ бирдем. Башта моннан ташыйбыз, аннан теге түтәйләргә барып, Мостаңгир карт буйдакның алам-саламын алабыз.

– Нигә алай? Ике бүлмәле фатир ташлап, кайсы тинтәге бер бүлмәгә күченә инде? Балта биреп шөшле алдым, алдаладым татарны!

– Заводка якын бит.

– Әйтерсең лә моннан ерак.

– Шулай да тегендә уңайрак бит, Сәлимә.

– Шулайдыр инде, анда завод, шау-шу, һава сөрем белән тулган. Монда уңайсыз бит, Идел дә борын төбендә, яшеллек тә күп, һавасы да чиста, урыны да тыныч...

– Татар гадәте... Борынгыдан ук ир кеше хатын йортына төшмәгән.

Сәлимә көләргә тотынды.

– Их, син, Мостаңгир-хан! Алайса, йортка керәсең килмәгәнгә генә шул тар бүлмәгә күчәргә уйладыңмы? Ата-бабаларның ул гадәтләрен мин кагыйдә итә алмыйм.

– Ярый, мин ордерны фатирга мохтаҗ кешегә бирермен. Сөенерләр.

– Без вакытлыча гына торырга җыенмыйбыздыр бит?

– Ә?

– Мин әйтәм, без вакытлыча гына өйләнешергә уйламыйбыздыр бит, дим.

– Безнең авылда Зиннәт бабай «духалегә» генә дип өйләнгән, диләр. «Духале»се «вакытлыча» дигән сүздер инде. Менә шул Духале Зиннәт бабай сиксән яшенә чаклы гомер кичергән духалегә генә алган карчыгы белән. Әллә ничә угыл, әллә ничә кыз үстергәннәр. Икенче карт Сәфәр абзый әллә унбиш хатынга җитте. Һәр өйләнгән саен, гомерлеккә дип ант итә, мескен. Ике атнадан соң тагын аерылышалар.

Мостаңгир телефон тәгәрмәчен әйләндерә башлады. Ике-өч гудоктан соң, теге башта телефон трүбкәсен алдылар.

– Рәсүл! – диде Мостаңгир.

– Мин! – дигән аваз ишетелде трүбкәдә.

– Бу мин әле, – диде Мостаңгир.

– Ишетәм, Мостаңгир.

– Карале, миңа дигән ордерны Сибай абзыйга яз!

– Кайсы Сибай ул?

– Бәрәкалла, Гайнуллин Сибайны белмәскә син. Сигезенче цехта.

– Ә-ә, аңладым. Нигә алай кинәт борылыш?

– Шулай, минем ордерны Сибай абзыйга язып бир.

– Кичәгенәк, фатир кирәк, дип кыдырып йөргән идең.

– Кичә кирәк ие, бүген кирәк түгел. Берүк корреспондентлар чакырып китерә күрмә тагы! Берәү акча янчыгы тапкан да иясенә кайтарган. Берәү үз теләге белән ордерын икенче кешегә яздырган. Фатир кирәк булса, алган булыр идем. Сибай абзыйга карап тормас идем. Кыскасы, ордерны төзәт! Приказ!

– Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр, алайса. Каян алдың фатир, әллә йортка кердеңме?

Трүбкәдә кычкырып көлгән тавыш ишетелде. Мостаңгир телефон трүбкәсен ташлады.

– Ыржайган, тиле! – диде ул, телефонга ымлап.

Сәлимә Мостаңгирны арка ягыннан килеп кочаклады.

Сәлимәнең эчке тавышы әйтә:

«Каян белмәк кирәк, менә без бик якын... Ничә ел узар, унмы, егермеме, әллә бер ел да тормабызмы? Әгәр дә дистәләрчә ел буена яратып-яратып та тормыш үзенең рәхимсез шартларын куйса, мәхәббәтебез чәлпәрәмә килсә?»

Ә Мостаңгирның эчке тавышы сөйли:

«Ул минем хатыным, иң-иң якын кешем. Вакытлар үтү белән үкенмәмме соң мин? Ничек булыр икән биш-алты елдан соң? Аеры-чөере, бер-беребезне яратмый торган кешеләр булмабызмы? Гүзәл гаилә кора алырбызмы? Әллә бик күп гаиләләр шикелле этле-мәчеле торырбызмы? Хисләр тузса? Болай уйласаң, гомергә дә өйләнә алмассың. Тефү-тефү, мин аны яратам, калганы турында бүгеннән баш ватасы юк!»

Мостаңгир, хатынының кочагыннан чыгып, шампан шәрабын ачты. Сәлимә иренең шешәне ничек итеп оста ачуына сокланып карап тора иде.

– Кайчан өйрәндең син шампанское ачарга? – диде хуҗабикә. – Атмады да, түгелмәде дә.

Мостаңгирның кәефе яхшы иде. Ул әйтте:

– Каты кыссаң, тавыш йә каты чыга, йә гел чыкмый, – диде. – Мин артык кысып газын чыгардым.

Чәркәләр тулы шампан шәрабы. Бөрчекләре чемердәп өскә калка. Чәркәләр зыңгылдап чәкәште. Илаһи төн аларны үзенең ләззәтле кармавычлары белән чорнап алды.

***

Көннәрдән бер көнне Сәлимә ятарга әзерләнә иде. Ишек кыңгыравы чылтырады.

– Хәзер, хәзер... – дип кычкырды Сәлимә.

Ишектә бер ир кеше күренде.

– Саумы, Сәлимә! – дип исәнләште әлеге кеше.

Сәлимә бу кешене күреп бер дә шатланмады.

– Ә-ә, синмени әле бу? – диде, канәгатьсез генә.

Ир кеше өй эчен карашы белән тикшереп чыкты да әйтте:

– У-у, син йокларга яткан идеңмени? – диде. – Керергә рөхсәттер бит? Комачауламаганмындыр бит?

Сәлимә сорауны җавапсыз калдырды. Ир кеше түргәрәк узды.

– Менә сиңа бүләк, – диде төнге кунак. – Каклаган каз.

– Каян килеп? – диде Сәлимә.

Ир кеше әрсез рәвештә фатир буйлап йөренә башлады.

– Журналистның хезмәте шулай инде аның... Сезнең авылда командировкада булдым... Нәфисә апага фатирга керттеләр... Әнә, Нәфисә апа сиңа каклаган каз җибәрде...

– Рәхмәт, – диде хуҗабикә, кырыс кына.

Сәлимә казны бер кырга этеп куйды. Ир кеше рөхсәтсез-нисез чишенә башлады.

– Син Нәфисә апаңа бик тә охшагансың икән... – диде журналист һәм, кемнедер эзләгәндәй, бүлмәне тикшереп чыкты, шикләнерлек нәрсә тапмагач, креслога утырды. – Йә, нихәлдә яшисең, Сәлимә? Сине күптәннән күргән юк. Вакыт булмады. Командировкалар... Син гел баштан чыкмыйсың. Кәефең юк мәллә, әллә берәрсен көтәсеңме?

Сәлимәнең чыдамы төкәнгән иде инде:

– Миша! – диде ул катгыян. – Мин кияүгә чыктым.

Ир кешегә бу көтелмәгән яңалык иде булса кирәк, ул каш уйнатып әйтә куйды:

– Чынлапмы? – диде.

– Чынлап, күптән инде, – диде Сәлимә.

– Менә сиңа! – диде Миша. – Ә мин ашыга-ашыга киләм тагын... Ирең...

– Мәскәүдә.

– Командировкадамыни?

– Ие.

– Алай икән...

Сәлимә һаман ишек катыннан китми. Тегенең чыгып киткәнен көтә.

– Тәбриклим, бәхетле булыгыз.

Сәлимә җавапсыз.

– Нигә бик иртә яттың? Телевизорда КВН бара...

Миша, хуҗа кебек, телевизорны кабызды.

– Михаил! Мин КВНнар белән кызыксынмыйм.

Михаил нәрсә эшләргә белми аптырап калды, ләкин ул китәргә ашыкмый иде.

– Хәтереңдәме, шушындый бер кичтә без синең белән икәүдән-икәү генә, чәй эчә-эчә, телевизор карап утырган идек?

– Үткән эшкә салават!

– Оһо, шулай укмыни? Ярый, мин бит туганыңның әманәтен тапшырырга гына дип кергән кеше... Алай кугач, чыгам, чыгам... Китмә, китмә, сандугач, син китәсең мин калам...

Төнге кунак ашыкмый гына киенә башлады. Җаен туры китереп, ул Сәлимәнең кулын тотты, кочакламакчы булды. Сәлимә кискен рәвештә аннан читкә тартылды.

– Шундый суыкта дустыңны урамга куасыңмы? Миһербанлы бәндәләр бу буранда этен дә куып чыгармый.

– Син, Михай, үзең акыллы гына кеше, шулай да син примитив. Күңелең белән башка бозык ирләрдән әлләни ерак китә алмагансың икән. Бәя күтәрергә тырышмаганымны күреп торасың. Һаман мескенләнәсең, этләшәсең, ә бәлки: кал Михаил, ирем бүген кайтмый әле, дип әйтүемне көтәсеңдер?!

Михаил, беренче күргәндәй, Сәлимәгә җитди карады һәм аңлады.

– Ярый, алайса, бигайбә, Сәлимә! – дип чыгып китте.

Аның артыннан ишекне ябып, Сәлимә бүлмәгә узды. Утны сүндерде. Ләкин озак та узмый ишектә тагын кыңгырау чылтырады. Сәлимә ишек янына килде.

– Кем бар анда? – диде Сәлимә.

– Бу мин, Сәлимә! – дигән тавыш ишетелде.

– Мостаңгир?

Сәлимә, чылбырларын чылтыратып, ишекне ачты. Ишектә шактый туңган Мостаңгир күренде.

– Нигә бик гаҗәпсендең? – диде мөсафир. – Көтмәгән идеңмени?

– Син сишәмбе көнне кайтырга тиеш идең бит, – диде Сәлимә.

– Күрәм, хатыным мин кайтканга сөенми.

– Җүләр! Чишен! Хәзер чәй куям.

Мостаңгир бүлмәне караштырып чыкты, Сәлимә җәһәт кенә кухняга кереп китте. Мостаңгир урындыктагы казны күреп, кулына алды.

Аш бүлмәсеннән Сәлимә тавышы яңгырады:

– Юлларың уңдымы соң?

– Уңды... уңганнары, уңмаганнары уңмады...

– Мин сораганны таптыңмы соң?

– Таптым!

Мостаңгир һаман каз белән мәшгуль иде.

– Син яңа гына кайттыңмыни? – диде Мостаңгир.

– Юк, көне буе өйдә утырдым. Нигә алай дисең?

– Бу нәрсә соң? – Аш бүлмәсеннән Сәлимә чыкты. – Әле яңа гына урамнан кергәндәй шакыраеп каткан.

– Ә-ә, каклаган каз. Авылдан апа җибәргән. Күчтәнәч. Әле генә кертеп чыктылар.

Мостаңгир казны урынына куйды. Ашыкмыйча гына тәмәке кабызды. Сәлимә казны кунага салып турый башлады.

– Мм, таман тозланган! – диде ханым. – Авыз ит, Мостаңгир?

– Ашыйсым килми.

– Син каклаган каз ярата идең бит. Мактый-мактый ашый идең.

Мостаңгир дәшмичә генә диванга сузылып ятты. Сәлимә дә эшне аңлый, ни әйтергә белми аптырап утырды. Соңыннан ул да ятты. Киеренке тынлык урнашты.

Мостаңгирның уйлары шактый киеренке иде.

«Теге ир безнең ишектән чыктымы, әллә башка кешеләрдәнме? Йөзе таныш кебек күренде. Сәлимә белән кинодан кайтканда очрап, исәнләшкән кеше түгелме соң ул? Теге исәнләшкәч, Сәлимә күрмәмешкә сабышкан кебек тоелды. Бу йортта торамы икәнни ул? Тагын бу каклаган казы... Менә сиңа бәхетле тыныч тормыш... Вак җанлы бәндә кебек ышанмаска, шикләнергә, сөйгәнеңнең артыннан шымчыдай күзәтергә, сагаларга өйрәтә микәнни соң ул ярату?»

Сәлимәнең дә зиһенендә уйлар кайнаша иде.

«Кәефсез кайтты... Башка чакта бер-ике көн күрешми торсак, еллар буе күрешмәгән кебек атылып, шатланып кайтып керә иде. Бүген ни булган? Әллә юри иртә кайттымы ул командировкадан? Мине башкалар белән тоту өчен? Көнләшүме бу? Димәк, ул миңа ышанмый. Ул гомерлеккә үзен хәсрәткә салачак. Ул хәсрәттә булса, миңа ни ямь? Көчле мәхәббәт иллюзия генәме икән соң ул?»

Мостаңгир йоклаганга сабышып ятса да, аның күзенә йокы эленми иде.

«Ичмасам, бер сүз әйтсен иде... Ятты да йоклады. Иркәләсен иде, юатсын иде, аклансын иде».

Сәлимә борсалана.

«Куйган чәемне дә эчмәде, ичмасам, болайга борылып ятсын иде. Ятты да йоклады...»

Мостаңгир:

«Шайтан белсен, нигә шулкадәр, йөрәгем авыртканчы ярата торганмындыр мин аны... Башка хатын-кызлардан аерылып торган җире дә юк... Яраттыра белә...»

Сәлимә тәвәккәлләргә булды:

«Ни булса да булыр, борылам да шытырдатып кочаклыйм».

Алар ярсып кочаклаштылар: ул үз теләгәнен башкарды.

– Кичер, Сәлимә, – диде Мостаңгир.

– Җүләркәем, – диде Сәлимә.

Бу йортка бу төндә мәхәббәт фәрештәсе иңде.

***

Бүлмәдә тәртипсезлек хуҗа. Мостаңгир күнегүләр ясап азаплана. Сәлимә кер үтүкли.

– Мостаңгир! – дип кычкырды Сәлимә.

– Кем тия? – дип сорады Мостаңгир.

– Ике куян койрыгын берьюлы тоткан кешене күргәнең бармы?

– Тотарга маташканнарын күргәнем бар.

– Күрмәсәң, күр. Әнә, шкаф астында идән ялтыраткыч, ике аягыңа икене ки. Менә сиңа рух күтәрер өчен музыка.

Сәлимә радионы ачты.

– Идәнне шомартасың – бер куян койрыгы. Физзарядка ясыйсың – икенче куян койрыгы.

– Гүзәл хатыннар акылга таман була, дип кайсы ахмагы әйткәндер. Каян килә ул сиңа хәйләкәрлек, дипломатия?

– Гади логика, үзең әйткәндәй, мантыйк фәне. Тимераякта шуганыңны күрәсем килде.

Дәртле музыка бүлмәне тутырды. Мостаңгир идән шомартырга тотынды.

Мостаңгир һаман уйлый.

«Шайтан алгыры, гашыйк булдым үз башыма, ахрысы...»

Сәлимә дә уйлый.

«Мин аны барыбер яратам!»

– Син гел бер урынны гына ялтыратасың түгелме соң? Бар әле, әнә тегендә аяк тимәгән җире калган.

– Чәйнегең чылтырый, – диде Мостаңгир.

– Ишетәм, – диде Сәлимә.

Сәлимә аш бүлмәсенә йөгерде.

– Сәлимәү!

– Әү.

– Ташла эшеңне! Бу приказ! Эшеңне ташла!

– Ни булды?

– Кемгәдер бүген егерме җиде тулган түгелме соң?

– Ай, Аллам, менә җүләр... Берәүләр утызга якынлаша, икенчеләр шуңа шатланып йөри.

Мостаңгир качырган урыныннан шәраб, тагын ниндидер уенчык чыгарды.

– Шешәсе миңа! Менә монысы утызга якынлашып килүчегә.

– Егерме җидесе тулган көнне ире яраткан хатынына кәҗә бүләк иткән.

Уенчык кәҗәнең башын селкетеп җибәрде дә Сәлимә балаларча сикереп куйды.

– Рәхмәт, Мостаңгир.

– Безнең сакал бигрәк тату Гали белән, менә кәҗә карап тора тәрәзәдән. Сакал аны печән белән кунак итә. Кәҗә аңа рәхмәт укый, Галиен селкетә.

– Хулиган!

– Тукай шигырьләрен яттан белгән кеше хулиган була алмый. Илле яшьлегеңә мин сиңа чын дөя бүләк итәм әле.

Сәлимә Мостаңгирны юри куа башлады, алар байтак вакыт шаярдылар.

Мостаңгир:

– Үтерәләр! – дип кычкыра.

Куышып аргач, алар табын янына утырдылар.

Мостаңгир шәраб алды сүзе әйтте:

– Илллене дә узып яшәсәк иде! Ура!

Сәлимә җитдиләнде. Ул:

– Амин берүк, Мостаңгир, – диде. – Чыннан да, иллегә чаклы синең белән тигез гомер кичерсәк иде... Әгәр дә без иллегә чаклы бергә яшибез икән, безнең арада төзәтә алмаслык хаталар булмый, дигән сүз.

Мостаңгир шәрабны татып бакты да әйтте:

– Шәрабы ла шәрабы. Тик кабарга гына әйбер юк.

Сәлимә, үпкәләгән бала сымак, иренен турсайтты:

– Мостаңгир, мыскыл итмә инде. Якшәмбе көнне дә җикмә мине. Кибетләргә чыгарга өлгермәдем... Борыч тел.

– Кем борыч телледер бит әле, – диде Мостаңгир.

– Сыр бар суыткычта, – дип кычкырды Сәлимә.

Мостаңгир суыткычны ачты:

– Сыр булганда, кеше ярлы буламыни? Һо, монда сыр бик аз калган... – диде.

– Авылдан килгән каз бар анда. Каклаган каз менә дигән закуска.

Мостаңгир казны алды.

«Каклаган каз... Дуңгыздан да яманрак күренә торган каз. Казкай, казкай, син гөнаһсыз ризык. Тик гаҗәп татлы аш ашаганда, кашыкка төшкән кыргаяк сыман син. Кем алып килде монда сине төн уртасында? Мин өйдә юкта. Менә бит күпме сораулар, казкай!»

Ул казны тиз генә эчкә тыгып куйды. Аның кәефе кырылган иде. Ул уйланып торды да шәраб салып эчте.

«Юк, мин үземне үзем тилертәм, ахрысы. Бу хатынга ышанмыйлармы соң? Мин тинтәк, көнче, аны да утка салам, үземне дә».

Сәлимә Мостаңгирны кочып алды да:

– Син мине сөясеңме? – диде.

Мостаңгир хатынының кулын кискен алып ташлады да әйтте:

– Синең бу соравыңа җавап бирмәсәң дә буламы? – диде.

Сәлимә аптырап калды, ул үпкәләде бугай:

– Була, нигә булмасын? – диде. – Гафу ит, бу бик ахмак сорау булды бугай шул.

– Кайсы вакытта сорыйсың бит!

Мостаңгир бер-бер артлы ике фужер шәраб эчеп куйды. Киеренке тынлык урнашты.

«Сөямме соң мин Сәлимәне? Кызык... Нәрсә соң ул сөю? Ярату, яратмау ни? Билгеле, мин Сәлимәгә нәфрәтле түгел. Димәк, формаль яктан мин Сәлимәне яратам...

Аннан соң ишетелерлек итеп:

– Мин сине яратам, Сәлимә! – диде.

– Ни өчен?

– Ни өчен? Ник, нигә яратасың? Мин бу сорауны яратмыйм.

– Ни өчен?

– Ни өчен соравы үз эченә ришвәт, сәүдә мәгънәсен алган. Әгәр кеше «ни өчен сөясең?» дигән сорауга җавап бирә ала икән, ул сәүдәгәр, ул ришвәтче – взяточник.

– Кызык, кызык...

– Ни өчен сөясең? Җавап: «матурлыгы өчен, батырлыгы өчен, куәте өчен, даны өчен, машинасы булган өчен, дачасы, акчасы күп булганы өчен»гә кадәр барып җитәргә була.

– Ерунда, Мостаңгир.

– Ә үзең курка калдың: бу ни сөйли, бу бит хаклы, дип уйлыйсың.

– Ни сөйлисең син, чепуха бу, тузга язмаган сүз. Сафсата!

– Ихтимал, Сәлимә, ихтимал. Алайса, җавап бир: матур булмаган кешенең сөелергә хакы юкмыни?.. Даны булмаган кешенең яратылырга хокукы юкмы?.. Ярлы кешенең, фәкыйрь адәмнең сөяргә, сөелергә хакы юкмы? Берәү батыр да, матур да, бай да түгел, ә форсат аны батыр итә, дөнья шаулый аның турында. Элек аңа игътибар итмәгән кызлар хәзер аның артыннан өерелеп йөри башлый. Чөнки дан һәрвакыт акча белән янәшә йөрүчән була.

– Бу бит чын мәхәббәт түгел, бу дан-шөһрәт ярату гына. Бозык кешеләрнең яки тәҗрибәсез кызларның ялгышуы гына.

– Алайса, син чын мәхәббәт белән сәүдә, коммерция мәхәббәте арасындагы сызыкны күрсәтеп бир!.. (Ул үзен-үзе кыздыра бара иде.) Һәйне ни өчен Матильдасын яратты икән? Матурлыгы өченме?.. Ярый, матурлыгы өчендер,

ә ул бозык кыздан башка матур кызлар беткәнме? Бөек шагыйрь үзенә тиң берәр башка затлы хатын таба алмаган булыр идеме? Үзен газапка салып, шагыйрь фахишә кызны сөя. Әллә аңа җиңел булгандырмы? Ир кешенең иң авырткан җире бар, ул да булса аның хатыны, аның сөйгәне. Әгәр дә бармак төртеп: әнә ул фахишәне сөя, дип мыскылласалар, ир кешегә аннан да зур хурлык юк. Димәк, эш матурлыкта гына түгел... Эш – Матильданың урам кызы булуында, Сәлимә.

– Тиле!

– Тиледер. Әмма Һәйне аны шул формада, шул эчтәлектә, шул килеш, шундый заманда яраткан. Ни өчен яраттың, дип сорасаң, Һәйне үзе җавап бирә алмаган булыр иде. Ләкин монда мең төрле сәбәп бар, социаль шартлар, мохит... мәхәббәтнең аңлатып булмый торган миллион төрле сәбәпләре бар. Бәлки, Матильда шул гәүдәсе, шул матурлыгы, шул беркатлылыгы белән бер бай кызы булса, Һәйне аңа игътибар итмәгән дә булыр иде.

– Мостаңгир, синең башың әллә нинди мәгънәсез чүп белән тулган... Моның белән син ни әйтмәкче буласың? Моның безгә ни катнашы бар? Сәер кеше син, җаным.

– Мин шул ук кеше, Сәлимә. Тик мин бүген күп сөйлим. Шул гына. Без, Сәлимә, стандарт уй-фикерләр белән яшәргә күнеккәнбез. Иске гадәтләр белән, иске кануннар белән... Ата-бабада булмаган инде ул хатын йортына ир төшү. Шуның аркасында күпме нервы, күпме күңелсезлек. Стандарттан чыксаң, сине фаҗига көтә, сүз, гайбәт көтә. Беләсеңме, минем турыда ни сөйлиләр? Мостаңгир бер карт хатынга йортка кергән, шул да булдымы ир кеше эше? Ата-бабасы булган кешеләр иде. Бу җебегән авыз булып чыкты, диләр... Яхшылык, матурлык өчен теләсә кем ярата аны, менә син гарип, фәкыйрь кешене яратып кара, аңа гашыйк булып кара. Әдәбият та, сәнгать тә рыцарьларга гына гашыйк булырга өйрәтә.

Урам яктан тынлы оркестр уйнаганы ишетелде. Бу – матәм маршы иде. Икесе дә тәрәзә янына килеп бастылар.

– Кемнедер җирләргә алып баралар. – диде Мостаңгир. – Берәүләр ял итә, берәүләр кабергә бара. Яшь кыз, ахрысы.

– Баш очында иреме, егетеме...

– Яратышканнардыр. Мәхәббәт булгандыр. Хәзер юк ул мәхәббәт.

– Нигә булмасын? Аны ире һаман ярата торгандыр.

– Аны түгел, Сәлимә. Табутта ятучыны түгел. Мәеткә карата мәхәббәт була алмый. Некрофиллар гына мәеткә гашыйк.

– Анысы ни-нәрсә тагын?

– Шундый ирләр була, алар хатын-кызлар мәетенә кызыгалар.

– Фу!

– Аның җанын ярата иде ул. Ә җан ярату ул – абстракция. Символ, абсурд. Хәтер. Томанлы хыял. Һич шигем юк, алар чын мәхәббәт белән бәйләнгән булгандыр. Ләкин кайда соң ул мәхәббәт? Кыз үлде. Ул инде кеше түгел, ул – мәет. Кайчандыр егет сөйгән кызның калыбы гына. Димәк ки, егет кызның тәненә караганда рухын күбрәк яраткан. Үтәр берничә ел, вакыйгалар егет аңыннан бу кыз сурәтен юып бетерер. Егет көнкүреш мәшәкатьләренә кереп батар. Икенче мәхәббәт монысын кысырыклап чыгарыр. Чөнки абстракт мәхәббәткә караганда, реаль мәхәббәт куәтлерәк.

– Җитте, Мостаңгир.

– Килешмисеңмени, Сәлимә?

– Белмим. Сине тыңлавы имәнгеч.

– Нишләмәк кирәк, бер очракта кешеләр, чынбарлыктан качып, иллюзияләр белән яшәүне хуплый. Икенчеләре кырыс чынбарлыкның кара ягын гына күрә алалар.

– Синең кәефең юк бүген, Мостаңгир. Ни сәбәптер, бүген син усал.

– Сәбәп бар, Сәлимә.

– Нәрсә сәбәп?

– Каклаган каз!

– Нинди каз? – диде Сәлимә, көлә-көлә.

– Мин шаярмыйм, Сәлимә! Менә бу каһәр суккан казны китерүче миңа каршы очрады баскычта. Аның исеме – Михаил! Ул синең күптәнге танышың. Кичер мине, Сәлимәкәй, сөям сине, үлеп яратам, ләкин бу сөюнең ләззәтенә караганда михнәте күбрәк... Шикләнәм, үрсәләнәм.

– Мостаңгир, ни сөйлисең син?.. Зинһар, кабат бер сүз дә әйтмә.

Мостаңгир:

«Сиңа җиңел... Син миннән шикләнмисең... Сиңа җиңел... Син – хатын... Син төгәл беләсең... булдымы хыянәт, юкмы?»

Һәм ул кычкырып әйтте:

– Ә мин белмим, белмим, сөйдем сине, ә кайда соң бәхет? Кайда соң ул тыныч гаилә тормышы, бер-береңне аңлап яшәү? Булдымы хыянәт, юкмы?

Сәлимә ике учы белән битен каплады. Мостаңгир шешә авызыннан шәраб эчә иде.

Сәлимәнең уйлары:

«Бу хәлләрдән соң Мостаңгир бөтенләй үзгәрде. Үткен сүзле, сау-сәламәт кеше боекланды, аның каш арасында җыерчыклар хасил булды. Мостаңгирны көнләшү, икеләнү, ышанмау корты эчтән әкрен генә кимерә башлады. Ул эштә дә сүлпәнләнде. Янып-көеп, завод өчен үләрдәй булып йөри торган Мостаңгир ваемсыз, битараф бер кешегә әверелде. Инде ул хәзер атлыгып өйгә кайтмый. Кайда булса да тоткарлану өчен, сыныкка сылтау табарга тырыша. Ә сыныкка сылтау һәр сәгать, һәр очрак, һәр почмак саен табыла да тора. Бу үзгәреш, бу киеренке хәлләр мине дә йончытты. Нишлим соң? Гафу үтенимме? Ни өчен? Минем гаебем нидә?.. Үтәр әле, тора-бара бар да җайланыр, дидем».

Чыннан да, аларның арасы көйсезләнде, җайсызланды.

***

Мостаңгир кайтты. Аны хатыны Сәлимә:

– Бик соң, кайда булдың? – дип каршы алды.

Бу сорау Мостаңгирның болай да киеренке сеңерләренә китереп сукты.

– Синең ни эшең? – диде ул, тупас рәвештә.

Сәлимә сүзсез генә ирен чишендерде.

– Нигә җавап бирмисең? – диде исерек ир. – Инде минем белән сөйләшергә дә җирәнәсеңмени? Кайда булдың, имеш, синең какое дело до этого? Актык акчамны эчәммени? Синең киемнәреңне сатып эчәммени?.. Нигә эндәшмисең? Нигә син ирең белән сөйләшмисең?

Сәлимә авыр көрсенде дә кайнар тыны белән:

– Үзгәрдең син, Мостаңгир, – диде.

Сәлимәнең тавышында аяныч та, ирен кызгану да, ачыну да, хәтта кимсенү-үкенү дә бар иде. Мостаңгир кинәт айнып киткәндәй булды. Аның куллары сәлперәеп төште. Әле генә ажгырып торган ир, кыйнап ташланган, йончылган кеше сыман, бөкшәеп калды. Сәлимә читкә китеп үкси башлады. Бу елау

куркудан түгел, гарьлектән дә түгел. Ни өчен елаганын ул үзе дә белми. Бу елау шат бәхетне каплап килә торган билгесез кара болытның котылгысыз якынаюын сизенеп елаудыр. Мостаңгир, нишләргә белмичә, Сәлимәнең елаганын озак кына тыңлап утырды. Ни өчендер Мостаңгиргә җиңел булып китте. Ә-ә, менә нәрсә кирәк булган икән аңа. Сәлимәнең җылавы кирәк булган. Күз яше кирәк булган. Хатын елый, димәк, монда ир хуҗа. Мостаңгир, канәгать көлемсерәп, урынына барып ятты. Сәлимә сирәк-сирәк кенә сулкылдый. Мостаңгир тагын торып утырды. Ул Сәлимә белән сөйләшергә, татуланырга тели иде. Ләкин сүз башларга кыюлыгы җитми. Үзләре янәшә утыралар, араларында – упкын. Сәлимә торып китте, Мостаңгир тугры маэмай кебек аңа иярде, Сәлимә утырды, Мостаңгир да янәшә утырды. Кыюлыгы җитеп, Мостаңгир хатынын кочты. Сәлимә аның күкрәгенә капланды.

Икенче көнне Мостаңгирның башы диңки иде... Теле чатнап ярылган... Күңеле болгана...

– Кая, баш төзәтергә нәрсә бар соң? – дип, шешәләрне әвеш-тәвеш китереп, бераз аракы эчте. – Чукынмасмы дөньясы... – диде ул, баш төзәтеп алгач. – Китәргә кирәк хатын йортыннан, җүнле ир хатынга йортка керми. Аерылышырга кирәк. Башка чибәрләр дә бетмәгән. Иргә чыкмаган яшь кызлар бетәсеме, үз цехыңда гына да никадәр. (Ул шыңшый башлады.) Башкалар да-ай бетмәгә-эн... Бетерәдер хәсрәтле уйларны...

Сәлимә байтактан Мостаңгирның кыланышын күзәтеп тора иде.

– Эчәсеңме? – диде ханым.

– Ә син күзәтәсеңме? – диде ире.

– Күзәтәм.

– Мин дә эчәм... Ире эчә Сәлимәнең, ире әлкәш Сәлимәнең... Хатыны интегә инде шул әлкәш белән, хәзер Мостаңгирның хезмәт хакын да үзенә бирмиләр, хатыны килеп ала, ха-ха-ха... Заманалар үзгәрде. Ире прогульщик, театрга йөрми, китап укымый... Урык-сурык кына эшли. Гел сыра мичкәсе янында... Менә хәзер мин сәрхушләрнең хәлен аңладым, карчык... Качып эчүе рәхәт икән ләбаса. Романтика!

Сәлимә Мостаңгирга аерым урын әзерләде.

Мостаңгир хатынының урын җәйгәнен айкала-чайкала карап торды да әйтте:

– Мостаңгирның хатыны ирен янына яткырмый икән... – диде. – Алар аерым йоклый икән...

Шулай итеп, алар беренче тапкыр аерым йокладылар. Әмма аларның күңеле, теләге бергә иде.

***

Сәлимә Мостаңгир торганчы өй җыештырып, ашарга әзерләп өлгергән иде инде. Мостаңгир да, һични булмагандай, кәефле иде. Ул киерелде-сузылды, тәмам уянып җитте.

– Яңа ел килеп җитте бит, Мостаңгир, – диде Сәлимә.

Мостаңгир җылы юрган астында рәхәт чигүен дәвам итте.

– Беркая да барасым килми, – диде ул, иркә баладай. – Өйдә генә утырыйк.

Сәлимәнең күңеле дә Мостаңгирның күңел кылларына тәңгәл корылган иде.

– Тел очымнан алып әйттең, – диде Сәлимә. – Икәү генә каршыларбыз... – Аннан соң кычкырды: – Чәй әзер, Мостаңгир әфәнде! – диде.

Мостаңгир ятак киемнәреннән генә юрган астыннан чыкты да әллә каян бер төргәк чыгарып хатынына сузды.

– Яңа ел котлы булсын, Сәлимә! – диде ул.

Сәлимә төргәкне сүтте дә «аһ» итте.

– Әнекәйләрем, калфак!

Мостаңгир театраль хәрәкәтләр белән, иелә-бөгелә тәгъзим ясап, баш иде дә әйтте:

– Ошбу энҗеле калфак безләрнең әнкәсе Васбиҗиһан карчыкның мирасы булыр имди. Васбиҗиһан вафат булганда, углы Мостаңгирга: «Балам, өйләнгәч, хатыныңа бүләк итәрсең. Бу калфак сигез буын хатын-кызның башында булган. Әманәтем шул: хатының синең белән бәхетле булсын!» – дип әйтеп калдырды. Сәлимә ханым, алыгыз, әнкәмнең васыятенә тугры калыгыз!

Сәлимә калфакны чәченә тагып карады. Көзге каршысына килеп тикшерде һәм бик канәгать калды. Мостаңгир шешә ачты. Кадеһләрне чәкәштергән чакта ишек кыңгыравы чылтырады.

Сәлимәнең тәне куырылып килде. Яңа елны гына көтеп торган бер юлаучы килә!

Мостаңгир ишекне ачты. Бусагада егет белән кыз күренде.

– Гафу итегез, – диде кыз. – Сәлимә апа шушында торамы?

Мостаңгир иңбашы аркылы гына Сәлимәгә кычкырды:

– Карчыгым, кунаклар!

Сәлимә, алъяпкычына кулларын сөртә-сөртә, ишек янына килде.

– Исәнмесез, Сәлимә апа, – диде кыз. – Сез мине танымыйсыздыр инде. Мин Иштирәктән.

– Үтегез! – диде Сәлимә.

Кунаклар эчкә узды.

– Мостаңгир, булыш, – диде Сәлимә.

Мостаңгир егет кулындагы төргәкне алып, урындыкка куйды. Сәлимә кызны чишендерә башлады.

– Бик вакытлы килдегез, – диде хуҗабикә. – Табын янына узыгыз!

Егет, төргәген чишеп, Сәлимәгә чәчәк сузды.

– Гөлчирә белән икебез дә Яңа ел белән котлыйбыз сезне! – диде егет.

– Бу минем ирем Сәмит була, – диде Иштирәк кызы.

– Алайса, ике бәйрәм, – диде Мостаңгир.

Кыз тарсынып тормый, сөйли дә сөйли:

– Без бер техникумда укыйбыз. Сәлимә апа, мин сезне хәтерлим әле. Сез малайлар шикелле, атка атланып йөри идегез авылда.

Барысы да көлде.

– Булды, андый хәлләр булды... – диде Сәлимә. – Мин абыйның атын кардунга менгерә торган идем.

Өстәл тирәли утырдылар.

– Мин Гыйлаҗетдин кызы Гөлчирә булам.

– Ә-ә, шулайдыр дип уйлаган идем, – диде Сәлимә. – Нәкъ Гайшә апага охшагансың.

– Мине әнигә дә, әтигә дә охшаталар.

– Син бит әле менә болай гына идең... Инде кияүгә чыгарга да өлгергәнсең.

Мостаңгир тезгенне үз кулына алырга булды, ахрысы. Чәркәләргә эчемлек салып чыкты да алкыш күтәрде:

– Әйдәгез әле, Яңа ел хөрмәтенә! Котлы булсын Яңа ел!

– Танышу хөрмәтенә! – дип өстәде Сәлимә. – Яшь гаилә хөрмәтенә!

– Кайда укыйсыз? – диде хуҗабай.

Сәмит хуҗаның соравына җавап бирергә алынган иде дә тончыкты. Кыз аның аркасын төя башлады. Үзе көлә.

– Без кулинарныйда, – диде кыз.

– Алайса, тәмле әйберләр белән өстәлегез тулы була икән.

– Сәмит баллы әйберләр ашамый... Сәмит, сиңа ипи алып биримме?.. Без укып бетерүгә, район үзәгендә кулинарный цех ачыла. Икәүләшеп шунда кайтабыз, Алла боерса... И-и, Сәмит, син әйтми утырасың тагын... онытып торам икән... Туган апагыз, Сәлимә апа, сезгә Яңа ел бүләге җибәрде. Инде узган атнаны ук алып килгән идек, юри бүгенгә саклап тордык... Сәмит...

Сәмит ишек янындагы урындыкка куелган төенчекне алып килде. Аның кулыннан төргәкне алып, кыз Сәлимәгә тоттырды.

Кыз өзлексез сөйләнә:

– Туган апагыз әйтә: Сәлимә белән Мостаңгир кияү каклаган каз ярата, ди... Мин әйтәм, Сәлимә апа ач түгел, дим. Казанга ит төяп йөрергә... Барыбер биреп җибәрде.

– Рәхмәт, Гөлчирә сеңлем, – диде Сәлимә. – Хәзер без аны... Мәле, Мостаңгир, туракла әле казны... Ике канаты безгә – кызларга. Тәпиләре сезгә – егетләргә.

Кыз белән Сәлимә көлде. Сәмит тә елмайган булды. Мостаңгир төкселәнде. Бераздан егет белән кыз кузгалды.

– Ярый, Сәлимә апа, Мостаңгир җизни, без киттек, – диде Гөлчирә. – Сәмит!

Сәмит ишек катында иде инде.

Сәлимә:

– Нигә алай бик тиз? – диде. – Утырырга иде инде бераз.

– Без шулай, Сәлимә апа, – диде Гөлчирә. – Төне буе кунактан кунакка йөрергә булдык Сәмит белән. Үзебез кунак чакырмадык, безне дә кунакка чакырмадылар. Менә шулай итеп, бүген таң атканчы танышларны әйләнеп чыгарга исәп. Ату бәйрәм саен гел общежитие, җыелышып эчәләр дә сугышалар. Кызыгы юк. Болай кызык ичмасам. Хушыгыз!

Кунаклар китте. Сәлимә аларны озата чыкты. Ишекне ябып, өстәл янына килеп, һични уйламыйча, каз турый башлады. Бер кисәк итне Мостаңгирга сузды.

Урамда Яңа ел каршылаучылар шаулаша. Күршеләрдә музыка. Мостаңгир дәшмичә генә Сәлимә сузган кисәкне алды. Икесе дә чәркәләрен күтәрделәр.

– Яңа ел белән котлыйм сине, Мостаңгир! – диде Сәлимә.

– Мин дә сине тәбриклим! – диде Мостаңгир, төксе генә.

Шәраб тулы чәркәләр тияр-тимәс кенә чәкәште.

Һавага ыргытылган пычкы тавышыдай пыяла зыңгылдады.

Ләкин аларның берсе дә шәрабка ирен тигезмәде.

Сәлимә белән Мостаңгир икесе ике якта. Үпкәләшкәннәрме? Икесе дә сүзсез. Урамда шатлык, бүлмәдә киеренке тынлык.

Сүзне Сәлимә башлады.

– Күпме шулай үзеңне газапларга була инде? Үзеңне дә, мине дә... Мин хәтта сәбәбен дә белмим, чамаламыйм да хәтта... Ни өчен син үзеңне эчтән талыйсың, син эчтән таланганга, минем йөрәк сыза. Ичмасам, сәбәбен әйт, ачыктан-ачык сөйләшик. Бәлки, минем гаебем бардыр, бәлки, синеке...

Мостаңгир хатынына карамыйча гына әйтте:

– Синең белән күпме яшибез, мин сине белмим.

Сәлимә гаҗәпсенеп иренә карады.

– Ничек инде син мине белмисең? Мин синең каршыңда, мин синең яныңда, мин синең белән бер юрган астында...

– Мин синең узганыңны, синең ни уйлаганыңны белмим.

– Минем узганым да сер түгел, Мостаңгир. Мин сиңа тол хатын буларак чыктым. Сине алдамадым, мин мулла кызы да, фәрештә дә түгел. Минем сиңа чаклы да башка ирләр белән мөнәсәбәтләрем булгалады. Иремнән аерылгач, әлбәттә. Ләкин алар узды, китте, көл булып, тузан булып очты. Аларның ни катнашы бар синең белән миңа? Син мине һәр кешедән көнлисең. Берәр ир минем белән елмаеп күрешсә, син: «Әһә, бу минем хатынның элеккеге сөяркәсе түгелме икән?» – дип кара көясең. Теге журналист авылдан алып килгән күчтәнәч казны кертеп чыкты, ул да сиңа минем сөяркәм кебек күренде... Әйе, шулайдыр. Синең хатының азгын, туймас җенесле бер авызлыксыз хатын. Зур борынлы ир күрүгә, итәген сала торган юмарт тәэминат бүлеге мөдирәсе! Ирләрнең барысы да минем белән йоклап чыккандыр... Хәтта йоклап чыккан булсам да, мин бит сиңа хыянәт итмим, сиңа кадәр булганнарның сиңа тырнак очы хәтле дә кагылышы юк, юк! Аңлыйсыңмы син, утын пүләне? Неужели инде мин хәзер сине белмәгән, күрмәгән чакта йөргән егетләрем өчен төннәр буе көнчел нотыкларыңны тыңлап чыгарга тиеш? Минем ни гаебем бар?

– Гаебең бар, димим...

– Гаебем булмагач, нигә син мине җәзалыйсың?

– Миңа караңгы, синең әллә нинди серләрең бар кебек. Мин сине өзелеп яратам, мин сине чыдый алмыйча сөям, сөйгәнемә күрә газапланам.

– Син мине газаплыйсың!

– Ә син газапланма. Минем кара көнләшү вакытларын сабыр гына үткәзеп җибәр.

– Көнләшү өянәгең килгән саен, мин чыгып кача алмыйм бит инде, аннан тагын син, кайда булдың, дип теңкәмә тиеп бетәчәксең. Инде бу иремнән уңдым, Аллага шөкер, дип яшәп ятканда гына, монысы да көнчел булып чыкты.

– Бәгыремне таламасын өчен, миңа бар да ачык булырга тиеш. Син миңа беренче ireңнән ник аерылганың турында сөйләмәдең.

– Сөйләдем! Барысын да сөйләдем.

– Эчми иде, тартмый иде, яхшы кеше иде, әниләр дә аны бик хөрмәт итә иде, дидең, дөрес. Шундый яхшы кешедән хатын китәмени? Дөрес түгел! Син нидер яшерәсең.

– Эчә иде, кыйный иде, гүләйт итә иде, әти-әниләрне дә рәнҗетә иде. Ул бик кабахәт кеше иде, аннан да җүнсезрәк ирне көндез чыра яндырып эзләсәң дә табалмассың! Күңелең булдымы?

– Юу-ук, ул эчми, ул сине кыйнамый да иде. Син нидер яшерәсең, Сәлимәкәй!

– Җанымны актарасың син минем... Борынгы аллалар дөньядагы бөтен начарлыкларны җыеп, бер сандыкка салганнар да, сакларга дип, Пандора исемле гүзәл хатынга тапшырганнар. Бу сандыкны ачарга ярамый, ачсаң, дөнья харап булачак, дип кисәткәннәр. Артык кызыксынучан Пандора беркөнне сандыкны ачкан, сандыктан хөсетлек, көнчелек, алдашу, астыртынлык, әхлаксызлык кебек кабахәтлекләр чыгып качкан. Кылганына үкенеп, Пандора сандыкның капкачын тиз генә япкан. Ләкин барлык әшәкелекләр дә чыгып өлгергән, сандыкта бары тик Өмет кенә калган. Син дә артык кызыксынучан булып чыктың. Мин сиңа сөйләрмен, ләкин ул сиңа җиңеллек китермәячәк, сине тагын да шикчәнгә әверелдерәчәк. Хатын-кызның сере булырга тиеш, син ул серне ачарга омтылма, үкенерсең!

– Сереңне ачмасаң да үкенәчәкмен!

– Ярый, мин сиңа барысын да сөйләп бирермен, ләкин син барыбер мине аңламаячаксың. Ни язган, шул булыр... Хамис белән без яшьли йөрешеп өйләнештек. Барысы да ап-ачык иде. Туганнар да безне хуплый. Без пар килгән. Ул баһадир егет. Мин назик кыз. Холыкларыбыз да туры килә. Ул кайнар егет, мин салкын-салмак кыз. Аның кайнарлыгы минем сабырлыкка килеп бәрелә иде дә, шунда сүнә иде. Ара бозылмый кала. Икенче мизгелдә ул инде елмая, мине ярата. Өйләнештек. Мәхәббәт, дип йөргәнем чәлпәрәмә килде. Мин аны яратмыйм икән. Мин аны сөймим икән.

– Ни өчен?

– Ни өчен? Ни өчен? Әниләр дә каныма тоз сала: ни өчен аерылыштыгыз? Ни өчен син аны ташладың? Эчә идеме, акча алып кайтмый идеме? Ни өчен икәнен әйтеп бирә алсам, мин үзем дә тынычланыр идем.

Сәлимә тынып калды. Хатын үз уйларына кереп китте. Ул элеккеге ире Хамис белән булган сөйләшүләрне ачык хәтерли иде. Хамис хәрби киемнән, мәһабәт ир-егет булып килеп басты аның каршысына.

– Сәлимә, – диде Хамис. – Туйдым мин синең бу капризларыңнан... Менә моннан гарык булдым. Бай булмасак та, безнең бар җиребез җитеш. Туганнар да безгә карап туймыйлар.

Сәлимә Хамиска аркасы белән тора иде.

– Ташласана, Хамис! – диде хатын. – Карап туймыйлар, сокланалар, имеш! Нинди төче сүзләр! Аларның үз карашлары, үз зәвыклары.

– Ә безнең карашлар, безнең зәвыклар үзгәмени? Син башка маймылдан яратылганмыни?

– Булды, Хамис, мин китәм!

Хамис үрсәләнә, нишләргә белми, ачыргалана:

– Сиңа аракы эчеп кайтып тукмый торган ир кирәк. Мин бит сине сөям, мин сиңа тырнак белән дә чиертмим... Ә-ә, аңлашылды, синең башка кешең бар!

– Юк минем башка кешем, Хамис Сәфәров! – дип кычкырды Сәлимә. – Юк!

– Димәк, күз тоткан, өмет иткән башка ирең бар. Кем инде ул?

– Башыма да килгәне юк. Акланырга теләгем дә юк!

– Димәк, күз тоткан кешең бар.

– Мине булмаган гөнаһым өчен акланырга мәҗбүр итмә, Хамис. Мәсьәлә ачык. Мин синнән китәм!

– Кешең булмагач, атаң башынамы китәсең син?

– Мин квартир таптым. Анда ремонт төгәлләнгәнче, авылга кайтып торам.

– Барысын да алдан уйлап куйган. Аңламыйм мин сине, Сәлимә. Аңлатып кит, юкса мин ничек итеп кеше күзенә күренерим?! Мине туганнарың да, дусларым да «ни өчен?» дигән сорау белән күмеп ташлаячак. Ни өчен?

– Мин сине яратмавымны аңладым, Хамис. Тынычлан. Бу сүзне мин әйтергә теләмәгән идем. Үзең мәҗбүр итәсең. Мин сине сөймим икән.

– Ух, сабырлык бир, Ходам!

– Син мәһабәт ир, бөтен гүзәлләрнең күз карашы синдә. Син төшеп калганнардан түгел. Минем китүем сине чыгырдан чыгармас. Ләкин...

– Тора-бара яратыр идең әле, уртак бала бәйләр иде. Бөтен кеше дә яратышып кына тормый.

– Юк, Хамис, вакытында өзмәсәк, алга таба безнең яшәү фаҗигагә әвереләчәк.

– Җаным, Сәлимәкәй...

– Нинди төче сүз – «Сәлимәкәй».
– Мин сиңа гомер буе шулай дәшә идем.
– Игътибар итмәгәнмен. Хәзер ул бик төче яңгырый.
– Сәлимә, әллә мин сине берәр вакыт бик рәнҗеттемме?
– Юк, рәнҗетмәдең, Хамис.
– Әллә берәрсе сүз җиткердеме?
– Юк, җиткермәде, мин синең башка кызларга карамаганыңны беләм.
– Шулай булгач, ни сәбәп?.. Әллә син берәр бай ир таптыңмы?
– Юк, минем бай сөяркәм юк, Хамис. Бер генә сүзем бар: мин сине сөймим икән?
– Ни кылаем соң? Мин ни эшләргә тиеш? Сине җибәрмәс өчен, югалтмас өчен, мин нишләргә тиеш?
– Берни дә эшләмә. Син мине тыныч кына чыгарып җибәр. Мин бары тик үз әйберләремне генә алдым. Фатир үзеңә кала, аны сиңа эш урыныңнан бирделәр. Ул синең малың.
– Әйт, кайсы ягым сиңа ятышмый, мин төзәлермен. Мин сиңа ярарга тырышырмын, Сәлимә. Тырышырмын.
– Ир булып кал, Хамис. Вакланма. Ялынма хатын-кызга. Хатын-кыз елакларны яратмый.
– Мин елак идеммени?
– Юк, Хамис, елак ир булмадың, син каһарман, син батыр егет...
– Соң, атаң башы кирәкме тагын сиңа – хатын-кызга? Мал табам, буем өрлектәй, акчаны көрим...
– Йөз гүзәл муеныңа асылынырга әзер тора. Ләкин...
– Ләкин син генә Алланың кашка тәкәсе! Син генә особая, син генә оригинальная, син генә затлы кан, син генә патшабикә, ана... сатасы... сытасы... Тилертәсең инде мине, валлаһи.
– Ямьсезләнеп аерылышасым килми, Хамис. Зинһар, ямьсезләнмик, тәмсезләнмик. Мин китим! Бәхетле бул! Сиңа чын күңелдән бәхет телим. Һәм син үзеңнең бәхетеңне табачаксың. Аңа ерак түгел! Хуш!
– Ярый... булды... ямьсезләнмик... Ләкин, Сәлимә, бер нәрсәне аңлап кит, миңа синнән башка хатын-кыз бәхет китерә алмый. Мин синнән башка бер генә хатын-кызны да сөя алмаячакмын. Минем табигатем шундый.
– Син мине сөясең?..
– Сөямен...
– Сөйгән кешеңә яхшылык эшләргә телисеңме?
– Әйе, телим...
– Әйдә, яхшылык эшлә, мине хәзер үк чыгарып җибәр!
Сәлимә ачкычларны өстәлгә ташлады.
Хамис, кызулыгыннан шартлый язып, бер җилкенеп алды да кинәт тынып калды. Ныклы бер карарга килде.
– Сине кирегә үгетләп булмас, ләкин шуны исеңнән чыгарма: кайда гына булсаң да, кем белән генә тормыш корсаң да, дөньяда мин барын онытма! Авыр булганда, юлың уңмаганда, син шушы йортка кире кайта аласың, ал ачкычларыңны.
Хамис ачкычларны Сәлимә кесәсенә тыкты.
– Мин сине көтәрмен. Мин сөекле кешемә яхшылык телим, ишек ачык, бәхил бул, Сәлимә! Ләкин мин синнән башка яши алмаячакмын! Сәлимә, мин синнән башка яши алмаячакмын! Сәлимә-ә...

Сәлимә кесәсендәге ачкычларны чыгарып, янә өстәлгә ташлады һәм:

– Бәхетле бул, Хамис! Хуш! – дип чыгып китте.

Хамис тилергән хәлдә иде. Ул тәрәзә янына килде, Сәлимәнең үзен ташлап китеп барганына карап торды, ишек катына килде, тагын тәрәзәгә капланды.

– Сәлимә-ә... Китте тимер хатын! Дөньяс-ссын сытыем! Бәхетле бул! Ярар, бәхетле булырмы-ын! Кешене янган утка ташлап, «бәхетле бул», дип әйтү – ул мыскыллау!

Ул алтатарын чыгарды, аны җентекләп караштырды. Көпшәсен чигәсенә тигезеп карады да үзалдына сөйләнә башлады:

– Бәхетле бул, дип әйтү – ул мыскыллау, ханым-әфәнде!

Ул алтатарын маңгаена тагын терәп карады һәм тәтегә басты. Алтатар атмады. Ул яңадан чакмасын күтәрде, аннан вазага атты. Ваза чәлпәрәмә килде. Хамис киеренке халәттә көлә башлады.

– Бәхетле бул, Сәлимә! Ха-ха-ха...

Сәлимә Мостаңгиргә сөйләвен дәвам итте:

– Шуннан соң Хамис, авылга кайтып, апам белән җизнәмә барысын да сөйләп биргән. Тегеләр, минем янга килеп, ике атна буе үгетләделәр. Апам елый, җизнәм ачулана. Алар Хамисне бик яраталар, үз итәләр иде. Хамис үз теләге белән Чечняга китте. Сугышка бармаса да була иде, югыйсә. Аның министрлыкта дус-ишләре күп иде. Китте Хамис – Чечняга китте...

Мостаңгир фаҗигале бу хикәяне нindидер канәгатьләнү белән ахырынача тыңлады.

– Ул бит синең аркада киткән Чечняга.

– Нишләп минем аркада булсын?

Мостаңгир Хамисне яклагандай әйтеп куйды:

– Казанда нишләсен ул синнән башка?

– Минем ни катнашым бар аның язмышында? – диде Сәлимә, кырыс кына.

– Димәк, катнашың бар.

– Юкны сөйләмәче!

– Кичер, хикәяңне бүлдердем. Хамистән аерылгач, син япа-ялгыз тормадың бит инде.

– Ялгыз тормадым.

– Димәк, синең күз алдында тоткан башка кешең булган?

– Юк, Мостаңгир, башка кешем юк иде. Хамистән аерылгач, ярты ел узгач кына, мин Идрис белән таныштым.

– Идрис көндәш.

– Сөйләмим!

– Гафу ит, Сәлимә, бүлдердем.

– Идрис начар кеше түгел иде.

– Гел сиңа гына туры килә яхшы кешеләр – эчми, тартмый торганнары...

– Мин үз астымнан уйлап чыгармыйм бит инде, шулай булгач, шулай сөйлим. Ышанмасаң, тыңлама!

– Идрис начар кеше түгел иде, дидең.

– Начар түгел иде. Ул мине хөрмәт итә иде. Яратканмыдыр, юкмы, әмма аның мине хөрмәт иткәнен бик яхшы беләм.

– Сез өйләнештегезме?

– Юк! Нигә кирәк ул рәсми кыягазлар? Аерыласы булса, сине кыягаз гына туктата алмый бит.

– Ул синең сөяркәң булып яшәде, шулаймы?

– Бәйләнмә! Ничек телисең, шулай уйла. Гражданский брак белән яшәдек. Күңелең булдымы?

– Гражданский брак белән, ие.

– Идрис минем белән никахлашырга теләмәде.

– Ул бит сине хөрмәт иткән, ни өчен?

– Мин аңа хатын була алмый идем.

– Ни өчен?

– Ул минем кебек баш бирмәс хатын белән яши алмас иде. Чөнки ул үзе баш бирмәс ир иде. Аннан соң мин аның туганнарына да ошамадым.

– Туганнары белән сез шулай якыннан аралаштыгызмыни? Димәк, эш өйләнешүгә таба барган?

– Алар килә иде, без кайткалый идек... Идрис хис кешесе генә түгел, зиһен кешесе дә иде. Мин аны күбрәк шуның өчен хөрмәт иттем.

– Ярата идем, диген.

– Юк! Хөрмәт итә идем... Идрис, бәлки, мине яраткандыр да, ул да бик көнчел иде, ләкин көнләшкәнен сиздермәскә тырыша иде, ул чәпчемичә генә, матур гына аерылды миннән.

– Үзе киттеме?

– Үзе китте.

– Ташлады, диген.

– Мин ташлап калдыра торганнарга охшаганмы?.. Ул китте. Арада бер юшкын калмады. Ул башкага өйләнде. Алар әйбәт торалар, дип беләм. Мин аның өчен сөенәм... Аннан Сергей белән очраштык. Анысы белән дуслык бик кыска булды. Ике очрашканнан соң, араны өздем.

– Ни өчен? Эчми иде, тартмый иде, шәп идеме?

– Нәкъ шулай! Серёжа да начар түгел иде. Ләкин ул минем кешем түгел иде.

– Кем соң ул синең кешең?

– Чүп сораулар белән мине тинтерәтмәсәң, әйтәм: минем кешем ул син – Мостаңгир... Михаил белән дә ара ябышып бетмәде.

– Михаил?

Мостаңгир ни өчендер «Интернационал» көен шыңшый башлады.

– И с интернационалом воспрянет род людской! Полный интернациональ баҗайлар куера.

– Үзең теләдең!.. Михаил да ирләрнең күпчелеге сыман беркатлы, примитив булып чыкты. Рас хатын аның белән бер юрган астында кендектәш булган икән, хатын аның колы, аяк чүпрәге булырга тиеш, дип уйлый иде, мескен.

– Хатынның ир каршысындагы вазифалары да бардыр бит?

– Бар! Ләкин кол дәрәҗәсендә үк түгел.

– 1917 елда сезгә тигез хокук яулап алып бирделәр бит инде.

– Миңа андый тигезлек кирәк түгел. Ир кеше – ир урынында, хатын үз урынында булырга тиеш. Алар беркайчан тигез була алмый.

– Менә монысы дөрес...

– Шуның белән минем коллекциям бетте. Аннан соң сайлаганым син булдың.

– Мин?

– Син!

– Минем белән син кайчан аерылышачаксың?

– Анысы синнән тора.

– Мәсәлән?

– Әйтә алмыйм. Алдагысын Алла белә. Тормыш күрсәтер. Ә хәзер йоклыйбыз.

– Мин әле һаман аңлый алмыйм, ни өчен син Хамисне ташладың. Шул өч минутлык очрашулар өченме?

– Нигә өч минутлык кына, без синең белән бер ел яшибез түгелме?

– Ә бала юк!

– Анысы ерак йөрмәс!

– Син әллә...

– Кысыр түгел! Мин үзем балага узмаска тырыштым. Ике ара ныгымыйча, булачак ятимгә узасым килмәде.

– Син балага узсын өчен, мин барысын да эшләргә риза. Шулай да ни өчен син Хамис Сәфәров кебек ирдән аерылдың? Шуны аңламыйм!

– Апам шулай ди, җизнәм шулай ди, туганнарым шулай ди, дус хатыннарым, эштәгеләр «ни өчен?» дип аптырата. Хәзер син тигәнәк кебек ябыштың. Ни өчен? Ни сәбәпле? Аны аңлатып буламыни? Мәхәббәтне аңлата алмаган кебек, яратып булмаганны, нәфрәтне ничек аңлатасың? Матур булганга сөйдем, эчкәнгә аерылдым, дип кенә аңлата торган булса, аны йөз мең ел элек аңлаткан булырлар иде. Ни өче-ен? Ни сәбәпле-е? Менә син мине ни өчен яратасың? Аңлатып кара! Ни өчен?.. Нигә эндәшмисең, Мостаңгир?.. Син шундый чибәр, диярсең.

– Әйе, син чибәр.

– Лидия чибәр түгелмени?

– Чибәр. Ләкин...

– Ләкин ул миннән күпкә чибәррәк... Син акыллы, диярсең.

– Әйе, син чыннан да акыллы... – диде Мостаңгир.

– Сафия Кадыйрова акыллы түгелмени? – диде Сәлимә.

– Акыллы. Ләкин...

– Ләкин ул тирә-яктагы без белгән хатын-кызларның барысыннан да акыллырак. Бу – бәхәссез... Әйт, син Сәлимәне ни өчен яратасың?

– Башкалар кебек чибәр булмаганың өчен.

– Монысы ярый.

– Башкалар кебек үк акыллы булмаганың өчен.

– Монысы да ярап тора.

– Башкалар кыйммәтле киенеп, бизәнеп, француз ислемайлары сөртеп, гүзәлләр рәтенә керә. Син гади киенәсең, хушбуй сөртмисең, бизәнмисең. Син бизәнмәгән килеш матуррак.

– Безнең җыештыручы Мәрфуга, гомумән, иннекнең ни икәнен белми. Нигә аны яратмыйсың?

– Ул бит башка.

– Башка түгел, Мостаңгир. Мәрфуга минем белән яшьтәш. Аңгыра түгел. Менә дигән хатын була алырлык кыз. Ул кияүгә дә чыкмаган, ул башкалардан да калмаган. Гражданский брак белән тордым, дигән булып себерелмәгән дә. Аның гөнаһы юк. Ул бер ир белән дә йокламаган. Аның узганыннан син көнләшерлек түгел. Ул әле кыз. Ямьсез дә түгел. Минем чама. Өйлән шуңа, үкенмәссең!

– Мәрфуга үзенә тартып тормый.

– Тартып тормый? Мин тартып тораммы?

– Магнит кебек.

– Димәк, Мәрфуга сексуаль хатын түгел. Шулаймы?

– Шулайдыр.

– «Дыр» түгел, шулай!.. Кияүгә чыгып яки башка ирләр белән гражданский

бракта тора башласамы – Мәрфугадан да магнитлы хатын булмаячак! Бүген аңа «уборщица», дип, бер генә ир дә игътибар итми. Ирләрнең күңел күзе сукыр. Әгәр дә күңел күзе ачык ир аңа игътибар итсә, күрер иде, Мәрфугада куәтле хисләр йоклап ята. Аны киендерсәң, аны бу эшеннән алып, чистарак эшкә куйсаң, Мәрфугаң «секс бомба»га әвереләчәк. Мин бу турыда беркемгә дә әйтмим, хәтта хатын-кызларга, дусларыма да әйтмим. Үзләре күрсен алмаз ташын. Җә, әйт, ни өчен син мине яратасың?

– Син әллә нинди...

– Димәк, син мине әллә нинди булганым өчен яратасың. Әллә нindиләр бик күп бит... Аптырама, йөдәмә, Мостаңгир, мин беләм синең мине ни өчен яратканыңны.

Мостаңгир аптыраган, ул Сәлимәнең дәвам итүен көтә иде. Сәлимә тынлыкны юри суза төшкәч, әйтте:

– Син мине сексуаль яктан уянганым өчен яратасың.

– Ничек?

– Шулай. Син мине өлгергән, тулышкан хатын булганым өчен яратасың. Син мине сиңа кадәр берничә ир белән озак вакытлар җенси мөнәсәбәттә булганым өчен яратасың. Көнләшә-көнләшә яратасың. Син көнчелегең килгән чакта мине үтерергә риза, көнчелек өянәгең узып киткәч, син мине үтерердәй булып яратасың, сөясең. Ярату өянәге узып киткәч, тагын көнчелек өянәгең башлана, син мине тагын көнлисең, син алдагы ирләр белән минем ятакта ничек булганымны авыру хыялыңда күз алдыңа китереп, төннәр буе йоклый алмыйсың, чөнки син мине бары тик үзеңнеке генә, дип күзаллыйсың, ә мин синеке генә түгел, алда дүрт ирнеке булганмын. Мин бит алар белән дә якын мөнәсәбәттә, төрле хәлләрдә булган хатын. Мин бит син очрарсың дип, алар белән мөнәсәбәткә керми торырга тиеш түгелмендер?.. Безнең тормыш әнә шушы ике өянәк, көнләшү һәм сөю өянәге арасында узачак. Катлаулы, авыр әлсерәткеч тормыш көтә безне. Әгәр дә син шул авыруыңнан арынмасаң, безнең юллар аеры. Чөнки минем синең каршыңда тырнак очы хәтле дә гаебем юк. Мин сиңа хыянәт итмәдем, хыянәт итәргә җыенмыйм да. Син дә ир булып кала бел!

Мостаңгир, хатынын беренче тапкыр күргәндәй, тотлыгып калды. Ул, йөз тапкыр гер күтәреп әлсерәгән батыр кебек, авыр сулап куйды:

– Һу-у, катлаулы мәсьәлә кузгаттык без бүген, – диде.

– Без түгел, син! – диде Сәлимә.

– Катлаулы мәсьәлә кузгаттым мин бүген!

– Син Пандораның сандыгын ачтың, чүлмәктәге җенне чыгардың.

– Сокланам мин сиңа, Сәлимә, сакланам да...

– Тотып буарга да телисең.

– Син – психолог.

– Мактау сүзләреңне әйтеп бетер.

– Син – философ.

– Мин сексолог та, психоаналитик та... Аңлыйм мин сине, Мостаңгир, аңлыйм, шуңа күрә мин сине гаепләмим дә. Сез ирләр, бигрәк тә мөселман ирләре, хатын-кызны самими, беркатлы, керфеген күтәреп башкаларга карамый торган, ак яулык бәйләп, җиргә генә карап йөри торган мәхлук зат итеп күрергә телисез. Бу – сезнең иң олы ялгышыгыз. Алар да Аллаһ тарафыннан яралтылган бәндәләр. Аларның да тою хисләре ирләрнеке кебек, кайбер очракларда хәтта ирләренекеннән артыграк та. Аларда да җенси комсызлык йоклап ята. Ул комсызлыкны котыртырга, алгысытырга мөмкин, аннан соң

женси тотнаксызлыкка барып чыгарга мөмкин. Ул комсызлыкны тыярга, авызлыкларга, араталар арасына кертеп бәйләргә мөмкин.

– Син миңа мәхәббәтнең анатомиясен ачып салдың түгелме?.. Анатомиясе ачылганнан соң, кеше бер-берсенә азгынлык, комсызлык тутырылган капчык итеп кенә карамасмы?

– Караганы карар. Ләкин психоанализның атасы Фрейд үз хатынын олы сөю белән яраткан. Врачларның да күбесе мәхәббәт хисләренең ни икәнен белә, аңлый. Алар бер-берсенә комачауламый. Садист, мазохистлар, маньяклар – үзләренең женси комсызлыкларын тыймаучы, киресенчә, котыртучы кешеләр.

– Сәлимәкәй!

– Мин монда, Мостаңгир! Синең янда гына!

– Мин сине өзелеп сөямен!

– Мин сиңа «яратам» дип тә, «сөям» дип тә әйтмәячәкмен.

– Ни өчен?

– Дөньядагы «яратам», «сөям» антлары миллиардлап янып, көлгә әверелде. Мин сөюемнең янып, көлгә әверелүен теләмим. Син миңа «яратам, сөям», диген, миңа синең шулай әйтүең бик тә ошый.

– Яратам, мин сине сөямен, Сәлимәкәй!

– Хатын-кыз «сөям» сүзен ашыгып әйтми, хәтта өзелеп сөйсә дә. Ир-ат берәр хатын белән ялгыз калдымы: «яратам, сөям, алтынга манам, өрмәгән җиргә утыртмам», дип бик юмарт вәгъдәләргә күмеп ташлый. Бичара хатын-кыз шул вәгъдәләр тавы астыннан чыга алмыйча гаҗиз була. Шул вәгъдә таулары астыннан чыкканда, инде вәгъдә биргән ир-атның эзе суынган була.

– Мин сине сөям, Сәлимә. Безне зөфаф кичәсе көтә!

***

Таң атар-атмас вакыт. Ял көне. Хуҗалар йоклый. Ишектә кыңгырау чылтырады. Тынлык. Тагын кыңгырау чылтырады. Мостаңгир, ятак киеменнән торып, ишек катына килде.

– Кем бар? – диде Мостаңгир.

Тыштан:

– Срочная телеграмма... – дигән тавыш ишетелде. Мостаңгир ишекне ачты.

Ишек төбендә почта хезмәткәре басып тора иде.

– Кемнән, кемгә? – дип сорады Мостаңгир.

– Монда кул куегыз... – диде почтальон.

Мостаңгир кул куеп телеграмманы алды.

– Рәхмәт, сау булыгыз... – дип, почтальон китеп барды.

Мостаңгир йокы аралаш, күзен ерта-ерта, телеграмманы укырга маташып карады.

– Сафаровагамы? – диде Мостаңгир. – Ялгыш керткәннәрме соң? Ә-ә, Сафарова Салимя!

Мостаңгир телеграмманы йокы бүлмәсенә, хатынына кертеп бирде, үзе төрттереп әйтте:

– Сафарова Салимя, сезгә срочная телеграмма...

Телеграмманы хатынына тапшырып, үзе ваннага кереп китте.

Сәлимә телеграмманы алды, кинәт йокысыннан айнып, агарынып китте:

– Әстәгъфирулла! – диде Сәлимә. – Йа, Аллам!

Мостаңгир ваннадан кычкырды:

– Ни булды, Сәлимә?

Сәлимә, халатын киеп, йокы бүлмәсеннән чыкты да ванна тарафына килде.

– Хамис Сәфәров Чечняда һәлак булган! – диде.

Мостаңгир ваннадан чыкты.

– Һәлак булган? – дип гаҗәпләнде. – Сафарова Салимя... Син аның фамилиясендә калган идеңмени?

– Менә сиңа – бәлеш! – диде Сәлимә. – Без бит законлы аерылышмаган.

Мостаңгир телеграмманы хатыны кулыннан алды, күз йөгертеп чыкты:

– Крепитесь, госпожа Сафарова, – диде ул, ярымшаярып. – Ваш муж майор Сафаров Хамис Идиятуллович пал смертью храбрых, при исполнении служебных обязанностей, защищая Родину. Просим Вас вылететь по месту назначения для траурной процессии. Все расходы Вашего пути берёт на себя МВД Татарстана. Командир гарнизона по борьбе с терроризмом в Чечне генерал-лейтенант Субботин.

Тынлыкта калдылар. Монда шаярыр урын юк иде.

Сәлимә аптырауда иде.

– Мин бит инде аның хатыны түгел... «Ваш муж майор Сафаров»...

Мостаңгир да уйлануда иде:

– Частьта синең Сафаров хатыны түгел икәнеңне кем белсен? – диде ул. – Анкеталарда син батырларча һәлак булган каһарман Сафаровның тол хатыны. Димәк, ул синең белән аерылганын беркемгә дә әйтергә теләмәгән.

Сәлимәне борчу басты:

– Кем уйлаган, кем белгән... Нишләргә?

– Барырга, әлбәттә, барырга кирәк, – диде Мостаңгир.

– Йа, Ходаем. Мин бит инде аны күптән оныттым... – Сәлимә еларга җитеште.

– Син аны онытмадың, – диде Мостаңгир. – Син аны онытырга тиеш түгелсең, ул синең никахлы ирең булган, ул хәзер дә синең ирең санала. Русия кануннары буенча, син – каһарманның тол хатыны. Син анда бармасаң, халык ни әйтер? Бу – рәхимсезлек.

– Мин бит аны яратмадым! – дип кычкырды Сәлимә, ачынып. – Мин аны ирем дип тә санамадым, минем өчен ул чит-ят кеше.

Мостаңгир Сәлимәсен иңнәреннән тотып, күзенә туры карады.

– Сәлимә, син каһарманнарча һәлак булган мәет белән көрәшәсең түгелме? – диде.

Мостаңгир гаять җитди иде.

– Син Чечняга барырга тиеш!

– Нинди каһарманлык ди ул, нинди «защищая Родину» булсын ул? Чечнядагы балаларны үтереп, карт-корыларны талап, кырып йөри торган солдат нинди каһарман булсын ди?

– Бәлки, ул анда балаларны, карт-корыларны үтерүчеләрдән саклаганда һәлак булгандыр.

– Белмим. Аерылыштык та бетте, дип уйлаган идем. Ул мине үлгәч тә эзәрлекли. У-һу-у, үләм, мин хәзер батырларча һәләк булганның кайгылы тол хатыны ролен уйнарга тиеш буламмыни? Кызганыч, бик кызганыч, Хамиснең шулай яшьли һәлак булуы, ләкин минем бу эштә ни катнашым бар? Аңа бер ел хатын булып торганыма күрәме мин бу театрны уйнарга тиеш? Бу бит комедия, маскарад, мәсхәрә булачак. Мин бит ялганлый алмыйм, мин кылана алмыйм, мин бит коры, туры хатын. Ничек итеп мин анда басып торыйм?

– Ярый, син аны яратмагансың, ярый сез аерылышкан, ләкин кешелеклелек

дигән нәрсә бар бит әле. Кеше бөтенләй белмәгән, күрмәгән кешенең кабере янында да моңлана, кайгыра.

– Мин дә ак яулык бәйләп, намазлык өстендә утырып та, яшертен генә төнге клубларга акча эшләргә йөргән кайбер кызлар шикелле икейөзле булып яшиммени, Мостаңгир? Бу минем холкымда юк, мин моны булдыра алмыйм.

– Ак яулык бәйләгәннәрнең барысы да төнге клубларга йөрми шикелле.

– Йөрмидер. Ләкин мин йөргәннәрен беләм. Миңа ВИЧ тикшертергә йөри торган ак яулыклы кызларны беләм.

– Җыен! – дип әмер бирде Мостаңгир. – Самолётка соңга каласың.

– Бармыйм!

– Сәлимә, барасың!

– Нишлим соң?

– Нишлисең? Хамис Сәфәров синең аркаңда Чечняга үлем эзләп киткән. Аңлыйсыңмы, үлем эзләп киткән!

– Саташма, Мостаңгир. Нишләп ул минем аркамда үлемгә барсын. Ул бит Русияне чеченнардан саклаганда һәлак булган.

– Казандагы фатирын ташлап, мондагы олы вазифасын калдырып, ул ни өчен ут эченә, мәгънәсез үлемгә китсен? Уйлап бак! Синең өчен.

– Нишләп минем өчен? Аның минем алдымда бернинди дә вазифасы юк иде.

– Син аның законлы хатыны, Сәлимә.

– Мин аның хатыны түгел. Мин синең хатының.

– Синең Хамискә карата нәфрәтең шулкадәр көчлеме?

– Минем аңа карата нәфрәтем дә, мәхәббәтем дә юк. Ул миңа чит кеше.

– Ул сиңа авылдаш, в конце да концов, ул кеше – в конце да концов! Эшендә синең аның белән аерылганыңны берәү дә белми бит. Телевидениедән күрсәткәндә, син булмасаң, кеше ничек аңлар?

– Фу, телевидениедән күренәсем килми.

– Киен!

Мостаңгир чемоданга әйберләр тутыра башлады. Шкафтан кара күлмәк, кара шәл алды.

– Анысы нәрсәгә инде аның?

– Кавказда хатыннар траур көнне кара күлмәк кия, кара шәл бөркәнә. Әйдә, мин сине озатам, билетлар алырбыз...

– Мостаңгир, аягым тартмый.

– Син матәм вазифасын үтәргә тиеш.

– Ялганлапмы?

– Кешегә зыян салмаса, ялган гөнаһ түгел, Сәлимә.

– Алайса, икәү барыйк. Зинһар, ташлама мине шушы минутларда.

– Әйдә!

***

Чәчәкләр, такыялар, язулар, кара-кызыл тасмалар. Ян-якларда – шәрәф каравылы. Табут янында кара бөркәвечле Сәлимә утыра, аның янында Мостаңгир басып тора. Икенче кырда сул беләгенә кызыл каймалы кара бәйләгән яшь офицерлар матәм кайгысында. Табутны урап, солдатлар, милиционерлар, кара киемле хатыннар, каракүл бүрекле кавказ кешеләре әкрен генә уза тора.

– Хатыны жалко! – диде бер лейтанант, Сәлимәгә ымлап.

– Бедняжка, кайгыдан гел бетерешкән, – диде майор.

– Ярый әле, янында туганы бар, – диде лейтенант.

– Балалары бар идеме икән? – диде майор.

– Юк! Балалары булмаган, – диде лейтенант.

– Анысы ярый икән, ятимнәре булмас, – диде майор.

– Сугышта һәлак булганнарның хатыннарына пенсия шактый саллы түләнә икән, – диде лейтенант.

Сәлимә янына бер чечен гаиләсе килеп басты. Ир белән хатын, бер кечкенә ир бала.

Ир кеше сак кына Сәлимәнең җиңенә кагылып әйтте:

– Ханым, сез Хамис Сәфәров мәрхүмнең хатыны икәнсез... Кайгыгызны уртаклашабыз. Урыны җәннәттә булсын. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун. Хамис кебек батыр, каһарман угыл үстергәне өчен, Татарстан халкына, сезнең үзегезгә чиксез рәхмәтләребез.

Иренең сүзен хатыны да җөпләде.

– Кардәшебез Хамис безнең менә шушы бердәнбер углыбызны үлемнән коткарганда...

Хатын яулык почмагына йөзен яшерде.

Ир дәвам итте:

– Хамис безнең кардәшебез, ул безнең нәселебезнең дәвамчысын коткарды... Батыр йөрәкле егет... Без, чечен халкы, аны мәңге онытмабыз.

– Зинһар, безнең өйгә дә керегез, – диде хатын. – Без сезгә – Казанга барырбыз, сез безгә килерсез. Араларны өзмик без, ханым.

Хатын Сәлимәнең муенына чылбыр такты.

– Бу чылбырны таккан кеше безнең канкардәшебез була, – диде хатын.

– Сезнең ир туганыгызга минем исән калган улым кечкенә бер истәлек бирә. Улым!

Ир бала кулындагы каракүл бүрекне Мостаңгирга сузды. Ир Мостаңгирга иелергә кушты. Мостаңгир иелде. Бала аның башына каракүл бүрек кигезде.

Ир янә Сәлимәгә, аннан соң Мостаңгирга әйтте.

– Ханым, кардәшем! Без углым Алвадига икенче исем бирдек, аның исеме куш исем Алвади-Хамис булыр. Алвади үзенең балаларына, оныкларына шушы исемне ияртәчәк. Алвади-Хамис, Җоһар-Хамис. Зинһар, безнең йортыбызга керегез. Сезнең ирегез Хамис Сәфәров турында күбрәк беләсебез килә. Без аның турында, аның бу батырлыгы турында буыннан-буынга сөйләп барырга тиешбез.

Хатын әйтте:

– Улым Алвади-Хамиснең дә, бөтен нәселебезнең дә теләге бар. Зинһар, безне тыңлап багыгыз! Хамис Сәфәровның җәсәден монда калдырыгыз. Без аны үзебезнең зиратыбызга җирләр идек. Без аның каберен карап торыр идек. Буыннан-буынга без оныкларыбызга аның турында сөйләп, аның рухына догалар укыр идек.

Офицерлар, солдатлар халыкны бер кырга урнаштырды. Олы дәрәҗәдәге офицерлар матәм мәрасименә әзерләнә башлады.

Генерал Субботин, Сәлимә белән Мостаңгир янына килеп:

– Ханым, гаиләгезнең кайгысын уртаклашабыз, – диде.

Рәсми хөкүмәт башлыгы да Сәлимәнең кайгысын уртаклашып китте.

– Примите мои соболезнования!

Генерал матәм процессиясен башлап җибәрде.

– Офицеры и солдаты, граждане Чеченской Республики. Эта земля видела много горя. Этот народ выдержал такие трудные испытания и испытывает

по сей день. Сегодня мы прощаемся с героем майором Хамисом Сафаровым из Татарстана. Он добровольно взялся защищать народ от посягательств террористов. Его никто не просил, его никто не уговаривал, ему никто не приказывал поехать из мирного Татарстана в пекло войны. Он сам откликнулся, он сам решил встать в строй защитников Родины. Его никто не просил, ему никто не приказывал броситься в бушующий огонь спасать детей и взрослых. Он спас шестнадцать детей и пятерых взрослых, выбрасывая их из окна горящего дома. И в последний момент на него рухнул горящий потолок. Ему приказали покинуть здание. Он не слышал или же он слышал плачь испуганных, загнанных огнём детей и не мог их оставить в беде. Это не входило в его прямые обязанности, но честный, сердобольный и большой отваги майор Хамис Сафаров не думал о перераспределении обязанностей, он мгновенно бросился в огонь во имя спасения детей. Мы скорбим вместе с чеченским народом, мы скорбим вместе с его отважной вдовой и родными, мы все скорбим. Пусть земля будет ему пухом!

Чечен кешесе сүз алды:

– Безнең Чечен илен төрле кешеләрнең аяклары таптады. Әле һаман да таптый. Безнең чечен иленә яхшы кеше аяк баса икән, чеченнның ишеге ачык, күңеле ачык, чырае ачык булыр. Шундый кешеләрнең берсе – Татарстан егете майор Хамис Сәфәровка бөтен чечен халкы, безнең бөтен гаиләбез мәңге рәхмәтле булыр. Аллаһ аннан разый булсын! Хамис Сәфәров Чечняга гөнаһсызларны үтерергә дип түгел, Хамис Сәфәров – гөнаһсызларны якларга, коткарырга кергән кеше. Ул үзенең вазифасын тулысы белән башкарып чыкты. Хамис – минем углымны, тагын унбиш баланы үлемнән коткарып калган баһадир. Ул – Татарстанныкы гына түгел, ул чечен халкының да бөек каһарманы. Аның исеме безнең нәсел исемендә мәңге, гасырлар буена сакланыр, исеме чечен халкының күңелендә һәйкәл булып урнашыр. Урының җәннәттә булсын, батыр татар егете Хамис кардәшем!

Матәм музыкасы уйный башлады. Табутны алып киттеләр. Сәлимә үксеп елый иде. Аны чеченнар, солдатлар урап алды.

***

Мостаңгир белән Сәлимә Чечнядан исән-сау әйләнеп кайтты. Икесе дә моңсу иде. Икесе дә күргәннәре турында уйлый. Алар кайтуга ук, Сәфәрова фамилиясен алыштыру, ЗАГСта никахлашып, иренең фамилиясенә күчү белән мәшгуль булдылар. Эшләрен җайга салып, тагын тигез тормыш белән яши башладылар. Ләкин аларның адресына күпләп-күпләп кайгы уртаклашу кебек хәбәрләр килә торды. Бу хәбәрләр Сәлимәнең һаман эчен пошыра иде.

– Бу телеграммалардан, хатлардан берәр вакыт тынычлык булырмы икән? – диде ул, чираттагы хатны алгач.

– Алар гаепле түгел, Сәлимә! – диде Мостаңгир.

– Гаепле түгел! Ә минем тынычлыгым юкка чыга! Мин тыныч кына, синең белән матур гына, үзебез теләгәнчә генә яшәргә телим. Миңа аларның проблемалары кирәк түгел. Мин аларның проблемалары белән кызыксынмыйм. Мин инде күптән Сәфәрова түгел, мин инде әллә кайчан синең фамилияңдә. Мин – Сәлимә Мостафина! Мин мәрхүм майор Сәфәровның тол калган хатыны түгел.

– Сәлимәкәем, җаным, тыңла әле, – диде Мостаңгир, сабыр гына.

Сәлимә аны тыңлап бетермәде:

– Мин һаман мәет белән аерылгысызмыни соң? – диде ачынып.

– Сәлимә! – диде Мостаңгир, кырыс тавыш белән. – Мәрхүмнең рухын рәнҗетмә!

– Нишлим соң? Минем вазифама керәмени соң ул еллар буе мәрхүмнең тол калган хатыны булып уйнау? Чечнядан атна саен телеграмма, атна саен хат, атна саен кунак. Кире җибәрә барачакмын барысын да.

– Тиле! – диде ире. – Чеченнарга кунакларны кайтару – ул аларның туганнарын үтерү белән бер. Мәктәпләрдән килгән хатларга мин җавап бирәм, сине катыштырмыйм.

– Батырларча үлгән каһарманның тол хатыны, мин аларга булмаган вакыйгалар турында сөйләргә тиеш икән, ничек итеп без бер-беребезне сөйгәнбез, ничек итеп танышканбыз. Мин хәзер үз ялганыма үзем ышана башладым. Син, ичмасам, әйтер идең аларга: юк, ул Сәфәрова түгел, ул аның толы түгел, алар аерылышкан, алар бер-берсен яратмаган, дияр идең.

– Юк, мин алай әйтә алмыйм.

– Куркак!

– Куркак шул! – диде Мостаңгир. – Ничек итеп мин сабый балага: Сәлимә апаң Хамис абыеңны яратмады, ул аның хатыны түгел, дип әйтим? Юк, Сәлимә, мин андый вазифаны үз өстемә ала алмыйм.

– Мостаңгир, әле күптән түгел генә син Хамистән дә, барысыннан да мине көнли идең, хәзер Хамис эшен башлап үзең йөрисең, хәтта дәвам итәсең. Кая китте синең Мостаңгирлыгың?

– Сәлимәкәем, мин сине сөям, мин сине тагын да ныграк сөям. Мин синең киребеткәнлегеңне дә сөям.

Ул Сәлимәне кочаклады, тегесе, яклау тапкандай, аңа сыенды.

– Җаным! – диде Мостаңгир. – Син ничек теге чеченнарның хисен аяк астына салып таптыйсың? Алар нәселенә Хамиснең исемен биргән. Хамис хәзер чечен халкының милли каһарманы сурәтендә. Алар җәй көне монда килеп, Хамис торган урыннарны, Хамис туган якларны карап, кинога алып, аның турында фильмнар төшереп, китаплар язачак. Син: мин аның хатыны түгел, дип бер кырда утырырсыңмы? Ярый, тора-бара аңлатырбыз. Тол калган хатынның кияүгә чыгарга хакы бармы? Бар! Алар аңлар, алар гафу итәр. Ләкин син Хамис Сәфәров язмышыннан беркая да китә алачак түгел. Син никадәр генә Сәфәров Хамистән качарга теләдең, ләкин Хамис Сәфәров сине эзләп табачак, һәм ул гомерең буе синең белән янәшә барачак.

– Син шуңа ияреп барырга ризамы?

– Риза!

– Мин сине яратам, Мостаңгир. Мин сине сөямен, Мостаңгир.

– Син ул сүзне әйтергә тиеш түгел идең. Тел яшерү бозылдымыни? – диде ире.

– Тел яшерү – табу бозылды, чөнки алда бала табу көтелә, – диде хатыны.

– Булмас ла! Валлаһимы?

– Валлаһи! Өч айлык!

– Мин сине яратам, Сәлимә, мин сине сөямен, Сәлимә.

– Без аңа нинди исем сайларбыз икән ул?


– Хамис!

– Хамис? – дип сорады Сәлимә.

– Хамис! – диде Мостаңгир.

***Редакциядән:***

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез!*



Айрат
Суфиянов

# ӨЗЕЛМӘСМЕ МИЛЛИ ШӘҖӘРӘ?

## Үс, күтәрел, исән халык!

Йолкып атсам, чәнчи, диеп,
Үткәннең һәр гөлчәчәген,
Бөтенлектән мәхрүм калып,
Корыр кебек киләчәгем.

Үткәннәрнең орлыгында, –
Туфрагында, зурлыгында, –
Күрәчәгем, күкләр язган.
...Батмас өчен хурлык татып,
Аныклансын хаклык, ялган...

...Үзебезне акларгамы –
Үткән чорны гаепләдек?
Гарасатын кузгаттык та
Аста калып гарипләндек.

Бүгенгегә – бүгенге юл,
Фикер-кояш кирәген дә
Аңла, дигән кисәтүле
Мәсләк яши йөрәгемдә.

...Карашыңда янсын чыраг!
Күтәрел син, исән халык,
Чордан чорга югарырак!
Син – баһадир, мәгърур Алып.
Торсын дөнья, таңнар калып.

Хак очкыны бөек җанны,
Юк, кысмасын, әзер калып.
Дошман аска тартканда да,
Үткәннәрдән гыйбрәт алып,
Үс, күтәрел, исән халык!

Үс, күтәрел, исән халык!..

Айрат СУФИЯНОВ (1958) – *шагыйрь; «Кылычлы җил» исемле китап авторы. Чаллыда яши.*

## Ул – очачак

Әйтте беркөн, татар дәверенең
Шанлы катламнарын ачты да:
«Солтан булмасам да, олтан булып,
Үз җиремдә тынсыз куырылып
Ятасым юк аяк астында».

Кем очарга туган, яраклашып,
Шуышудан саклар үз-үзен.
Тойган хәлдә халкы бәһаләрен,
Зурлык йөрткән күңел җәүһәрләре
Бизәр яшәвенең нигезен.

Кем очарга туган, ул – очачак –
Күк киңлеге аңа кадерле.
Шикләнмим дә, ул дөреслек эзләр,
Яңа буын офыкларын күзләр,
Атып төшергәнгә кадәрле...

## Туган телем

Яшәртә дә, мине яшәтә дә
Сабан туе – халкым бәйрәме.
Саф татарча дәшсәм, тау өстендә
Тамырлана гөлләр бәйләме.

Саф татарча шаулый урманнар да,
Саф татарча чыңлый чишмәләр.
Саф татарча җырлап тау башыннан
Хур кызлары суга төшәләр.

Саф татарча сайрый тургайлар да,
Таңны ялгап зәңгәр кичләргә.
Бердәм булса, милләт таркалмаса,
Үз астында үзе тапталмаса,
Көчем җитәр ут-су кичәргә.
Чит-ятларга үтенечем төшеп,
Җаным-тәнем, бар барлыгым өшеп
Уралмам да үкенечләргә.

Татар булып җиргә туган өчен,
Татар моңын табам кайдан да.
Гаҗәпләнмәм, саф татарча аһәң
Ишетелә калса айдан да.

Үз халкымның киләчәген уйлап,
Бәгырькәем меңгә теленгән.
Дөньялыктан, Раббым, аерсаң да,
Аермачы туган телемнән.
Мәңге татлы, мәңге тансык булган,
Кеше иткән соңгы телемнән.

Егам, диеп, сөлге салучылар
Табылмасын халкым биленә...
Милләт багы шаулап чәчәк атсын,
Үткәндәге бөеклеге кайтсын –

Татар телле татар иленә!

## Җирсеп яшим

Җирсеп яшим мин, каңгырып,
Сагышымны куандырып,
Чит-ят җирдә меңнәр кебек.
Киенгән дә тоташ актан,
Хәтер булып балачактан
Урап кайткан көннәр үбеп
Туймый һаман чәчләремне.
Шуңа күңел – чәчәгемме,
Кабатлыйсың, имнәр сибеп:
– Туган якның кары кайнар,
Ташы да, – дип, – мендәр кебек.
Кушылалар, гөр-гөр килеп,
Күгәрченнәр, мин кайчандыр
Көлә-көлә җимнәр сипкән.
Инде язмыш күзләремә
Һич уңмаслык сагыш чиккән.
Меңнәр алар, тамырларын
Җирсеп читтә газап чиккән.
Үз-үземне өнәмичә
Чит-ят күреп, гүя читтән
Карап торам соңгы чиктән.
Үткәннәрем күптән үткән,
Кайтмас инде урап бүтән.
...Авып төште күкрәгемә
Әтәч кунган иске читән...

## Вакыт кына җиңүчедер

**1**

Савап түгел... чарасыздан
Ләгънәт юллап, чорны бозган
Карагруһлар оясына,
Килгәнемне хәбәр иттем
Җәбер-золым дөньясына.
Шоңкар булды гадел сүзем
Кешелеклелек кыясында.
Сүндермәдем йөрәгемнең
Газамәтле кояшын да.
Кулларыма алып сөйдем
Ак күгәрчен балаларын.
Ата-бабам каны сеңгән,
Туфрагына шаны иңгән
Иксез-чиксез далаларның,
Күккә багып, ыңгырашып
Җимерелгән калаларның
Тәмугында хәтер булып,
Әрнүле җыр яза-яза,
Мең уяндым... Бармы җирдә
Моннан авыр, олуг җәза?
Йа Ходаем, корбаннарга
Укыгандыр кем җеназа?
Үз халкымның үткәннәрен,
Бүгенгесен, киләчәген,
Тоташтырып, эзләп йөрдем
Иттифакның гөлчәчәген.

**2**

...Ә чор мине үги күреп
Камчылады, ни үчедер?
Әйтмәде ул сәбәбен дә,
Яратмады ни өчендер?
Исемемне оныттымы?
Отылдыммы? Чор оттымы?

Чор да гүргә иңүчедер...
Иләк аша үткәрүче,
Җир тарихын күтәрүче
Вакыт кына җиңүчедер...

## Туган туфрак дәшә

Таш йортларга сыймый сытылып та,
Киңлекләргә күпме омтылып та,
Бәхет кошын тапмыйм күптәннән.
Өннәремә түгел, төшләремә
Кендек каным чәчри үткәннән...

Әйтерсең лә язмыш, сыный-сыный,
Сындырырга теләп кыйный-кыйный,
Камчы аша мине уздырган.
Баш очымда җиде юл чатының
Кара тузаннарын туздырган.

Туздырган да газап, үкенечнең
Әрнүендә кабат тудырган.
Сагынуның сары касәсен дә
Мөлдерәмә, күздәй тутырган.

Авыл киләчәген кайгыртудан
Нинди файда, чәчәп шәһәрдә?
Урыслашкан оныкларда безнең
Өзелмәсме милли шәҗәрә?

Мөмкин түгел канны яңарту да,
Аерылып туган җирләрдән.
...Кыш көне дә читтә җан теләнә
Мәтрүшкәләр исен – җилләрдән.

Мөмкин түгел, иңдә канат тоеп,
Үсенепләр ашу күкләргә.
...Тамырлылар һаман басуларда
Җиргә батып, җирне күтәрә.

Ил алдында алар хөрмәтлеме?
...Хыяллары ауный тупсада.
Без – шәһәрдә... Качып котылдыкмы?
Туган туфрак дәшә:
«Кайтачаксыз… үлгәч булса да...»

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез!*

Айгөл
Әхмәтгалиева

# АК ЧИТЕК

БӘЯН

Нургаян тәмәке пыскытырга өйрәнде. Югыйсә, башлангычта укыганда ук, күрше малайлары белән тәмәке тартабыз дип, әздән генә лапасларын яндырмый калгач, әнкәсеннән гомерлек сабак алган иде. Училищеда тракторчылыкка укыганда да, армиядә чагында да тәмәке, аракы ишене авызына якын китермәде. Ә менә монда, больницада, өйрәнде. Беркөнне, ирләр бәдрәфенә кергәч, аркасын стенага, беләкләрен култык таякларына сөяп, комсызланып тәмәке суырган абзыйга карап-карап торды да тартырга сорады.

Чәче кырып алынган, шуңа күрә колаклары шактый зур, мәзәк булып күренгән, кырык биш яшьләр тирәсендәге ир белән артык җәелеп сөйләшкәннәре булмаса да, Нургаян аның Гриша исемле икәнен дә, очучы булганлыгын да, өйрәнүләр вакытында бик каты имгәнгәнен дә белә. Григорий Петрович та шактый айлар ятакка кадакланып яткан иде, әкренләп аякка басып килә менә. Ул Нургаянга шиклерәк караш ташлады да күлмәк изүеннән тәмәке, шырпы алып, кулына сонды.

– Ничек, алга китеш бармы?

Нургаян, тәмәкесен, ут элдермәгән килеш, ирен читенә кыстырды, әкрен генә баш чайкады.

– Функция диделәрме, арка миеннән шуны алганнар ие бит. Анысы нидер, мин рәтләп аңламадым да... Файдасы тия торган нәрсәдер, дисәм, юк, бер үзгәреш тә булмады...

Гриша да, нәкъ Нургаянның хәрәкәтен кабатлап, баш чайкады:

– Пункция. Миннән дә алабыз дигәннәр иде, риза булмадым. Син зря, канишны... Ярар инде, хәерле булсын берүк.

– Врач әйткәч, ризалаштык инде, без беләбезме, алармы. – Нургаян гасабиланып тәмәке кабызды. Йотлыгып, тәмләп бер-ике суыргач, ул да стенага сөялде. – Син ничек, әле чыгарабыз димиләрме?

– Бер-ике атнадан өйгә! Туйдым, тую белән туйдым, брат! – Гришаның кырыс йөзенә, сынык кашларына, бераз бөкрерәк борынына, елтыр башына тиклем өмет нуры йөгерде. – Һавага ук булмаса да, өйгә, чёрт возьми, өйгә!

*Ахыры. Башы узган санда.*

Онык туган бит минем, оныk! Күр, нинди бүләк белән каршылыйлар! – Кайчандыр болытлардан да югарырак очкан, биеклекләрне иярләгән, аннан лапылдап җиргә төшәргә мәҗбүр булган алыптай ирнең йөзе сабыйларча бер иләслек белән балкый иде. Ул, әле тартып та бетермәгән тәмәкесен ташлап, тагын яңасын кабызды. Алкаланып чыккан төтенгә карап-карап торды да, уртадагы алтын тешен җемелдәтеп: – Хәзер тётя Нина килеп керәчәк, дөньяны сасытасыз. Ну ничего, вредный карчык түгел ул... Син новичок кебек, моның белән дуслык юкмы әллә? – диде, тәмәкесен тартмыйча, баядан бирле ике бармак арасында тоткан Нургаянга игътибар итеп.

Сөйләшергә сусаган идеме, гадәте шундыймы, өйгә кайту сөенеченнән теле телгә йокмый идеме – Гриша бер сүздән икенчесенә сикерде.

– Тарткан юк, – диде Нургаян, турысын әйтеп. – Бүген әллә нәрсә, йөрәк янганнан димме...

– Да, егет, аңлыйм. – Гриша, башын читкә борып, уртын чәйнәп торды. – Сиңа инде бөтен больница шакката, молодец, түзәсең.

– Кеше шаккатырыр өчен ятмыйм мин монда. – Чыннан да, Нургаянга тирә-яктагы кешеләр, аларның язмышлары, ни уйлаулары бөтенләй диярлек әһәмиятсез иде. Зәйтүнәсеннән дә мөһим, аннан да кирәкле, аннан да якын беркем, бернәрсә юк иде – монда ярты ел яту дәверендә Нургаян бүтәннәр белән артык аралашмады да. Утыз тештән чыкканның утыз илгә таралуын белми түгел; кеше хәлен, үз башына төшмәсә, барыбер һичкем аңламый, артык сүзләр кемгә, нигә кирәк? Үзеннән сорашырга маташучылардан тизрәк ераклашу ягын карады, башка авыруларга сорау биреп тинтерәтмәде. Аның бу больницадагы дөньясы Зәйтүнә яткан палата белән чикләнгән кебек иде.

Ә менә Григорий Петрович, күрәсең, андый түгел. Барысын да күреп-белеп, кызыксынып тора бугай.

– Сезне дә документлар белән озак йөрттеләрме? – диде ул, култык таягын шыкылдатып, бәдрәф кабинасы янындагы тәрәзә төбенә барып утыргач.

Бу тар, сасы урында иркенләп сөйләшеп торырга аз гына да теләге юк иде, шулай да әлеге сорауны ишеткәч, Нургаян әңгәмәдәшенә гаҗәпләнеп карады.

– Нинди документлар?

– Хатының колхоз эшендә имгәнгән, диделәр түгелме?

– Шулай инде. Эштә. – Нургаян чигәсен кашып куйды.

– Акт төзегәннәрдер бит? – Гриша, каршысында торган ирнең аптыраулы йөзеннән барысын да аңлаган иде, шулай да сорашуын дәвам итте. – Соң, эштә булгач, производственная травма була бит инде. Колхоз профкомы социаль страхование, пособие түләү турында кайгырткандыр бит? Акт төзегәнсездер?

– Юк, алай бернинди кәгазь-мазар тутырмадык. Аның ишене каян белик?!

– Ничек инде? Әйтүче дә булмадымыни? – Гриша аты-юлы белән сүгенеп куйды. – Колхозыгызда, ярар, койрыкларын бот арасына кыстырганнардыр, врачлар да әйтмәдемени?

– Юк инде. Бездә документ кайгысы булдымыни? Кирәге дә юк. – Нургаян, сүзен раслап, кулын селтәде.

– Дерёвня! – Бу сүзне Гриша һич кенә дә мыскыллап әйтмәде, киресенчә, Нургаянны кызганып кабатлады. – Дерёвня! Эш вакытында имгәнгәч, колхоз җитәкчеләре, профком сезнең арттан кайгыртып үзе йөгерергә тиеш иде бит. Һич югы, ялынып булса да... Ник, закон дигәнне бөтенләй белмисеңмени?

– Авылның законы үзе белән инде аның, Григорий Петрович. Авызыңда кара кан булса да, кеше алдында төкермә, диләр бездә. Шуның белән шул.

– Алай булмый бит инде, егет. Уң яңагыңа сукканга сул яңагыңны куеп торырга өйрәнмә! Бик тиз сытып китәрләр. Сөйлә әле, нәрсә, ничек булган иде анда?

Нургаян кулындагы төпчеген эчтәге чиләккә томырды да Зәйтүнә белән килеп чыккан хәлне теләр-теләмәс кенә шәрехләп бирде. Аны ияген уа-уа тыңлап торган Гриша янә сүгенеп куйды.

– Гаепле кешегә суд булдымы соң ичмаса? Шофёрга, дим?

– Шофёрга? – Нургаян, шул вакыйгадан соң күзгә-башка бер генә дә чалынмаган Ренатны уйлап, аптырап китте. – Юк инде, ниткән суд...

– Ну и ну! Ул да килмәде, эндәшмәде дисәң, шушыннан пике ясап төшеп китәм хәзер, – диде Гриша, бу юлы тавышында ярылып яткан ачу белән, артындагы тәрәзәгә ымлап.

– Килмәде. Эндәшмәде. Хәтта... гафу да үтенгәне булмады. – Бу хакта менә хәзер, шушы минутта гына исенә алган Нургаян инде үзе дә Гриша кебек үк гаҗәпкә калган иде. – Кая, тагын берне бир әле, Григорий Петрович.

Әңгәмәдәше, аңа дәшми-нитми генә, тәмәке сузды. Ике ир, берсе тәрәзә төбенә утырган, икенчесе стенага сөялгән килеш, телсез калгандай, сөйләшми генә төтенгә күмелделәр.

– Ох, боларны! – Ишектән чиләк, швабра күтәреп кергән кечкенә буйлы карчык аларга йодрык болгады. – Дөньяны сасыткансыз! Тәмәкегез тәмәке түгел! Вот махорка булса! Барыгыз, марш палатагызга!

– Тётя Нина, красавица моя, мин кайтып киткәч, кемне ачуланырсың икән син, ә? – Гриша башта горкылдап ютәлләде, аннан шаулап көлеп җибәрде. – Есть, товарищ капитан!

– Минем капитанлыгым... – Тётя Нина аңа ачусыз гына чүпрәк белән селтәнде. – Менә сине кем әйтер капитан авиации дип? Бала-чага...

Ишеккә юнәлгән егетләрне санитарканың аркылы сузылган швабрасы туктатты.

– Стоп! Гриша, тәмәке калдыр. Мин дә сез бөркетләр кебек кара яндырыйм әле бер. – Карчык бездәй карашы белән башта Гришага, аннан Нургаянга кадалып торды. – Бу егетне бозма, кирәкмәгән гадәткә өйрәнмәсен. Ул синең кебек түгел. Бүтәннәр кебек тә түгел.

Бу араларда Нургаянның җаны үзенә урын таба алмый үрсәләнә. Ярты ел, әйтергә дә ансат түгел, ярты ел аларның бу стеналар арасына кереп бикләнүенә! Көзне, кышны уздырдылар. Инде менә язга кереп барышлары. Мендәргә сөялеп утыра башласа да, Зәйтүнәнең әле дә булса аякларында бер хәрәкәт тә сизелми. Алай гына да түгел, алар күз алдында кибеп-сулып бара шикелле. Даруларның да, көн саен ясаган массажларның да тәэсире сизелми. Көне-көне белән ирнең өмет канатлары сынып та киткәндәй, әле ярый Зәйтүнәсе сер бирми. Үз хәлен онытып, кояш кебек балкып елмая да, Нургаянның кулына кагылып: «Әллә кайчан үлгән идем инде мин. Әле дә син бар, Нургаян», – ди, шул сүзе белән иргә Алып көчләре өстәп.

Нургаян ары киткән Гришага кул изәде. Култык таяклары таш идәнгә түгел, йөрәккә бәрелеп шыкылдый диярсең: шык-шык, шак-шок... Бу шыкылдауда өмет авазы бар. Кеше атлый, үз аягы белән атлый! Таянып булса да атлый. Шул рәвешле ул, әнә, балкон янына барып баса, бикле тәрәзә аша булса да, кышкы матурлыкка сокланып тора ала. Туйса, кире борыла. Теләсә, палатага керә, теләмәсә, коридорның бер башыннан икенчесенә сәяхәт итә. Үз аягы белән атлап, врач кабинетына бара, тыңлыйлармы-юкмы, анысына игътибар итмичә, зарын түгә. Йә булмаса рәхмәт әйтә. Яки бу җирем, теге җирем авырта, дип,

нидер таләп итә. Зары-таләбе үтәләме – анысы мөһим түгел, иң мөһиме – ул йөри, әкрен генә булса да, үзе теләгәнчә йөри! Ә менә Зәйтүнәсенә нишләргә?..

Нургаянның өзелеп-өзелеп тагын тәмәке тартасы килде. Бу юлы йотлыгып, тётя Нина әйткәндәй, кара яндырып, комсызланып тартасы килде.

Ир, палатага керергә ашыкмыйча, берчә ишек тоткасына тотынып торды. Рәзифәне, муенчагын салдырмасалар да, өенә кайтарып җибәрделәр. Любаны апасы, коляскага утыртып, еракка, Төмән шәһәре тирәсендә яңа гына төзелгән Тараскүл дигән тернәкләндерү үзәгенә алып китте. Шулай, биредә беркем дә гомерлеккә тукталып калмый, искеләр китә, яңалар килә. Зәйтүнә янындагылар да әллә ничә алышынды инде, ә ул һаман ята бирә. Кайчанга кадәр? Эх, шул сораугa өздереп кенә, өметле бер җавап бирсәләр...

Нургаян эчкә узды. Зәйтүнәнең караватын күптәннән тәрәзә буена күчергән иде, хатыны карашын яз кояшы баккан зәңгәр күккә төбәгән дә тын алырга да курыккандай ята. Калын чәче тузгып мендәргә таралган.

– Чәчеңне әллә хәзер юыйкмы, әнисе, кичкә калдырып, теге юлы да юеш чәч белән йокладың, – диде Нургаян, тумбочканы ачып, пыяла савыттагы шампуньны барлагач. Әйтерсең, әле яңа гына ишекнең теге ягында бик озаклап шушы хакта гына уйланган да, катгый карарга килеп, палатага кергән.

Зәйтүнә эндәшмәде. Үз уйларына чумган идеме, ишетмәдеме, күзен тәрәзәдән алмады. Тышта яз. Агачларга сизелерлек булып яшел сут таралгандыр. Тал песиләре бөрегә тулышып ятадыр. Көндезләрен, кояшның елмаюы алдында бил биреп, гөрләвеккә әверелгән кар сулары йөгерешәдер... Йөгерәдер шул, йөгерәдер... Җырлый-җырлый йөгерәдер. Йөгерәдер... Бала чыгарам, дип, ашкына-ашкына, кошлар кайтадыр. И-и, әнисенең йорты өстеннән тагын кыр казлары, торналар тезелеп үтәр инде. Бала чыгарам, дип ашкынып кайтулары булыр. Ишегалдында хуҗа булып йөргән күгәрченнәр, аларны күреп, әллә көнләшүдән, әллә сөенүдән, үзгә бер гөрләшү белән гөрләшергә тотыныр... Әле Зәйтүнә кияүгә киткәнче, тавыкларга сипкән бодайга әверепме, аларның лапас тирәсенә бер күгәрчен ияләшкән иде. Гарип иде ул. Тумыштан шулай булганмы, бер явызның кылыгымы – сыңар аягында гына титаклый иде. Икенче аягы, канатларын аралап, өскә үк кайтарылып чыккан да һавага карап тора. Әй шул күгәрченнең үҗәтлеге! Бер тәпие белән койма өстенә дә килеп утыра, лапас кыегына да кунаклый. Яшәргә, ничек тә яшәргә тырыша иде, бичара. Хәзер кайларда, исәнме икән ул?.. Бик кызгана иде аны Зәйтүнә. Бервакыт бакча казышырга килгән Нургаянга да күрсәткән иде. Егет икенче көнне үк кечкенә җимлек ясап китерде. «Тавыктан бодай калырмы, дип тилмермәсен, үз өе булсын», – дип шаяртты, җимлекне бакча коймасы янындагы агачка элеп куйгач. Кыз шунда ипи валчыгы да чыгарып сибә иде, Сабантуйга кыздырырга дип саклап кына торган ярты табак көнбагыш та күгәрчен сыена әйләнде.

Ә менә хәзер Зәйтүнә үзе яралы күгәрчен хәлендә. Кошчыкның, берәү генә булса да, йөрерлек, әйе-әйе, йөрерлек аягы бар иде! Аяккынамы, канатлары бар иде аның, канатлары! Зәйтүнәнең... Канаты юк, дисә, гөнаһ булыр. Нургаяны янәшәдә бит, ул – канат та, хатынның ярты җаны да.

– Чәч дисеңме? – Зәйтүнә иренә борылды. Моңсу елмайды. – Кис, дим, бит, Нургаян, бу кадәр авыр толымнарны юу – мең мәшәкать.

– Мин юам бит аларны, синмени? Бөртегенә дә тимибез! Шул толымнарың белән гашыйк иттең дә, хәзер кис, имеш...

Нургаян хатынына шаярып кына бармак янады.

– Мин бәләкәй чакта әнкәйнең дә толымнары озын иде, – диде ул,

Зәйтүнәнең чәчен юып, сөлге белән яхшылап корыта-корыта. – Беркөнне карасам, җилкәсеннән генә калдырып кисеп ташлаган! Әй үпкәләдем шунда әнкәйгә, әй ачуым килде... Мәктәпкә кыска чәчле укытучы килсә, шуның дәресендә утыруларга тиклем яратмый торган идем... Синең бит, Зәйтүнәкәем, кисәргә кул күтәрелә торган чәчмени бу?! Әзрәк кипсә, агач тарак белән тарыйбыз аны хәзер...

– Нургаян... – Зәйтүнәнең күзләрендә сагаю чалынды. – Бая йөзең качкан иде. Берәр нәрсә булмагандыр бит?

Һай, бу хатын-кыз! Җиде кат җир астыннан елан шуышып үткәнен дә сизеп алыр!

Палатаның шыксыз почмакларында хатынының җавап көтеп төбәлгән карашыннан качар урын юк иде.

– Булуын булмады... Теге лётчик турында әйткән идем бит, аягына баскан, дип... Шуның белән сөйләшеп тордым. «Эш вакытында имгәнгәч, документлар тутырырга тиеш идегез, колхоз кайгыртырга тиеш иде», ди. Ренатны да искә төшерде. Суд булдымы, ди... Шуларны исәпләп уйга төшкән идем. Без соң, берсенә бер сүз кузгалтмадык бит...

– Кузгалта күрмә, Нургаян. – Гүя ире менә шушы минутта ук кемнедер судка бирергә җыена – Зәйтүнә, коты очып, баш чайкады. – Үзем гаепле, шул кабельне алып куям дип, иелмәгән булсамчы... Ятсын иде, тапталсын иде – бетмәс иде әле... Колхоз дип тә авыз ача күрмә. Гомер булса, шул авылда, шул кешеләр белән яшисе. Ренатны да судка бирүдән ни мәгънә – аннан аякка бассаммы? Ашлык машинасын минем өскә юри аударган кеше түгел. Хатыны бар, баласы бар, берүк кеше рәнҗеше ала күрмик. Кирәкми. Тыныч кына яшәсеннәр.

– Тыныч кына? – Нургаян бу сүзләрне хатынына түгел, үзалдына әйтте. – Тыныч кына яшәп ята шул. Килеп хәл сораганы да булмады. Күңел хакы өчен генә дә. Колхоз җитәкчеләре турында әйтәсе дә юк.

– Үзләре беләдер.

Ир дә, хатын да байтак кына сүзсез тордылар. Тук чырайлы җитәкчеләрнең безнең илдәге законнарны уңнан да, сулдан да урап үтә белүләре икесенә дә билгеле: нәрсәдер дәгъвалап йөрүдән ни файда? Аларга тавыш-гауга да, кемнеңдер баш иеп килүе дә, гафу үтенүе дә кирәкми иде.

– Син янымда. – Зәйтүнәнең акбур төсенә кергән бармаклары иренең кул аркасына йомшак кына кагылды. – Миңа бүтәннәрнең кызгануы кирәкми.

– Кызганыч! Бик кызганыч. Без кулдан килгәннең барысын да эшләдек. – Клара Денисовна күзлек өстеннән без кебек кадалган карашын Нургаянның маңгаеннан алмады. Ул ни өчендер ирнең күзләренә түгел, аның маңгаена текәлгән иде, әйтерсең, шунда язылган язмыш китабын бите-бите белән укырга маташуы. – Тугыз ай дәваладык, инде моннан да артык биредә ятуның мәгънәсен күрмим. Хатыныгызны өйгә алып китә аласыз. Кәгазьләр артыннан әллә кая йөрисе булмас, барысын да моннан әзерләп җибәрәбез.

– Нинди... кәгазьләр? – Нургаянның күзләре үзенең күлмәк төймәсенә беректе.

– Хатыныгызга беренче төркем инвалидлык бирелә. Сезгә барысын да аңлатырлар, авылыгыз фельдшерына да күрсәтмәләр җибәрелер, анысы өчен борчылмагыз... Коляскага гариза язарсыз, үрнәген бирерләр.

– Сез бит... Таякка таянып булса да йөрер, дидегез... – Нургаян бу минутта чарасызлыкның үзе иде.

– Увы... Хатыныгыз беркайчан да аягына баса алмаячак. Мин аңа да, сезгә дә сабырлык кына тели алам...

Тышта яз. Май аеның, ап-ак чәчкәгә күмелеп, яшәү җыры турында аваз салган чагы. Яшәү җыры! Тик нишләп шулкадәр моңлы, шулкадәр сагышлы, шулкадәр тетрәндергеч, үзәк өзгеч соң ул? Яз бит, дөньяның яшь, саф, матур, күкрәп торган мәле бит! Ә шомырт чәчәгенең ап-ак таҗларын рәхимсез усал җилләр өзгәли. Тырнакларыңны учларыңа батыра-батыра булса да шул җилләргә каршы торырлык көч табарга кирәк. Кирәк!

***

Сабый баланы күтәргәндәй, Зәйтүнәне кулына күтәреп, баскычтан менгәндә, Нургаянның борын төбендә генә ишек ачылып китте, уч төбе кадәр генә ыштан кигән Наил атылып та чыкты, үкчәсен ялтыратып, шунда ук кире томырылды. Малай әтисе белән әнисен танырга өлгермәдеме, әллә каршысында кисәк пәйда булудан куркып киттеме, аның:

– Әбей, әбей! – дип чәрелдәгәне өйалдын яңгыратты.

Саимә кискән токмачын куна тактасына таратып маташа иде, оныгының чатыр чабып керүен үзенчә аңлап:

– Нәрсә, җитешмәдеңме? Астыңа пес иттеңме, улыкаем? – дип, онлы кулын алъяпкычына сөртә-сөртә, аның каршысына атлады.

Наилнең:

– Кеселәл, кеселәл! – дип сөрән салуына ияреп, бусагада хатынын күтәргән Нургаян күренде.

– Әнкәй, өйгә килен төшерәм, каршы ал! – дип шаяртты ул, үзен муеныннан кочкан Зәйтүнәне әкрен генә әйләндереп. – Улым, нәрсә, әллә безне онытып та куйдыңмы син? – диде әбисенең итәк артына поскан Наилгә күз кысып.

– Ай Алла, ай Алла, – дип бертуктаусыз кабатлады каушап төшкән Саимә, исәнләшергә дә онытып, кая барып тотынырга да белмичә. – И-и, мин, исәр, ирәвәнләп торам, башкаем әйләнеп киткән булды бит кисәк... Әйдүк, әйдүк, балалар, түрдә урын да әзер... И-и, киленкәем, кайттың бит, Аллага шөкер, кайттың! – дип, Зәйтүнәнең кулын кысты, беләген сыпырды, җәймәгә төренгән аякларын сөеп-сөеп алды. – Аллага мең шөкер, өебезгә кайттың! – дип тәкрарлады. Караватның чыбылдыгын күтәреп, чәчәкле зур ястыкны ары тартты, бире тартты да: – Йомшаграгын салыйм әле, монысы катырак шикелле, – дип сөйләнде, шунда ук кире куйды. – Аллага шөкер, кайттың бит!

Иренең кулларыннан тып итеп сикереп төшеп, улын кочагына ала алмау хәсрәтеннән баядан бирле күз яшен тыялмаган Зәйтүнә, ястыкка сөяп утырткач, ниһаять, телгә килде:

– Шөкер диярлек түгел шул, әнкәй, – диде ул, учы белән йөзен сөртеп. – Менә шушындыйракка калдым бит... Улыкаем, Наилкәем, кил инде, җаныкаем, сөйим үзеңне, тотып булса да карыйм!

– Әниеңне кочакла инде, улым, әниең кайтты бит! – Саимә ятсынып һаман үзе артына поскан малайны кулыннан җитәкләде. – Син кайтуга менә ничек үстем, диген. И-и, көләр инде әниең, минем улым куркак куян икән, дияр...

Нургаян көйләп-чөйләп тормады, улын ике куллап күтәрде дә, башын түшәмгә тигерерлек итеп чөеп-чөеп алгач, битеннән, маңгаеннан үбә-үбә, Зәйтүнәнең кочагына китереп салды. Үзе улының кояшта янарга өлгергән муенын, ялтырап торган шәрә табанын кытыклап, ишеккә юнәлде:

– Әнкәй, Вәсимгә дә кер, дигән идем, чаең булса...

Томырылып килененә карап торган Саимә, яңа исенә килгәндәй, дертләп китте дә кече якка юнәлде:

– Ничекләр булмасын, чәй дә бар, ашым да пешкән, токмач салып кабартып кына алам! Чакыр, берүкләр чакыр, каян кая апкайтып, кешене ишек төбеннән борып җибәрергә...

Зәйтүнә, кочагында ятсынып, шулай да шуып төшәргә ашыкмыйча сәерсенеп яткан улының ялангач аркасын бертуктаусыз сыпырды. Үзенең күзеннән әрнетеп-әрнетеп өзлексез яшь акты. «Улым, улыкаем», дип кабатлады ул, куеныңдагы бу нәни йомгакны кемдер алып китүдән курыккандай, малаен ныграк кочаклап. Юеш иреннәре белән аның ялтыр башын, озын керфек каймаланган күзләрен, күпереп торган кул аркаларын үпте, калтыранган бармакларын көчкә тыңлатып, шәрә тәпиләрне сөйде. Малай әллә аптырап, әллә шомраеп калган иде: үзен кочакларга тулы ирек биреп, тып-тын калды, аваз-өн чыгармады. Әнисе аның саен улын ныграк кочты, аның саен күзеннән мөлдерәп яшь коелды. Йә Хода, бу минутларны чынлап тояр көннәре дә бар икән! Дөньядагы иң хуш ис белән өртелгән нарасыен төшләрендә ничә назлады, ничә иркәләде – өнендәге коточкыч чынбарлык белән очрашканда, бу көннәргә барып җитә алмас кебек иде. Больницаның салкын стеналары, тәнен-җанын тимер кыршау кебек кысып, шуннан инде мәңге ычкындырмас кебек иде. Кеше кулларына калып булса да, кайтты бит, улыкае янына кайтты!

Әнисенең күкрәгенә башын салып яткан малай таныш исне тойдымы, күкрәк сөте исенә төштеме, ни булса да булгандыр – күзләрен шар ачып, уймак иреннәрен бөтереп, аның йөзенә күтәрелеп карады.

– Син сын әнейме?

Әни, димәде улы, кызык итеп, әней, диде.

Зәйтүнә бармагы белән аның кашына кагылды.

– Чын, улым, чын!

– Син минем әнейме?

– Синеке, улым, синеке... – Яшь ана җиһанда иң бәхетле кеше кебек балкып елмайды.

Ул арада өйгә шаулап Нургаян белән Вәсим килеп керде. Өстәл тирәсендә кайнашкан Саимә белән күрешкәч, Вәсим мич аралыгында кулын юып чыкты, гөлдерәвек тавышы белән бөтен өй эчен тутырып, сөйләнә-сөйләнә, урындыкка утырды.

– Мәшәкатьләнәсе түгел иде инде, өйдә дә пешкәндер. Ну шулай да Саимә апаның мич ипиен авыз итәсе килә, малай! Авылда синекенә җиткән юк, Саимә апа, ишетәсеңме? Минем хатын, Венераны әйтәм, ни уңган булса да, мич алдында биеп торса да, болай ук оста пешерә алмый!

Күрше якта һәр сүзне ишетеп яткан Зәйтүнә, улының бармакларын берәм-берәм үбеп назлаган җиреннән, күкрәген калкытып, тирән сулыш алды. Вәсим – Нургаянның бер урамда уйнап үскән, бер сыйныфта укыган җан дусты, туйлары да бер тирәдәрәк булды. «УАЗик»та колхоз рәисен йөртә ул. Нургаяннарны алып кайтырга рәис үзе җибәрде дисә дә, ай-һай, еламаган балага имчәк каптырмыйлар – мин барам дип чәчрәп торгандыр әле. Ачы таңнан кузгалып юлга чыккан, менә, караңгы төшәр-төшмәстә Казаннан алып та кайтты. Аның «минем хатын... мич алдында биеп тора...» дигән сүзләреннән сискәнде Зәйтүнә. Җылы җәймәгә төрелгән аякларын үрелеп сыпырды. Ә ул... башка беркайчан да... Үз аякларына басып, җиңен сызганып, куәс тә баса алмый, каенанасы өйрәткәнчә, унар йомыркага тугланган тәбикмәк пешерәм дип, мич алдында да кайнашмый.

Зәңгәр буяуга буялган, оч-очларына ак бизәк төшерелгән көянтәсен элеп, коега да, ерак чишмәгә дә бармый. Иренең төз аркасы артына басып, аның кебек үк булмаса да, каерылып-каерылып, печән дә чапмый...

Наил әнисе кочагыннан балык шикелле шуып кына төште.

– Тоҗлы, – диде малай, үзенең иренәнә сыланган яшьләрне учы белән сөртеп. Үкчәсен ялтыратып, теге якка йөгерде. – Әней елыыый!

Балалы өйдә бур тормас, ди.

Саимә, өстәл буеннан кыймылдаган Нургаянга, «үзем» дип ымлады да, ишекне ябып, килене янына чыкты. Аның нәзекләнеп калган кулын учына алды.

Зәйтүнә каенанасына борылды. Чәчләренә иртә чал төшкән иде аның. Арттан чөеп бәйләгән яулыгы астыннан көмеш-көмеш булып күренә. Нургаянның күзләре – суйган да каплаган, нәкъ әнисенеке. Икесенеке дә җылы коңгырт. Гәүдәләре дә охшаш, озынча, чандыр. Тик Нургаян, әтисенә охшап, каракучкыл, Саимә исә – ак тәнле, кояшка күренсә дә карала торган түгел, ә дигәнче, тиресе янып-пешеп чыга да кубып та төшә. Шуңа күрә ул басуда эшләсә дә, бакчада казынса да, озын җиңле күлмәктән, башына япкан яулыктан булыр. Ул да ябыгып киткән шикелле. Тугыз ай буе берүзе дөнья көтү өстенә кечкенә бала карау сиздерми калмаган...

– Киленкәем, – диде Саимә, дәшкән уңайга агач урындыкны караватянына китереп, шунда утыргач. Тагын Зәйтүнәнең кулын тотты. – Аллаһының сынавыдыр бу, нишлисең. Бетеренмә дә, кайгырма да. Баш исән булганда, адәм баласы ничек тә чыдый ул. Әле син берүзең түгел. Ирең бар, улыкаең. Мин кырыеңда, кодагый шушында. Һи-и, теттереп яшисең әле!.. Мин дә яшәдем бит. Тәнем авыртмаса да, гомер буе имгәнгән җан белән яшәдем... Нургаяным да шулай яшәде, әйткәне генә юк. Атасы, «Урал» матаена балаларын утыртып, безнең капка төбеннән узганда, бәгырькәйләре өзелгәндер... Утыз биш яшемдә ирекәемне башка хатын тартып алды – җир читенә алып китсә, җиңелрәк буласы иде. Бер авылда, бер урамда бит. Иртән үтсәм дә, парлап күзгә чалыналар, кич үтсәм дә... Бауга меним микән әллә, дигән чакларым булды – җан сызлавына түзәрлегем беткән иде. Авыл җирендә ирсез тормышны әйтмә инде син аны... Улым хакына түздем, уртларымны чәйни-чәйни түздем. Салкын мунчага бикләнеп, бүре урынына улап-улап еладым да, шул чагында әйттем үземә: һи-и, Саимә, минәйтәм, каш ярылып күз чыкмаган, нишләп үзеңне берүзем калдым дип кимсетәсең, дидем. Берүзем булырга, улым бар бит минем. Үсеп җитәр, өйләнер, гөрләтеп килен төшерербез, бәбәйләр үстерербез – нишләп берүзем булыйм, дип юандым. Сыртың сынса да, кешегә сер бирмә, дип яшәдем. Нургаянымны әтисенә каршы бер котыртканым булмады, якын итеп, күргәндә, әткәй, дип тор, ди идем. Яңа хатыныннан туган балаларына да кара коелмадым. Аралашсыннар, бер-берләрен туган итсеннәр, дидем. Өстерүчеләр булды, янәсе, нигә аралаштырасың аларны, малаеңның чыраен да күрсәтмә... Шундыйларга үч итеп, йөземне балкытып яшәдем, киленкәем. Кара, сезнең туйда аталары да түрдә утыргач, Нургаянның сөенүләре... И-и, мине... үземнекен сөйлим, сөйлим – ничекләр телемә тилчә чыкмыйдыр. Синең белән күрешми торгач, киямыл[1] сагынып беткәнмен бит. – Саимә, кеткелдәп, урыныннан торды. – Ашны бу өстәлгә әзерлим, киленкәем, җыйнаулап утырырбыз әле. Сез кайтуга тавык суйдырттым, и аның шулпасының тәмлелеген күрсәң!.. Кодагый да килеп җитәр хәзер. Инде ике урап китте. Йөрәгенә урын тапмый тагын кайтып киткән булганые...

[1] Киямыл – диал., шултиклем, шулхәтле дигән мәгънәдә.

– Рәхмәт, – диде Зәйтүнә, керфек кагып. – Рәхмәт сиңа, әнкәй!

Һәрбарчасына өр-яңадан яши башларга өйрәнү кирәк иде.

Иртәнчәк көтү куарга чыккан хатыннар телендә йөзгә бөтәрләнгән бер яңалык кич җиткәндә меңгә йомарлана. Төчкерсәң – авырый, диләр, кычкырып җырласаң – исерек тамгасы сугарга да күп сорамыйлар, сыерыңның койрыгы гына пычракка батып көтүгә китсен – авылның бер ялкавы исемен ябыштырып куялар. Ныклап карасаң, авыл халкы бертөсле тәгәрмәчтә әйләнә шикелле: бәрәңге утырталар, фәләннәр әллә кайчан алган, дип ярыша-ярыша, бәрәңге алалар; фәләннәр әллә кайчан кыркыган, дип уфтана-уфтана, сарык йоны кыркыйлар; фәләннәр бәйләгән, минеке таралып ята, дип үзләрен сүгә-сүгә, суган бәйлиләр; дөбердәтеп иртә-кич сыер савалар, май язалар, таба төбен сары май белән генә майлап, тәбикмәк пешерәләр; мич тутырып ипи яки көлгә тезеп көлчә салалар, ул ипи-көлчәләрне, мичтән алуга, ястык өстенә кадерләп кенә тезеп яткыралар. Суына төшкән ипине күкрәккә терәп, кибән башын каерып кисәләр дә, өстенә юка гына май ягып, яки писүк сибеп, бала-чагага тоттыралар. Авылның эреле-ваклы малай-кызы, кулларындагы шул ипине дөньядагы иң затлы, иң тәмле ризык күреп, уенга чаба. Тәгәрмәч исә һаман үз күчәрендә әйләнә: хатын-кызлар – Түбән очныкылар да, Югарыныкылар да, кышын-җәен иңбашларына көянтә элеп, Хәлим бабай яки Халик бабай коесыннан су ташый, һәр ике хуҗаның да гомергә капканы келәгә бикләгәне, суга килгәннәрдән түләү сораганы юк, иң мөһиме – чәчеңне-башыңны туздырма, яулык яп та кое капкачын ачык калдырма. Җәй җитүгә, авыл халкы, ике-өч көнгә генә колхоз коллыгыннан котылып, бөтенесе бер булып печәнгә төшә. Колхозның йөк машинасын, тракторын йөрткән шофёрлар ул чорда ханга, солтанга әйләнә: син бит минем сабакташ, дус, өченче буын туган... дип зурлап, алар артыннан зур чират тезелә. Чабылган, өелгән печәнне һәркемнең тизрәк ихатага алып кайтасы, сәндерәгә менгереп урнаштырасы килә. Кичен бер-ике рейстан төп-төз, чибәр генә кыяфәттә урап кайткан шофёрны өченче, дүртенче рейста көтеп торучыларга авыргарак туры килә, алар рәхмәт йөзеннән артыграк сыйлап ташлаганнарны сүгә-сүгә, теш кысып, төн уртасында печән ташыйлар, машинаны күчергән саен йоклап киткән шофёрны уятып изаланалар. Авылда иң кирәкле кеше – рәис тә, мәктәп директоры да, бухгалтер да түгел. Кемдә йөк машинасы һәм кемнең кулында амбар ачкычы – алар Алланың кашка тәкәләре дә инде. Утын алып кайтасымы, саламмы, печәнме, тегермәнгә бодай алып барасымы – идарәдән сиңа бер түгел, йөз рөхсәт кәгазе бирсеннәр, шофёрны игә-чөйгә китерә алмасаң, алып кайтырсың, бар... Колхоз кырында гектар-гектар булып үскән карабодайны, умарталыктан алынган мичкә-мичкә балны, рәешкә генә киярлек кызыл эчле кәлүшләрне әллә син колхоз рәисе өй борынча таратып йөрер дисеңме? Язын да бил бөктегез, җәен-көзен чөгендер, бәрәңге басуында чиләндегез, алны-ялны күрми басу сөрдегез, комбайн-тракторда үпкәгезгә тузан тутырдыгыз, билдән саз ерып, авыр чиләкләр күтәреп, фермада сыер саудыгыз, дип, ләббәйкә, дип, хезмәтегезнең рәхәтен сез дә күрегез, дип, капка төбенә китерер дисеңме? Йөз суы түгеп, мескенләнеп, идарә ишеге төбендә таптанганчы, амбар мөдире белән дуслаш син – менә шунда төп хуҗаның кем икәнен чамаларсың...

Болар барысы да – бер тәгәрмәчтә шул. Тик анда һәркем аерым-аерым әйләнә. Тотып селкесәң, берәүнең дә сандыгы буш түгел. Тик сандык капкачын бик сирәкләр кеше күзенә киереп ача, кайберәүләр хәтта үзләре дә ярыктан гына үрелеп карый. Кайберәүләр өчен – мең йозакка бикләнә ул, ачмаслык, кузгалтмаслык, көн күзенә чыгармаслык итеп.

Нургаян белән Зәйтүнәгә өр-яңадан яши башларга өйрәнү кирәк иде. Ир белән хатын – куш тирәк: төбе дә бер, тамыры да. Аларның икесенә бербөтен булып, сабырлыкны, чыдамлыкны һәм мәхәббәтне юлдаш итеп, ә күз яшьләрен – сандыкка бикләп яшәргә, чит-ятларга күрсәтмәскә кирәк иде.

***

Нургаянның икенче кат шулай өзелеп, эчләре актарылып елавы.

Булгандыр, балачакта да, яшүсмер чагында да, үз әтисенең башка капка төбенә барып туктавын күргән мәлләрдә дә, ул ояда туган балаларның әти дип авыз тутырып дәшүләрен ишеткәннән соң да сатлык күз яшьләре үзенекен итми калмагандыр.

Зәйтүнәсе авыргач, икенче кат өзелеп елавы. Тәүге тапкыр тугыз ай больницада ятканнан соң кайтырга җыенгач, врач кабинетыннан Зәйтүнәгә «беренче төркем инвалид» дип бирелгән катыргыны алып чыккач елады. Аскы катка төшеп, аулак почмакка барып, стенага башын терәп елады. Иңбашларын дерелдәтә-дерелдәтә, өзелеп, бәгыре теленеп, озаклап елады. Япь-яшь, чибәр, чәчкәдәй хатынының гомерлеккә гарип калуын башына сыйдыра алмыйча, сыйдырырга теләмичә елады.

Бүген исә ул дусты Вәсимнең, хатынын култыклап, клубка юнәлүен күреп калды. Белә иде, кичен клубта «Хыянәт» дигән һинд киносы күрсәтеләсен белә иде. Саргайган кәгазьгә кызыл буяу белән эре итеп язылган белдерүне үз күзләре белән укып үтте. Башта игътибар итмәдеме, күңел күзе белән күрмәдеме, числосын дикъкать белән карамады. Карагач, читкә тайпылды. Төп-төгәл бер ел элек, нәкъ шушы көнне ул да Зәйтүнәсе белән кинога җыенган иде. Анда да һинд киносы буласы иде. Арада 365 көн җәйрәп ятуына ышанырлык түгел. Көннәр генә түгел, уч төбенә язылган язмыш җәйрәп ята шул...

Тракторын капка төбендә сүндереп, ишегалдына атлаган ир урамга борылып карады. Кичке эңгер-меңгер төшеп килә, урам башыннан ак күлмәк, ак кепка кигән Вәсимнең хатынын култыклап клубка юл тотуы күренде. Ул да булмады, алар якынлашканда, тагын бер капка келәсе чылтырап күтәрелде, көлешә-көлешә, бер-берсенең култыгына сарылып, яңа өйләнешкән яшь пар килеп чыкты. Шат авазлар кичке урам кочагына сыенды.

Нургаян абзар эченә узды. Ялкау гына күшәп торган сыер йорт хуҗасына иренеп кенә башын борды да, койрыгы белән селтәнеп, чебен-кигәвенгә сыдырды. Түр бүлемдә сарыклар бәэлдәште. Куначага менеп кунаклаган тавыклар, ризасызлык белдереп, нидер бүлешеп алды. Ир аларның берсенә дә игътибар итмәде. Сәндерәгә менә торган баскычка башын терәп, сулыгып-сулыгып елап җибәрде.

Бу аның икенче кат шулай өзелеп елавы иде. Зәйтүнәсен култыклап, инде беркайчан да авыл урамыннан парлап узмаячагын белүдән үзе өчен дә, гөл чәчәге кебек хатыны өчен дә эче актарылып елавы иде. Болай булырга тиеш түгел иде, түгел иде... Яши генә башладылар лабаса! Матур итеп, бер-берсен яратып. Ап-ак хыяллар белән.

Ирнең җанына баз салкыны үрмәләде. Кул астында булса, кабы белән тартып бетерергә әзер иде – котырып-котырып кесәсеннән тәмәке эзләде. Каян булсын, Казаннан кайтканнан бирле тартканы юк. Иртәгә үк тартмалап алып куярга кирәк булыр. Җан ярсуын ничек басарга белмәгәч, йодрыгы белән агач баскычны бәргәләргә тотынды. Кулы канап, авырта башлагач та туктамады, «түз, Зәйтүнә түзә бит. Мондый гына авыртугамы әле...», диде, тиле кеше

кебек үз-үзе белән тарткалашып. Бераздан суына төште. Акылы айныды. Кул аркасын печән белән сөрткәләп, абзардан чыкты.

Бакчада юынып, өйгә керүгә, каршысына йөгереп килгән улын кочаклап алгач, җаны басыла төште. Әнисе мич алдында коймак пешерә, өйгә тәмле булып таба ашы исе таралган иде. Түр якка, китап укып яткан Зәйтүнәсе янына үтеп, аны кочып хәл-әхвәл белешкәч, бөтенләй тынычланды. Ярар, бүтәннәр парлап клубка йөрсен, алар исә үз дөньяларын булдырырлар...

– Иртәгә җыйнаулап балыкка төшәбез, әнисе, сиңа да кармак ясыйм, – дип каш сикертте ул, кулына тотып кергән сөлгене иңбашына ташлап. – Учак ягарбыз, уха пешерербез...

– Әтей, байыкка? – Ни арада колагына чалынган диген, Наил, сикергәләп, әтисенең чалбар балагына ябышты. – Әней дә, әбей дә, мин дә?

– Ерак әбиең белән якын әбиеңне дә ияртәбез, аларсыз ничек инде.

– Каммак бал?

– Һи, кармакның иң олысы сиңа, улым. – Нургаян шаяртып кына улының борын очына чиртте.

– Уйа! Әбей, каммак бил! – Малай мич янына атылды, коймак майлап яткан әбисенең итәгеннән тарткалады. – Каммак бил!

– Китчәле, исәр сөягеңне калкытып йөрмә! – Әбисе яратып кына оныгын битәрләде. – Төн уртасында кармак таптырмасаң...

Зәйтүнә иренә сораулы карады. Шифоньердан алган чиста күлмәкнең төймәләрен барлаган Нургаян янә каш сикертте.

– Күл буена төшәбез. Анда черки инде черкилеккә, ничава, учак ягып куркытабыз аларны. Син тоткан балыкны...

Зәйтүнә аны бүлдерергә ашыкты:

– Китчәле, Нургаян, миннән нинди балыкчы чыксын?

– Ничек чыкмасын? Икәү тотканда, иң олысы кемгә эләгә иде, оныттың дамыни?

– Ул бит... элек...

– Балык элек тә балык, хәзер дә балык инде ул, Зәйтүнәкәем. Синең белән мин дә шулай. Элекке белән бүгенгене кара-каршы куярга маташма...

Нургаянны икенче көнне иртән, эшкә җыенып, капкадан чыкканда, артыннан әнисе дәшеп туктатты.

– Улым, күлгә аппарам дип, Зәйтүнәнең күңелен алгысытып калдыра күрмә берүк. Матаең белән генә урап менәрсез.

– Бәй, җыйнаулап барабыз, әнкәй. Иртәрәк кайтам, көн яктысында барырбыз. Трактор арбасына төйим дә үзегезне...

Саимә аны кул хәрәкәте белән туктатты.

– Җыйнаулап барган чак та булыр, Алла боерса. Бүген икәү генә төшегез. Мин Наилне ияртеп Югары очка чыгып кайтам, кодагыйга кич утырырга. Бәләкәй кармагыңны калдыр, инештә дә балык бетмәс. Кичә баланы котырттың бит...

Күзгә кереп барган табигатьнең күзгә күренмәгән, әмма бәгырьне айкап-айкап алган моңы бар. Җилләр кочагына ашкынган яфраклар биюендәме ул моң, сагыш төсе белән сугарылган басу-кырлардамы, җылы якка китәргә иртә булса да, хушлашып калырга ашыккандай баш очыннан сызылып үткән киек каз юлындамы – анысы билгесез. Әмма ул моң үзәкне өзә. Әле гомерләрнең көзе булмаса да, андый көзләргә ерак, бик ерак тоелса да, җанга билгесез бер моң урала да куя.

Нургаян матаен әкрен генә күлнең читенә үк диярлек китереп туктатты. Әле кайчан гына алар монда Зәйтүнәсе белән җитәкләшеп, йөгерә-йөгерә килерләр

иде, ярты төн утырып, икесенә бер балык каптырсалар да, алтын тапкандай куанырлар, аннан ул балыкны суга кире җибәреп көлешерләр иде...

– Элекке учак урынын эзләп азапланмыйм, Зәйтүнәкәем, тотабыз да шушында ягабыз, ни дисең? Сиңа менә монда җайлырак булыр... – Ир күз карашы белән тирә-юньне айкады да куш каен тирәсенә кулы белән ымлады.

– Миңа шушында утырсам да ярар, күтәреп-төшереп мәшәкатьләнгәнче... – Матай бишегендә төренеп утырган Зәйтүнә, көзге күлнең карасу төсен күреп, сискәнеп китте. Моңарчы шушы урынга җәен дә, көзен дә килә торганнар иде, күлдә йолдызлар коенганы гына күзгә чалынган шул ул чакларда... Ә бүген – бар дөньясын көз төсе, көз моңы урап алган.

Нургаян аның сүзенә карап тормады, бишек капкачын ачып, башта олы мендәрне, юрганны чыгарды, аларны агачлар тирәсенә җайлап урнаштырды. Шуннан соң Зәйтүнәне күтәреп алды, мендәр өстенә утыртып, аякларын җылы юрган белән төреп куйды. Чөнки Казаннан кат-кат кисәтеп кайтардылар: аякларга аз гына да салкын ярамый, диделәр, туңдырмаска куштылар.

– Хәзер ут элдереп җибәрәбез, әнисе. Менә монда ярармы? Көлгә бәрәңге күмәрбез. Балык эләксә, шулпа да мишәйтләмәс...

– Балыгын үзең карарсың инде, Нургаян.

– Икәү тотабыз, әнисе! Юрганың белән алдыма утыртам мин сине, бер дә аптырама...

Ике яралы җанны үзләрен генә калдырырга теләп, балыклар да качышып беткән идеме – икесенә ике кармак салып, бербөтен булып байтак кына утырсалар да, бармак буе балык та эләкмәде.

– Ярар безгә, прастуй авыл баласына, кабыклы бәрәңге дә, – дип шаяртты чебеннән фил ясарга яратмаган Нургаян, алып килгән бәрәңгеләрне бераздан көлгә күмә-күмә.

Ә учак үзе көлгә калмаган иде. Күккә ашардай булып, һаман өскә, югарыга үрләде дә үрләде ул, үз яктысы, җылысы белән янындагы икәүне генә түгел, йөзләрне, меңнәрне җылытырга теләгәндәй, көзге кыраулардан курыкмагыз дип көч бирергә омтылгандай, юлын адашканнарга сукмак күрсәтергә тырышкандай, сүнми-сүрелми янды да янды.

– Нургаян, – диде Зәйтүнә, иренең алдында, аркасын аның күкрәгенә терәп утырган килеш, – сиңа сүзем бар...

– Син сөйләрсең, мин җырлармын, күңелең тулса – еларсың, – дип җырлап җибәрде Нургаян, аны ике куллап кочаклаган килеш, җыр сүзләрен үзенчә үзгәртеп. – Сөйлә, әнисе, таңга кадәр сөйләсәң дә бер сүзем юк.

– Бик кыен булыр бит сиңа, Нургаян... – Зәйтүнә әйтәсе килгәнен ни рәвешле башларга белми иде, шулай да тәвәккәлләде. Башындагы шәлен сүтеп кире бәйләде, үрелгән толымнарын күкрәгенә төшереп куйды. – Күңелең төшкән хатын-кыз булса... Минем бер каршылыгым юк... Үзең аңлыйсыңдыр... Тик мине ташлама инде син, Нургаян. Синсез өч көн дә яши алмам. Наилне дә... ятим итә күрмик инде... Әтисез үсүнең ни икәнен синең белән миннән дә ныграк аңлаган кеше булырмы...

– Зәйтүнәкәем, акыллы дигән авыздан да исәр сүз чыгар икән кайчак... Тузга язмаган нәрсә сөйләп утырасың! Синнән башка беркем дә кирәкми миңа, җүләркәем! Бигрәкләр дә каты яратам бит үзеңне, бер-бер тылсымың бардыр, мөгаен.

– Артык яратканнарның бәхетле булганы бармы соң, Нургаян? И-и, Ромео белән Джульеттаны кызганып, яшь түгә торган идем...

– Кит әле, таптың чагыштырырга... Әллә кайдагы буржуй балаларын искә төшермәсәң... Чын мәхәббәт булса, аны ничек тә сакларга тырышырлар ие әле. Һе, җайлы бит, үлеп котыла, имеш... Урыслар нәрсә ди: безвыходное положение булмый, диме? Ә мин – авыл малае, ишектән кусалар – тәрәзәдән керергә өйрәнгән, тормыш сынауларына баш иеп торырга җыенган кеше юк монда, син мине ул кадәр көчсезгә санама инде, Зәйтүнәкәем...

– Сүзне борырга дигәндә...

– Бормыйм, Зәйтүнәкәем, бормыйм. Килде-китте сүзләр белән башымны гына катырма...

Нургаян башын хатынының иңбашына салды, иреннәрен хатынының колак яфрагына, аннан яшь тамчылары тәгәрәшкән бит очына тигерде. Өтеп алырдай кайнар сулышы белән муен артын кытыклады. Беркадәр вакыт үткәч, инде иреннәре кавышкан мизгелдә, чык тамчысы ялтыраган күз алмасында үз шәүләсен дә күргән Нургаянның:

– Зәйтүнәкәем, бердәнберем... – дип пышылдаганы, учак телләренә сарылып, күкләр катына чөелде.

***

– Нургаян, кыен булса да, син миңа почмак ясап бир инде.

Ире, әлеге сүзләрнең мәгънәсенә төшенмичә:

– Нинди почмак, әнисе? – диде, аптырый төшеп.

– Шушында, карават буенда. Су кертеп булмасмы? Электр плитәсен менә монда, идәнгә көйли аласың. – Зәйтүнә, йөзтүбән яткан килеш, кулы белән тәрәзә астына ишарәләде. – Бу тирәгә шүрлек элсәң, бөтен вак-төякне тезәргә булыр. Табак-савытны, энә-кайчы ишене, үтүкне... Куна тактасы ишене мондарак куярга була.

– Токмач басам, димисеңдер бит? – Нургаян әле һаман хатынының тел төбен аңлап бетермәгән иде.

– Нигә басмаска? Ике кулым бар, Аллага шөкер, токмачын да басармын, ипиен дә.

– Син нәрсә инде, Зәйтүнә, әнкәйнең зарланганы юк, ипиен дә сала, ашны да пешерә. Әби дә көн саен килеп йөри, алар җитешмәсә, үзем эшлим – укам коелмый. – Нургаян, сөйләмә дә дигәндәй, баш чайкады да үзе үк сүзенә ялгады:

– Кирәк дисәң, суын да кертермен, барысын да көйләрмен анысы, сиңа ничек җайлы – шулай урнаштырырбыз, әнисе, – диде, каршы төшеп хатынының кәефен кырмас өчен. – Бөтен эшне бездән тартып алмакчы булам дисең инде.

– Бөтенесен түгел. Эшли алырдаен. – Зәйтүнә шаяртмый иде. – Олы өйгә ни кирәк – кече өйгә шул кирәк, диләр, шушы почмакта кече өй яса инде син, Нургаян, – диде ул, сүзен кире какмаслык үтенү белән.

– Ярар, әнисе, ничек дисәң – шулай булыр!

Шулай булды да. Торба юк, насос юк, тегесе юк, монысы юк димәде Нургаян, бөтен урам халкын шаккатырып, кышын да катмаслык итеп өйгә су кертте. Нәрсә кирәксә – җир тишегеннән булса да эзләп табарга тырышты, юк әйберне үзе ясады, әллә нинди осталарны көнләштерерлек эш кораллары булдырды. Зәйтүнәсе помидор үсентеләре үстерәм дигәч, идәнгә тар-тар бүлемнәр ясап тезде, почта аша әллә ниткән орлыклар кайтартты. Хатынының «чеби карасам...» диюе булды – аның буе җитәрлек урынга сап-сары тавык чебиләре чиелдашкан тартма утыртып куйды.

Зәйтүнәсе исә эш белән кинәнде. Ул күз нурларын текәп үстергән үсентеләр яз башында ук чәчәккә бөреләнде, үз бакчаларына да, күрше-күләнгә өләшергә дә

җитте. Чирәмгә таралганда, сары йомгаклар инде тәмам ап-ак чебешләргә әверелеп йөгереште. Йөзтүбән ятып, керен дә юды Зәйтүнә, үтүкләде, текте, ямады. Каенанасы да, әнисе дә башта «үзем, үзем» дип өзгәләнсәләр дә, әлеге шөгыльләрнең Зәйтүнәгә бер дәва икәнен аңлагач, үзләре үк йөгертеп эш таба башладылар: «Килен, синең кулың угата[2] тәмле, коймак кына туглап ал әле»; «Кызым, син теккәннең җөе җөйгә ятып кына тора – оекбаш табанына ямау салып бирсәң...»

Саимә килененең сабырлыгына аптырый иде. Ник бер зарланып карасын да ник бер кара көеп эндәшсен! Тәне дә, җаны да сызланадыр бит үзенең, ник бер сиздерсен! «Әнкәй» дип өзелеп тора, йөзеннән яктылык китми. Нишлисең, язмыштан узмыш юк, һәрберсенең язмышына шушы сынау язылган – кая да качып котыла алмыйсың. Беркөн бакчада икәү кайнашканда, улына да шулай диде Саимә: «Язмышыңа язылган, – диде. – Зәйтүнәне рәнҗетсәң, мәңге бәхиллегем юк, улым. Аны бәхетсез итеп, синең дә беркайчан бәхетле буласың юк – язганы белән килешеп яшә», – диде катгый итеп, васыять әйткәндәй.

Берәүнең дә гомере мәңгелек түгел. Әле җиргә нык басып йөргәндәй күренсә дә, алдагысын уйлап, Саимәнең дә йөрәге телгәләнә. Әле авырлыкны барысы да бүлешеп күтәрәләр, кодагые да, көн туса, Зәйтүнә янында. Ике карчыкның гомер офыгы әллә ни еракта шәйләнми – аннан соң бөтен мәшәкать Нургаяны җилкәсенә генә өелеп кала бит. Аңа да сабырлыклар бирсен Ходай, булган акылыннан гына аера күрмәсен...

Халисәттәйнең дә, көн-төн туса, теләгән теләге – кызына да, киявенә дә Аллаһы Тәгалә сабырлыклар бирсен, дигән сүзләр иде. Ана кеше өчен бала хәсрәтеннән дә тирәнрәк, бала кайгысыннан да ачырак кайгының булуы мөмкин түгел – кызын уйлап, йөрәге тузды, челтәрләнде карт ананың. Ул да түзде. Хәсрәтен йөзенә чыгармыйча, кызына сиздермичә түзде. Таң атса, Югары очтан, бакчалар артлатып кына бу якка чыкты, Зәйтүнәсенең җан ярасын үзенә күчерердәй булып, аның янында булашты; ике кодагый, берберсенә терәк булып, оник тәрбияләделәр, авыру хатынны карадылар, тәне авыртмасын дип, бу якка борып яткырдылар, мендәргә сөяп утырттылар, кулына эш көйләделәр, арыгансыңдыр дип, йөзтүбән яткырдылар. Яшәргә, ничек тә дөнья көтәргә тырыштылар. Һәркөнне, эштән кайтуга, Нургаянны кайнар аш, улының яңгыравык тавышы, өч яралы җанның якты йөзе каршылый иде. Кичен караңгы төшүгә, «үз өемдә генә йоклый алам», дип, Халисәттәй Югары очка кайтып китә. Янә бакчалар артлатып кына. Умарта күчедәй гөҗләгән уйларын буйсындыра алмыйча, шул уйлардан авырая төшкән башын иеп кенә, үзенең тәбәнәк түшәмле, дүрт тәрәзәле өенә кайтып бара ул. Каныннан, җаныннан яралган газиз баласының хәсрәтен киметә дә, бүлешә дә алмаудан гаҗиз булып, аны кызганудан буй-буй булып аккан яшьләрен сөртеп тә тормыйча, карашын кәлүш очына төбәгән килеш, атлый да атлый. Ә күз яшьләре өйгә кайтып кергәч тә ага бирә: карт ананың йөрәк сагышы, йөрәк яше, үзе гүргә кергәнче, бәлки, аннан соң да озата барачак мәңгелек ярасы булып, ага да ага алар.

Халисәттәй, иртәгәсен ул яраны янә күкрәгенә йомарлап, беркемгә дә күрсәтмичә, янә кызы янына ашыга.

***

Ашыгып яшәмәсәң дә, әллә ни арада уза икән бу гомер. Күз керфеген кагарга өлгермисең – кояш инде офыкка юл тота...

[2] Угата – диал., аеруча, бигрәк тә дигән мәгънәдә.

Нургаяннарга килен төшә бүген. Капка төбендә кайнашкан халык сабырсызланып урамны күзәтә: машиналар кычкырткан тавыш ишетелсә, кемдер юл бүләргә, кемдер кәнфит җыярга, кемдер фотога төшерергә ашыга. Тәрәзәдән күзен алмаган Зәйтүнә дә көтә. Йөрәге уч төбенә төшеп утырган диярсең. Югыйсә, Рәйләне тәүге күргәндә үк холык-фигылен чамалап, ошатып, бик якын итеп өлгерделәр. Шулай да ул бу өйгә моңарчы кунак буларак кына килсә, «Нургаян абый, Зәйтүнә апа», дип эндәшсә, бүгеннән аларга – килен, улларына – хатын, йортка – хуҗабикә булып аяк атлый. Авыз тутырып әти-әни дип әйтә алырмы, өй түрендә көнен дә, төнен дә ятарга мәҗбүр Зәйтүнәдән тиз арада бизеп, Наилне калага алып китү җаен карамасмы? Җавапсыз сораулардан ана кешенең башы тубал булды, янына керә-чыга йөргәннәрнең нидер соравы, кызыксынуы бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты. «Урамда түгел, шушында, үз урынымда каршы алам киленне», – дип кистереп әйтүенә борчылып та куйды. Эче пошып, кырык тапкыр көзгегә күз салды: челтәрле ак яулык астыннан ике калын толымы түшләре чигүле зәңгәрсу кофтасына салынып төшкән. Кашык очы белән сызгандай туры кашлары да, үз гомерендә бер тапкыр буяу күрмәгән керфекләре дә, иннек сөртүне белмәгән иреннәре дә – барысы да үз урынында. Улы белән килененә каптырасы бал белән май да түгәрәк подноска куелган, кашык онытылмаган; аяк астына дигән кершәндәй ак мендәр үз янына салынган. Бүләккә дигән, шәфталу төсендәге нәфис яулык кул астында. Һәммәсе дә бар, әзер кебек инде...

– Кайталар!

Ачык тәрәзә аша башта шул аваз, аннан әллә ничә машинаның бер булып кычкыртканы, җыр-музыка агылып керде.

«Төкле аягың белән! Төкле аягың белән, балакаем!» – Зәйтүнә, каядыр соңга калудан курыккандай, каударланып, шул сүзләрне кабатлады.

Бераздан, өй эченә шаулап кергән яшьләр тавышын күмеп, Наилнең: «Әни, без кайттык!» – дигәне, Нургаянның, дулкынланыбрак: «Әнисе, киленеңне каршы ал!» – дигәне ишетелде. Бусагада җете кара костюм-чалбар кигән Наил һәм идәнгә тигән ап-ак күлмәктән, күз явын алырлык чибәр, яшь Рәйлә пәйда булды. Зәйтүнә, каушавыннан сүзен дә онытып, мендәрне үз янына идәнгә куйды, шуннан соң гына, өзеп-өзеп:

– Түрдән узыгыз, балалар! Кызым, төкле аягың белән! – дия алды.

Рәйлә, вак-вак атлап, Зәйтүнә янына килде дә:

– Исәнме, әни! – дип шулкадәр ачык итеп күреште, аннан, үзе дә каушый төшеп, Зәйтүнәнең җилкәсенә ап-ак челтәр шәл салды. Кисәк кенә күңеле тулган Зәйтүнә, улы белән килененә бал-май каптырырга да онытып, берара тын торды. Әни, диде Рәйлә, исәнме, әни, диде! Әни, диде! Зәйтүнәнең керфегендә көмеш яшь тамчысы җемелдәде.

Наил дә, иелеп, әнисен кочаклап алды. Аның да күңеле тулганы күренеп тора иде, Зәйтүнә, шуны абайлап, улына ныклык өстәп, көләч елмайды. Үрелеп, баһадирдай улының иңбашларын сыйпады, шуннан соң, исенә төшеп, килененә бүләк яулыкны сузды.

– Башыңда тузсын, кызым, бәхетле бул берүк!

Туй турында барысы да хәл ителгәч, Зәйтүнә генә түгел, Наил дә көл астында көйрәгән учак утына әйләнде. Югыйсә, Рәйлә белән ачыктан-ачык сөйләшенгән, кыз кая, нинди йортка киләсен яхшы белә. Мәхәббәтләре айлар гына түгел, еллар белән сыналган. Рәйләнең йөз-кыяфәте генә түгел, күңеле дә матур – монысына да кат-кат инанды Наил. Шулай да, шулай да... Беркөн килеп Рәйлә әнисенә ялгыш каты бәрелмәсме? Аңа кыек сүз әйтмәсме? Шуны

уйлап борчыла иде егет. Мондый хәл була калса, ике ут арасында калырга туры килсә... Юк, юк, башына каян җыен тузга язмаган уй кереп тула диген... Балачактан, үзен белә-белгәннән бирле, әтисе аны: «Улым, син безнең бер генә бөртек. Мин булсам да, булмасам да, әниеңнең иң олы терәге син», – дип үстерде. Әнисенең башка әниләргә охшамавы белән ул сабый чактан килеште: нәни куллары белән кечкенә генә ярдәм күрсәтә алуына да сөенеп туя алмый иде. Аш ягыннан табак алып чыкса да, мич арасыннан берәмләп бәрәңге ташыса да, авып төшкән урындыкны турайтып куйса да, әнисе аның башыннан сыйпый, җан җылысы белән елмая. Улының кул арасына керүенә бер сөенсә, кече күңелле булып үсүенә мең шатлана иде. Наил мәктәпкә кергәч, ике әбинең кулына тоттырмыйча, күлмәк-костюмнарны үзе үтүкләде, дәресләрне үзе әзерләтте әнисе, маңгаенда «кәҗә» генә калдырып, улының чәчен үзе алды.

Әтисенең аны кулларына гына күтәреп мунчага алып китүен, күтәреп алып кайтуын, кулларына күтәреп, матай бишегенә утыртуын, әле балыкка, әле мәтрүшкәгә, әле пиннек бәйләргә алып баруын, кулларына гына күтәреп, бәбкә сакларга алып чыгуын күреп үсте Наил. Әнисе белән киңәшләшмичә, бу йортта бер эш тә эшләнмәде. Әбиләре исән чакта да шулай булды:

– Килен, чегәннәр чәчәкле келәм сатып йөриләр, әллә аш ягына берәрне алып куйыйкмы, ни диярсең?

– Кызым, кеше бакча сөрә башлады инде, әллә кияү минекен дә сөреп ташласынмы?

– Әнисе, берәр келәт эшләсәм, дим, мунча тирәсенә бастырыйм микән, бакча буенаракмы?..

Ә хәзер? Хәзер ничек булыр? Рәйлә бу гадәтләрне кабул итәрме? Әнисенә ялгыш каты бәрелмәсме?

Туй алдыннан Наил менә шундый борчулы уйга төшкән иде. Түзмәде, кәләшенең күзенә карап, уйларын ачыктан-ачык уртаклашты.

Рәйлә исә, шомырт күзләрен кысып, нәкъ аның әнисе кебек җылы елмайды:

– И Наил, – диде ул, егетнең дулкын чәчләренә бармак очы белән кагылып. – Мин нигә сине сайладым дип уйлыйсың соң син? Синең ышанычлы терәк булырыңа ышандым. Әниеңне шулай хөрмәт итмәсәң, аны кайгыртмасаң, борылып караган булыр идемме? Икәү булсак, авырлыкларны да бергә бүлешербез, Наил, – диде ул, йөзеннән нур бөркетеп.

Бу җиһанда һәрнәрсәнең төсе, тавышы бар. Шуны күрә-ишетә белгән кеше – бәхетле дә инде. Бәхетнең үзен эзләп, әллә кайдагы Каф тавы түбәләренә менү дә кирәкми. Бөдрәләнеп аккан болытларга күзләреңне күтәреп кара – син бәхетле. Күрә белүең белән. Ул болытларның кайсын юрганга, кайсын аргамакка, кайсын карлыгачка охшатып соклана белүең белән бәхетле. Күк йөзеннән ишелеп-ишелеп яңгыр яки кар яуганда, бәллүр тамчыларны учыңа алып кара – син бәхетле. Аллаһ сиңа ике кул биргән, яманга үрелмәсен, яхшылык кылсын, дип биргән – шуны аңлый алсаң, син бәхетле. Йөрәгеңнең һәр тибешенә сөенә белсәң – син бәхетле. Үзеңнең кемгәдер бик кадерле булуыңны белсәң яки тирәякта синең өчен бик кадерле кешеләр булуына төшенсәң – син бәхетле. Кар астыннан гөрләвекләр җырын ишетсәң, яфраклар лепердәгәндә, аларның бер Аллаһка зикер кылып утыруларын аңласаң – син бәхетле. Утлы күмер йотып яшәгән мәлләрдә дә шөкер дип кабатлый алсаң – син бәхетле.

Зәйтүнә дә шулай диде. «Аллага шөкер, япа-ялгыз түгелмен», – диде. «Аллага шөкер, ике кулым бар», – диде. «Аллага шөкер, баламның туен күрә алдым», – диде. Бу көннәргә килеп җитәр кебек тә түгел иде: элегрәк «улымның

мәктәпкә киткәнен күрсәм иде», – дип хыялланды; укып бетергәнен күрергә язсын иде, дип теләде; туйкаен күрә алсам иде, дип өметләнде. Менә бит, Аллага шөкер дими, ни дисең: барысы да насыйп булды. Гомер булып, инде оныклар сөю бәхетенә дә ирешсә...

***

– Әллә соң сүзләрең фәрештәләрнең амин дигән чагына туры килде микән, Нургаян? – диде Зәйтүнә, үзен мунчадан күтәреп чыгып, кәнәфи аркасына терәп утырткач, башына чалма итеп ураган сөлгене сүтә-сүтә.

Нургаян кече бүлмәдән салкын әйрән алып чыкты, караватка утырып, банка авызыннан гына тәмләп карады да хатынына сузды.

– Катыгын күп итеп салдым, син яратканча. Нинди сүзне әйтәсең?

– Өйләнешкәнче, кич чыккач, гел әйтә идең бит... – Зәйтүнә, шул көннәрне хәтерендә яңартырга теләпме, күзләрен йомды. – Кулларымда гына күтәреп йөртер идем, дия идең.

– Күтәрәм дә, әһ тә итмим, Зәйтүнәкәем. Ә ул чагында кая ул күтәртү... Дүрт ел йөрдек – биленә кагылсам да, кәҗә бәтие кебек читкә сикерә идең бит...

– И-и, алай ук булмагандыр... Ышана идем бит сиңа, Нургаян, үземнән битәр сиңа ышана идем...

– Соң, ул ышанычны яулар өчен, башта сине капчык белән кулга ияләштердем, аннан сарык бәрәннәре ташып, ничә пар аяк киеме туздырдым!

Уен катыш чынын әйтүе Нургаянның. Унынчыны бетергәч, Алабугага китапханәчелеккә укырга китәм дип хыялланган кыз кисәк кенә ниятен үзгәртте, авылда, әнкәй янында калам, диде. Бу сүзләр теленнән төшкәнче, Зәйтүнә барысын да кырык кат уйлады, кырык бизмәнгә салды. Ничә уйласа да, тәбәнәк түшәмле, дүрт тәрәзәле өйдә ялгыз башы торып каласы әнкәсе кызганыч иде. Олыгаеп кына килгәндә, бер иптәш булыр дип, Зәйтүнәне тапкан, күз карасы кебек күреп, аны баккан, үз авызыннан өзеп, иң тәмлесен аңа ашатырга, иң матурын аңа кигерергә тырышкан әнисе берүзе нишләп бетәр? Аннары, Зәйтүнә үзе дә ул таш каласында әнисеннән, Нургаяннан башка нинди ямь табар? Шуларны соңгы тапкыр күңеленнән кичергәч, тотты да әнкәсе янына, сарык фермасына эшкә чыкты.

Нургаян аны күрер өчен фермага да килә, яңа туган сарык бәрәннәрен икәүләп эчкә – җылы бүлемгә ташыйлар иде.

Ирнең шуны күздә тотып шаяртуы.

– Мунчаны да өй эчендә салуыгыз иллә дә әйбәт булды, – диде Зәйтүнә, яңа өйдәге уңайлыкларга мең дә беренче кат шөкер итеп. – Синең дә яшең бара, Нургаян, мине йөртүләре җиңеләймәс. Коляскага ияләшергә кирәк инде.

– Әйтәсе бармы, әнисе, утыз җиде ел көткәч, коляска да кайтып җитте бит, – дип көлде Нургаян, ел саен яңа гариза язарга баруын искә алып. – Безнең илдә халыкны кайгыртмыйлар дип әйтеп кара син!.. Әй, Зәйтүнәкәем, ул колясканы, бик кирәксенсәк, әллә кайчан сатып та алганыек. Ике кулым барында, сине генә күтәрмәскә... Җайлы дисәң, өй арасында йөрерсең анысы...

Ишегалдында Актырнакның иркәләнеп кенә һау-һаулаганы ишетелде, кызларның мәктәптән кайтуын сөенеп каршылавы. Капкадан чит кеше керсә, бер дә болай йомшак тавыш чыкмый үзеннән, дөньяны шаулатып өрергә тотына. Шунысы әйбәт тә инде: Зәйтүнә кеше-кара кергәнен алдан ук белеп тора.

Өйалды ишеге ачылып-ябылды.

– Бабыкай! – дип сөрән салды өченчедә укучы Гөлүсә, кереп җитмәс борын сабырсызланып.

Бишенчегә күчкән Илүсә, үзенең апа икәнен искәртеп:

– Кычкырма шулхәтле! Әбекәй йокласа, – дип, аны шелтәләп куйды.

Онықларының каршысына чыккан Нургаян, аларның аркасыннан сөйде дә, бик җитди төстә, ике кулы белән сумкаларын капшап карады:

– Кая, берәр симез икеле юкмы монда алай-болай?

Бабаларының җор теленнән тәм табып, кытыкланып көлә-көлә, кызлар Зәйтүнә янына йөгереп керделәр:

– Әбекәй, Илсөяр апа сиңа сәлам әйтте!

– Әбекәй, инештәге басманы сындырганнар, бер генә тактасы калган!

– Әбекәй, беркөн әйткәниек бит, Рәхимә апаның казлары югалган, диеп. Тапкан!

– Ие, кем инде, теге... әй, исемен оныттым... Әлләкем апаларның лапасында булган ди!

– Әбекәй, Вәсим абыйның аягы сынган ди!

– Аяклары, диген. Икесе дә сынган бит.

Кызлар әбиләрен авыл яңалыклары белән таныштырырга ашыккан арада, бабалары, аларны бүлдереп:

– Һай, кычыткан чыпчыклары, Вәсим абыегызга ни булган? Каян ишеттегез? – диде, бик аптырап.

Кызлар, дәрестә җавап биргәндәй, икесе беравыздан чатнатып:

– Сүз иясе белән йөрми! – диделәр, кайчандыр Нургаян үзе өйрәткән җөмләне сүзен сүзгә кабатлап.

– Ярар, алайса хет шунысын әйтегез, шилмалар: бүлнистәме Вәсим абыегыз, өйдәме?

Гөлүсә белән Илүсә бер-берсенә борылып карап тордылар да, авызларын уч белән каплап, пырхылдап көләргә тотындылар. Аякларын юка юрган белән төреп, кәнәфидә утырган Зәйтүнә көлемсерәп баш чайкады. Сабыйларның иң рәхәт, ваемсыз чаклары шул...

– Җә инде, рәтләп әйтегез, – диде ул да, түземлеге төкәнеп. – Аяк сынганга көләләр димени, менәтрәк.

– Өйдә-ә-ә ди, – дип сузды Илүсә, көлүдән көчкә тыелып. – Нияз әйтә, бабай идәндә ятып йөри ди, бәбәй кебек шуышып. Ике аягына да теге ни... нәрсә куйганнар соң инде...

– Гипстыр, – диде Нургаян, мунча сөлгесен муеныннан алып. – Кая, урап кайтыйм әле. Әнисе, сине караватка күчеримме? Болай арып бетәрсең.

– Күчер, үзеңә тыныч булыр, иркенләп йөрерсең.

Кызлар үз бүлмәләренә йөгереп, өсләрен алыштырган арада, Нургаян да шкафтан шакмаклы яшел күлмәген алып киде.

– Яка тирәләре бөгәрләнгән, берүк сал, үтүкләп алам, – диде Зәйтүнә, аңа күз төшерүгә, шул арада идәндә торган үтүкне дә кабызды.

– Яраган инде, әнисе, пенсионер бабайга... Минем якага кем карап торсын.

– Карамаса да, күрүчесе табыла аның. Хатынының кулы юк микәнни, диярләр... Китер, китер...

Нургаян капкадан керүгә, ишегалды чирәмендә мүкәйләп йөргән Вәсимне күреп, аптырап китте. Дустының ике табаны да гипска катырылган, шулар өстеннән оекбаш киеп куйган. Ике тезендә – оныгының хоккей уйнаганда кия торган «калкан»нары. Ике кулына исә хатынының аякка элә торган артсыз башмакларын кигән дә, шуларны шап-шоп китереп, йөреп маташа.

– Нәрсә, ахир, мине олы капкаңны ачып каршыламакчы идеңме әллә? – дип

шаяртырга ашыкты Нургаян, аның үпкәли торган гадәте юк икәнен белгәнгә, сүзен елмаюдан башлап.

– Шулай итмәкче идем дә, бер мәшәкатьтән коткардың, – диде үзе дә сүзгә аптырамаган Вәсим. Кулына кигән алсу төстәге җилем башмакны салмый гына, уң кулын һавага күтәреп, сәлам бирде. – Өйдә хатын мырлый, аяк астында йөрмә, утырып кына тор, ди. Шуңа үч итеп, ишегалдына чыктым. Әйдә, түрдән уз, яшьти, – дип, җылы яктагыча йөзем куаклары үрләгән беседкага ымлады.

Нургаянның:

– Кая, булышыйм, – дип иелүен күргәч, Вәсим йөзен җыерып баш чайкады.

– Үзем! – диде ул, кистереп. – Син мине, башын иеп, биш тиен акча эзләп йөри дисеңме әллә. Юри йөрим, сынган аякларга үч итеп йөрим... Картаеп килгәндә, шушы көнгә калдырмасалар...

Нургаян – атлап, Вәсим – мүкәйләп, беседка эченә керделәр, тимердән челтәрләп эшләнгән эскәмиягә утырдылар.

– Болай дигәнгә хәтереңкалмасын, яшьти, ну барыбер әйтәм: синең Зәйтүнәң алдында оят, шуңа йөрим. Мин әйтәм, Зәйтүнә теттереп эш эшләгәндә, миңа кул кушырып ятарга соң... Бакчага дип чыккан идем, кереп кенә җитәлмәдем әле. Кишер йолкыйсы бар дип чәпчи бит. Иртәрәк дип торам. Үз туксаны туксан. – Вәсим башы белән өй тәрәзәсенә ымлады. – Юри чыктым, үзем йолкыйм, дим, берегез дә кирәкми, дим. Ике кул бар – нигә, рәхәтләнеп йолкыйм.

– Кызлар кайтып әйтмәсә, әле ишетмәгән дә идем, – диде Нургаян, аның аякларына карап. – Син соң, кай арада, кайда җитештең?

– Тиз икән ул, яшьти... – Вәсим баш түбәсендә ялтыраган пеләшенә чәпелдәтеп алды. – Менә бу ахмак башны саклыйм дип, аяксыз калды абзаң... Кичә бит малай түбә яптырды, мин дә буталып йөргән булдым шунда карт дивана. Аста калайны әләктереп кенә торсам ярамаган, юк, баскычка менеп басарга кирәк бит, кысылып торырга... Ул калайның как миленький гына менеп киткәнен дә күрдем мин, менеп тә җиткән иде, нәрсә дип ычкынгандыр. Туп-туры минем өскә очты, җүнсез. Күз кырыем белән генә шәйләп алдым, мин нәрсәдер уйлаганчы, баш үзе эшләп өлгерде – арт белән генә читкә сикердем. Анда таш булган икән, ике аяк табаны чәлпәрәмә килгән... Ну сикермәсәм – муенны гына кисеп үтәсе иде... Кичен район бүлнисенә алып китте малай – шатырдатып гипска катырып куйдылар – менә шул. Ничава, бер-ике айдан салып ташлыйм мин аны.

Өйдән, идән юган чиләк-мунчаласын тотып, Вәсимнең хатыны Венера күренде. Алтмыш яшьләр тирәсендә булса да, килешми дип тормаган – мич кадәр гәүдәсенә сыланып ябышкан кара трико, кыскарак кына аксыл футболка киеп куйган. Беседкада Нургаянны күреп, ул да Вәсим шикелле, уң кулын күтәреп сәлам бирде.

– Өйгә кер дигән кеше юкмы, Нургаян? Безнең бабай миннән зарланамы? Кеше көлдереп йөрмә, дим, берәр колак салса сүземә... Керәсезме, чәй кайнаган? Кыстыбый да пешергәнием. Зәйтүнә ничек, әйбәт кенәме?

– Әйбәт кенә әле, Венера, Аллага шөкер, – диде Нургаян, җавап көтеп тормыйча сорау арты сорау белән кумәргә яраткан Венераны, тын алган мәлендә, җайлы гына бүлдереп. – Сәлам әйтте.

– Рәхмәт, рәхмәт, – диде Венера, кулындагы юеш чүпрәкне җилләнә-җилләнә селкеп, койма башына элгәч. – И-и, элек кич утырырга бара торганыек, әйме, Нургаян? Сине җырлата торганыек, әйме? Хәзер дә җырлыйсыңмы син? Бетте, малай, кешегә йөрүләр дә бетте, бу вакытны гел җиткерә торган түгел, сиңа да шулай тоеламы? Вәсим, син минем розовый тапочканы күрмәдеңме, бая гына баскыч төбендә торган кебек иде?

– Күрмәдем. – Вәсим, аның такылдавыннан туеп, җирдә яткан башмакларны эскәмия астынарак күчерде. – Хатын, өйгә кереп-чыгып йөрергә рәт чамалы, белеп торасың. Чәеңне монда гына чыгар. Боярлар шикелле, киерелеп утырыйк әле бер. Безгә хәзер, пенсионер бабайларга, пачут булырга тиеш. Мәй дә чыгар дияр идем, Нургаян ни, мәчеткә йөргәч...

– Мәчеткә йөргәнче эчкән диярсең... Аңа ярты халык ышанмый инде, авылда, тракторда эшләп, кешегә утынын-печәнен ташып, бер румкы эчмәгән кеше буламы? Нургаян, әллә биргән антың бар идеме соң, ә? Хет безгә генә әйтериең инде, ә? Кара, сиңа чәйне сөтләп ясыйммы, күрәгә салыйммы?

– Ярар ла, эчмәгән чәй түгел, мәшәкатьләнмә, Венера, – диде Нургаян, озаклап утырырга җыенмыйча, хатынның соңгы соравына гына җавап биреп.

Тик кунакчыл хуҗалар баш тартырга ирек бирмәделәр. Тиз арада беседкадагы агач өстәлгә сөт өсте, бал, телем-телем киселгән кибет күмәче, кыстыбый, чәйнек һәм чынаяклар чыгып утырды.

– И Нургаян, кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә, ди, мәгәр дә дөрес икән, әйме? – Венера кереп-чыгып йөргән арада да, чәй ясаганда да, үзе өстәл артына килеп утыргач та, сүздән туктамады. – Бабайны әйтәм, әле аяктан калганына, ачуым да бер килмәгәе, тәүлек тә булмаган, аның көеннән торукайлары... Ятса – утырам, ди, утырса – урамга чыгам, ди, көен көйләтә, әйме, бабай? Сине әйтәбез әле, ничекләр генә сабырлыкларың җитәдер... Әле хатын-кыз, мыр-мыр килсә дә, көйли-чөйли инде ул, авыруын да карый, дөньясын да көтә. Син бит ир-ат, мырлаганыңны да ишеткән юк, ничекләр...

– Карале, хатын, патефоныңны туктат әле... Писүк апчыкмагансың. – Вәсим мәгънәле генә итеп ияк какты.

– Ай Алла, бал куйдым бит, писүк ди... – Венера җәлт кенә кечкенә савыт белән писүк алып чыкты. – Әйтәм бит, иркәләнеп каласы килә, шулаймы, бабай? Менә кичә мине тыңласаң... Яшь чагың түгел, тегендә-монда менеп йөрмә, дидемме – дидем. И-и, мине юрикәйләр дә тыңламый бит ул...

– Малаеңа әйтәсе иде. Кеше куян куа дип, каланча хәтле йорт җиткермәсә... Ул ике катлы йортта куышлы уйнамакчы булаламы, белмим.

Вәсимнең малае урамның иң очында ике катлы таш йорт җиткереп ята иде, ата кешенең шуны әйтүе. Хәзер кеше ничек тә берсен-берсе уздырырга тырышып ярыша шул: йорт җиткерсә – күршесенекеннән биегрәк, койма яңартса – бүтәннекеннән чәчәклерәк-чуклырак, машина алса – тегенекеннән затлырак, кыйбатлырак булсын...

– Синең малай акыллы булды, – диде Вәсим, Наилне күздә тотып. – Курчак өе кебек итеп эшләдегез дә куйдыгыз.

Өч-дүрт ел элек Нургаяннар да яңа йорт җиткереп керделәр. Күршеләренеке кебек ике катлы итеп күтәрмәсәләр дә, зур, иркен итеп эшләделәр. Суы, газы кергән – элекке кебек мичкә утын ягып, чыра телеп азапланасы юк. Шәһәр фатирыннан ким түгел, ванна-мунчасына тиклем өйгә көйләделәр. Өй салуның ние бар – чутлыйсы да мүклисе, дисәләр дә, күзгә күренгән-күренмәгән мең мәшәкате бар инде анысы. Шунысы рәхәт: кырыклы кадакка да тилмергән чор түгел, акчаң булса, жаның теләгән нәрсәне табып була. Авыл җирендә күпләп мал асрасаң – акчасы да кулга кереп тора, карарга гына сабырлыгың җитсен. Сөтен, итен шәһәргә дә илтеп йөрисе юк – авылда сыер-бозау тотучылар бетеп бара, аларның да тамагы бар, каймак, кәтлит ишесен ашыйсылары килә...

– Кызлар да үсеп килә, кирәк иде инде, кирәк, – диде Нургаян, артык

җәелеп китми генә. – Ул төзелешне бер башласаң, бетәргә җыенмый икән лә. Кул кычытып тик тора.

– Безгә соң хәзер, ишегалдында кадак кагып, бакчада жук чүпләп вакыт үткәрсәк кенә инде... – Вәсим шулай диде дә, гипслы аякларына карап, кызганыч елмайды. – Жук отпадает. Моның белән чүпләп булмас. – Иелеп, эскәмия астыннан ал башмакны болгап күрсәтте.

– Бәрәңге алыр вакыт җиткән, нинди жук сөйләп утырасың? – Венера, чәй ясаган җиреннән башын күтәрде дә, аһ итте. – Әстәгым, шул башмакны сорыйм бит, күрмәдем, ди. Нишлисең аның белән?

– Шаулама. Пирчәтке урынына ул, бик җайлы нәмәрсә икән. Җирдә йөргәндә, кул пычранмый.

– Үтерә бу бабай мине, чистый үтерә. – Венера, оныкларына ияреп, иренә бабай дип эндәшә башлаган иде, шул сүзгә тәмам ияләшкән икән – Вәсим дигәне ишетелми хәзер. – Эш сорап тинтерәтә. Тик утырмыйм, эш тап, ди бит, ә. Сиңа түгел, яшьләргә дә эш юк авылда, шуңа таешып беттеләр дә инде. Нургаяннныкылар калды да безнекеләр калды.

– Килен әйбәт булды, – диде Вәсим, чәенә сыек бал салып. – Ул котыртса, шундук шәһәргә сыпырта иде безнеке дә.

– Зәйтүнә дә Наил өйләнгәнче гел шулай дип борчылган иде. Килен шәһәргә апкитеп бармасмы дип өтәләнде.

– И-и, сезнең Рәйлә гел үзегезнең сыңар бит, каяннар тапкан аны Наил... – Венера күмәч телеменә мул итеп сөт өсте, аннан бал ягып, тәмләп чәй эчкән җиреннән сөйләшергә дә җай таба иде. – Ул эшкә дисеңме, ул сабырлыккамы – кит, үзегезнең кыз булса да, болай ук охшамас иде. Әле беркөн кибеттән икәү бергә кайттык, мине беләсең бит, телем тик тормый – бик авыр түгелме, дип сораштырдым инде. Бәй, тормыш булгач, төрле чак була бит, гаепмени... Ир белән хатын арасында да табак-савыт шалтырамый тормый... Андый чакта каш та җыерыла, тел дә катып китә... Шулай дигәнием, елмайды гына Рәйлә. «И Венера апа, бөтен курыкканым – авызымнан әнкәйне рәнҗетерлек сүз генә тәгәрәп төшә күрмәсен, дим», – ди үзе, балакаем. Әйтәм бит, геләннәр үзегез, бөтенегез бер камырдан сез... Нургаян, нигә ул кыстыбыйны санап кына ашап утырасың, кыстый торган гадәт юк – алга куелган, ашап бетереш, чәшкеңне этмә, чәй ясыйм.

Нургаянның, амин тотып:

– Әппәр иттем, Венера, барысы да бик тәмле, Алланың рәхмәте яусын, – дип битен сыпыруы булды, Вәсим чәйнек-чынаякларны бәреп төшерерлек тавыш белән шаулап көләргә тотынды.

Венера башын тотты, Нургаян да, көлүнең дәвамын көтеп, ахиренә төбәлде. Икесе дә белеп торалар: димәк, Вәсим нәрсәнедер исенә төшерде.

– Әппәр, дигәч... – Вәсим һаман, шүрәле кытыклагандай, шырык-шырык килә иде.

– Карт исәр, кем әйтер шушыны акыллы дип... – Венера үзе дә иренә кушылып елмайды.

– Безнең бит төпчек кызның ире урыс, үзең беләсең. – Ирнең чырае бер мизгелгә сытылып-җимерелеп алды. – Җир йөзендә татар беткән...

– Ярар, ярар, башлый күрмә берүк. – Венера да, үзенең дә йөрәк ярасы булган сүз җебен кузгатырга теләмичә, чыраен сытты.

– Ярар, чурт с ним... Сабантуйга кунакка кайтканнар иде. Шушында утырып ашлар ашадык, бер табак итне бөкләп куйдык. Миннән күреп, кияү дә битен сыпырып, әппәр итеп утыра иде. Венераның бәләкәй тактага куеп бәлеш табасы

алып чыкканын күргәч, коты очты моның. «Ой-ой, ещё не әппәр, ещё не әппәр», – дип, кулын кирегә болгарга тотынды, мин сиңа әйтим... Шул искә төште.

– Таптың кызык. – Кызы белән киявен искә төшергәч, Венераның йөзе качкан иде.

Вәсим дә бу юлы елмаймады.

– Үзең гаепле. Чаллыда укыган чагында башына яулык ябып кайткач, син дуладың. «Авыл халкы алдында оятка калдырып, абыстай кебек төренеп йөрисең, берәү дә болай кыланмаганны», дидең, оныттыңмы? Яулыгы белән бергә акылын да салдыргансың инде... Әнә, хәзер бүтәннәрнең кызлары кайта, яулык бәйләп, татар ирен култыклап...

Нургаян Вәсимне кыстап-кыстап та үзе белән мәчеткә ияртә алмады моңарчы. Соңгы араларда, кызын кияүгә биргәннән соң, башына бер-бер уй төштеме – ниндидер хикмәт белән җомга намазында күренгәли башлады шулай да. Венерасы аңа да баштарак өнәмичәрәк карады, тора-бара әллә кул селтәде, әллә килеште – аны-моны әйткәне юк бугай. Ир белән хатын – ике чабата, бер кием инде ул: Вәсим белән Венера да, карап торганда, икесе бөтенләй ике төрле кебек тоелсалар да, төбенә тоз коеп төпченә башласаң, бердәй холыкка киләсең дә юлыгасың. Әллә кай арада гына дөбердәтеп тавышланып та алалар, шаулатып көләргә дә тотыналар.

Менә әле дә әйткәләшергә әзер мизгелдә, капка төбеннән ап-ак биек машинаның түбәсе күренеп китүгә, бөтенләй башка сүзгә күчүләрен сизми дә калдылар.

– Рәхимәттәйнекеләр тагын яңа машина алган икән бит, синең тракторың чаклы бар, Нургаян, әйтмәсәм дә булмады, – диде Венера, муены каерылганчы урам якка борылып. – Каян акча җиткерәләр диген, машина арты машина алыштыралар, нәрсәсенә исләре китәдер.

– Барысын да белеп торасың үзең, Венера. – Нургаян, кайтырга ниятләп, урыныннан кузгалырга итте.

– Кеше тикшерергә дисәң, моңа куш инде... Үзен белми... Шул машинага алданып, миңа кияүгә чыкканын сизми дә калды бит ул, – дип көлде Вәсим, Нургаянның ашыкканын сизмичә, иркенләп яңа сүз башлады. – Әле ул чакны колхоз машинасына утырмаган идем бит, бу күрше авылда, бүлнистә эшләп йөри. Беркөнне әйтеп ташладым бит, шимбә көнне эштән каршыларга машина белән киләм, юл чатына чыгып тор, дидем. Безнең әткәйнең «Зәпәрәе» бар иде, син дә хәтерлисең микән, яшьти?

Нургаян, кыймылдарга, аны бүлдерергә кыенсынды, башына киеп өлгергән кепкасын салып кулына тотты:

– Хәтерләмәскә. Әтәч кикриге шикелле кып-кызыл «зәпәрәйне»...

– Шуның белән килергә исәп. Ну әткәйгә әйтеп булмый бит, кызлар янына барам, машинаңны бир әле, дип... Мине беләсең, күп уйлап торырга яратмыйм. «Чаллыдан абый кайткан, юл чатында көтеп тора, диделәр, шуны алырга киттем», – дидем дә, ачкычны эләктереп, гаражга чаптым. Инде кузгалдым гына дигәндә, ишекне ачып, әткәй менде дә утырды. Мин дә барам, ди, малай! Киттек инде икәүләп... Юл чатында нинди абый булсын, анда тиклем кайтса, нәрсә дип безне көтеп торсын... Ә Венера түтәң тора! Түшләрен киергән, мин сиңа әйтим, тәти күлмәкләрен киеп куйган... Шту син, машиналы егетләр кемгә тәтегән әле ул чакта!

– Теле булмаса, карга күтәреп китәр иде шушыны... – Венера, чынаякларны җыя-җыя, урыныннан торды. – Нургаянга да кырык сөйләгәнсеңдер инде бу әкиятеңне, башын катырма.

– Нишләп әкият булсын. Әткәй белән барып алу хакмы – хак. Утырып кайттыңмы – кайттың. Шул кайтудан берегеп тә калдың инде, гөнаһ шомлыгына...

– Вәсим, хәл беләм дә кайтам дип кергән идем, хәтәр җәелеп утырдым. Китим әле мин. Син, давай, тизрәк терел, бу таш бәтинкеләрне ыргытып, йөгереп йөрергә язсын. – Нургаян аягына ук торып басты, дустына кул биреп саубуллашты да, рәхмәт әйтеп, капкага юнәлде. – Йөгерә башлагач, Венера әйтмешли, кич утырырга килерсез әле, яшь чакларны искә төшереп, җырлашып утырырбыз, Алла боерса.

– Барабыз, барабыз, Нургаян, бабайны гына аякка бастырыйк та...

Нургаян урам буйлап үзләренә юнәлде. Көн кичкә авышып килә иде. Ник бер кеше заты күренсен! Каңгылдашып йөргән казлар да күзгә чалынмый. Бала-чага турында әйтеп тә торасы юк. Алары авылда бармак белән санарлык кына инде, булганы да өйдә йә компьютерга, йә телефонга берегеп утырадыр. Һәй, элек соң, бу урам гөрләп тора иде бит! Халык бәрәңге сабагы чаба башлаганчы, берара эштән арыныбрак тора иде: капка төбендә эскәмия-эскәмия булып күршеләр гәп сата иде. Арканны иңбашына салган бала-чага, көтү кайтканчы дип, су буена бәйләнгән бозауларын алып кайтырга чаба иде. Бер төркеме каз-үрдәкләр юллап әйләнгәли иде. Хәзер исә үле тынлык.

Нургаян авыз эченнән генә җыр көйләп атлады, атлаган уңайга, үзалдына көлемсерәп, Вәсим белән Венераны исенә төшерде. Алар, авылның йөзләгән, меңләгән гаиләләре кебек, тыйнак бер ихласлык белән үз көйләренә яшәп яталар. Алар да, шул йөзләр, меңнәр кебек үк, авылның күзе, колагы, жанының бер өлеше. Авыл җанының гына түгел, гомер буе шушы туфракта гомер сөргәч, җирнең дә бер өлеше шикелле. Сулар һава, эчәр су ничек кирәк булса, аларга җир дә шулай кирәк. Сәбәп булса да, булмаса да, ишегалды чирәменнән көнгә кырык кат урап керү кирәк. Әнә бит, Вәсимне кара инде: сабый бала шикелле тезендә шуышып булса да, җирдә йөрергә тырыша! Бер дә болын шикелле өйләренең зал ягында, келәм өстендә мүкәйләми. Җаны алгысынып, чирәмгә чыккан!

Авыл кешесенең табынган бәхете дә үзе кебек үк гади, самими. Аяк терәп йөрер җир булсын аңа, җанга тынычлык иңдерә торган тымызык җилләр исеп үтсен; өенә су кергән булса да, тешне камаштырырлык саф суны тансыклаганда, машинага бидон утыртып барып кайтырлык җырчы чишмә булсын. Кичен, юеш аркасына олы сөлгесен салып, мунчадан чыккач, өйгә керергә ашыкмыйча, ләззәтләнеп сокланырга йодрык-йодрык йолдызлар булсын. Шуларга карап торганда, кетер-кетер кимерәм дип алма өзеп алырга, бакчадан үрелеп торган алмагач булсын. Ул мизгелдә яңа сыгылган әфлисун, анар сутлары, фанта, спрайт кирәксенми кеше. Салкын катык болгатып, өч литрлы банка белән әйрән тоттырсыннар яки сап-салкын чишмә суы белән сыйласыннар үзен. Шәһәр халкы мунча ташына сибәргә дип кытайдан, Гарәп Әмирлекләреннән әллә ниткән хуш исле майлар кайтартып тинтерәсә, авыл кешесенең барысы да кул астында: кычытканын, әремен, мәтрүшкәсен, кыр бөтнегән, ромашкасын, кандала үләнен төнәткән кайнар суны ташка чажылдатып сибеп җибәрә – кыйммәтле хушбуйларың бер якта торсын!

Язга кергәндә, шәһәрнең ыбыр-чыбыры, кулчатыр тотарга иренеп, яңгырдан зарланса, авыл кешесе күккә карап яңгыр көтә: яусын, чәчүләр башланганчы, җиркәйләр туенып, йомшарып калсын, дип тели ул. Җәйләрен, өтеп алырдай кыздырган кояштан туярга өлгергән шәһәр халкы: «Их, бер коеп үтсә иде», дип ялварса, авылныкылар, киресенчә, печән өстен, урак өстен яңгырларсыз гына уздырсак иде, дип үрсәләнә.

Авыл кешесе кыш уртасында: «Быелгы җәйдә Төркиягә барыргамы, әллә Грециягәме?» – дип, туристик белешмәләр актарып интекми. «Берәрсе бозау суйса, балаларга берәр ботын алып куярга булыр», – дип, кибет ишегенә эленгән белдерүләрне күзәтә. «Бу атнада кайтмадылар, бәрәңгеләре бетеп китмәде микән?» – дип, һаман каладагы балаларын уйлап борчыла. «Йомырка чиләкләп җыелды, берәрсе артыннан булса да җибәрәсе иде», – дип, кайткан-киткәнне барлый. Картаеп килгән авылның яшәү мәгънәсе – шәһәргә сибелгән балаларын, оныкларын кайгырту. Һәр почмактан хәвеф-хәтәр сагалап торган хәзерге заманда аларны, сакласа, бер Аллаһ үзе генә саклый ала шул... Менә шушы хакыйкатькә төшенүчеләр сирәк. Авыл уртасында иман йорты булып калыккан мәчет бусагасын авылның ничә кешесе атлап керә икән? Күп булса, алты-җиде... Мең, миллион сәбәп табалар – йөрмиләр. Кыйбласызлыкның, имансызлыкның чишмә башын коммунизм төзеп маташкан елларга сылтау җиңел дә соң, ә бит бүген акылга килергә беркем комачауламый. Күңеленә иман орлыгы салынган кеше күзгә күренеп үзгәреп китә, йөзенә нур иңә, ул, үзе дә сизмәстән, яхшылык арты яхшылык кылырга омтыла. Әнә бит, һаман шул Вәсимгә кара... Яшеренбатырын түгел, саран дип булмаса да, элегрәк кысмырлыгы бар иде: артык бер генә тиен дә чыгармас, кесәсендәгене санап кына торыр... Ә беркөн?..

Наил аларны үзе белән шәһәргә алып барды. Нургаян – Зәйтүнәгә кирәк-яраклар алырга дип барса, Вәсимгә бөерләрен тикшертергә кушканнар икән – ул җай чыкканда барыйм, УЗИга күренермен, дип утырды. Вәсимне шәһәр үзәгендәге түләүле клиника янында калдыргач, Нургаян белән Наил сәүдә үзәгенә кереп киттеләр. Сөйләшенгән вакыттан күпкә иртәрәк Вәсим янына дип килсәләр, ул алардан да җитезрәк булып чыкты – инде урамда, аягын аякка чөеп, эскәмиядә утыра иде.

– Тиз тоткансың әле син, – диде Нургаян, артык гаҗәпләнмичә. Түләүле дигән клиникаларда да хәзер су буе чират икәнен белә, анда эшләүчеләр, берничә ел элек, килгән һәркемне май кояшы кебек балкып каршы алсалар, зарларын яртышар сәгать тыңласалар, инде елмаерга да вакытлары юк – бер ишектән кертәләр, икенчесеннән чыгаралар. Кайчандыр совет системасында алган тәҗрибәләрен искә төшереп, кабат үз калыпларына утырулары бугай...

– Тиз, – диде Вәсим, нишләптер саран гына итеп.

– Нәрсә диделәр, караучы булгандыр бит?

– Күрсәтәм дисәң, карамый ни...

– Рәтләп әйт әле, ахир, УЗИга күрендеңме соң син?

– Юк.

Инде Нургаян гына түгел, Наил дә аптырап китте. Багажник капкачын шапылдатып япты да башта машинага утырып маташкан Вәсимгә, аннан әтисенә сораулы караш ташлады. Нургаян иңсәсен генә җыерды.

– Вәсим, сиңа охшамаган әле бу... Авызыңнан сүз алып булмый.

Вәсим арткы урындыкка җайлап кереп утырды да, киттек дигәндәй, кул изәде.

– Нәрсә әйтим. Күренеп тормадым. Күренерсең, шуннан нәрсә? Ком, диярләр инде, таш, диярләр. Кемдә юк инде ул ком... Цемент, дисәләр дә гаҗәп түгел.

– Үтерәсең син, Вәсим абый. Әле килгәндә бөтенләй башкача сайрап килгән идең бит, – диде Наил, көзге аркылы артка күз ташлап.

– Әй, энекәш, кычытмаган җирне кашып йөрмим әле. – Вәсим киерелеп утырды. – Тәрәзәң караңгы, мине күрүче юктыр. Каешны әйтәм, эләктермәдем, агай-эне күренсә, сызгырырсың.

– Ул каеш агай-эне өчен түгел бит, Вәсим абый, үзең өчен, – дип елмайды Наил, янә көзгегә карап.

Нургаян тиз генә эндәшмәде. Ул ахиренең тикмәгә генә борылып чыкмавын аңлый иде. Тик нәрсә булган?

– Карале, Вәсим, монда чит кеше юк. Гомер буе бер табактан ашадык. Әйт – нәрсә булды?

– Булмады, дим, кара, ышанмый... – Вәсим берара тын торды. Алдауны килештермәде, тамагын кырып кына: – Түлке син Венерага әйтеп торма инде, яшьти. Кырык сүзгә җитәр... – диде, ялварган тавыш белән. – Ни бит... Чират алдым да, кеше күп булгач, ураштырып килим дип чыгып киттем. Теге башта, чатта, бер бәләкәй кенә малай тора, муенына пыяла тартма аскан. Ни микән дип кырыена килгән идем, акча җыеп тора икән. Үзенә түгел, ике яшьлек бер кызның йөрәгенә чит илдә апиратсия ясарга акча кирәк, дип язганнар. Ул кызның матурлыкларын, томраеп карап торуларын күрсәң! Венера бөгәрләп тоттырган бер биш меңлек бар иде, шул тартмага салдым да киттем. Минем бөергә әле берни булмаган, дөбердәп эшләп тора, бу бала бигрәк кызганыч тоелды. Аннан, теге көнне, мәчеттән кайтканда, сөйләшеп кайткан идек бит... Бу дөнья, ахирәт турында... шул да искә төште... Бәләкәй генә булса да, савап булмас микән, дидем, Нургаян...

Нургаян сүз катмады. Наил генә: «И Вәсим абый, тартма тотып чыккан мошенниклар булмаса ярар да соң», – дип, авызын ачмакчы иде, ярый әле вакытында тыелып калды. Кешенең якты ниятенә балта чапкан шикелле булыр иде...

– Ярар, анысы әйбәт булган, ахир, – диде Нургаян, нидер уйлап байтак кына сүзсез торгач. – Элек булмады шул, кая ул чит илләргә барып дәвалану... Андый мөмкинлек булсамы... Зәйтүнәне чит илгә генә түгел, җир читләренә күтәреп барыр идем... Килгән-килгән, үзең дә күренеп чыгасы идең, анлык кына акча миндә дә бар. Әллә кире керәсеңме соң, ахир?

– Кая ул керү! Наил, туктый күрмә... – Вәсим талпына-талпына кул болгады. – Бик китереп кысса, киленер әле...

Тәки тыңлата алмадылар Вәсимне, өчәүләп авылга кайтып киттеләр.

Шуларның барысын уйлый-уйлый, урам буйлап атлаган Нургаян, кайтып җиткәч, үзләренең капка келәсенә кулын салды да кире алды. Ишегалдына кермәде. Гаебе бар кешедәй, башын иеп кенә, капка төбендәге эскәмиягә утырды. Чәй эчкәндә нәрсә ди Вәсимнең хатыны? «Бер румкы эчмәгәнеңә ярты авыл ышанмый», диме?.. «Биргән антың бармы әллә», ди...

***

– Юк-юк-юк, аштан ниткән олы булу ул? – Нәзирә өзми-куймый кыставын белде, Нургаянның лычма су булган телогрейка җиңеннән тартып, өйгә әйдәде. – Өшеп беткәнсең, чиргә олгашасың киләмени? Мәмрәп торган сарык итеннән аш пешердем, чәем кайнаган. Керәсең, керәсең, мине санламаган шикелле борылып китсәң, мәңге бәхиллегем юк, – дип, әллә ниләр сөйләргә тотынгач, Нургаян да, кирза итекләрен лашпырдатып, башкалар артыннан иярде.

Югары очта ялгыз гына яши иде Нәзирә. Күрше авылга кияүгә чыгып, ике-өч ел торды микән, аерылып кайтты да әбисенең иске йортын иплән-сипләп, шунда яши башлады. Ире дә юк, ирсез торганы да юк, дип сөйли авыл халкы, Нургаянның исә, әллә нигә бер күргәндә, исәнме-саумыдан ары сүз алышмагач, аның тормыш рәвеше белән кызыксынганы да юк. Алай гына да түгел, йөз-

чыраен сурәтләп бир, дисәләр, аны да әйтә алмас иде. Колхоз диләнкесен кискән җирдән, Нәзирәгә бер йөк агач кайтарырга кушкач, ялгыз хатынның ишегалдына трактор белән агач кайтарып бушатулары менә. Коеп яуган яңгыр астында ярый әле урманнан чыгып өлгерделәр, батып калсалар, эшләре хөрти иде. Өч ир-ат юан-юан агачларны җитез генә бушатып та ташладылар, аварга торган бакча коймасы буена берсе өстенә икенчесен тезеп тә куйдылар. Яңгыр астында кып-кыска халаттан шәрә балтырларын ялтыратып әрле-бирле йөргән Нәзирә:

– Чыланасыз инде, айкайларым, манма буласыз инде, – дип, алар янында өтәләнде.

– Киптерү синнән инде, Нәзирә, синнән, – дип, аңа күз кысты ирләрнең берсе, пеләш башындагы яңгыр тамчыларын сыпыра-сыпыра.

Хатын колын шикелле иһаһайлап көлеп җибәрде:

– Миннән калмас. Әйдәгез, өйгә үтегез. Чәем дә, мәем дә әзер. Ашым да пешкән, – дип, янбашларын уйната-уйната, баскычка атлады.

Нургаян, тракторны капка төбенә чыгарып куйгач, кайтырга кузгалмакчы булды.

– Нәзирә, җегетләрне сыйла, мин өйгә, – диде ул, болдырдан менеп барган ирләргә кул изәп.

– Юк-юк-юк, аштан ниткән олы булу ул?.. – Ватык патефон шикелле, хатын шул сүзләрне кабатлады.

Ничарадан бичара төстә башкаларга ияреп, Нургаян да өйгә узды. Өс киемнәрен сала башлагач, оекларына тиклем чыланганнарын абайлаган ирләр ишек төбендә икеләнеп калдылар.

– Бер аптырыйсы түгел, салыгыз, сал, мичем кайнар, шунда кибәргә куя торам. Һи, өйдә наски беткәнмени, – дип, күгәрчен урынына гөрли-гөрли, Нәзирә өчесенә дә оекбаш китереп тоттырды. – Кая, оялган кыяфәт чыгарып тормагыз әле, ачуым бер килмәгәе. Мин юеш наски күрмәгән кешеме...

Уйнак та, боеручан да тавышка буйсынган ирләргә сарык йоныннан бәйләнгән ап-ак оекбашларны ялт киеп куярга гына калды.

Пәрдәләре ныклап тартылган тәбәнәк тәрәзә буенда иске генә агач өстәл тора. Хатын җитез хәрәкәтләр белән чуар клеёнка җәйде, ә дигәнче, мич буендагы тумбочка өстеннән алып, каерып киселгән икмәк, табагы белән кайнар ит китереп утыртты, ирләрне өстәл янына дәште. Алар утырышкан арада әллә каян гына кырлы стаканнар да, шешә белән акбаш та менеп кунаклады. Урталай киселгән помидор, кыяр, бөҗралап туралган суган кисәкләре өелгән калай тәлинкә пәйда булды. Тирән тәлинкәләргә аш бүленде.

– Булганыннан җитешегез, эшләгәндәге кебек җимертеп, умырып ашагыз, берүк кыенсынып тормагыз! – дия-дия, Нәзирә шешәне кулына алды, ирләрнең берсенә дә тоттырмыйча, аларны гаҗәпкә калдырып, теше белән ялт кына бөкесен ачты да, көлә-көлә Нургаянга сузды.

– Мәле, Нургаян, бушатып җибәр, күз көеге кебек утырмасын монда. Сезнең хөрмәткә үзем дә тотып куям, – дип, дүрт стаканны аның каршысына тезде.

Нургаян стаканнарның өчесенә аракыны мул итеп агызды, соңгысына төбен күмәрлек итеп кенә салды.

– Мине ул хәтле бетереп ташлама инде, Нургаян, – дип, авызын турсайтты Нәзирә, – тигезләп сал, җәлләмә.

– Сиңа дигәне түгел лә. Үземә ул. Шул җитә.

Нургаянның сүзеннән хатын үзе дә, ирләр дә түшәмне җимерерлек итеп көлеп алдылар.

– Суфыйланып утырма әле. Дөбердәтеп сал. – Нәзирә шулай диде дә, шешәне күтәреп, үзе аракы койды.

Ашамый эчкәнгәме, әллә гадәтләнмәгәнгәме, Нургаянның башына бик тиз китте. Болгаткалап, кайнар ашны бер-ике генә кабып карады да кашыгын читкә куйды. Зәйтүнәсенең җептәй өй токмачын яраткан Нургаянга бармак юанлыгы кибет макароны салынган аш, тәмле генә булса да, тамагыннан үтмәстәй тоелды.

Ә менә аракы үтте. Башта икеләнеп торса да, үз-үзенә ачуы килгән ир салынган аракыны каплап кына куйды. Ә нигә эчмәскә? Ул кемнән ким? Көнозын эшләде. Аруы хак. Күптәннән болай тугарылмавы да хак. Ул да ир-ат. Әнә, башкалар бер дә баш ватып җәфаланмый, Нәзирәне мактый-мактый, итен дә кисәкләп-кисәкләп кабып кына йоталар, аракысына да чырай сытып тормыйлар. Нургаян монда алар кебек тамыр җәеп утырырга җыенмый, тагын печтик кенә авыз итсә... Аз гына, йөрәк ярсуларын басарлык кына... Утыра торгач, тәненә гаҗәеп рәхәтлек, җылылык таралды. Бая гына юан күренгән токмачлар да нечкәргәндәй булды, ир бер тәлинкә ашны төбенә кадәр ашап бетерде. Нидер сөйләштеләр, ул да нәрсәдер әйтеп мыгырданды. Күз алдындагы дүртпочмаклы өстәл дә түгәрәкләнгәндәй тоелды. Нәзирәнең, ялангач беләкләрен, шәрә ботларын ялтыратып, өстәл тирәли бөтерелүе дә, әле берсенең, әле икенчесенең колак төбенә иелеп, кычкыра-кычкыра көлүе дә ачуын китермәде. Янәшәсендә кемдер урыныннан кузгалды, артсыз урындык шапылдап ауды. Кемдер: «Нургаян, кайтабызмы?» – дип эндәшкәндәй булды. «Хәз-зер, хәз-зер», – дип, телен көчкә әйләндерде Нургаян, татлы йокысыннан аерыла алмыйча, урындык аркасына башын салып. Шап-шоп ишек ябылды, күз алдында кемдер әйләнгәләде, менә ул кемдер дигәне аның янына ук килеп басты бугай. Сары май кебек йомшак куллары белән ирнең җилкәсен, муенын иркәләде.

– Нургаян, кил әле, менә монда күчеп ят әле. – Ниндидер ымсындыргыч тавышка һәм кайнар кулларга буйсынып, Нургаян аягына күтәрелде, аларга ияреп, иске шкаф янындагы сиртмәле караватка ауды, өеп куелган мендәрләр ирнең башына ишелеп төште. Колак төбендә Нәзирәнең яна-пешә нидер пышылдаганы ишетелде, кулларын җитез-җитез йөртеп, ирнең күлмәк сәдәфләренә, бил тирәсенә үрелгәне сизелде. Менә ул Нургаянның сул кулын алып, үзенең шәрә күкрәгенә терәде, сабырсызланып, елан күк бөтерелә, шуыша башлады. Ирнең бөтен гәүдәсенә рәхәт чемердәү йөгерде, һәр күзәнәгенә кайнар кан килеп тулды, ул, кайда, кем белән икәнен дә онытып, әлеге дәртле биюгә кушылырга теләде. Ярымачык иреннәре дә, дәрткә тулышып, үзенә иш эзләде. Шул мәлдә, инде идән белән түшәм бер булып әйләнергә әзер мизгелдә, йөзенә Нәзирәдән яңа эчелгән аракы, суган, сарымсак исе килеп бәрелде дә, күңеле болгануга түзә алмыйча, ир кинәт күзен ачты, авызын тотып идәнгә иелергә генә өлгерде...

Минутында айнып китте ул. Эчкән аракысы чыгып беттеме, әллә кайда икәнен аңышудан акылына килдеме, ашыга-ашыга ишек төбендәге телогрейкасына үрелде.

Нәзирә, халатының өске төймәләрен элэктерергә ашыкмыйча, аңа сарылды.

– Тукта инде, Нургаян, иртә бит әле, китмә, – дип пышылдады, күпне вәгъдә иткән һәм күпне көткән күзләрен майландырып. – Курыкма, бөтенләйгә алып калырга җыенмыйм. Ял ит бераз. Миңа да ял булыр.

Ир аның кулларын җилкәсеннән ачу белән сыпырып төшерде.

– Кайтырга кирәк. Зәйтүнә борчыладыр.

– Зәйтүнә? – Нәзирә ямьсез итеп көлеп куйды. – Гарип хатының янына кайтып, ни кырмак буласың? Син өйдә булсаң да ята инде ул, өйдә булмасаң да...

Ирнең күзләрендә яшен уты киселеп үтте, тимер кебек куллары хатынның беләзеген авырттырып кысты да, йөзенә чабып җибәрергә әзер булып, һавага күтәрелде, кире төште.

– Сукты дип уйла.

Нәзирә кызарынды-бүртенде дә, селтәнеп, үзе Нургаянның яңагына сугып җибәрде. Ир аны туктатмады. Уңлы-суллы яңаклаган шәйгә хатын еларга, шыңшырга тотынды:

– Бар, олак, пешмәгән, җебегән, бүкән... Ирмен дигән ир булсаң... Анда гына хатын, имеш...

Нургаян артыннан ишек күк күкрәгән тавыш чыгарып ябылды.

Тракторын кабызып, үзләренә кайтырга чыкканда, яңгыр туктаган, тәмам караңгы төшкән, һәр йортта ут алынган иде. Кайтып җиткәнче, Нургаян үзен битәрләүдән туктамады: «Вәт дивана мин, ә, вәт дивана! Елан авызына шушылай барып керәләрдер шул! Әткәйне дә шул рәвешле генә әверткәннәрдер әле! Их, мин! Дивана, диген, дивана! Зәйтүнәнең күзенә ничекләр карар идем? Их, аңгыра шалкан...»

Ишегалдына караган тәрәзәдә Зәйтүнәнең томраеп торган күз карашы чагылып үтте. Болай да үзен мең гаепле хис итеп, төз атларга тырышкан Нургаян шул караштан тигез җирдә абынып, чайкалып куйды.

Наил йоклаган, әнисе исә мич арасында кайнаша иде. Улына пышылдап кына: «Озакладың бүген», дип эндәшкәне ишетелде. Нургаян, песи адымнары белән басып, Зәйтүнәсе янына үтте, бусагадан атлауга:

– Әнисе, мин исерек. Бераз. Ачуланма! – диде, мәктәп баласыдай оялчан йөз белән, пышылдап кына.

– Беләм, – диде ястыкка терәлгән Зәйтүнә, иренең аягындагы ап-ак оекбашларга күз төшереп. – Әнкәй сөенгәндер.

– Тсс! Күрмәде! – Нургаян бармагын иренендә терәде. Лап итеп диванга барып утырды. – Түлке син ни... ачуланма, әнисе. Вәсим сыйлады. Утырып алдык әзрәк.

– Вәсим? – Хатыны ни өчендер көлемсерәде. – Ә-ә... Син ят, Нургаян, әнкәй күзенә күренеп йөрмә. Арыган, диярмен. Ят.

– Ярар, әнисе, ярар. – Нургаян мең рәхмәтле күзләре белән хатынына яратып карады.

***

– Бабагыз озаклады әле. – Зәйтүнә, башын күтәреп, тәрәзәгә борылды.

– Эскәмиядә утыра бит ул, – диде Гөлүсә, җитен чәчләрен җилфердәтеп, урам якка карап алды да. – Әбекәй, безнең бабыкай кызык инде ул, име? – Кызчык, нидер искә төшереп, челтерәп көләргә тотынды. – Бакчада да җырлап йөри ул, капка төбендә дә. Минем дә җырлыйсы килә дә, мин оялам, кеше ишетсә, әллә ничек.

Зәйтүнә, үрелеп, оныгының аркасыннан сөеп алды, Гөлүсәнең кулында кысып тоткан телефонына, колакчынына ымлады:

– Боларны киеп, бүтәннәр җырын тыңлаганчы, үзең җырла, бабаңа охшагансың, моңың бар, бер дә оялма...

Гөлүсә иреннәрен мәзәк итеп бөрештерде, бер урында басып торалмыйча, аяк очларында бөтерелеп алды. Шул арада ялт кына Зәйтүнәнең муеныннан кочып үтәргә дә өлгерде.

– Әбекәй, син бит бүген шаңгә пешерергә өйрәтәм дигән идең, оныттың бит, – диде, курчакныкы кебек төймә күзләрен зур ачып.

– И сабырсызкай... Онытмадым. Әнкәң келәткә яңа алынган бәрәңге куйдым, дигән иде, шуны алып кер, бәбкәем, өчәүләп тиз генә әрчеп атарбыз. Апаң камыр басар.

– Теге көнне коймак камырын да ул болгатты, монысын мин басып карыйм. Әбекәй, шулай диярсең инде, яме? – Кызчык, кулларын күкрәк турысына куеп кылана-кылана, ялваргандай кыяфәт чыгарды. – Әй, бәрәңгене апкермим лә, ишегалдында гына әрчеп керәбез. Түлке, әбекәй, камырны апама бастырма, ну, пажааалысты... Минем дә өйрәнәсем килә.

– Ярар, бәбкәем, ярар. Икегезгә дә эш табылыр. – Зәйтүнә күбәләк кебек бөтерелә-бөтерелә чыгып йөгергән оныгы артыннан елмаеп кул изәде.

Бәхетләре булсын берүк! Аллага шөкер, икесе дә тәүфыйклы булып үсеп киләләр. Кыз бала – кыз бала инде, аларга он бир, камыр бир, тегесен пешерергә өйрәт, монысын... Хәер, өйрәткәнне генә дә көтеп тормыйлар, телефонны гына кабызалар да, Интернеттан әллә ниләр табып, пешереп тә куялар. Кем кемнән күбрәк өйрәнәдер әле...

Зәйтүнә, терсәкләренә таянып, янә тәрәзәгә борылды. Нургаянның көтү каршыларга дип утыруы микән? Алай дисәң, иртәрәктер әле... Тәрәзә ачык – сыер-сарык тавышы ишетелгән кебек түгел... Уйланып утыра микән? Бу йортка Рәйлә килгәнче, егерме ел буе сыер сауды бит Нургаяны, егерме ел! Иртә таңнан сыерны савып, көтүгә озатты, эштән кайтып керүгә, малларны карап, тагын сыер саварга ашыкты. Зарланам дисә, тел тибрәтер мәлләре күп, һай, күп иде дә соң. Зарланмады. Шушы гомер эчендә «их» дигәне дә булмады ирнең. Оныгы әйтмешли, гел җырлады микән? Елар чакларда да йөрәк сагышларын җыр белән басты микән?.. Күрче, әле дә эскәмиядә җырлап утыра түгелме соң?

Зәйтүнә ястыгыннан калкына төште. Иренең күкрәк тавышы белән үзалдына моңлануы, тәрәзә пәрдәләренә сарыла-сарыла, өй эченә үтеп керде:

Алтын алка сына, диләр,
Сынмый да, бөгелми дә.
Сиңа булган мәхәббәтем
Сүнми дә, сүрелми дә...

И Нургаян, Нургаян... Телеңә түгел, йөрәгеңә сандугач кунган бит синең... Шулай булмаса, сүрелмәгән мәхәббәтеңнераслап, утыз җиде ел буе кулларыңда күтәреп йөртер идеңме?.. Ничәләр әйтте Зәйтүнә: барасы килгән җиреңә бар, миңа гына карап ятма, диде. Клубка концерт-спектакль килсә дә, «бар, күреп кайт», дип үгетләде. Мәҗлесләргә чакырганда да, шул ук сүзләрне әйтте. Нургаянның гына үз сүзе сүз булды: «Юк! – диде. – Аның ише җиргә барсаң, парлап бар инде ул, юк икән – ялгыз каз шикелле, күз көеге булып йөрмә!» – диде, бармады. Зәйтүнә урынга калган көннән башлап, бер генә тапкыр да сәхнәгә менеп, кеше алдында җырламады. Элек ничек хыяллана иде үзе: «Мин җырлармын, ә син, әнисе, ак читекләреңне киеп, күбәләк кебек бөтерелә-бөтерелә биерсең», – ди иде. Насыйп булмады. Ак читек тә өр-яңа килеш сандык төбендә ята бирде. Аларны киеп, Нургаян теләгәнчә, тыпыр-тыпыр биергә дә, керт-керт басып, чишмәгә барырга да насыйп булмады Зәйтүнәгә. Ә менә... ире әйткәнчә, пар булып, гел янәшә булып, ак булып яшәргә язган икән... «Берсе – син, икенчесе – мин», дип көлгән иде Зәйтүнә, шул читекләрне

кулына алып куанганда. Читекләр дә аерылмас пар булып сакланды, Зәйтүнә белән Нургаян да...

Адәм баласы җиргә михнәт белән сыналыр өчен туа, диюләре хактыр. Сабырлык белән сыналадыр. Уңга-сулга әйләнеп карасаң, рәхәт белән, бәхет белән сыналганнар да бардыр, тик аларның берсе дә Зәйтүнә янәшәсендә түгел... Каенанасы Саимәгә кара – үз гомеренең кай мизгелендә рәхәт күрергә өлгерде икән? Сабые, Нургаяны туып, аны кулына тоткан мәлдә бәхет күлендә коенып алгандыр. Шуннан кала? Тома ятимлектә үткән бала чагындамы? Яшьлеген урлаган сугыш чорындамы? Күршеләрнең капка төбендәге кычыткан өчен зар елаган ачлык елларындамы? Ирен тартып алган хатын белән бер авылда, бер урамда гомер кичергәндәме? Әти дип әйтергә тилмергән, әтиле килеш ятим үскән улының күзләрендәге әрнүне күргәндәме? Килен рәхәте күрермен дип хыялланган картлык көнендә авыру килененә үзе таянычка әйләнгәндәме? Кайчан, кайчан гына рәхәт күрергә җитеште икән соң ул? Әллә соң... мәңгелеккә күчкән мизгелдәме? Нәкъ үзе теләгәнчә: җомга иртәсендә, йоклап яткан җиреннән тыныч кына күчте дә куйды бит. Менә шуны бәхет дисәң генә инде... Аңа да сабырлыкны учлап-учлап биргәндер Аллаһы Тәгалә, түз, дигәндер, әҗерен ахирәттә алырсың, дигәндер. Шулай булмаса, ни сабыр дигән каенана да түзәр-түзәр иде дә беркөн килеп улына әйтер иде: «Туйдым, – дияр иде. – Картлык көнемдә минем дә тынычлап яшисем килә, – дияр иде. – Синең дә бәхетле булуыңны, мәшәкатьсез генә яшәвеңне күрәсем килә», – дияр иде...

Ә Зәйтүнәнең үз әнисе? Аның өлешенә тигән көмешләр дә – шушылар бит инде, шул чорның ачыдан-ачы нигъмәтләре: сугышы, ачлыгы, колхоз коллыгы... Аның да бар юанычы, бар бәхете һәм бар бәхетсезлеге – карап торган Зәйтүнәсе иде бит... Үз балаңның «әнкәй» дип күзгә карап тилмереп ятуларын күреп тору – җирдәге тәмугка тиң булгандыр лабаса... Ни сабырлыклар белән түзде икән соң бичара ана? Кайлардан көч алды икән? Берәр бөртек күз яшен күрсәтсә... Берәрсенә барып зарын түксә... Берәрсен гаепләсә... Берәрсенә дәгъва белдерсә... Күңеле мөлдерәмә тулы мәлләрдә камзул кесәсенә салган дисбесен чыгарыр иде дә иреннәрен кыймылдатыр-кыймылдатмас кына зикер кылып утырыр иде. Хәл-әхвәл сораучы булса, «Аллага шөкер әле», дип җаваплар иде. Ул да сабыр булып яшәде, сабыр гына китеп барды. Авырлыкны бергә бүлешкән ике карчык, җәннәт ишекләреннән үткәндә дә, бер-берсеннән калмаска теләгәндәй, бергә киттеләр. Әнкәсенең йөзенә яулык япкан Нургаян ишегалдына чыкканда, Халисәттәйнең комган күтәреп койма буйлап килеп барышы иде. Әлеге хәбәрне ишеткән карчык: «Хәзер, кияү, кереп җитәм», дип калса да, бусаганы үз аягы белән атлап кермәде. Эзләп чыкканда, ул комганын җиргә куйган, үзе баскычка утырган да, ял итәргә генә теләгәндәй, яны белән сөялеп, күзләрен йомган иде.

Нургаян белән Зәйтүнә ничек түзделәр икән? Ике әнкәйне бер көнне мәңгелеккә озатуны ничекләр күтәрделәр икән?.. Мең дә беренче кабат «Аллага шөкер», дими, тагын ни дисең – бирде бит, сабырлыгын да, түземлеген дә бирде! Йөрәк кыл урталай ярылыр яки капылт кына туктап калыр мизгелләрдә дә яшәү көче бирде...

«Минем хәлне дошманыма да күрсәтмәсен». Бу сүзләрне Зәйтүнә күңеленнән генә дә, кычкырып та ничә әйткәндер... Утыз җиде ел... Йа Раббым, бу аякларны да чыклы үләннән яланаяк йөгереп йөрсен, балаларны каршылыйм дип капка ачарга йөгерсен, җиргә басып йөрсен дип яралткансыңдыр да соң, юклык белән сыныйм

әле дип, үзең үк сынау җибәргәнсеңдер... Күтәрә алырдаен... Ярты гәүдә белән булса да тырышып-тырмашып яшә әле, яшәү көчен югалтма, син бу дөньяга яшәр өчен килдең, дигәнсеңдер... Янында Нургаяны булмаса, сабыр канатлары гына түгел, яшәү теләге дә әллә кайчан каерылып, сынып, изелеп беткән иде. Ул булды, бүгенгәчә «Зәйтүнәкәем» дип дәшәрлек мәхәббәте булды, җан җылысы булды. Төчеләнмәде, әмма «бигрәкләр дә каты яраттым шул үзеңне» дигән сүзләрне кабатлаудан туктамады. И Нургаян... Сүз бирсәң, үтәми калмадың шул...

***

Нургаянның мәчеткә юл тотуы иде. Әбәдкә бикләнгәнче дип, почтага да сугыласы итте. Килеп керде дә аптырап калды: компьютер каршында утырган Мәрзия борынын тарта-тарта мышык-мышык елый, өстәлдә яткан телефоннан бер җырчының «Дәшмәгез, дәшмәгез» дип өзгәләнгәне ишетелә.

– Берәрсе кыйнадымы әллә, Мәрзия, суган суы түгәсең? – дип шаяртырга итте Нургаян, ни әйтергә белмәгәч, уенга борып.

Мәрзия, тутырган тавык кебек гәүдәсен көчкә кыймылдатып, урыныннан торды, тәрәзә төбендәге сумкасыннан кулъяулык чыгарып, күзен, борынын сөртте. Стенага эленгән көзгегә карап, сарык йоны кебек бөдрәләткән кыска сары чәчләрен рәтләгәндәй итте. Шуннан соң гына Нургаянга борылды.

– Жәлке бит. – Хатын ияге белән әле дә булса җыр яңгыраткан телефонга ымлады.

– Телефоның ватылдымы, дисәм... – Нургаян, аптырап, җилкәсен җыерды.

– Җырчыны әйтәм. «Йөрәгем урталай ярыла», дип җырлый бит, бичаракаем. Бәй, син дә кырык укыгансыңдыр инде, Нургаян абый, иң күп гәзит синдә: бөтен җиргә яздылар, ире белән аерылышкан бит, җаныкаем. Телевизордан да күрсәттеләр. И-и, күзкәйләр генә тигәндер, башкача булмас... – Мәрзия тагын күз төпләрен сөрткәләде. – Шушы җырын тыңлыйм да елыйм, тыңлыйм да елыйм, бигрәкләр дә кызганам үзен. Йөрәгем ярыла, ди бит, ярыла, ди!

– Шул гынамы? – Нургаян көлемсерәп куйды.

– Нәрсә шул гынамы? – Мәрзиянең күзләре шар булып түгәрәкләнде.

– Башка бер кайгың да юкмы, дим? – Нургаян утка-газга түләргә дигән кәгазьләрне кесәсенә кире салып, ишеккә борылды. – Намазга соңга калам бугай...

– Ярар, без пенсиягә чыккач йөрербез инде. Вәгазь тыңларга да вакыт булыр. Әле берсенә-бер җитешә торган түгел. – Мәрзия, авыр сулап, телефоныннан яңа җыр кушты.

Нургаян, урамга чыккач, кәләпүшен салып, ни өчен икәнен дә аңламастан, кулында әйләндерде, бик дикъкать белән эчке ягына текәлеп торды. Гүя башы уйсыз, буп-буш калган иде, шушы сәер халәттән арына алмыйча, ике-өч адым атлады да, мәчетнең бөтенләй бүтән якта икәнен абайлап, кире борылды. Шунда гына исенә килде. Нишләде бу дөнья, нишләде? Ризыкка да, малга да туеп сикергән халык кайсы якка, кайчан, кем артыннан салулап китте? Кара инде бу Мәрзияне, үз тормышында бер хәсрәте юк кешедәй, артист хатын өчен күз яше түгеп утыра. Үз улына акыл сорап, елый-елый дога кылса, аңлар да идең. Утыз яше тулып килгән малае, авыл халкы алдында рисвай булып, эчеп, азып-тузып йөри, өйләнергә дә исәбе юк. Аңа да әйтеп караганнары булды: мәчеткә сугыл, тыңлап булса да утыр, диделәр. Багана буйлы егет, саргайган тешләрен күрсәтеп, ыржаеп кына көлде, нәкъ әнисе кебек: «Пенсиягә чыккач йөрермен әле», – диде. Ярый ла сиңа ул яшькә җитәрлек гомер язылган булса... Гомер язылып та, акыл керерлек булса... Вакыт юк, диләр. Гыйбрәтле сүз

тыңларга вакыт юк, ә җыр тыңларга, ул җырчыларның эчке киемнәренә чаклы салып чайкаган гайбәтләрне ишетергә, укырга, чәйнәргә вакыт бар – шунысына шаккатарсың! Дөнья кендеге – артистлар хәзер, кеше күзе алдында алардан да кәттәрәк беркем, һичнәрсә юк. Бот буе бала-чагадан алып ак сакаллы бабайга кадәр кайсы артистның кем белән торганын, нинди машинада йөргәнен, аена ничә сум штраф түләгәнен белә, тик... үзенең яшәү мәгънәсе, яшәү асылы турында гына белми, белергә дә теләми. Ул бүген яши, ашый, эчә – шунысына канәгать. Туфрактан яралган кеше янә туфракка әверелгәч, ни булыр, анда ни көтә; адәм баласына яшәү һәм үлем биргән Аллаһы Тәгалә хозурына нинди гамәлләре белән барыр – мондый сорауларга җавап эзләп тинтерәмиләр. Эх, Нургаян үзе дә хакыйкать асылына соңлап төшенде. Күпме яшәп, чын-чынлап, чәчләрне йолкып үкенерлек бер генә гамәле бар: бала чакта, яшьрәк чакта кул күтәреп дога кылуны, намаз могҗизасын белмәде. Чорга сылтаргамы? Пионер, комсомол булып горурланып йөргән елларның денсезлегенәме?..

Бүгенге акылкае булсамы... Ул чакта ук алдына намазлык җәяр иде дә сәҗдәгә егылыр иде. Намаз соңында, күз яшьләреннән тартынмыйча, дога кылып, Аллаһы Тәгаләдән сорар иде. Күпне түгел, бала вакытта бер генә теләген ирештерер иде: әткәсен, күреп туялмаган, җанга якын газиз әткәсен үз янына кайтаруны сорар иде. Аһ, әтиле килеш ятим булуның авырлыгы! Таулар да, кыя ташлар да күтәрә алмас ул авырлыкны үз башыннан кичергәннәр генә беләдер. Әллә кайда да түгел, бер авылда, бер урамда бит әткәсе! Күрешкәндә «улым» диеп дәшсә дә, җан ярасын басарга шул сүз генә җитә димени? Яңа оясында яңа хатыны да, яңа балалар да Нургаянны чит итмәделәр анысы, караңгы чырай каткан кеше булмады, килеп керсә, чәй эчәргә дәштеләр, бер ата балалары, дип, туган итәргә тырыштылар. Шулай да, шулай да... Әткәй бит ул! Берәү генә бит ул! Ничекләр аны икегә бүлмәк кирәк?.. Урамда «Урал» матаеның тавышы ишетелә калса, Нургаян ишегалдына атылып чыгар иде. Койма ярыгына сарылыр иде. Ике күзе, чишмә кебек мөлдерәмә тулып, шул ярыктан кара матайны каршы алыр, озатып калыр иде. Менә аның әтисе, телогрейкасының изүләрен ачып, учма-учма чәчен җилгә сибеп, урам буйлап матайда килә. Артына, биленнән ике кулы белән кочаклап, төпчек малае утырган! Тешсез авызын ерып, иң бәхетле кеше кыяфәтендә елмаеп бара! Борын очына сибелгән сипкелләренә кадәр елмая! Ул бәхетле! Чөнки аның әтисе үз янында, якында, янәшәдә. Малай шуңа күрә елмая!

Әтиле әтисез Нургаянның койма ярыгына берегеп калган күзләреннән исә тамчы-тамчы яшь коела...

Зәйтүнәсе өчен дә намазлыкка егылып сорый белмәде – үкенеч булмый, ни булсын? Сынау килгән мәлдә ярдәм сорап кешеләр катына гына барып баш иделәр шул, кул күтәреп дога кылуны уйламадылар, намазны белмәделәр... Кешеләрнең дә төрлесе очрады. Бәхеткә, яхшылары күбрәк иде. Авылдашлар дисеңме, туганнар, дуслар... Әткәсе дә, аның ул нигездә туган балалары да бер йодрык булып ярдәмгә ашыктылар, кайгы килгәч, авырлыгын алар да күтәрде. Фельдшер Рәхимә апаны әйт син... Көнен чакырасыңмы, төненме, мәҗлестә утырган чагымы, мунча кереп ятуымы – юк диюне белмичә, йөгереп килеп җитә иде... Авыл үзенең гадилеге, ихласлыгы белән бу хәсрәтне ничек тә җиңеләйтергә, бүлешергә тырышты. Шәһәр күпкә кырысрак иде... Бер-бер кәгазе булмаса, кешене бөҗәк урынына да күрмәгән эреле-ваклы оешмалары шактый иде аның. Инде җыелып бетте дигән документлар арасыннан койрыгы ошап бетмәгән имзага бәйләнеп булса да тәм табучылар бар иде. Ишектән ишеккә йөртергә яратучылар байтак иде. Инвалид

кешенең генә түгел, сау-сәламәтнең дә бер кадере булмавын күптән аңлады инде Нургаян, шуңа күрә тиешлесен дә даулап йөрмәде, кул гына селтәде. Селтәмәс тә иде... Бер баруында, озын тырнагын да, иреннәрен дә кып-кызылга буяган, керфекләрен буяуга катырган ханымның: «Хатыныгыз һаман исәнмени әле?» – дип соравын ишетте дә, өстәлдә таралып яткан кәгазьләрне учына йомарлап, кабинеттан чыгып китте. Коляскасын да, арбасын да башларына капласыннар, ике кулы бар чагында, Зәйтүнәсен күтәреп йөрмәскә...

Йомгак урынына тәгәрәгән уйлардан азан тавышы арындырды. Нургаян, адымын кызулатып, мәчет ишегалдына атлады. Ул эчкә үткәндә, яшел келәм өстенә дүрт-биш кеше тезелеп баскан, иң читтәгесе – туйга килгәндәй ак күлмәк, кап-кара костюм-чалбар киеп, яланбаш кына торганы – кайчандыр шофёр булып эшләгән Ренат иде.

Аны күргәч, Нургаян ни уйларга да белмәде. Утыз җиде ел эчендә Ренат белән бер генә авыз сүз дә алышканнары булмады аларның. Күрешкәндә, ияк кагып кына исәнләшкәндәй итеп үттеләр, актан-карадан бер-берсенә сүз катмадылар. Аның әлегәчә мәчеткә аяк басканы күренмәде. «Зәйтүнәнең хәле ничек?» – Ренатның теленнән шушы бер сорау төшсә, Нургаян җанын кысып торган кыршаудан котылыр иде. Юкса, күңелендә алып аткысыз ачу да, үпкә дә сакламый, теге вакытта Зәйтүнә дә кат-кат әйтте, гаепләп, тәмсезләнеп йөри күрмә, ашлык төягечне юри аударган кеше түгел, диде. Барысын да аңлый Нургаян, тик бер нәрсәне генә аңламый: ни тота, ни тыя бу кешене күңел хакы өчен генә булса да хәл-әхвәл сорашудан?

Намазы намаз булмады ирнең. Уйлары чуалды, ничек кенә бирелеп укырга тырышса да, сәҗдәгә иелгәндә, күзалдында Ренатның шәүләсе бөтерелде. Доганы да ашык-пошык кылып, кайтырга кузгалды. Тик мәчетнең тимер капкасына үрелүгә, арттан куып җиткән тавыш кулына китереп органдай булды:

– Нургаян... ашыкмасаң, сөйләшер идек...

Нургаян, үз колакларына үзе ышанмыйча, артына борылды. Аннан, чалбар өстеннән чыгарып куйган күлмәк итәгенең вак шакмагында тузан бөртеге күреп, бармак очы белән шуны каккалады. Капка келәсендә дә бер-бер тап булды, ахыры, икенче кулы белән аны сөрткәләде.

– Ашыгыр җир... юк инде. – Шуннан соң гына Ренатка күтәрелеп карады.

Нургаяннан өч-дүрт яшькә генә олы булса да, Ренатның чәче агарып, маңгай турысыннан коелып беткән. Бүген кияү егетедәй киенсә дә, ыспай костюмы астыннан иңсәләренең салынып торуы шәйләнә. Авыруы бар икән, ике кулы да бертуктамый сизелер-сизелмәс калтырый. Элек зәп-зәңгәр булып янып торган күзләре уңып киткән, тоныкланып калган. Шулай, картлык килсә, яшьлекнең төсен урларга дип килә шул...

– Юл өстендә торганчы, тегендәрәк барып утырабызмы соң... – Ренат ишегалдының кашкарыйлар үскән почмагындагы эскәмиягә ымлады.

– Утырып сөйләшерлек сүзмени? – Нургаян төртмә телле түгел иде, шулай да тавышында киная яңгырагандай булды.

Ике ир эскәмиянең ике башынарак килеп утырдылар. Берсе дә сүз башламады. Капкадан берәм-берәм чыгып киткән агайларны күз карашы белән генә озаттылар. Тирә-якта хушбуй булып таралган кашкарыйлар исе һәм төклетура тавышы гына торып калды.

Бераздан гына Ренат тамак кырып куйды:

– Киләсе килгән ие. Мәчеткә, дим. Әллә кайчаннан.

– Яхшы иткәнсең.

– Хатын килә. Күптәннән. Гарәпчә укырга да өйрәнгән.

– Беләм. Икәү-өчәү инде алар. Чәчәкләрне дә шулар үстерә.

– Мулланы әйтәм. Яшь булса да, акыллы күренә.

– Гыйлеме бар. Эшләсен генә.

– Тавышы моңлы. Күздән яшь килде прәме.

– Вәгазьне дә шәп сөйли.

– Кеше әз икән.

– Килерләр. Син дә килгәнсең бит. – Нургаян читкә карап кына шулай диде. Ул баядан бирле сүз башлануын көтә иде.

Ренат төртелеп калгандай булды. Алай да үзен кулга алды, салмак тавыш белән дәвам итте:

– Килдем. Җанга тынгы табып булмас микән, дидем... Ышансаң ышан, ышанмасаң юк: әле бүген белер-белмәс укысам да, шулкадәр рәхәт булып китте! Ничә еллар... мин дә тынгы күрми яшим бит, Нургаян... Үземне-үзем ашап... Көчем җитмәде, сезнең урамга төшеп, капкагызны ачып керергә, Зәйтүнәне күреп, гафу сорарга көчем җитмәде. Бүгенгәчә. Әгәр шул вакытны... саграк булсам... Болай да килеп чыкмас иде... Син мине күрми, белми, дөньяның артына тибеп яши дип уйлама. Күреп торам, Зәйтүнәне кулларыңда күтәреп йөрүеңне дә күрәм, күргән саен үземне кимерүем арта гына... Арыдым мин, Нургаян, җилкәмне баскан йөкне күтәреп арыдым... Яшәлде инде. Гомер дә әллә ни арада узды да китте. Күңел тынычлыгы булмагач, яшәүнең дә яме юк. Үземне дә уйлыйм, сезне дә... Хатын әллә кайчаннан ачулана. Намазга бас, Аллаһыдан гафу сора, ди. Тәүбә итәргә куша. Баштарак җен ачуым чыга иде шулай дигәненә. Тәүбә итәргә, мин җинаять кылган кеше түгел, төрмәдә утырмыйм... Тора-бара аңладым: яшәвемнең төрмәдәгедән кай җире артык? Үз-үземне бикләгәнмен инде мин... Бүген монда килгәч, әйтәм бит, әллә ничек булып китте... Зәйтүнә янына барсам... Бәхиллек сорасам... Нәрсә диярсең, Нургаян?

– Мин ни әйтим? Зәйтүнәдән сора. Килгән кешене куып чыгарганы юк...

– Шулай дисеңме? – Ренатның тавышы сизелерлек җанланды. – Алайса, кичкә таба... сездән урап китәм. Зәйтүнәне күрәм. Каршысына утырып, сүзләремне әйтәм, яме?!

– Алла боерса, диген, Ренат.

– Ә? Юк, киләм булгач киләм инде. Син каршы килмәгәч... Кич абызателне киләм.

– Алла боерса, диген. Кичкә кадәр кем белән нәрсә буласын бер Аллаһы Тәгалә генә белә.

– Ә-ә-ә... – Ренат, каударланып, урыныннан торды. – Киләм, Алла боерса. Киләм.

***

Көзге кояш димәссең, хәйран юмарт елмаеп маташа иде. Хәзер язы – язга, җәе – җәйгә охшамаган: кешеләрне генә түгел, табигатьне дә аңламассың. Яз ашыгып килә, җәй ашыгып китә. Барысы да каядыр ашыгалар, кабаланалар. Яшәп калырга ашыгумы бу? Ә бит, баксаң, никадәр генә кабаланма яки никадәр генә салмак кыланма, һәр сукмакның ахыры – бер нокта, бер чик. Ул чикнең теге ягында – башланмаган чиксезлек...

Ниткән көн булды соң бу? Дулкын-дулкын булып, әллә нинди уйлар чигә буйлап бәреләләр дә сугылалар. ...Нургаян, үзенең эленке-салынкы гына атлавын абайлап, гәүдәсен турайтты, адымын тизләтте. Һи, элек кенә ул, илле-алтмыш

яшькә җиткән агайлар инде авыл аксакалы, яшисен яшәгән карт бабай булып тоела иде, аларга башын иеп, бөкрәеп, аяк сөйрәп атласа да килешәдер шикелле иде. Үзеңә килеп кагылгач, алтмышында да, алтмыш бишендә дә картайган кебек түгел икән лә, күңел һаман яшь... Шулай дип уйлагач, күңеле күтәрелеп китте, аякларына җитезлек иңде. Баш иеп атларга соң... Күр, дөньясы нинди матур! Күктә ник бер болыт кисәге күренсен – чалт аяз, зәп-зәңгәр гөмбәз. Әле үләннәр дә күзгә бирешергә җыенмый: ямь-яшел булып утыралар. Матур дөнья, матур... Хәтта бик ямьсез дигән җиреннән дә матурлык табарга була, күңел күзеңне генә ачып кара. Зарланырга, уфтанырга, таллар кебек бөгелергә, чал имәннәр кебек чартлап сынарга ашыкма гына. Яшәргә килгәнсең икән, яшә! Чөнки... шулай кирәк. Яшәргә, ничек тә яшәргә кирәк...

Үз урамнарына борылам дигәндә, тыкрык буйлап судан кайтып килгән кыз баланы күреп, Нургаян барган җиреннән туктап калды. Кызның иңбашында көянтә-чиләк, өстендә – күкрәкчә дә кендеген күрсәтеп торган кыска ыштан, аякларында... ак читек иде. Нургаян берничә адым атлады, күзләрен челт-мелт китереп, шул читеккә төбәлде. Читек үк түгел, әллә ниткән хикмәтле, тишекле-тишекле, чүпрәк дисәң чүпрәккә охшамаган, оек дисәң – оек булмаган киң балтырлы ак итек икән... Көянтәле кыз, аңа сәерсенүле карап, ашыгып кына узып китте, Нургаян исә, борылып бер күз салды да, чалымнарыннан Вәсимнең шәһәрдән кайткан оныгы икәнен искәреп, үзеннән ераклаша барган читекләргә янә текәлеп карады. Бу балакай үзенең никадәр бәхетле икәнен дә абайламый бит! Бәхетнең ни икәне хакында уйланганы да юктыр, чишмә чагылышында да, көзгедә дә үзенең яшьлеген генә күргән чагы...

Зәйтүнәнең ак читекләре исә өр-яңа килеш сандык төбендә саклана... Пар булып, бүгенгәчә ак булып... Нәкъ аларның хисләре кебек... Сынаулардан кер дә, тузан да кунмаган мәхәббәтләре кебек. Әйе, читекне киеп туздыру насыйп булмады Зәйтүнәсенә, аларны киеп, бизәкле көянтәсен асып, су юлына бару да насыйп булмады. Тик Аллаһы Тәгалә аларга бәхетсезлек белән сынаган бәхетне дә бирде ләбаса... Пар канат булып, бер-берсенә кирәк һәм терәк булып, бер-берсен яратып яшәү бәхетен бирде.

Таһир-Зөһрә, Ләйлә-Мәҗнүн кебек бер-берсе белән кавыша алмаганнарның мәхәббәтен җырга салганнар. Кыйсса итеп язганнар. Телдән-телгә сөйләгәннәр. Һи-и, кавышып, бер түбә астында яшәсәләр, мәхәббәтләре күпмегә җитәр иде икән? Нургаян белән Зәйтүнә шикелле, көн саен бер-берсенең күзенә карап, «әле дә син бар», дип, кырык ел буе яшәп күрсәтсеннәр иде алар...

Тукта, тукта, нәрсә дип көн буе агын-карасын уйлап, бизмәнгә салып йөри дисә... Нинди көн соң әле бүген? И-и, кешегә пенсияне тикмәгә бирәләр, дисеңме... Хәтер, диген! Зәйтүнәсе белән язылышкан көннәре бит! Кырык ел элек, нәкъ шушы көнне, ак күлмәккә, ак калфакка төренгән Зәйтүнәсен кулларына күтәреп, үзләренең бусагасын атлаган иде. Гомеркәйләр, диген... Кырык ел үткән!.. Җырга тиң гомер бит! Сагышлы, моңлы, үзәк өзгеч булса да, җырга тиң!..

Әле дә син бар әле бәхетемә,
Әле дә син бар әле дөньяда.

Нургаян, учына бәхет кошы кунгандай канатланып, теленә килеп сарылган җыр сүзләрен көйли-көйли, Зәйтүнәсе янына ашыкты.

# ҖӘҺӘТ ТӘНКЫЙТЬ

*Хөрмәтле укучылар! «Казан утлары» журналы әле генә «табадан төшкән» – укучы кулына барып ирешкән әдәби әсәрләргә тәнкыйди анализ-бәя бирә торган «Җәһәт тәнкыйть» сәхифәсен ачып җибәрә. Тәнкыйть материалларына куела торган төп таләп – текстның һәм уңай, һәм җитешмәгән якларын күрсәтү. Яңа исемнәргә, яшь авторларга игътибар юнәлтеп, сәхифә сәләтле, каләмле яшьләр өчен иҗат лабораториясенә әйләнер, әдәбият мәйданында үз сукмакларын, үз язу стильләрен табарга ярдәм итәр дип исәплибез. Җәһәт тәнкыйть язмаларындагы бәя белән килешмәгән укучыларыбызны сайланган әсәр хакында сөйләшүгә кушылырга чакырабыз.*

### Айгөл Әхмәтгалиева. «Ак читек»

Айгөл Әхмәтгалиева – яраткан авторларымнан. Әсәрләрен укый башласаң, җырлап торган сөйләме үзенә тарта. Аның әдәби телендә Фатих Хөсни аһәңнәре яңгырап китә. Әмма бу – лиро-эпик тел, нәсер, шигъри проза теле түгел. Матур әдәби телне заманча хәрәкәттәге тормыш вакыйгаларын тергезү белән куша алган эпик хикәяләү бу. Урынлы һәм уйлап сайланган һәр сүз тирәлекнең матур сурәтен тудыра, шул сурәт күз алдына килеп, сине олы җанлы, матур күңелле кешеләр дөньясына алып кереп тә китә. Укый башладыңмы – аерыла алмыйсың.

Яңа повесть белән дә шулай – «Ак читек»тә Нургаян белән Зәйтүнәнең беренче сөйләшүенә «колак салуга», алар тормышы белән яши башлаганыңны сизми дә каласың! Аларның өе-дөньясы да, камыр пешерергә әзерләнгән өстәл дә, бабалары белән сөйләшкән Гөлүсә һәм Илүсә дә – шушы ике кешенең бар тирәлеге күз алдында җанлы булып калка.

Повесть – бүгенге авыл тормышының иң актуаль проблемалары (үзара салым җыю, чүплекләр, кешеләрнең усаллануы һ.б.) фонында гаҗәп матур мәхәббәт тарихын тергезә, шушы мәхәббәт сынавында кешенең олы җанлылыгына, түземлегенә һәйкәл коя.

Яратып өйләнешкән, беренче уллары туган гаиләгә бәла килә – Зәйтүнәнең аркасына погрузчик авып, яшь хатын аяксыз кала. 37 ел хатынын караган, «кулларында күтәреп йөрткән» ир аны яратудан туктамый; җор телле, киң күңелле, олы җанлы Нургаян, сабыр һәм түзем, акыллы Зәйтүнә искә төшерүендә автор аларның беренче танышу көннәрен дә, өйләнешүләрен, бәхетле тормышларын, больница юлларын да, яңадан яшәргә өйрәнүләрен дә күз алдыннан үткәрә.

Геройлар идеаллаштырып тасвирланганнар. Аларның тормышы, дөньяга карашы, эш-гамәлләре сокландыгыч бер поэма хасил итә. Айгөлнең сөйләм теле

шулкадәр йөгерек һәм сыгылмалы – кызганудан күзләрдән яшьләр килә, кеше күңеленең олылыгына карата горурлык уяна – хисләр бәйләме кичерәсең. Әмма, тормыш нинди генә авырлыклар китерсә дә, бәхетле, шөкер итеп яшәгән кешеләр тарихының ышандыру көче зур түгел. Әкиятләрдәгечә уңай һәм тискәрегә аерылган геройлар, шушы ак һәм карага бүлеп бәяләнгән дөнья схематик тоела. Нәтиҗәдә, төп геройларга карата кулланылган психологизм, укучыны көчле кичерешләргә дучар итсә дә, фикри киңлеккә алып чыга алмый. Нургаянның эчке монологлары – һич тә авырлыкны үз җилкәсенә күтәргән көчле ирнеке булмыйча, хисле хатын-кыз уйларын хәтерләтеп куя. Әйтик, ирнең гамәл дәфтәре турындагы, хатынын ялгыш рәнҗетмәдемме дигән уйланулары *(№2, 61 бит)* шундыйлардан. Зәйтүнәнең кичерешләре дә, психологик яктан үзгәрү, икеләнү, тормыштан ваз кичү, кабат терелү нокталарын урап узып, гел «яхшы кеше» амплуасында кала. Әйтерсең лә язучы бу геройларын гади кешеләр кичерергә мөмкин сызлану, көнләшү, рәнҗү кебек хисләрдән араларга омтыла – нәтиҗәдә, алар олы характер буларак күренми. Ринат яки Нәзирәгә, Сафиуллин яки авыл җитәкчеләренә карата психологизм кулланылмау бу геройларны тискәре герой төркеменә кертеп куя. Ак һәм кара бәрелешә – яхшылык җиңеп чыга!

Әкияти схеманы язучы символлар белән тирәнәйтү омтылышы ясый: әсәр башында әйтелгән ак күбәләк, мәхәббәт хисе символы итеп уйланылган ак читек, шул ак читекнең әсәр ахырында Вәсим оныгының аягындагы итектә «кабатлануы» – шундыйлардан. Әмма болар гына мәхәббәт сюжетын повесть таләп иткән иркенлеккә чыгармыйлар.

Әлбәттә, «Золушка сюжеты»н әдәби катламнарның берсе итеп, заманча повестьлар язучылар, шуның белән әдәби уңышка ирешүчеләр юк түгел. Әмма бу вакытта шул әкияти тарих янәшәсендә башка тарихлар тергезелү шарт. Айгөл повестенда да тагын бер яки ике тарихның янәшә-уралып урнашуын күрәсе килә.

Повестьларны иҗтимагый, фәлсәфи мөстәкыйль катламнар белән баету да киң таралган. Ләкин моның өчен без өйрәнә торган әлеге әсәрдә детальләр булып чәчелгән хәзерге авыл турындагы өлешләрне – андагы тулаем үзгәрешләр тарихы буларак күз алдына китерерлек итеп зурайту сорала.

Гәрчә Айгөлнең хикәяләрендә без шушы берничә башлангычны тоташтыруның матур үрнәкләрен очратабыз. Әйтик, «Кайтаваз» хикәясендә психологизм да, фәлсәфә дә, иҗтимагый-сәяси бәя дә бер үремтәдә килеп, әсәрне көчле бер әдәби яңгырашка алып чыга: аны кат-кат укырлык әсәр ясый. Димәк, әдәби осталык та, мондый төр әсәрләр язу тәҗрибәсе дә бар А.Әхмәтгалиевада. Мин аннан, татар әдәбиятының Ә.Еникиләрдән килгән күпкатламлылык традицияләрен дәвам итеп, сүз сәнгатебезне дөнья әдәбияты фонында күрсәтерлек повестьлар көтеп калам.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*



Гөлүсә
Батталова

# РӘШӘ ИДЕ ЕРАК ДӘВЕРДӘН

## Үзең булсаң...

Палачларның явыз бурзайлары
Йолыкканда горур җанымны –
Үзең булсаң! – димен. – Үзең булсаң! –
Дөнья белмәс гаҗиз чагымны.

Үзең булсаң, төн куеныннан шыткан
Таңда күрмәс идем кан төсен.
Үпкәләргә тулган шөбһәләрнең
Син таратыр идең барысын.

Телсез-чукрак тәкъдирләрдән аяп,
Үксезлектән йолыр идең дә,
Дала бәгырендә онытылган
Канатлы рух калкыр иңемдә.

Үзең булсаң, бишек җырларыма
Акланууны кушмас идем дә...
Үз канымнан җиде ятлар туса,
Ни йөз белән багыйм Иделгә?!

Дөньясына аңлатасы иде
Бу туфанның бөтен дәһшәтен...
Татар дигән бөек исемең бар –
Үзең булсаң икән, ДӘҮЛӘТЕМ!

Гөлүсә БАТТАЛОВА – *шагыйрә; «Бер йотым бәхет» исемле китап авторы. Әтнәдә яши.*

## Очар идек...

– Канат булса, очар идек! – дисең.
Күкләр – биек! – дисең. Белмисең –
Күккә ашкан күпме канатсызлар
Хәтерләми бүген җир исен.

Күкләр барын искәрмәгән күпме –
Канатлары исән килеш тә!
Биеклектә очу бөеклеге
Хөр җаннарга бары килешә...

– Очар идек... – дисең, – көнләшсеннәр
Түбәнлеккә дучар үзәннәр!
Очар идек тә бит, туганчы ук
Канат очын безнең кискәннәр...

## Тагарак

Бүген генә ярылмады ла ул!
Күптән инде, күптән чатнады...
Ул үзе дә оныткандыр кебек
Яраларсыз, гамьсез чакларын.

Ыңгырашты юкса – кем ишетсен?!
Колакка бит монда катылар.
Дала рәшәсендә юл бутаган
Бүгенгене иңләр атлылар.

Яргаланды... тузды... чәрдәкләнде...
Черек агач төсе йөгерде...
Дәшәм, диеп, кыюлыгын җыйды –
Әрсез эпипәләр бүлдерде...

Ә беркөнне! Күздән шуып төшеп,
Чәлпәрәмә килде күзлекләр.
Тагаракта – ярык. Ә кесәдә...
Ә кесәдә – иске берлекләр...

Ахырзаман! – диеп шаулаштылар,
Бүген – матәм, бүген ят та үл!
Ә тагарак?
Ә тагарак күптән...
Күптән инде ярык иде ул...

## Сиңа сыенам

Кара көзнең вак шәүләсе бии,
Дәрман алып учак туеннан.
Дөнья гамен учка йомарлыйм да
Сулык-сулык сиңа сыенам.

Җан түренең бакый шамаиле
Тузанланган шушы дәвердә
Синдә эреп, синдә югалуым
Табигый да кебек, сәер дә...

Дөньясыннан бер уч җылы тапмый,
Аңлау тапмый газап чиккәндә,
Тансыкланган икән кайнар тының
Яшьли кырпак төшкән чигәмдә.

Җан тартмаган тәүбәләрне әйтеп,
Кире кайтып шомлы уемнан,
Кара көздән кышка тапшыр, диеп,
Коткар, диеп, сиңа сыенам...
Сиңа... сыенам...

***

Син, мәхәббәт, безгә соңлап килдең,
Сүнде инде җәйнең кузлары...
Януларсыз чатнап кипкән йөрәк
Сулык-сулык рәхәт сызлады.

Соң икән... Соң... Язмыштыр бу, диеп,
Кабул итсәк Күкләр хөкемен –
Кем ярлыкар? Кем әҗерен түләр
Бу җиһанда ялгыз үксүнең?

Син, мәхәббәт, безгә соңлап килдең...
(Күзләрнең юк тамчы гөнаһы!)
Тере җанның соңгы талпынуы –
Язык диеп язма, Илаһым!..

## Калатау

Беләм – җирдә Чатыртаулар барын,
Айгыртаулар барын күккә ашкан...
Калатауга менеп җан яңартсам,
Яши башлыйм төсле яңабаштан.

Беләм – җирдә биеклекләр барын,
Бөеклекләр барын чиктән ашкан.
Калатауның тыйнак олпатлыгы
Кадерлерәк миңа кыя таштан.

Беләм – җирдә хак тарихлар барын,
Ялган әкият барын көчләп таккан.
Үз-үземне эзләп табар Калам,
Ничә гасыр инде бикле капкаң...

Беләм – җирдә таш калалар барын,
Башкалалар барын читкә каккан.
Калатауның кара еланы да
Мең ел белә кебек мине яттан.

Беләм – җирдә Чатыртаулар барын,
Айгыртаулар барын күккә ашкан.
Калатауга карап тау булалсак,
Яши башларбыз күк яңабаштан.

## Парлы бию

Ә ул чакта... коры август иде...
Һәм... төн иде безне яшергән.
Биек яр өстендә парлы бию
Рәшә иде ерак дәвердән.

Мәҗүси җил садә кыргыйлыкның
Биһуш булып үрде чәчләрен.
– Бу – мәңгелек халәт! – дидем шашып.
Акыллырак идең. Дәшмәдең...

Аһ, биедек! Күзләрдәге очкын
Үкчәләргә төште ургылып.
Искәрмәдек, давыл чәчәкләре
Эзебездә калды сузылып.

Җилеп үтте (давыл чыктымыни!)
Августлары безнең җәйләрнең.
Танголары булды... Вальслары...
Ятлар белән... Ятка әйләнеп...

Бөтерелде дөнья, кыргыйлыкның
Тамчысына кадәр күпсенеп.
Җаннар җәй эзләде, август көтте,
Кайнар кочакларда күшегеп...

...Һәм быел да... янә юеш август...
Кемнең кемнән усал көлүе?!
Мәңгелекнең үзе булган икән
Ике җанның парлы биюе...

## Без икәү

Килеш-килбәт ярыйсы да кебек,
Тик модадан чыккан холыклар.
Бер чырайга карап, кайдан белик,
Җиң эчендә ничә йодрык бар?!

Акыллылар өчен без – исәрдер –
Исбатлыйсы килми киресен!
Чын йөзеңнән йөз чөерсәң генә,
Үз булала шакал тиресе!

Әлмисактан калган сабый җаннар –
Юаш бәхет бездә куш учлап!
Теш сындырыр насыйп ризыкларны
Тәкъдир әзерләгән борычлап.

Тәкәбберләр куык кабартканда,
Безнең үрләр – нәни калкулык.
Шул үрләрнең, ярый, җегәре бар
Таш кыялар булып калкырлык!

Заман үзе, бәлки, ят итәдер –
Сирәк нөсхә безнең ишеләр.
Таш гасырдан калган гадилек, дип
Сәерсенсен, әйдә, кешеләр.

Килеш-килбәт ярыйсы да кебек...
Тик модадан чыккан холыклар.
Иман даулап җанга ябышсалар,
Җебеп тормас ләкин йодрыклар!

## Кычыткан

Юашланган быел кычытканнар...
Зәһәрлеген җуйган нигәдер...
Табигать тә заманына күрә
Ялгышамы әллә нигә бер?

Өтеп алыр ут-ялкынын тоймыйм –
Көлтә җыям ялан кул белән.
Өтәләсен иде шунда берсе,
Әрнү көтеп бүген тилмерәм!


Әллә үзем тупасландым микән,
Тән газабын бер дә тоймаслык.
Күзәнәкләр җанны алдалыймы –
Дөньясыннан качкач ихласлык...

Бармак битен үлән чагу нәрсә,
Инанганың үтсә кылычтан!..
Үз ишләрем, диеп сыйпап үттем –
Юашланган быел кычыткан...

# БӨЕК ӘДИП

*«Бу – озын буйлы, ябык гәүдәле, салам чәчле, эре сөякле кешене кырда күрсәң – игенче, юлда күрсәң – кучер дип, итек тегүче яисә мөсафир түгелме дип тә уйларга мөмкинсең; тумышыннан ук рус кешесенең рәвешчагылышын үзендә туплаган халык ул».*

*Степан Свейг*



**Л.Н.Толстой һәм А.М.Горький. Ясная Поляна. 1900 ел.**
*С.А.Толстой фотосы*

Максим Горький – дөньяви бөек әдип. Аның гомер юлы четерекле вакыйгаларга шулкадәр бай, гыйбрәтле, әйтерсең, ул җир йөзендә яшәгән 68 ел эчендә өч гасырлык дәвер кичергән.

Ул 1868 елның 16 мартында Түбән Новгород шәһәрендә дөньяга килә. Яшьли ятим кала. Кырыс холыклы бабасы өендә аңа җылы итеп эндәшүче бердәнбер кеше – әбисе Акулина Муратова була. Караңгы тормышның сирәк эләккән якты истәлекләре булып, Алексей Пешковның урамда, шәһәр читендә, Идел ярында бергә уйнаган дуслары – Язь, Хаби, Чурка, Вяхирь, Кострома кушаматлы рус, татар, мукшы малайлары хәтерендә кала. Ә үзенең кушаматы – Башлык була.

Беркөнне аңа бабасы Василий Каширин болай ди: «Ну, Ляксей, ты – не медаль, на шее у меня не место тебе, а иди-ка ты в люди». Шулай итеп, Алексей Пешков 11 яшендә өйдән чыгып китә, ялланып, төрле эшләр башкара: ул – пароходта савыт-саба юучы, ул – магазинда әйбер ташучы, ул – икона ясау остаханәсендә өйрәнчек; аннары һөнәр мәктәбендә белем ала.

Алексей Пешков 1884 елда, университетка керү нияте белән, Казанга килеп төшә. Кирәк бит, нәкъ шул елда университетка түбән, ярлы катлаудан чыкканнарны һәм яһүдләрне алуны бик нык чикләргә дигән устав чыккан була, булачак даһи каршында затлы уку йортының саллы ишекләре ябыла. Менә шул дәвердән инде аның өчен «тормыш университетлары» дигән хикмәтле дөнья ишекләре киереп ачыла. Эт тибенкесендә яшәп тә, ул нинди генә катлау кешеләре белән аралашмый. Һәрберсеннән кызык табып, мәгънә эзләп, күңеленә сала бара. Юкка гына ул, «мин тәнем белән – Түбән Новгородта, ә рухым белән Казанда тудым», дими.

Великоросс тәкәбберлеге, битарафлык аның табигатенә хас түгел. Казанның үзендә яшәп, татарларны искәрмичә каламы, әлбәттә, искәрә, күрә, ишетә, тоя һәм мондый юлларны язып калдыра:

«Китаптан туеп, моңсуланган чакларда Татар бистәсенә барасым килә иде. Анда ниндидер үзгә бер төрле, пөхтә тормыш кайный, анда эчкерсез, ягымлы, рус телен мәзәк итеп бозып сөйләшүче кешеләр яши; кичләрен биек манарадан мәзиннәре, моңлы көй сузып, мәчеткә чакыра. Минем уемча, татарларның яшәү рәвеше бөтенләй бүтәнчә корылган, мин белгән, миңа куаныч китермәгән тормыштан нык аерылып тора иде».

Семёнов пекарнясында эшләгәндә, Алексей Пешков лавка тотучы Андрей Деренков белән таныша. Аның шәхси китапханәсеннән гаҗәеп китаплар алып торып, төннәр буе укый. Ницше, Шопенгауэр, Гартман, Каро, Сёллиның философик хезмәтләрен өйрәнеп, аң-зиһенен чарлый. Андрей Деренков тирәсендә алдынгы карашлы студентлар кайнаша, ул, юмарт буларак, һәрберсенә ярдәм итә, акчасын кызганмый. Тәмам бөлеп, бурычка батканы билгеле булгач, аны полиция эзәрлекли башлый. Деренков Себер якларына качып китәргә мәҗбүр була.

Кирәк бит, ярты гасырдан соң калкып чыгып, ул Максим Горькийга хат белән мөрәҗәгать итә. Андрей Деренков язмышына большевиклар «лишенец» дигән мөһер сугып, яшәрлеген калдырмаган булалар. 1936 елда Максим Горький Деренков яшәгән төбәкнең партия өлкә комитеты секретаре Р.П.Эйхе исеменә хат юллый. Деренковның заманында сәяси тоткыннарга, студент хәрәкәтенә ярдәм иткәнлеген тәфсилләп яза, җитмештән узган өлкән кешегә мәрхәмәт күрсәтүләрен үтенә. Шуннан соң Деренковка пенсия билгеләнә, Горькийга рәхмәтле булып, ул Анжеро-Суджен районында йөз яшькәчә җитеп, 1953 елда дөнья куя.

Алексей Пешков, бер яктан, марксистик әдәбият, икенче яктан, дин, философия, тарих белән кызыксына. Кызыксына, дию генә аз. Тирәннән өйрәнә, канына, вөҗүденә сеңдереп үзләштерә. Бу чорда дөнья философиясенә караган китаплар Европадан күпләп керә, русчага тәрҗемә ителә. Укырга – ирек. Нинди генә сораулар бимазаламый яшь буынны. Мин ни өчен яшим? Аллаһ – мин «бар», дисәм – бар, мин «юк», дисәм – юкмы? Яшәү мәгънәсе нидә? Әнә шундый мең-мең сорау кайный яшьләр җыелган җирдә; «сүз акробатикасы»на бирелеп, күңел чоңгылларына артык тирән төшеп, чыга алмыйча азаплану зыялылыкка омтылган, уйланучан яшьләр өчен хас була ул заманда.

Бәргәләнгән җанын тынычландыруны Алексей Пешков җиңел хәл итмәкче була. Револьвер сатып ала да, караңгы төшкәч (1887 елның 12 декабре), Казансу ярына килә. Текә яр, кыргый куаклыклар. Җәсәдемне кар сулары ияртеп аска төшерер дә, олы сулар агызып алып китәр, дип уйлый ул. Язмыш дигәнең кайчакта кечкенә генә очраклылыктан тора шул. Әгәр ул төнне Алексей Пешков, яр буена килешли, песи баласы белән сөйләшеп утырган каравылчы агайны искәреп тукталмаган булса, суыктан калтыранган песине җәлләп, толып эченә алып җылыт син аны, дип каравылчыга әйтмәгән булса... тын гына үтеп китәр иде шулай... үлеменә таба... шартлау тавышына каравылчы игътибар да итмәгән булыр иде... Әле генә сүз каткан егет киткән тарафтан ату тавышы яңгырагач, каравылчы йөгереп бара, хәлнең мөшкел икәнен күреп, тиз генә үз постына кайтып полиция чакырта, извозчик яллап, ярымһушсыз егетне хастаханәгә кадәр озатыша бара. Үпкәсенә ядрә тигән егетнең палатасына да килеп йөри әле. Шулай итеп, татар агае – Мостафа Юнысовның гадәти-ярдәмчел холкы булачак әдипнең гомерен саклап калуда хәлиткеч роль уйный.

Шунысы кызыклы: атаклы җырчы булачак Фёдор Шаляпин белән Алексей Пешков бер үк чорда, бер үк урамнардан йөргәннәр, яшәгән җирләре дә бик

якын булган, әмма бер-берсен күреп белмәгәннәр. Икесе бер үк көнне опера театрына килеп, хорга җырчы булып керергә имтихан тотканнар. Шаляпин «яраксыз» дип табыла, ә Горькийны хорга алалар. Тавышы хәйран көчле була егетнең. Ходай Тәгалә, шушындый сәнгать юлыннан китмәсен тагын, дип, аның язмышына «төзәтмә» керткән ахрысы. Бервакыт, вагонга йөк төяп бетергәч, Алексей Пешков, өскә менеп, йөкне торыпша белән капларга керешә, шул мәлдә көчле җил кубарылып, егетне торыпшасы-ние белән вагон өстеннән алып ата. Егет муен турысы белән рельска төшеп бәрелә. Шунда аның тавыш җепселләренә зыян килә. Менә ни өчен, замандашлары язганча, Максим Горькийның тавышы тонык, руслар әйтмешли, «саңгырау» булып калган икән.

Шулай итеп, «Казан ятимнәре» – тормыш төбеннән, ярлылыктан калыккан, охшаш язмышлы ике даһи – Шаляпин һәм Горький, танылган шәхесләр булгач кына танышып, дус булып китәләр.

Еллар узгач, Парижда яшәгәндә, Фёдор Шаляпин болай дип яза: «Мин белемле кешеләрне хөрмәт итәм. Горький искиткеч белемле иде. Аны галимнәр, философлар, тарихчылар, рәссамнар, инженерлар, зоологлар, тагын әллә кемнәр даирәсендә күргәнем булды. Һәрчакта да Горький белән үз өлкәсенә караган темага сөйләшкәндә, бу компетентлы шәхесләр аңарда үз тиңдәшен күрә иделәр. Горький дөньяның бик кечкенәсеннән алып зур нәрсәләргә кадәр бай мәгълүматка ия иде. Мисал өчен, әгәр мин Горькийдан балан чыпчыкларының яшәү рәвешен сорасам, Алексей Максимович бу кош турында шундый бөртекләп сөйләр иде, мең ел буена яшәгән балан чыпчыкларының барчасын җыйсаң да, үзләре хакында болай ук төгәл әйтә алмаслар иде».

Яшьлегендә Алексей Пешков босяк булып ил гизә, «халык урманын ерып», кайларга гына барып чыкмый: Кавказ, Кырым, Бессарабия, Украина далалары... Әйтерсең, ул язачак әсәрләренә язмышлар аланыннан нектар туплап йөри. Ниләр генә күрми, ниләр генә кичерми чуар, күпмилләтле, могҗизалы, акылга сыймас шаукымлы-кырыс Рәсәй киңлекләрендә.

Менә бер генә мисал: Херсон өлкәсенең Кандыбовка (Кандыбино) авылына килеп кергәч, шаккатып кала: урамга халык җыелган, җигүле арбада – кул-аягы бәйләнгән яп-ялангач хатын-кыз. Җирән чәчле ярсыган адәм аны чыбыркы белән туктаусыз яра. Хыянәт иткән хатынын шундый җәзага тарткан икән бу. Халык арасыннан ник берсе ярдәмгә килсен. Алексей Пешков, гаделсезлеккә каршы торучан аяусыз егет буларак, әлеге хатынны коткарырга дип ташлана. Мужиклар аны, урап алып, таптап-изеп ташлыйлар. Кабыргалары сынган, тынсыз калган егетнең гәүдәсен авыл читендәге пычракка илтеп ташлыйлар. Җылы, дымык мәтеле җир егетнең тәненә көчен кайтара. Исән кала. Бу хәлдән тетрәнүе шулкадәр көчле була, савыкканнан соң да әле озак вакытлар кулына каләм ала алмый, сынган рухы дәвага озак бирешми.

Утызынчы елларда Кандыбовка авылы кешеләре Максим Горькийга хат язалар. Кичерүен сорыйлар. Теге җирән чәчле кансыз адәмнең Сильвестр Гайченко икәнен әйтәләр. Шулай итеп, ике арада җылы хатлар алышу китә. Авыл халкы тарафыннан Максим Горькийга үзәк мәйданда бронза бюст куела.

Аның баштагы чорга караган язмалары төрле газеталарда Иегудиил Хламида исеме белән басыла. «Макар Чудра» хикәясен 1892 елда беренче тапкыр Максим Горький псевдонимы белән чыгара. Аннары бер-бер артлы пьесалар, повестьлар языла башлый.

1901 елда Максим Горькийны Император фәннәр академиясенең шәрәфле академигы итеп сайларга ниятлиләр. Әмма аның дәүләткә каршы язган

рекламацияләрен, кулга алынуын, Түбән Новгородтан куылып, полиция күзәтүе астында яшәвен искә алып, патша Николай Икенче академиянең бу карарын раслап кул куймый. Патшага протест, Горькийга теләктәшлек йөзеннән, Чехов белән Короленко да шәрәфле академик исемен алудан баш тарталар.

Максим Горький төшенкелеккә бирелми, киресенчә, рухи ныгый гына бара. XX гасыр башында рус әдәбияты галәмендә моңарчы күрелмәгән талант иясе, уе белән дә, буе белән дә, хезмәте белән дә, сәләте белән дә – чын баһадир калка. Көтмәгәндә, халыкның үзеннән чыккан бу мәһабәт кыя гарасатлы иҗаты белән күпләрне сискәндерә, сокландыра, куркыта, аптырата, көнләштерә. Көнләшү шаукымы хәтта Лев Толстойның үзен дә читләтеп узмый...

Максим Горькийның пьесалары йөзләгән театрларда куела башлый. Әсәрләрен бөтен Европа илләре тәрҗемә итәргә керешә. Россиядә исә халык арасында шулкадәр популяр була, танылган артистларныкы кебек, аның да сурәте төшкән открыткалар меңәрләп сатыла башлый. Кыяфәт, гәүдә торышы нинди диген: аякта – ваксаланган күн итек, кара чалбар өстенә чыгарып салынган киндер күлмәк, билбау, күперенке кара мыек, куе чәч. Нәкъ шулай киенеп, «Мин – Максим Горький», дип йөрүчеләр күренә башлый. Төрле шәһәрләрдә халыкны җыеп, нәкъ аныңча «о»лаштырып сөйләп, очрашулар оештыручы «Максим Горькийлар» артык ишәеп киткәч, чын әдип үзе, «халыкчан» өс киемнәрен алыштырып, европача киенергә мәҗбүр була.

Үпкә чире белән интеккән әдип, 1906 елда дәваланырга дип Европага китә. Италиядә тукталып, ул Тиррен диңгезенең Неаполитан култыгындагы Капри утравында 7 ел яши (1906-1913). Вилласында кунаклар өзелми. Монда танылган шәхесләр – Нобель премиясе лауреаты Эмиль Беринг, В.И.Ленин, Иван Тургенев, Фёдор Шаляпин, А.В.Луначарский, Иван Бунин, Леонид Андреев, К.С.Станиславский, Саша Чёрный, Илья Репин, Оскар Уайльд, Анри Жид, Райнер-Мария Рильке, Пабло Неруда, Грем Грин, Александр Дюма, Альберто Моравия, Сомерсет Моэм һәм башкалар, төрле елларда килеп, Капри утравының тынычлыгын «бозалар». Аралашалар, сәяси темаларга бәхәсләр куба, яңа әсәрләр укыйлар, җитдилектән арыганда исә, йомры сүз, шаярту, көлешү уртага чыга.

Кызышып алгач, утрауның яр кашагасында яшәүче оста балыкчыларын да ияртеп, кунакларны Горький диңгез киңлекләренә, нәни утрауларга алып китә. Борынгы Неаполитан кояшы астында истирәхәт чигәләр. Асылмалы казанда уха кайный, йөземнән сыгылган шәраб җемелдәп тустаганнарга ага, түгәрәк табында шигырь, җыр тынмый. Ә инде, йөрәк җитеп, акуланың үзен ауларга адарыну... Мондый чакта Горький мәҗүси бер халәткә керә. Ул – сәргаскәр, балыкчыларның һәр ымына буйсынырга әзер. Әсирлеккә эләккән диңгез хакиме ярсулы бәргәләнә, көймәне чөеп атарлык елгыр көч белән ургый-сикерә. Шушындый дәһшәтле-мәгърур көчкә ия соклангыч ерткычны эләктер әле... Горькийның күзләрендә кыргый дәрт уйный, аучылык азарты, соң кимәленә җитеп, мускулларын шыгырдатып тартыла. Менә акуланы бердәм командалар астында ярга сөйриләр, хәле китә бара дисәң дә... юк әле, вакыт-вакыт ыспай гәүдәсен чөеп, елдырым-уйнаклап ала, хәнҗәр-хәнҗәр тезелгән тешләре дәһшәтле елтырый. Инде ярга өстерәп чыгарып тәмам җиңгәч, еш-еш сулу алган, әсәренгән Максим Горький, балыкчылар төркеменнән читкәрәк китеп, кулларын як-якка җәеп, ком өстенә чалкан төшә. Бу мәхшәрне үзе генә җиңеп чыккан баһадир шикелле, күккә карап ята. Күз төпләрендә – бәхетле яшь тамчылары. Менә хәзер, менә хәзер табын янында аның хөрмәтенә тостлар яңгырар.

Нинди рәхәт чаклар. Алда – еллар аша нинди хәтәр тетрәнүләр көткәнен белмәгән ваемсыз, кояшлы мизгелләр. Бәлки, бу Максим Горькийның дөньялыкта кичергән, соңгы сулышында да искә төшерерлек иң сәгадәтле мизгелләре булгандыр...

Горькийның мәшһүр язучы икәнен дә, «Италия әкиятләре», «Тәүбә» кебек әсәрләренең нәкъ менә шушында язылганын да, хатыны – Мария Андрееваның үз илендә иң гүзәл актриса саналуын да, аларга килгән кунаклар арасында дөнья бәясе торырлыклары барлыгын да Капри утравындагы халык бик белгән һәм горурланган. Шул горурлыкны буыннан-буынга тапшыра барып, бүгенге көнгәчә китереп җиткергән. Утрауның йөзек кашыдай шәһәрчегендә, кешене олылый белү мисалында, күркәм генә урамга әдипнең онытылмас исеме кушылган. Парк уртасына бюст куелган. Ул яшәгәндәгечә сакланган вилла диварына истәлекле язу беркетелгән. Бу сәнгатьле төзелгән йортның хәтер нуры мөлдерәп торган иң якты тәрәзеннән түбәтәй кигән олуг зат, тылсымлы сүз остасы – «Максим бабай», мут елмаеп, безнең заманга бармак янар шикелле... Юк шул инде... Диңгез кадереннән яралган бу кояшлы утрауга Күк катларыннан вакыт-вакыт кайткалап, аның сәмави рухы гына саваплы тынычлык алып китәдер, мөгаен...

Чабаталы Россияне революция ялкыны белән тетрәтеп, тарихта күрелмәгән биеклекләргә ирешергә мөмкин дигән самими хыял ул дәвердә бик күп зыялыларның аңын биләгән. Максим Горькийны да бу хыял алгысытып яшәткән була. Әмма революция давылы котырынып алганнан соң, ул шаккатып кала: илдә аяусыз террор, кырылыш, талау, җимерү башлана. Большевиклар бернинди канунны да танымыйлар, манаралар аударыла, әхлакый нормалар бетә. Горькийның гонорар акчасын савып яшәгән бу мәкерле кавемнең, хакимият урыннарын биләп алгач, чын йөзе ачыла. Дус дип йөргән Ленинга да туры сүзле, гаделсезлеккә каршы баручы Горькийның кирәге бетә. Ул аңа комачау итә. Астыртын-хәйләкәр юлбашчы үгетләп, алай гынамы – таләп итеп, Максим Горькийны чит илгә дәваланырга җибәрә. Италия диктаторы Бенито Муссолини Каприда яшәргә рөхсәт бирми, «пролетариат язучысы» Соррентода төпләнергә мәҗбүр була (1924-1933 еллар).

1918 елдан 1933 елга кадәр Максим Горький кандидатурасы Нобель премиясенә биш тапкыр тәкъдим ителә. Соңгысында – аның белән куелганнардан Иван Бунин әлеге бүләкне алуга ирешә. (Әх, дип уйлап куясың, Максим Горькийда бер тамчы гына яһүд каны булса... аласы иде бит). Ул, бернигә дә карамыйча, көнгә унар сәгать язу өстәленә «сәҗдә кылып» эшли. 1925 елда «Артомоновлар эше» дигән роман-трилогиясен тәмамлый. Иҗатына хилафлык китермичә, дөньядагы, илдәге әдәбият-сәнгать яңалыклары белән дә кызыксынып бара. Совет иленнән аңа меңнәрчә хат килеп тора: әдәбиятчылар, эшчеләр, авыл хәбәрчеләре, мәктәп укучылары яза. Төгәл адресын белмәгәннәр дә хат юллыйлар: «Италия. Самара», дип тә, «Швейцария. Остров Кипр. Горькому», дип конверт тышына язып җибәргәннәре дә, барыбер, югалмый. Европа Максим Горькийның кайда яшәвен белә.

Монда яшәгән елларында Горький шәхси сәркатиб, хуҗалык эшен алып баручы тота, әмма иң ышанычлысы, якын иткән таянычы, теләктәше Мария Закревская-Бенкендорф-Будберг була. (Ул ире граф Бенкендорф үлгәч, барон Будбергка кияүгә чыккан – бу фамилияләр шуннан.) 1919 елда, беренче тапкыр танышкан көндә үк, әлеге искиткеч кызыклы ханымга Горький «корыч ханым» дип әйткән була.

Мария (якыннары аны «Мура» дип йөртәләр) – җитез, тәвәккәл, һәммә эшкә маһир ханым буларак, Горький өендәге бөтен тормыш агышын бармак тирәли бөтереп йөртә. Хәтта акча кәгазьләренә кул кую да аңа ышанып тапшырылган була. Ул, дөньяның төрле тарафыннан килгән хатларны барлап, рәткә китереп тора. Европа матбугатында чыккан яңалыкларны, игътибарга лаек китапларны инглизчәдән турыдан-туры тәрҗемә итеп, Горькийны таныштырып бара. Гүя ул олуг әдипнең рухи шәүләсе: илһамлы минутларның кадерен тоеп, дөнья ваклыкларыннан, кирәкмәгән хәбәрләрдән аралап, даһины кагылгысыз биеклеккә күтәреп, иҗади тәхет югарылыгында тота белә. Кайчандыр баронесса Будбергка атап Блок шигырь язган булса, Горький исә дүрт бүлекне тәшкил итәчәк «Клим Самгин тормышы» дигән яңа яза башлаган романын Марияга багышлый.

– Илгә бергә кайтыйк, – дип, Горький никадәр үтенсә дә, Мария бирешми. «Баронесса» һәм «пролетар язучы» – бу титулларның янәшә булуын совет халкы кичермәс», – дип, кайтмый кала. *(Бөекбритания гражданлыгын алып, Лондонда яши башлый, язучы Герберт Уэльска кияүгә чыга.)*

1925 елда яңа әсәрен – роман-эпопеясын язарга керешкән *(ул бу әсәрнең соңгы бүлеген редакцияләп чыга алмый кала, гомере өзелә)* әдип, эшен бүлеп, 1928 елда улы Максим белән Мәскәүгә кайтып төшә. Белорус вокзалында аларны кыл сафка баскан кызылгвардиячеләр ташкыны тантаналы каршы ала. Вокзал мәйданы шау итеп тора. Монда – дәүләт эшлеклеләре, язучылар, артистлар, завод-фабрикалардан килгән эшчеләр яраткан язучысын алкышлап сәламлиләр.

Берничә ай эчендә Максим Горький дистәләрчә шәһәрдә (шул исәптән Казанда да) халык белән очраша, илдәге үзгәрешләрне үз күзләре белән күрә. Артык зур тәэсирләнүдәнме, дымлы көз җитүдәнме, авыруы тагын көчәя, ул кабат Соррентога китәргә мәҗбүр була.

Ике арада йөри торгач, барыбер туган илгә гомерлеккә дип кайту көне җитә.

Горький дөнья сәхнәләрен тоткан дусты Шаляпинны да илгә кайтырга кыстап карый. Әмма Шаляпин кырт кисә: «Бушка җырларга мин кош түгел!» – ди. Әлбәттә, бөек җырчыны илдә күтәреп алган булырлар иде. Нишлисең, егерменче елларда төн уртасында өенә көн аралаш бәреп кереп, тентү оештырып, кул астына эләккән әйберләрен надан-тинтәк солдатларның талап чыгып китүен күргән, мондый мәсхәрәдән күңеле каткан җырчы, илгә инде хыялында гына кайтырга була. Шулай итеп, очрашкан чакларында Казанны,аның тын урамнарын искә төшереп, хискә бирелергә яраткан ике бөекнең юллары гомерлеккә аерыла.

Хакими көче ныгыгач, Сталинга рухи таяныч кирәк була. Халыкның яратканына әверелгән әдипнең ул илгә кайтуын бик тели. (Бәлки, үзе турында китап язар дип тә өмет баглагандыр.)

Аның әмере белән, Горький исеме паркларга, урамнарга, корабларга бирелә. Мәйданнарда аның хөрмәтенә куелган һәйкәлләр, бюстлар калка. Каршы килә алмый бөек әдип, бу фанфаралы шаулар үтәр, иҗат калыр, вакыт катламнары астында утлы лавасы сүнмәсен генә... дип типкәндер аның олыгаеп арган җаны...

Максим Горькийга беркем татымаган уңайлыклар тудырыла. Асраулар, хезмәтчеләр, мул гонорарлар, Мәскәүнең үзәгеннән борынгы затлы особняк бирелә (бүгенге көндә Горький музее). «Горькийны Сталин алтын читлеккә япты», – диләр әче теллеләр.

Ә кемнәрдер бүген дә Горький күләгәсеннән гөнаһ эзләп бәргәләнә, эпилептик фикерләр кузгатып, даһиның тарихи пьедесталын кечерәйтергә адарына. Горький гаепле, имеш, ул, фәкать ул – кылыч болгап, Сталинга каршы

барырга тиеш иде. Ә калган язучылар, данга күмелеп, күндәм генә классик булып, тыныч култыктан күзәтеп кенә торырга тиеш булганнар икән...

Әсәрләренә иелеп карагыз: яфрак өзелгәннән дә гаҗәеп фәлсәфә чыгара белгән әдип, бу җирдә артык күпне кичергән, артык күпне белгән олылык иясе, әлбәттә, әлеге очракта аның зиннәтле байлыклардан һушы китеп, дан рәшәсеннән алданып, аңы томаланмагандыр. Сизгер күңеле сызылып сулкылдагандыр, әмма...

Совет язучыларының беренче съездын ясканып оештыру мәшәкате белән йөргәндә, Горькийны олы кайгы аяктан ега; беренче хатыны Екатерина Пешковадан туган, 37 яшенә җиткән улы Максим кинәт вафат була. Бу кайгыны өлкән әдип бик авыр кичерә. Хәзер инде аның таянычы булып, тәрбиягә алып үстергән улы Зиновий кала. Ул да еракта, чит илдә. Зиновий Пешков (1884-1966) – (Яков Свердловның бертуганы) кечкенәдән үк укырга хирыс була. Җиде тел белә (шул исәптән гарәп, япон, кытай телләре). Ул – Франция армиясенең генералы, төрле сугышларда катнашып, легендар батырлыклар кыла, сыңар кулын өздерә, җитмеш тапкыр дәүләт бүләге алуга ирешә, соңрак дипломатия эшенә күчә.

Максим Горькийны ялгызын гына калдырмыйлар. Якыннарының шифалы сүзе, эчкерсез мөнәсәбәте, дәүләти югарылыктан торып әйтелгән юату сүзләреннән үтемлерәк, әлбәттә. Халык та үзенең кадерле язучысын ташламый. Тагын да чалара төшкән олуг әдип тормыш җаена әкрен генә кайтып төшә. Ачылу көне берничә айга кичектерелгән язучылар съезды, ниһаять, 1934 елның 17 августында эшен башлап җибәрә. Шушы кадәр күп язучының бер учка җыелуы – күрелмәгән вакыйга. Дулкынландыргыч рухи бергәлек! Үзәктә – Максим Горький. Төрле милләт язучыларының кайгыртучан әткәсе шикелле күзәтә, сыный, уй-гөманнарын күңеленә сала. Төп докладында ул татар әдәбияты турында да этрафлы сүз әйтә.

Кайчандыр: «Мин татарларның тырыш, аек акыллы, саф әхлаклы, максатына ирешү үҗәтлегенә күңел йомшаклыгын да куша алган халык икәнен балачактан ук беләм», – дип язган олпат әдип «үз татарлары» – Казаннан делегат булып чакырылган язучылар эргәсенә килә, сөйләшә, фикерләшә, фотога төшә.

Еллар узгач, шул съездда делегат буларак катнашкан Гомәр ага Бәширов үзенең истәлекләрендә Хәсән ага Туфанның әйткәннәрен болай дип яза:

*«...ул безне, чыннан да, бик ярата иде. Хәтереңдәдер, язучыларның беренче съездында татар әдәбияты турында махсус доклад тыңланды. Ул бит көн тәртибенә Горький тәкъдиме белән кертелгән иде. Шул съездда, көндезге тәнәфес вакытында, безне, татар язучыларын, Лидия Сәйфуллина эзләп тапты. «Картыгыз сезне шул арада сагынып та өлгерде, үз янына чакыра», – ди бу. Барсак, аның янына үтеп керә алмаслык. Тирә-ягын хәбәрчеләр, фотографлар, кино кешеләре әйләндереп алган. Ә ул, берничә карамастан, безне янына утыртты да, әти кеше кебек, бөтенесен белешергә, сорашырга тотынды.*

*Әйе, ул безне ата үзенең улларын яраткан кебек ярата иде. Аның безнең әдәбиятны даими кайгыртуын татар язучылары һәрвакыт сизеп тордылар».*

Максим Горькийның төрле елларда шактый күп әсәрләре татарчага тәрҗемә ителә, сайланма әсәрләре 6 томда басылып чыга, пьесалары сәхнәләргә менә.

Язучыларның илкүләм форумыннан соң, елдан артык вакыт узгач, Максим Горький авырый башлый. Тән авыртуыннан бигрәк җан сызлавы борчый аны. Өенә бит аның көн аралаш йөздән артык кеше килеп тора иде. Зыялы катлауданмы, гади халык вәкилеме – һәрберсенең үз гозере, үтенече, кайгыгаме бар. Алар бит танылган әдипнең абруена, гаделлегенә, һәммә нәрсәне чишә аласына ышанып килә. Әнә бит ул – борынгы йортының эчке архитектура

бизәлешенә хилафлык китереп булса да, аскы каттагы бүлмәләрен сүттереп, киңәйттереп, килгән кешеләргә уңайлы булсын дип, олы зал ясаткан.

Максим Горький гүя – үзе бер Кремль. Эчкерсез кабул итә халыкны, гозерләрен күңеле аша үткәзеп тыңлый, бар эшен калдырып, ярдәмгә ашыга. Үзенең генә көченнән килмәгән очракта тагын да көчлерәкләргә мөрәҗәгать итә – барыбер үз дигәненә ирешә. Хәзер менә... авырып киткәч, олы бүлмә ямансу бушлыкта...

Олуг әдипнең авырып киткәнлеген ишетүгә үк, Лондоннан Мария – баронесса Будберг кайтып төшә. Аны күргәч, тән көче сула барган әдипнең күзләрендә: «Менә шушы корыч ханым мине үлемнән йолып калачак инде...» дигән сыман тересу-җете өмет чаткысы уянгандыр ул мизгелдә.

Әмма... Тәкъдирне кирегә борырга хәтта Сталин кодрәте дә җитә алмый шул. Мария күпме елларны бергә кичергән әдипнең соңгы сулышына кадәр баш очында утыра. Ярабби. Акыл адашып калырлык нинди уравыч аның гомер юлы: ымсындыргыч упкынлы да, кырыс кыялы да... Үзе бер шаукымлы роман, тетрәндергеч поэма... Мария, кадерле истәлекләрдән тыны кысылып, әле кайчан гына дөньяны киеп яшәгән азамат ирнең маңгаена учын куя. Хәлсез җыерчыклары арасыннан шытып чыккан салкын тир бөртекләре аның учын пешерә. Соңгы тапкыр...

1936 елның 18 июнендә шанлы «Давыл хәбәрчесе»нең йөрәге тибүдән туктый.

Күк гөмбәзендә эре бер йолдызының нурын җуйган ил өстенә кайгы канаты җәелә. Тетрәп калган халык, капылт кына Ходайны искә төшереп, күккә бага.

Әйе, Максим Горький – дөньяви-бөек әдип, дидек. Аның йөзләгән телләрдә өч йөз миллион данәгә якын китаплары басылган. Искиткеч бай әдәби хәзинәсе – кешелеккә калдырган үзе бер пирамида.


Бу – титаник талантның сүз кодрәте белән тантана итү мирасы.

Бу – кешелек рухын югары камилләргә җиткереп, яшәү мәгънәсен Ходай каршында раславы.

Бу – «Кеше – горур яңгырый!» дип, яшьлегендә әйткән шигарьне, тетрәнүләр аша үтеп тә, үз иманына тугры калып раславы.

Лев Толстойдан соң рус әдәбиятының «алтын дәвер» капкасын ябып, мәңгелек кәгъбәсенә юл алган олуг әдип ул... Капканың бу ягында исә бүтән үлчәмдәге эпоха нәүмиз торып калды...

**Марсель ГАЛИЕВ**



Максим
Горький

# ЛЕВ ТОЛСТОЙ

ЯЗМАЛАР

*Бу китап Лев Николаевич башта – каты авырып, аннары – чирен җиңеп – Гаспрада, ә мин Олеизда яшәгән чактагы өзек-өзек язмалардан тупланды.*
*Ашык-пошык языштырган кәгазь кисәкләрен мин инде җуйган идем, күптән түгел генә бер өлешен табып алдым. Моңа тагын Лев Николаевичның Ясная Полянадан «качуы» тәэсиреннән язылып та тәмамланмаган хат өстәлде. Хатны, бер сүзен дә үзгәртмичә, шул дәвердә кәгазьгә төшкәнчә бастырам. Тәмамлый алмыйм, моны эшләү, ни сәбәпледер, ярамый дип саныйм.*

*М.Горький*

**I**

Аллаһка ымсынган уй-фикерләре аның күңелен һәрдаим бимазалап торды. Кайчакта бу – уй-фикер генә түгел, ә өстен кодрәткә каршы килү үҗәтлеге кебек тоела иде. Бу хакта ул еш уйлана. Картлык галәмәтеме, үлем киләсен сизенүеме дисәм, юк, бу аның рухындагы кешелек горурлыгыннандыр дигән гөманга киләм. Бәлки, ул бераз кимсенәдер дә, кем-кем – Лев Толстой башың белән үз ихтыярыңны илаһи тойгыларга буйсындыр әле! Әгәр ул табигать белеме фәннәре буенча галим булса, әлбәттә, шаккаткыч фаразлар кылыр, бөек ачышлар ясауга ирешер иде.

**II**

Куллары гаҗәеп иде аның – беренче карашка ямьсез дә кебек, кан тамырлары ишелеп, бүртеп тора. Әмма тәэсирле, иҗади дәрт, илһам белән яралтылган куллар. Леонардо да Винчиның да куллары, бәлки, нәкъ менә шундый булгандыр. Мондый куллар белән бөтенесен дә майтарып була. Гадәттә, ул, сөхбәтләшеп утырганда, бармакларын аралап, хәрәкәтләндереп куя, йодрыкка йомарлый, аннары, кинәт кенә йодрыгын ачкан мәлендә, саллы сүзен әйтә. Алланың үзенә охшап китә, дияр идем. Юк, Саваофка да, олимпиянекеләргә дә түгел, ә «алтын юкә төбендә өрәңге тәхетендә утырган»

рус алласына охшый. Ул кадәр үк мәһабәт булмаса да, бүтән аллалардан күпкә хәйләкәррәк түгел микән әле...

### III

Леопольд Сулержицкийга мөнәсәбәте хатын-кызларча, бик ягымлы. Чеховны аталарча ярата, бу яратуда тудыручыга хас горурлык сизелә, ә Сулерга карата ул һәрчак мөлаем, соклanудан беркайчан да туймас сихерче кебек, аңардан кызык таба. Мондый артык хисләнүе бераз көләсене дә китерә. Әйтик, карт кызның попугайны, көчекне, мәчене яратуы кебегрәк. Сулер – безгә ят, ниндидер күз күрмәгән бер илдән килеп төшкән соклангыч иректле кош сыман. Аның кебекләр үзәктән читтәге төбәкләрдә урнашкан нинди дә булса шәһәрнең йөзен, рухиятен үзгәртеп ташларга маһирлар. Йөзен бозарлар, ә җанын, әллә нинди мутлыклар эшләргә дуамал алгысытып, кузгатып калдырырга мөмкиннәр. Сулерны ярату җиңел, күңелле кеше, тик минә хатын-кызларның аңа кимсетебрәк караулары мине аптырата, ачуымны китерә. Бәлки, бу кимсетү түгел, ә яшерен сагаюдыр. Сулер – ышанычлы түгел. Иртәгә ни кыласын белеп булмый. Бәлки, ул бомба ыргытыр, ә бәлки, берәр трактирда хорда җырлый башлар. Аның дәрт-дәрманы өч гасырга җитәрлек. Яшәргә алгысыну уты аңарда хәттин ашкан, гүя, ул тирләгәндә дә, артык кызган тимер кебек, очкынланып тирли.

Шулай да бервакыт Сулер Толстойның бик каты ачуын китерде. Анархизм белән мавыккан Леопольд шәхес ирекe турында еш кына кайнарланып сөйли, бәхәсләшә иде. Андый чакта Лев Николаевич аны үчекли, ирештерә.

Хәтерлим әле, Сулержицкий каяндыр кенәз Кропоткинның брошюрасын табып алган да, шуны селки-селки, көне буе анархизмның шәплеге хакында җимергеч фәлсәфәгә бирелеп йөрде.

– Их, Лёвушка, җитте сиңа, туйдырдың, – дип, канәгатьсезлек белдереп ишарә ясады Лев Николаевич. – Попугай сыман, һаман бер сүзне тукыйсың: «Азатлык, азатлык...» – кайда, нәрсәдә аның мәгънәсе? Син үзең күзаллаганча ирекле булуга ирешсәң – нәрсә үзгәрәчәк? Философик мәгънәдән чыгып караганда – төпсез бушлык, ә тормыш чынбарлыгында – син ялкау бер теләнчегә әйләнәсең. Үзең хыялланганча ирекле булдың ди, йә, тормыш белән, кешеләр белән ни-нәрсә бәйләр соң сине?! Әнә кошлар ирекле, ә барыбер оя коралар. Син бит оя да кормаячаксың, ата эт кебек, кая телисең, шунда җенси теләгеңне канәгатьләндереп көн күрәчәксең. Җитди генә уйлан бу хакта – үзең үк шуңа киләчәксең: ирек ул – бушлык, чик-чама белмәү.

Кашлары усал җыерылды, бер мәл дәшми утырды да тыныч тавыш белән өстәп куйды:

– Христос ирекле була. Будда – шулай ук, икесе дә яшәешнең гөнаһын үзләренә кабул итеп, җир тормышына ихтыяри әсирлеккә төшә. Шуннан ары берәү дә китә алмый, берәү дә. Ә син, ә мин кем, нәрсә? – акыл сатарга! Без якыннарыбызга булган бурыч-вазифалардан ирекле булырга тырышабыз, югыйсә бит шул вазифаларыбызга бәйлелекне тою безне кеше иткән, мондый тойгыларсыз ерткыч җәнлек хәлендә яшәгән булыр идек әле...

Мыскыллы көлемсерәп:

– Хәзерге көндә без ничек яхшырак тормыш итү хакында гәп куертабыз. Моннан файда әллә ни түгел дә кебек, шул ук вакытта аз да түгел. Менә син минем белән ярсып бәхәсләшәсең, ачуың кабарып, борының шәмәхәләнеп чыга, ә кизәнеп суга алмыйсың, хәтта сүгенмисең дә. Әгәр син үзеңне чынлап та ирекле тойсаң, дөмектерер идең мине – бары шул гына.

Бераз тын утырганнан соң, өстәп куйды:

– Ирекледек шунда – кайчан ки бөтенесе дә минем белән килешә, әмма ул чакта инде мин бар булудан туктыйм, чөнки без үзебезне бәрелешләрдә, каршылыкка дучар ителүләр аша гына кеше итеп сизәбез.

### IV

Гольденвейзер, бирелеп, Шопенны уйнаганда, Лев Николаевич шундый уйларын белдерде:

– Алманның кайсыдыр бер кәрлә генә патшасы әйткән бит әле: «Колларга ия булырга теләгәндә, күбрәк музыка язарга кирәк», – дигән. Бу – дөрес фикер, дөрес күзәтү, музыка аңны томалый. Барыннан да битәр, католиклар моны яхшы аңлаган. Безнең поплар, әлбәттә, чиркәүдә Мендельсон аһәңнәрен кабул итмәячәк. Тулада бер поп мине: «Христос яһүд түгел», – дип ышандырырга тырышты, югыйсә яһүд алласының улы булганын да, әнкәсе яһүдә икәнен дә таный үзе, ә барыбер: «Христосның яһүд булуы мөмкин түгел», – дип, үз сүзен сүз итә. «Ничек соң алай булгач?» – дип сорыйм. Җилкәсен җыерып куйды да: «Сие для меня тайна!» – диде.

### V

«Интеллигент ул – Галиция кенәзе Владимирко; ул XII гасырда ук: «Безнең чорда могҗизалар була алмый», – дип әйткән. Шул дәвердән соң инде алты йөз ел гомер узган, зыялылар әле һаман бер-берсенә: «Могҗиза булмый, могҗиза булмый», – дип тукыйлар. Ә бөтен халык, XII гасырдагы кебек, могҗизаларга отыры ышана бара.

### VI

«Азчылыкка Алла барына ышану кирәк, чөнки аларның калган бөтен нәрсәсе дә бар, ә күпчелек мохтаҗлыктан ышана».

Мин моны бүтәнчәрәк аңлыйм: күпчелек Аллаһка – куркудан ышана, бик азлар гына – күңел байлыгыннан. *(Төрлечә аңлау булмасын өчен, әйтеп китим: дини иҗатны мин, әйтик, Христос, Будда, Мөхәммәд турында язылганнарны, сәнгать әсәре – фантастик роман кебек кабул итәм. – **М.Горький искәрмәсе.**)*

– Андерсен әкиятләрен яратасызмы? – дип сорады ул бервакыт. – Марк Вовчк тәрҗемә иткәннәрне укып, мин аңламаган идем, ун еллап вакыт үткәч, китапны кулга алып, кабат укый башладым да кинәт бөтен ачыклыгы белән төшенеп алдым: Андерсен бик тә ялгыз зат булган икән. Бик тә. Мин аның тормышын әйбәт белмим; азып-тузып яшәгән бугай, күп сәяхәт иткән, болар бар да минем фаразны раслый – ул ялгыз кеше булган. Шуңа күрә дә ул балаларга йөз борган. Әмма бала-чага олыларга караганда ныграк кызгана белә дию – ялгыш караш. Балалар бернине дә кызганмыйлар, аларга җәлләү хисе бөтенләй хас түгел.

### VII

Миңа буддачыларның катехизисын укырга куша. Буддизм һәм Христос хакында ул һәрчак хискә бирелеп сөйли; Христос турында ул – аеруча дәртләнеп, пафос белән сөйләми, сүз сөрешендә бер дә күңел утының очкыннары сизелми. Христосны ул беркатлы, җәлләүгә мохтаҗ дип саный, хәер, кайчакта сокланып та ала, ләкин барыбер яратып бетерми шикелле. Шөбһәләнә дә бугай: килсен Христос рус авылына – кыз-кыркын аны көлкегә калдырачак.

## VIII

Бүген аңарда бөек кенәз Николай Михайлович булып китте. Акыллы кеше күренә. Үзен гади генә тота, аз сөйләшә. Гәүдә торышы күркәм, күз карашы матур. Кул хәрәкәтләре салмак. Лев Николаевич, ягымлы елмаеп, аның белән әле французча, әле инглизчә сөйләште. Русчага күчеп, болай диде:

– Карамзин – патша өчен язды. Соловьёв – озын һәм күңелсез итеп, ә Ключевский исә үз кәефен күтәрү өчен язды. Хәйләкәр: өстән генә укыйсың – мактаган шикелле, асылда – битәрли.

Кемдер Забелинны искә төшерде.

– Сөйкемле зат. Тәкъва кеше. Иске-москы җыярга ярата, кирәген дә, кирәкмәгәнен дә. Ризык турында шундый итеп яза, әйтерсең лә беркайчан да туя ашамаган. Бик тә кызыклы кеше.

## IX

Толстой – таяк тотып, җирне адымлап үлчи-үлчи барган мөсафирларны хәтерләтә, алар бит монастырьдан монастырьга, бер изге кабердән икенчесенә меңәр чакрым җир үтәләр, кереп сыеныр урыннары да юк, бөтенесе дә аларны чит итә. Бу дөнья да, Аллаһ та алар өчен түгел. Гадәт буенча гына дога кылалар, ә эчтән яшерен генә Аны күрәлмыйлар; ни өчен соң әле язмыш аларны җирнең бер тарафыннан икенче тарафына куып йөртә, ни өчен? Бу кешеләр – юл кырыендагы төп, чияләнгән тамыр, таш кисәге – боларга абынып, тәнеңне авырттырырга да мөмкинсең. Кирәге бармы аларның? Кайчакта үзеңнең бүтәннәргә охшамаганыңны күрсәтеп шаккатыру, килешмәгәнеңне белдерү, бәлки, – кирәкле шәйдер.

## X

«Фридрих Прусский бик шәп әйткән: «Һәркем үзен a sa fason *(үзенчә –* ***фр.)*** коткарырга тиеш». Тагын болай дигән: «Теләгәнчә сүз көрәштерегез, әмма карусыз буйсыныгыз». Ә инде үләр алдыннан: «Коллар белән идарә итеп арыдым мин», – дигән. Бөек дип аталган кешеләр коточкыч каршылыклы була. Әмма ул бөтен ахмаклыклары белән бергә кичерелә. Хәер, каршылыклы булу ахмаклык дигән сүз түгел әле. Җүләр – үҗәт була, ләкин үз-үзенә каршы килми. Әйе, Фридрих сәер бәндә булган: алманнарның иң көчле патшасы дигән данга ирешкән, ә нишләптер аны хәтта Гёте да, Виланд та яратмаган...»

## XI

Кичә кичтән ул, Бальмонт шигырьләре уңаеннан:

– Романтизм – дөреслекнең күзенә туры карарга куркудан килә, – диде. Сулер, аның белән килешмичә, артык тәэсирләнүдән пышылдап, патетик рухта тагын шигырьләр укырга кереште.

– Лёвушка, шигырь түгел, шарлатанлык бу, урта гасырларда моны «ерундистика» дип атаганнар, мәгънәсез сүз тезмәсе. Поэзия ясалма була алмый:

...үзем дә белмим ни җырласымны,
Әмма күңелдә моң өлгерә,

– дип, Фет чын халыкчан хисен белдергән әнә! Мужик та ни җырлаганын белми: «Ох, да-ой, да-эй» – ә бит кош сайраган кебек, күңел түреннән асыл

җыр калка. Сезнең әнә яңаларыгыз бармактан суырып яза. Французлардагы тинтәклек – «артикль де Пари» – менә шул инде синең шигырь үрүчеләреңдә. Некрасов та шигырь-мигырьләрен тоташ көчәнеп язган.

– Ә Беранже? – дип сорады Сулер.

– Беранже – башка! Французлар белән сезнең арада нинди уртаклык бар? Алар – хисчән; рухи тормыш аларга, тән ләззәте белән чагыштырганда, ул кадәрле мөһим түгел. Французга иң мөһиме – хатын-кыз. Французлар – тузып, таушалып беткән халык. Табиблар әнә: «Үпкә авырулы кешеләр хисчән була», – диләр.

Сулер, гадәтенчә, күп сүз болгатып, турысын әйтеп бәхәсләшергә кereште. Л.Н. аңа карап елмайды да:

– Бүген син көйсез: нәкъ кияүгә чыгарга өлгереп җиткән, ә кияү табалмаган туташ кебек...

## XII

Авыру аны тәмам яндырып, коргаксытып чыкты кебек, ул эчтән дә җиңеләеп, үтә күренмәле булып калды, тормышка карата хәерхаһлы халәте көчәйде сыман. Күзләре – җетеләнде, карашы – үтәли тишеп төбәлә. Дикъкатен туплап тыңлый, гүя онытылганнарны яңарта, моңарчы белмәгән яңаны олы ышаныч белән көтә. Ясная Полянада ул бу дөньяда бөтен нәрсәне белгән, бүтән инде беләсе калмаган, барысы да хәл ителгән кеше шикелле тоела иде.

## XIII

Әгәр ул балык булса, әлбәттә, океанда гына йөзәр иде, беркайчан да эчке диңгезләргә кермәс, елгаларны инде әйткән дә юк.

Монда бит аның тирәсендә нindидер маймычлар кайнаша, ул ни әйтсә дә, аларга кызык та, кирәк тә түгел, дәшми торуы да куркытмый, аларга кагылмый. Аның дәшмичә тын торуы шундый мәһабәт, ул дөнья акылын туплаган чын бер дәрвиш кебек.

Гәрчә ул үзенә кирәкле темаларга күп сөйләшсә дә, тагын да күбрәген әйтеп бетерми шикелле. Күңелендә – үзе дә курыккан уйлар тулгана, ахрысы.

## XIV

Кемдер аңа Христоска багынучылар хакында язылган әкият күчермәсен җибәргән. Шундый ләззәт белән ул аны Сулерга, Чеховка, миңа укыды. Укуы – искиткеч! Шайтаннарның помещикларны җәзалавы турындагы өлешен бигрәк тә рәхәт чигеп укыды. Менә монысы миңа бик үк ошап бетмәде. Эчкерлелек аңа хас түгел иде югыйсә, әгәр аның бу мизгелдән ләззәт алуы чын күңелдән булса, бусы инде тагын да начаррак.

Аннары ул болай диде:

– Менә мужиклар сүзне ничек шәп үрә белә. Бөтенесе гади, сүз аз, ә хис – тулып ашкан. Акылның асылында сүз аз була: ярлыка, Ходаем, дигән кебек.

Әкият исә рәхимсез иде.

## XV

Мине якын итүе – этнографик кызыксынудандыр. Ул бик аз белгән кавемнең бер заты идем мин аның карашынча. Бары шул гына.

## XVI

«Үгез» дигән хикәямне укыганда, ул рәхәтләнеп көлде, «Телнең фокусларын» беләсең, – дип, мактап та куйды.

– Шулай да сүзләр белән оста эш итә белмисез. Бөтен мужикларыгыз да чамасыз акыллы. Тормышта бит алар, сантыйга салышып, ятышсыз сүзләр сөйлиләр – нәрсә әйтергә теләвен тиз генә аңлый алмыйсың. Юри шулай итәләр, оешып бетмәгән сүз артында синең күңел бушатканыңны беләсе килү теләге ята. Рәтле мужик алай тиз генә акылын ачып салмый, бу аның файдасына түгел. Чөнки ул белә: тинтәк кешегә мөнәсәбәт – гади, хәйләсез, аңа менә шул кирәк тә! Аның каршында күңел изүен ачып ташлыйсың икән, ул синең бөтен йомшак ягыңны күреп-сизеп алачак. Мужик һәркемгә сагаеп карый, эчке уйларын хәтта хатынына да ачып салмый. Ә сезнең бар да күңелен җилбәгәй ачкан, һәр хикәягездә – ниндидер акыл ияләренең галәми корылтае. Җитмәсә, бар да афоризм әйтеп сөйләшә – дөреслеккә хилафлык бу, афоризм – рус теленә ят нәрсә.

– Ә мәкальләр, әйтемнәр?

– Алар бүтән. Бүген генә тумаган.

– Шулай да сез үзегез еш кына афоризмнар кулланасыз бит.

– Беркайчан да! Аннары сез бөтен нәрсәне артык матурларга тырышасыз: кешеләрне дә, табигатьне дә, бигрәк тә – кешеләрне! Лесков шулай иде, бизәкләп язучы, купшы, буш, күптән инде аны укымыйлар. Беркемгә дә иярмәгез, беркемнән дә курыкмагыз – шул чакта бөтенесе дә әйбәт булыр...

## XVII

Миңа укырга биреп торган көндәлек дәфтәрендәге бер юл сәерлеге белән аптырашта калдырды: «Бог есть моё желание».

Бүген, көндәлекне кайтарып биргәндә: «Нәрсәне аңлата бу?» – дип сорадым.

Күзләрен кысып, дәфтәр битенә карады да:

– Тәмамланмаган фикер, – диде. – Бәлки, мин болай дип әйтергә теләгәнмендер: Бог есть моё желание познать его... Юк, алай түгел... – дип, көлеп куйды да, дәфтәрне көпшә итеп бөтереп, кафтанының мул кесәсенә тыкты. Аллаһ белән әллә нинди, аңлап булмаслык мөнәсәбәттә ул, кайчакта миңа «бер өндәге ике аю» халәте кебек тоела.

## XVIII

Фән хакында.

«Фән ул – шарлатан алхимиклар тарафыннан ясалган алтын коелмасы.

Сез аны гадиләштереп, бөтен халыкка аңлашылырлык итәргә уйлыйсыз икән, димәк, бихисап ялган акча басачаксыз. Халык, бу тәңкәләрнең асыл бәһасенә төшенгәч, безгә рәхмәт әйтмәс бит».

## XIX

Юсупов паркында йөрибез. Ул Мәскәү аксөякләренең хокуклары турында мавыктыргыч итеп сөйләп бара. Клумбада, урталай бөгелеп, филнеке кебек юан ботларын ялтыратып, мул имиләрен дерелдәтеп, олы гәүдәле рус хатыны эшли иде. Ул, хатын ягына игътибар белән карап торды да:

– Менә шушындый кариатидалар иңендә тора бу дуамал, мәһабәт ил. Мужиклар, хатын-кызлар бил бөгүдән, салым җыюдан гына да түгел, чын

мәгънәсендә халык каныннан тора. Әгәр дә дворян катлавы вакыт-вакыт менә шушындый алашалар белән кан яңартмаса, күптән инде зәгыйфьләнеп, үлеп бетәр иде. Минем замандагы аксөяк яшьләрнең көч-дәрманын юкка исраф итүе – бер эзсез, җәзасыз кала димени? Аннары, азып-тузып арган күпләр, тынычланып, асрау кызларга өйләнеп, таза, шәп нәсел калдырдылар. Һәрхәлдә, бу очракта да мужик көче коткарды. Ул һәрчак әзер тора. Шулай кирәк, нәселнең бер яртысы – көчен үзенә файдаланырга, икенче яртысы, кушылып, куе авыл канын да бераз эретергә тиеш. Бу – файдага, – диде.

## XX

Хатын-кызлар турында бик теләп, француз романчылары кебек күп сөйли, әмма аның рус мужигы кебек тупас әйтеп куюлары бигрәк тә баштагы чорда мине изә иде.

Бүген, миндаль чаукалыгында йөргәндә, ул, Чеховка төбәлеп:

– Яшьлектә азгынлыкка хирыс идегезме? – дип сорады.

Антон Павлович, оялчан көлемсерәп, сакалын сыйпап, нәрсәдер мыгырданып куйды; Лев Николаевич, диңгез ягына күз төбәп:

– Мин чамасыз ... – дип, җөмлә азагында ул, башка орган кебек, мужикларча саллы сүз кулланды. Әйтерсең лә башка, ипле сүз таба алмый. Шуңа охшаш сүзләр аның кабарынкы мыегы астыннан солдат тупаслыгын җуеп, гадәти булып, табигый яңгырап чыга. Беренче очрашкан чаклар хәтергә килә: минем «Варенька Олесева», «Егерме алты һәм берәү» хикәяләре турында гәпләшәбез. Гадәти күзлектән караганда, аның һәр җөмләсе «әшәке» сүзләр чылбырыннан тора. Мин, кыенсынып, гарьләнеп тә куйдым: әйтерсең лә мине бүтән телне аңларга сәләтсез дип саный. Хәзер инде төшенәм: моңа хәтер калу – акылсызлык булган.

## XXI

Менә ул кипарис астында таш эскәмиядә утыра; арыган, ябык, бөрешкән гәүдәсе Саваофка охшаган, кызылтүш артыннан кабатлап, сызгырынгалап, кәефен күтәрә. Кош каракучкыл яшеллек арасына посып сайрый. Ә ул, үткен карашлы күзләрен кыса төшеп, иреннәрен балаларча очлайтып, кошка ияреп, сызгыргандай итә.

– Шаша бит кошкай! Өздерә! Күр, син аны?!

Мин аңа кызылтүшләрнең холкы бик тә көнчел икәнен әйттем.

– Гомере буена – бер җыр, ә үзе көнчел. Ә адәми затның күңелендә – йөзләгән җыр, шулай да аны көнчелектә гаеплиләр – гаделме соң бу? – диде ул, үз-үзеннән сорагандай, һәм уйга талды... – Шундый мизгелләр була, ир кеше, беркатлыланып, хатын-кызга ачылып китә, үзе турында белмәскә тиешне дә сөйләп ташлый. Сөйли дә оныта, ә хатын-кыз онытмый. Көнләшү – бәлки әле, җаныңны түбәнсетүдән, көлкегә каласы килмәүдән туган куркудан киләдер. Хатын-кызның к...ны тотканы түгел, җаныңны йомарлаганы куркынычрак.

– Бу фикерегез «Крейцерова соната»да бирелгән тойгыларга каршы килә бит, – дигәч, сакал-мыекларына кадәр елмаю нурын таратып, ул:

– Мин кызылтүш түгел, – диде.

Кич белән йөрергә чыккач, көтмәгәндә болай дип әйтеп куйды:

– Ир кеше җир тетрәүләрне, коточкыч авыруларны, җан сызлануларын кичерә, әмма гомер-гомергә аның өчен иң хафалысы – йокы бүлмәсе, ятак газабы. Шулай булган һәм шулай булачак.

Моны әйткәч, ул вәкарь белән елмаеп куйды. Кайчакта шулай була: эчтән изеп, гел әрнетеп торган, ниндидер авырлыктан кинәт котылган кебек, рәхәт итеп елмая иде ул. Нинди дә булса уй-фикер аның җанына талпан кебек кадала; ул аннан тиз генә котыла алмый, канын эчәргә җай бирә, тулышып, өлгереп җиткәч, үзеннән-үзе тәгәрәп төшкәнен көтә белә.

Еш кына әйтә иде:

– Мавыктыргыч итеп сөйли беләсез, китапча түгел, үз сүзләрегез белән, саллы итеп.

Телдә киткән чатаклыкларны һәрчак искәртеп, үз-үзенә генә сөйләнгән кебек, тавышын күтәрми генә әйтеп куя:

– «Подобно» дигән сүз янәшәсендә – «абсолютно»... Югыйсә «совершенно» дип тә әйтеп була бит!

– «Хәлсез субъект» – рухлары бөтенләй туры килмәгән шушы ике сүзне рәттән куярга мөмкинме? Әйбәт түгел...

Тел куәсенә карата артык бәйләнчек булып тоела иде кайчагында. Бервакыт әйтә:

– Кайсыдыр язучыны укыганда тап булдым: «Кошка» һәм «кишка» сүзләрен бер фраза эчендә кулланган. Чиркангыч! Укшый яздым.

Тагын үзалдына сөйләнгәндәй:

– Подождём, под дождём – болар арасында нинди уртаклык бар?

Парктан кайтып кергәч, әйтә:

– Әле генә ишеттем, бакчачы: «Насилу столковался», – ди. Сәер бит? Якорьларны коялар, өстәлне түгел. «Ковать» һәм «толковать» фигыльләре ничек бәйләнә ала? Филологларны яратмыйм, мавыгучан халык, әмма тел өлкәсендә аларны җитди хезмәтләр көтә. Без үзебез дә аңламаган сүзләр белән эш итәбез бит. Әйтик, «просить» һәм «бросить» фигыльләре ничек яратылган?..

Еш кына Достоевскийның теленә туктала иде:

– Язганы шыксыз иде, сизеп торам, кыланып, юри ямьсез итеп язды. «Идиот»ында сүзләрне ничек бөгәрләп китерә: «В наглом приставании и афишевании знакомства», – ди. Мин уйлыйм, «афишировать» дигән сүзне ул юри гариплэтә, чөнки Көнбатыштан кергән чит-ят сүз. Кичереп булмаслык хаталар да җибәрә: мисалга, Идиот: «Ишәк – миһербанлы, яхшы кеше», – ди, ләкин берәү дә көлми бит, гәрчә бу сүзләрдән соң көләргә яисә ничек тә булса искәрергә тиешләр иде. Ул аны үзеннән мыскыллы көлеп йөргән өч бертуган сеңелкәшләр янында әйтә бит. Бигрәк тә Аглая каршында.

Аның бу китабын мактамыйлар, төп уңышсызлыгы шунда: кенәз Мышкин – эпилептик. Әгәр сәламәт булса – аның самими, чиста күңеле безне әсир итәр иде. Әмма аны сәламәт адәм итеп сурәтләргә Достоевскийның кыюлыгы җитмәгән. Шунысы хак: ул, гомумән, сәламәт-таза кешеләрне яратмый иде. Үзе авыру булгач, бөтен дөнья авыру дип ышана иде...

Сулер белән икебезгә «Сергий атакай»ның ничек түбәнлеккә төшүе хакында укыды – рәхимсез күренеш. Сулер, иреннәрен чөмәйтеп, дулкынланудан кыбырсып куйды. «Син нәрсә, ошамыймы әллә?» – дип сорады Лев Николаевич.

– Артык аяусыз, Достоевскийдагы кебек. Ул кызын әйтерием, күкрәкләре дә тәбикмәк кебек. Нишләп соң ул чибәр, сәламәт хатын-кыз белән гөнаһ кылмый?

– Бу очракта инде гөнаһ кылуны аклап булмас иде. Беркем күз төшермәгән кызны җәлләп гөнаһланган, дип кичерергә мөмкин әле.

– Мин аңламыйм мондыйны.

– Син күп нәрсәне аңламыйсың, Лёвушка, син хәйләкәр түгел...

Безнең янга Андрей Львовичның хатыны килде дә, сүз өзелде. Сулер белән икесе флигельгә кереп киткәч, Лев Николаевич болай диде:

– Леопольд – мин белгәннәр арасында иң чиста кеше. Ул шундый: ярамаганны фәкать кемне дә булса кызганудан гына эшли.

## XXII

Еш кына ул Аллаһ турында, мужиклар, хатын-кызлар хакында тәмләп сөйли. Әдәбият аның өчен, гүя, чит өлкә – бик сирәк, саран гына кузгатып ала. Хатын-кызга ул килешеп булмаслык дошманлык аша карый, әгәр инде Кэти яисә Наташа Ростова кебек булмасалар, ягъни җитәрлек дәрәҗәдә тар фикерле түгелләр икән – шәфкать көтмә. Бу инде – бәхетле мизгелләрне күпме булдыра алган, шул чаклы чумырып алырга өлгерә алмаган ир затының дошманлыгы, ә бәлки – «тәннең түбән ләззәткә омтылышына» каршы рухның дошманлыгыдыр? Бу – «Анна Каренина»дагы кебек салкын дошманлык. Якшәмбе көнне Руссоның «Тәүбә»се хакында Чехов һәм Елпатьевский белән гәпләшкәндә, ул «тәннең түбән ләззәткә омтылышы»н бик мәгънәле аңлатып бирде. Сулер бөтен сүзләрен дә язып барды, аннары, кофе кайнатыр өчен, шул кәгазьләренә ут элдереп, спиртлы лампаны кабызды. Үткәнендә ул Лев Николаевичның Ибсен хакындагы әйткәннәрен язып барган кәгазьләрен утка бирде. Лев Николаевич туй йолаларының символик мәгънәгә ия икәнен мәҗүси бер хис белән, мавыгып сөйләгән иде. Кайбер фикерләре В.В.Розановныкы белән чагыша да иде – бу язмаларын да Сулер югалткан булып чыкты.

## XXIII

Иртән Феодосиядән аңа штундистлар *(Библияне үзләренчә аңлатырга тырышучылар)* килгән. «Таза, нык бәдәнле ир-егетләр», – дип, бүген көне буе алар турында сокланып сөйләде. Табында да аларның мәзәк сүзләрен мисалга китереп, сабыйларча эчкерсез көлде.

Аштан соң террасага чыккач, болай диде:

– Күп тә үтмәс, без халык телен бөтенләй аңламый башлаячакбыз. Менә без әйтәбез инде: «прогресс теориясе», «тарихта шәхеснең роле», «фән эволюциясе», «дизентерия», дибез. Ә мужик: «Без капчыкта ятмый», – ди, һәм бөтен теорияләрең, тарихларың, эволюцияләрең кызганыч, көлке булып кала, чөнки кеше аңламый торган нәрсәнең халыкка кирәге юк. Әмма мужик безләрдән көчлерәк, яшәүчәнрәк. Нидер булыр да, без дә, атцур кавеме кебек, бетәрбез, ахрысы. Әйткәннәр бит бер галимгә: «Бөтен атцурлар кырылып бетте, монда бер попугай калган, алар телендә берничә сүз белә!» – дигәннәр.

## XXIV

«Тәне белән – хатын-кыз, ирләргә караганда, эчкерсезрәк, ә уе – ялган. Әмма алдаган мәлендә ул үз-үзенә ышанмыйча ялганлый, Руссоны әйтәм: үз ялганына үзе ышана».

## XXV

«Достоевский үзенең акылдан язган бер персонажы турында: «Ул үзе ышанмаган кешегә хезмәт итүе аркасында үзеннән дә, башкалардан да үч алып яши», – дип яза. Чынбарлыкта Достоевский үзе турында язган, дөресрәге, үзе турында нәкъ шулай әйтә ала».

## ...БИЗДЕРГӘН ДӘ ТЕЛ!

Яхшы гамәлләрдән үрнәк алмау – ул мәгънәсезлек. Яманнардан гыйбрәт алмау – ул рәхимсезлеккә илтә.

Демократик ил – Финляндиядә 10 мең санлы саами халкы – боланчылар яши. Саамилар – эскимосларга кардәш. Финляндиядә саами халкы башлангыч белемне саами телендә ала. Саами мәктәпләре заманча җиһазландырылган. Финнар саами халкының телен, йолаларын күз карасы кебек саклый, фин хөкүмәте саами халкына мәгариф чыгымнарына акча бүлеп бирә. Башлангыч мәктәпне ана телендә укып бетергәч, алар финча, шведча, инглизчә укый башлый.

Чехиядә яшәүче 40 мең немец халкы бөтен коммуникацияләргә дә ия: ана телендә белем алу, радио-телевидение, матбугат һ.б.

Финляндиядә 300 мең швед халкы яши. Аларның теле – икенче дәүләт теле. Финляндиядә яшәүче швед, һәр оешмага кереп, шведча сөйләшә ала, шведча язылган документ сорарга хокуклы. Шул 300 мең швед Финляндиядә тәүлек буе үз телендә радио тыңлый, телевизион тапшырулар карый.

Һиндстанда рәсми телләрнең саны – 22. Дәүләт теле буларак, һинди телен генә калдырырга маташканнар иде дә, башка телле өлкәләр моңа каршы чыкты. Һәм алар җиңде. Бу – матур үрнәк. Нигә күршебездән, ерак Һиндстаннан үрнәк алмаска!

Америкада күпләп яшәүче һәр милләт үз телендә 24 сәгать буена телевизион тапшырулар карый ала. Ни өчендер, Мәскәүдәге Мәркәзи телевидениедә чувашча да, башкортча да, нугайча да, кумыкча да, чеченча да, марича да бер генә тапшыруның да булганы юк.

Нигә без Ана телебездә белем алырга булган хокукларыбызны якламыйбыз? Нигә без башка милләтләргә Мәскәү телевидениесеннән Ана телләрендә тапшырулар булуын таләп итмибез? Еламаган балага имезлек каптырмыйлар!

Ата-аналарның Ана теленнән баш тартуы татар милләтен халыкка (народка) калдыра, Ана теленнән ваз кичкән халык халыкчага (народностька) әйләнә, Ана телен кирәксенмәгән халыкча ни урысча, ни татарча белми торган өергә әверелә! Өергә әверелергә теләмәсәгез, милли хокукларыгыз барлыгын онытмагыз!

**Рабит БАТУЛЛА**

### XXVI

– Чиркәүнең кайбер сүзләре гаҗәеп аңлаешсыз, мисал өчен: «Господня земля и исполнения её» дигән сүзләрнең мәгънәсе нидә? Бу бит – изге язмадан түгел, ә ниндидер популяр фәнни материализмнан.

– Бу фикернең мәгънәсе кайда да булса шәрехләнгәнме сезнең? – дип сорады Сулер.

– Мало что у меня истолковано... «толк-то есть, да не втолкан весь», – диде дә хәйләкәр елмайды.

### XXVII

Ул авыр, мәкерле сораулар бирергә ярата:

– Үзегез турында нәрсә уйлыйсыз?

– Хатыныгызны яратасызмы?

– Сезнеңчә, ничек, минем улым Лев талантлымы?

– Сезгә Софья Андреевна ошыймы?

Аның каршында алдашу ярамый.

Бервакыт ул миннән:

– Сез мине яратасызмы, Алексей Максимович? – дип сорады. Бусы инде – баһадирның шуклыгы; Новгород шамакае Васька Буслаев яшь чагында шундый хикмәтләр чыгара торган була. Сугышырга җыенган кебек, үчекләп, сынап карый. Кызык бу. Әмма үзеңә кагылса, күңел кабул итми. Ул – шайтан, ә мин сабый гына әле, кагылмаска иде бит миңа.

### XXVIII

Гади генә әйткәндә, бәлки, мужик аның өчен күңел болгаткыч истер, шул исне гел тоеп торганга, ихтыярсыздан аның хакында сөйләргә мәҗбүрдер.

Кичә кич мин аңа генерал хатыны Корнэ белән ничек сугышуым хакында сөйләдем. Ул, күкрәген уа-уа, нечкә тавыш белән кыраклап, күз яшьләре бәреп чыкканчы, рәхәт чигеп көлде.

– Көрәк белән! Күтенә көрәк белән, ә? Кирәк бит! Зур көрәк идеме?

Бераз хәл алгач, җитдиләнеп:

– Сез әле кызганыбрак суккансыз, бүтән берәү булса, башына тондырыр иде. Йомшак кылангансыз. Аның сезгә теләге булганны аңладыгызмы соң?

– Хәтерләмим инде, аңлаганмындыр дип уйламыйм.

– Ничек инде! Шулай икәне күренеп тора ич!

– Уемда бүтән нәрсә булган ул чакта.

– Бүтәнме-юкмы – барыбер! Сез, күрәм, хатын-кызга бик хирыс түгел. Сезнең урында бүтән берәү булсамы, үзенә каратып, карьера эшләр, йортка хуҗа булып алыр, аннары шул хатын белән бергәләп, типтереп эчеп ятар иде.

Бераз тын торганнан соң:

– Мәзәк сез. Үпкәләмәгез – бик мәзәк кеше сез! – дип өстәде. Шунысы сәер: аяусыз, усал булырга бөтен мөмкинлегегез бар, ә сез шәфкатьле. Ык кеше сез, монысы әйбәт...

Бераз дәшми утырды да гамьле итеп әйтеп куйды:

– Акыл шәрифләрегезне аңлый алмыйм, бик тә чытырманлы, ә менә йөрәгегез – акыллы. Акыллы йөрәк!

И с к ә р м ә. Казанда яшәгән чакта мин генерал хатыны Корнэга ишегалды себерүче сыйфатында ялланган идем. Иреннән тол калган француз ханым

үсмер кызларныкы сыман бәләкәй аяклы, юантык гәүдәле иде; һәрвакыт сусап ачылган тере күзләре гаҗәеп матур иде. Иргә чыкканчы, ул, минем уемча, вак-төяк сатучы яисә аш пешерүче, яисә «күңел күрүче мәгъшука» булгандыр. Иртәдән үк эчеп ала, ишегалдына йә бакчага юка күлмәге өстенә кызгылт сары төстәге халат салган килеш кенә чыга, аягына татар теккән сәхтиян читек кигән, баш түбәсенә аннан-моннан гына тараштырып өеп куйган куе чәче, таралып, алсу битенә, ачык муенына төшкәләп тора. Яшь шайтан, француз көен шыңшып, бакча буйлап йөренә, минем эшләгәнне карап тора, вакыт-вакыт кухня тәрәзәсенә килеп:

– Полин, давайте мне что-нибудь, – дип дәшә.

«Нәрсә дә булса» дигәне һәрчак бертөрле – боз салынган стаканлы шәраб.

Йортының түбәнге катында өч ятимә кыз яши, әтиләре интендант-генерал каядыр китеп олаккан, әниләре – үлгән. Генерал хатыны Корнэ бу туташларны җене сөйми, төрле низаглар чыгарып, алардан котылмакчы иде. Русча ул начар сөйләшә, әмма сүгенүе шәп, саллы йөк төяүчеләрнеке кебек. Шундый тыйнак, нигәдер курку кичергән моңсу, яклаучысыз туташларга мөнәсәбәте миңа бер дә ошамый иде аның. Бер көнне, төш җитәрәк, кызлар икәүләшеп бакчада култыклашып йөриләр иде, кинәт генеральша каяндыр кайтып керде, салмыш иде, кычкырып, туташларны бакчадан куа башлады. Алар карусыз гына борылуга, Корнэ калиткага аркылы басты да, русның үткен сүзләрен сайлап, ат өркетерлек итеп сүгенергә тотынды. Сүгенмәвен, туташларны үткәреп җибәрүен үтенгән идем, ул миңа төбәп акыра башлады:

– Я снай тибе! Ти – им лязит окно, когда ночь...

Мин, кызып китеп, иңеннән умырып тотып, калиткадан читкә этәргән идем, ычкынып китте дә ал ягы белән миңа таба борылды, халатын ачып ташлап, күлмәк итәген күтәрде дә ярып салды:

– Я луччи эти крис!

Мин үз-үземне тыеп кала алмадым, гәүдәсен бордым да көрәк белән йомшак «мендәренә» китереп ордым. Ул калиткадан чыгып очты, ишегалды буйлап йөгерә-атлый, шаккатып, өч тапкыр кабатлады:

– О! О! О!

Ышанычлысы – Полинадан паспортымны алдым да (ул да һәрчак кызмача, әмма бик мут иде) бар байлыгым сыйган юл капчыгын култык астына кыстырып, ишегалды буйлап капкага таба киттем. Кулына кызыл яулык тотып тәрәзә янында торган генеральша кычкырып калды:

– Я не звать полис – нитщего – слюший. Иди ещё назади... Не надо боясь...

## XXIX

Мин аңардан:

– Познышевның: «Табиблар меңнәрчә, йөз меңнәрчә кешене үтерделәр, үтереп торалар», – диюе белән килешәсезме? – дип сорадым.

– Моны белү бик кызыкмы сезгә?

– Бик.

– Алай булгач, әйтмим! – дип, эре кул бармаклары белән уйнап, хәйләле көлемсерәде.

Искә төште: аның бер хикәясендә медицина галиме белән авылның ат врачы чагыштырыла: «Гильчак», «почучей», «спущать кровь» дигән сүзләр шул ук нерв, ревматизм, организм кебек мәгънәләрне белдерә түгелме соң?» Боларны бит Дженнар, Беринг, Пастерларны белгән кеше әйтә. Мут та соң!

### XXX

Сәер бит, ул кәртле уйнарга ярата. Ничек кенә әле, онытылып, кызып китеп уйный. Куллары шундый сизгерләнә, гүя ул кәрт кәгазьләрен түгел, ә бармаклары арасына тере кошны яшерә.

### XXXI

«Безгә гомер, һичшиксез, аның соң минутына кадәр гаярь көрәшеп яклар өчен бирелгән», – дип Диккенс бик акыллы әйткән. Үзе югыйсә, язучы буларак, артык самими, лыгырдык, фикерле дә түгел. Ә шулай да романны беркем булдыра алмаганча әйбәт төзи. Бальзактан шәбрәк. «Китап язарга күпләр алгысый, ләкин бик сирәкләр генә язган китаплары өчен соңыннан ояла», – дип кемдер әйткән бит. Бальзак оялмаган, Диккенс та... икесенең дә йомшак әсәрләре аз түгел. Шулай да Бальзак барыбер даһи, бүтәнчә әйтеп булмый – даһи...

Кемдер Лев Тихомировның «Мин ни өчен революционер булудан туктадым» дигән китабын алып килгән. Лев Николаевич китапны өстәлдән алды да, болгый-болгый, болай диде:

– Бу китапта сәяси үтерешләр, мондый көрәшнең анык идеягә корылмавы турында әйбәт әйтелгән. Мондый идеяне, җан кыючы, акылына килеп, фәкать анархиягә ирешкән шәхеснең чиксез хакимлеге, җәмгыятьне, кешелекне күралмавы гына тудыра ала, ди. Бу – дөрес фикер, әмма «анархия» дип китап хатасы киткән, аны «монархия» дип алыштырырга кирәк. Әйбәт, дөрес идея, моңа бик күп террорчы абыначак әле, мин намуслыраклары хакында әйтәм. Кем тумыштан үтерергә ярата – ул абынмый. Аның абыныр каршылыгы юк. Әмма ул – террорчылыкка эләккән гади бер җан кыючы...

### XXXII

Кайчакларда ул, Идел төбәгеннән килгән хәреф ятлаучы сектантка охшап, үз-үзеннән канәгать булып, башкаларны күралмаска әйләнә; фани дөньяның яңгыравыклы дәү кыңгыравына килешми болай. Кичә әйтә миңа:

– Сезгә караганда, мин мужиграк, мужиклыкны сездән яхшырак тоям.

Йә Хода! Кирәкми аңа моның белән мактану, кирәкми!..

### XXXIII

«Тормыш төбендә» пьесасыннан бер өзекне кычкырып укыдым. Ул дикъкать белән тыңлады да:

– Нигә дип яздыгыз моны? – диде.

Булдыра алганымча аңлатып бирдем.

– Бездә гел шулай: бөтен нәрсәгә әтәч кебек сикереп менәргә торалар. Менә тагын сез... бөтен тишек-тошыкларны үз буявыгыз белән буйыйсыз. «Алтын укасы коела, дуңгыз тиресе кала», – дип Андерсен әйткәнне онытмагыз. Ә безнең мужиклар: «Бар да үтә, бердәнбер – дөреслек кала», – диләр. Бизәкләргә кирәкми, соңыннан үзегезгә кыен булыр. Аннары... бигрәк купшы тел, фокуслар белән, алай бармый. Гади итеп язарга кирәк, халык әнә нинди гади итеп сөйли, бәйләнешсез дә кебек, барыбер шәп! Мужик, укымышлы барин кызы кебек: «Әгәр дүрт һәрвакыт өчтән зуррак икән, нишләп өчтән бер дүрттән бердән зуррак?» – дип сорап тормый. Күз буяуларың кирәкми.

Ул мин укыганнан бер дә канәгать түгел иде. Бераз тын утырганнан соң, каядыр читкә карап, кашларын җыерып әйтте:

– Картлачыгыз әйбәт тәэсир калдырмый, аның шәфкатьле булуы ышандырмый. Актёр – әйбәт кенә. «Мәгърифәт җимешләре» белән танышмы сез? Минем андагы пешекче сезнең актёрга охшаган. Пьеса язу – авыр эш. Фахишәгез әйбәт чыккан, андыйлар булырга тиеш. Тормышта андыйларны күргәләгәнсездер бит?

– Күрдем.

– Әйе, бу сизелә. Дөреслек һәркайда ярып чыга. Күп урында үзегездән чыгарып сөйлисез, шуңа да үзенчәлекле характерлар тудыра алмагансыз. Бар да бер чыбыктан. Хатын-кызны аңлый алмыйсыз шикелле, аларның берсе дә уңышлы чыкмаган, берсе дә. Хәтерләмисез аларны...

А.Л.ның хатыны килеп чәйгә чакырды; ул, өстәл яныннан торып, шулкадәр җитез-җитез атлап китте ки, әйтерсең, әңгәмә тәмамланганга сөенгән иде.

## XXXIV

– Күргән иң куркыныч төшегез нindirәк иде?

– Мин төшләрне сирәк күрәм, хәтердә дә калдыра алмыйм. Шулай да күргән төшләремнең икесе гомергә истә калыр, мөгаен. Бервакыт мин күк гөмбәзен төче авыруы кыяфәтендә, черек итеп күрдем: яшькелт-сары төстә, йолдызлары да әллә нинди – нурсыз, яссы түгәрәк шикелле, җемелдәмиләр дә, арык кеше тәнендәге бетчәләр кебек. Күгәрек күк йөзеннән, еланга охшап, салмак кына, кызгылт төстәге яшен уты шуыша, йолдызларга тиеп-тиеп китә; ул кагылган йолдыз шунда ук бүселә башлый, шарга әверелә дә тавышсыз гына чәлпәрәмә килә, урынында төтен кебек кара тап кала, ул да тиз арада үлекләгән, сыек күк битендә сеңеп югала. Шулай итеп, йолдызлар бер-бер артлы чатнап коелып, бөтенесе дә сүнеп беттеләр, күк гөмбәзен коточкыч караңгылык басты, аннары йомарлам-йомарлам оешып кайный башлады һәм кисәк-кисәк умырылып, сыек дерелдәвек рәвешендә минем башка коелырга тотынды, ертык-умырыклар арасыннан, түбә калаена охшаган ялтыравык караңгылык чагылып китә иде.

Лев Николаевич болай диде:

– Бу инде сезнең белекле китаплардан килә, астрономиядән ни дә булса укыгансыздыр да саташып бастырылгансыз. Ә икенче төшегез?

– Икенче төш: карлы киңлек, шундый тигез, кәгазь бите кебек, ник бер калкулык, ник бер куаклык булсын, сирәк кенә урында кар астыннан берән-сәрән чыбык очлары шәйләнә. Шул үле дала карында офыктан-офыккача, соры эз булып, күренер-күренмәс юл сузылган. Юлдан соры төстәге киез итекләр атлап бара – үзләре генә.

Аның шүрәленеке кебек йөнтәс кашлары күтәрелде, миңа сынап карап торды, уйланды.

– Куркыныч бу! Сез чынлап та шулай күрдегезме, уйлап чыгармыйсызмы? Монысы да китап шаукымыннан.

Кинәт, ачуы чыккан кебек, бармаклары белән тез өстенә шапылдатып, сүзен кырыс кына дәвам итте:

– Сез бит эчүче түгел? Кайчан да булса эчүгә бирелеп, аннары ташлаганга да охшамыйсыз. Ә бит бу төшләрегездә нindiдер сәрхушлек бар. Алман язучысы Гофманның, әнә, ломбер өстәлләре урам буйлап чабыша, аның бөтен язганы шундыйрак, чөнки ул сәрхуш булган, безнең грамоталы кучерлар әйтмешли – «калаголик». Буш итекләр бара – бу бит, чынлап та, коточкыч! Уйлап чыгарган булсагыз да – бик яхшы! Куркыныч!

Көтмәгәндә, ул сакал бөртекләренә кадәр яктырып елмайды, бит очлары хәтта янып чыкты.

– Күз алдына китереп карагыз инде: Тверской буйлап капылт кына ломбер өстәле йөгереп чыга, акбур тузгытып; такталары шапы-шопы килә, яшел тукымасында язылган саннарга чаклы күренә – акциз түрәләре анда өч тәүлек буена күз дә йоммыйча кәртле уйнаганнар, өстәл болардан гарык булып чыгып качкан, – дип, рәхәтләнеп көлде дә, миңа ышанып бетмәвенә хәтерем калуны сизенеп:

– Төшләрегез табигый түгел, китап шаукымыннан дигәнемә үпкәләдегезме әллә? – диде. – Үпкәләмәгез, була бит шулай, һич уйламаганда, кабул итә алмаслык дәрәҗәдә нindидер хикмәт башка килә, син аны уйлап чыгаруыңа үзең дә ышана алмыйсың, төштә күргәнгә сылтап калдырасың. Бер карт помещик сөйләгән иде: төшендә ул, урман эчләп бара торгач, далага килеп чыга; дала түреннән калыккан ике калкулык кинәт хатын-кыз имиләренә әверелә, имиләр арасыннан кара йөз күтәрелеп килә, тасрайган күзләре урынында – ике тонык ай. Ул үзе бу мәлдә хатынның аяклары арасында басып тора. Каршында – тирән, кара упкын – аны үзенә суыра, имеш... Шуннан соң помещикның чәчләре агара башлады, куллары калтыравыкка әйләнде, шифалы сулар белән дәваланырга дип, чит илгә табиб Кнейпка китеп барды. Ул шундыйрак нәрсә күрергә тиеш иде инде, чөнки азгын бәндә иде.

Минем җилкәмнән кагып:

– Сез сәрхуш та түгел, азгын да түгел – каян килә мондый төшләр? – диде.

– Үзем дә белмим.

– Үзебез хакында без берни дә белмибез шул!

Ул тирән итеп сулыш алды, күзләрен кыса төшеп, уйланып торды да тагын өстәп куйды:

– Берни дә белмибез!

Бүген кичкырын, һава суларга чыккач, ул мине култыклап алып әйтте:

– Итекләр үзләре генә бара, диген, ә?! Буп-буш итекләр – шап-шоп, ә кар шыгырдый! Шәп бит! Шулай да сез – китапча. Ачуланмагыз, әйбәт фал түгел бу, бик комачаулаячак бу сезгә.

Минем аңа караганда китапчарак булуым икеле, ә менә бу юлы ул миңа, үзенең аклануларына карамастан, аяусыз рационалист булып күренде.

## XXXV

Кайчакларда шулай тоела: ул әле генә күз күрмәгән дөньялардан килеп төшкәндер кебек; анда башкача уйлый-хисләнәләрдер, бер-берсенә мөнәсәбәтләре дә үзгәдер, хәтта йөрешләре, телләре бүтәнчәдер. Почмакта утыра ул әнә, арыган, соры гәүдәсенә, гүя, чит җирләрнең тузаны сарган, телсез шикелле, ятсынган күз карашын дикъкать белән төбәп, барын да күзәтә.

Кичә, төш турысында, ул кунак бүлмәсенә нәкъ менә шулай – җаны еракка ашкан шикелле килеп керде, диванга утырып торды да, учы белән тезләрен кинәт ышкып, чыраен сытып, әйтеп ташлады:

– Бу әле бөтенесе дә түгел, юк бөтенесе түгел!

Арабызда үтүк кебек тупыйк һәм тинтәк күренгән берәү:

– Сез нәрсә турында? – дип сорап куйды.

Ул аның аша үткен карашын йөгертеп алды да, алга таба авышыбрак, табиб Никитин, Елпатьевский һәм мин утырган терраса ягына ым кагып:

– Сез ни хакында гәпләшәсез? – дип сорады.

– Плеве турында.

– Плеве... Плеве турында...

Гүя, ул бу исемне беренче кат ишетә – уйга калып, бераз тын утырды да, кош кагынгандай кинәт талпынып, сүрән генә көлемсерәп, сүзгә кереште:

– Бүген иртәдән бирле башымда сантый уйлар тулгана; кабер ташыннан укыдым, дип кемдер әйтте миңа:

Под камнем сим Иван Егорьев опочил,
Кожевник ремеслом, он кожи всё мочил,
Трудился праведно, был сердцем добр, но вот,
Скончался, отказав жене своей завод,
Он был ещё не стар и мог бы много смочь,
Но Бог его прибрал для райской жизни в ночь
С пятницы на субботу страстной недели…

Шулайрак дәвам итә инде... – диде, аннары шактый гына утырганнан соң, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп, башын чайкый-чайкый:

– Кешенең ахмаклыгында, әгәр төбендә явызлык ятмаса, күңелне кузгата торган сөйкемлелек була... Һәрчак шулай... – диде.

Ул арада төшке ашка чакырдылар.

## XXXVI

«Исерекләрне җенем сөйми, ләкин эчеп алгач, күз алдында үзгәреп, кызыклы кешегә әверелгәннәр дә очрый, ул – телгә осталык, ул – матур фикерле белү, елдамлык, сүз байлыгы дисеңме. Андый очракта мин шәрабка фатиха бирәм».

Сулер сөйләде: Лев Николаевич белән Тверской буйлап баралар икән, Толстой ерактан ук ике кирасирны күреп ала. Хәрби киемнәрендәге җизләрен кояшта елтыратып, бер төптән чыккан шикелле, бер аяктан атлап киләләр икән болар, йөзләре дә яшьлек һәм көч-дәрманнарыннан канәгать калудан балкыган. Толстой канәгатьсезлек белдерә башлаган:

– Нинди тантаналы ахмаклык! Таяк белән кыйнап өйрәтелгән җәнлекләр кебек...

Әмма, кирасирлар килеп җитеп, алар белән тигезләшкәч, Толстой туктала да, ягымлы караш белән озатып калып, соклануын белдерә:

– Нинди чибәрләр! Борынгы римляннар кебек, ә, Лёвушка?! Ул кодрәт, ул чибәрлек – йә Ходаем! Адәми затның чибәрлеге – нинди күркәм, нинди затлы!

## XXXVII

Эссе көн иде, ул мине түбәнге юлда куып җитте – атка атланып, Ливадиягә барышы икән. Тәбәнәк, тыңлаучан татар атына утырган, соры киемнән, гөмбә кебек ак киез эшләпәсе астында гөнҗәлә чәч, сакал-мыек, болай ул гномга охшаган.

Атын тыя төште, мин тезген янәшәсеннән теркелдим. Сүз ара сүз чыгып, В.Г.Короленкодан хат алуымны әйттем. Толстой, ачуы кабарып, сакалын селкетеп алды:

– Ул Аллага ышанамы?

– Белмим.

– Иң мөһимен белмисез икән. Ул – ышана, әмма атеистлар каршында уңайсызлана.

Көйсезләнеп, күзләрен усал кысып, үзалдына мыгырдана башлады. Үземнең артык икәнемне сизеп, мин китәргә ниятләгән идем, туктатып калды:

– Кая сез? Мин атлатып кына барам.

Тагын сукранган кебек итеп:

– Сезнең Андреев та атеистлардан ояла, Аллага ышана бит югыйсә, Аллаһ аның өчен – дәһшәтле.

Бөек кенәз А.М.Романовның биләмәләре чигендә юл уртасына бер-берсенә бик якын килеп баскан бертуган өч Романов гәпләшеп тора иде: Ай-Тодор хуҗасы, Георгий һәм тагын берәү, Дюльбердан Пётр Николаевич иде шикелле. Һәрберсе вәкарьле, эре гәүдәлеләр. Юлны ике тәгәрмәчле фаэтонга җигелгән атлар бөягән, җитмәсә, кырыйда, аркылы килеп, иярле ат басып тора. Лев Николаевичка үтеп китәргә ара юк иде. Ул Романовлар ягына кырыс, таләпчән карашын төбәде. Ә тегеләр аңа кадәр үк аркалары белән борылып басканнар иде. Иярле ат бер урында таптанып алды да кырыйгарак чигенде, Толстойның атын үткәреп җибәрде.

Ике минутлап сүзсез барганнан соң:

– Таныдылар бит ахмаклар, – диде.

Тагын бер минуттан соң:

– Ат аңлады Толстойга юл бирергә кирәклеген, – диде.

**XXXVIII**

«Барыннан да битәр – үзегезне үзегез өчен саклагыз, шул чакта кешеләргә дә артып калырсыз».

**XXXIX**

«Нәрсә ул – белү? Менә мин беләм: мин – Толстой, язучы, минем хатыным, балаларым, чал чәчем, ямьсез чыраем, сакалым бар – боларның барысын да паспортка язалар. Җан хакында паспортка язылмый, мин бары шуны беләм: җан Аллаһка сыгынырга тели. Ә Илаһ үзе ни? Минем җаным аның бер бөртегеме? Кем уйлана белә, аның өчен ышану кыен бирелә, ә **Аллаһныкы булу өчен,** фәкать Аңа ышанып кына яшәп була. Тертулиан әнә: «Фикер – үзе явызлык», дигән».

**XL**

Үзенең вәгазьләре бертөрлерәк булуга карамастан, чиксез күпкырлы бу – әкияти зат.

Бүген паркта Гаспра мулласы белән гәпләшеп торуын күзәттем дә... мулла каршысында ул үзен, гүя, соңгы көннәре хакында фикер алышу сәгатьләре җиткән ышанучан-беркатлы гади бер мужик кебек тота. Әллә инде юри куырылып баскан, нык бәдәнле, саллы гәүдәле татар каршында ул буе кечерәеп калган бер картлач шикелле күренә, җаны, гүя, яшәү мәгънәсе хакында тәүге тапкыр уйга калып, үзен бимазалаган сорауларны бирергә куркып тора. Йөнтәс кашларын гаҗәпләнгән рәвешле күтәргән, түземсез, елдырым утлары сүндерелгән күзләре сагаюлы ачылып-ябыла. Күпләрне чарасыз калдыра торган, үтәли тишеп караган күз алмаларын сүрелтеп, ул мулланың киңчә йөзенә төбәлгән. Яшәү мәгънәсе, җан шәрифе, Хак Тәгалә хакында ул муллага «балаларча» сораулар бирә, гадәттән тыш елдамлык белән Коръән шигырьләрен Инҗилнеке һәм пәйгамбәр тәфсирләре белән бер-бер артлы чиратлаштырып әйтә. Чынында ул бөек артистка, акыл иясенә хас булганча, гаҗәеп сәнгатьле итеп уйный иде.

Берничә көн элек кенә, ул Танеев һәм Сулер белән музыка хакында сөхбәтләшеп утырганда, үзенең искиткеч соклауын белдерде, хәтта аның шулай соклана алуы, дөресрәге, соклана белү сәләте үзенә дә ошый иде. «Музыка хакында бөтенесенә караганда да әтрафлырак, тирәнрәк итеп Шопенгауэр язды», – диде. Сүз уңаеннан Фет турында көлкеле мәзәк сөйләде. Музыканы «җанның телсез догасы» дип атады.

– Ничек инде – телсез? – дип сорады Сулер.

– Сүзсез булганга. Фикергә караганда, аһәңдә җан күбрәк. Фикер ул – акча янчыгы, анда – тиеннәр, ә аһәң керләнмәгән, асылы саф.

Ягымлы, самими сүзләр сайлап, ләззәт белән сөйләгән җиреннән ул, кинәт кенә сакалы куелыгыннан елмаеп, иркәләгән кебек, йомшак кына әйтеп куйды:

– Бөтен музыкантлар да – тилемсә кешеләр. Музыкант – никадәр талантлырак, шулкадәр чикләнгәнрәк була. Шунысы сәер: аларның барысы да диярлек дингә бирелгән.

## XLI

Кирәкмәгәнне сөйләүчеләрне ул тыңламый да, аларга ышанмый да. Асылда, ул сорамый, ә сорау ала. Сирәк әйберләр җыючы кебек, коллекциясенең бөтенлеген бозмаганны гына үзенә ала.

## XLII

Почтаны барлаганда әйткәне:

– Шаулаган булалар, язган булалар, үлеп китсәм, бер елдан сораячаклар бит:

– Толстой? Ә-ә, теге итек тегәргә маташкан графмы һәм аңа нәрсәдер булган, – әйеме, шул үземе?

## XLIII

Берничә тапкыр мин аның йөзендә, күз карашында чагылып киткән аерым бертөрле хәйләкәр елмаю күрдем, үзе яшереп куйган әйберен үзе дә уйламаганда табып алып, канәгатьлек кичергән кешенең елмаюы иде ул. Каядыр яшергән дә оныткан, кая гына куйдым соң ул кирәкле әйберне, дип, күпме көннәр буена эчке бер хафалану кичереп йөргән. Бу хафалануын сизеп алырлар да аңа нинди дә булса этлек эшләрләр дигән курку кичергән. Кинәт кенә табып алган бит. Шатлыгы бөтен вөҗүденә таралган, моны сизүләре дә борчымый аны, бөтенесенә хәйләкәр елмаю аша карап әйтә шикелле:

«Мине берни дә эшләтә алмыйсыз».

Кайдан, нәрсәне тапканы хакында – ләм-мим.

Аңа карап гаҗәпләнеп туя алмыйсың. Шулай да аның белән еш күрешү авыр, ә инде бер түбә астында, җитмәсә икең бер бүлмәдә яшәүне күз алдына да китерә алмыйм. Бу – бөтен нәрсәне көйдергән кояшлы чүлдә калган кебек булыр иде, ә кояш үзе, кара төн чиксезлеге белән куркытып, сүнеп бара.

## *ХАТ* *

Әле генә Сезгә хат җибәрдем. «Толстойның качуы» турында телеграмма алдым да, уемда, Сездән аерылмыйча, тагын язам.

Бу хәбәр хакында ни дә булса әйтергә теләгәнем, бәлки, буталчык чыгар,

* Хат 1910 елның 3 (16) ноябрендә В.Г.Короленкога язылып та тәмамланмаган һәм җибәрелмәгән, аннары бу бүлеккә тагын М.М.Коцюбинский һәм Е.П.Пешковага язылган хатлардан өзекләр кертелгән.

бәлки, артык кискен, усал да әйтелер – сездән гафу үтенәм, чөнки мин шундый халәттә, әйтерсең лә бугазымнан кысып алып, тынымны буалар.

Аның белән күп тапкыр сөхбәтләшеп утырган булды. Кырымда, Гаспрада чагында янына еш килә идем, ул да миңа бик теләп килә иде, бөтен китапларын да йотылып яратып укыган кеше буларак, мин аның турында, гомум караштан үзгәрәк, кырысрак хөкем чыгарсам да, моңа хакым бар дип саныйм. Бүтәннәрдән калышып фикер йөртмим, аның кебек тә катлаулы, каршылыклы, даһи мәртәбәгә бөтен яктан да килгән гүзәл кеше юк. Гүзәл, дип, киң тарафка куеп, гадәти сүзләргә сыялмый торган аерым бер мәгънә салып әйтәм. «Карагыз, гаҗәеп кеше яши бу җирдә!» дип, һәммәсе ишетерлек итеп кычкырасы килү теләген уята торган ниндидер җене бар иде аның. Ул галәми колачлы булса да, беренче чиратта, кеше иде – кешелек кешесе.

Әмма мине үҗәт, залими омтылыш белән Лев Николаевич Толстойның тормышын менә шуңа җиткерергә тырышу – «житие иже во святых отца нашего блаженного боярина Льва» – менә бу мине аңардан ерагайта иде. Сез беләсез микән, ул күптән инде «газап кичерергә» әзерләнә иде; Евгений Соловьёвка, Сулерга моның әлегәчә барып чыкмавына үкенүен дә белдергән. Әмма ул, үз ихтыяры ныклыгын гадәти сынап карау өчен, газапка дучар ителүне генә күздә тотмый, ә максатчан, кабатлап әйтәм, үз дини өйрәтмәләренең басымын көчәйтү өчен, үзалдына аяусыз максат куеп, вәгазьләрен кире кагылмаслык дәлилләп, үз интегүләре мисалында, кешеләр каршында изгеләндереп – кабул кылырга мәҗбүр иттерергә тели, кабатлап әйтәм – мәҗбүр иттерергә! Чөнки белә, вәгазьләре җитәрлек дәрәҗәдә ышандыра алмый; сез аның үз өйрәтмәләренә-вәгазьләренә, үз шәхесенә карата шикләнүләрен белдергән гыйбрәтле мисалларны, вакыты җиткәч, көндәлекләреннән укырсыз. Ул белә: «газап чигүчеләр, интегүчеләрнең сирәкләре генә деспот, залим булмый кала» – ул барын да белә! Ә шулай да әйтә: «Үз фикерләрем өчен газап чиксәм, тәэсире бөтенләй бүтәнчә булыр иде», – ди. Нәкъ менә шушы карашы мине аңардан читләштерә иде, чөнки мин моны ирексезләү дип тоям, теләге: намусымны йолып, билэп алу, тәкъвалы кан җемелдәвенә күмү, муеныма догмат камыты кидерү.

Ул еш кына теге дөньядагы үлемсезлек хакында мавыгып сөйли, әмма аңа күбрәк дөньяның бу ягындагысы ошый иде. Чын, асыл төшенчәдә чын милли әдип буларак, ул галәми күңелендә милләтнең бөтен житешсез якларын, тарихыбыз биргән җәза-имгәнүләрне туплаган иде.

Аның 1905 елда язган «Интеллигенция, дәүләт, халык» дигән хатын искә төшерегез әле, хәтер калдыргыч, яманлыкка сөенү түгелмени! Сектантларча: «Әһә, мине тыңламадыгызмы!» – дигәне аңкып тора. Үз сүзләренә үк нигезләнеп, мин шул чакта болай дип хат язган идем: «Ул «күптән инде рус халкы турында һәм аның исеменнән әйтү хокукын җуйды», чөнки мин шаһиты: үз янына эчен бушатырга дип килгән халыкны ул тыңларга да, аңларга да теләмәде». Хатым зәһәр килеп чыкканга, мин аны җибәрмәдем.

Менә хәзер ул, үзенең уй-фикерләренә югары мәгънә бирү өчен, бәлки, соңгы сикерешенә талпынгандыр. Василий Буслаев кебек, ул, гомумән, сикерергә ярата иде, ә кыйбласы – һәрчак изгелеген раслау, нур такыясы (нимб) ягына юнәлгән булыр. Бу – инквизиторлык, гәрчә өйрәтмәләре Россиянең борынгы тарихы белән, даһиның шәхси вөҗдан газаплары белән акланса да. Аныңча, изгелеккә – гөнаһлардан куаныч алып, тормышка булган ихтыяр көчен кол итү юлы белән ирешелә. Кешеләрнең яшисе килә, ә ул: «Җирдәге тормыш берни

тормый!» – дип ышандырмакчы. Россия кешесен моңа бик җиңел ышандырып була... Гомумән алганда, ул, әлбәттә, Платон Каратаев та, Аким да, Безухий да, Неклюдов та түгел – болар табигать һәм тарих тарафыннан Толстойча яратылмаганнар. Үз вәгазьләрен тагын да ныгыту өчен генә ул аларны төзәтте. Шунысы инкарь ителерлек түгел: тулаем алганда, Русь ул – түбәндә – Тюлин, югарыда – Обломов. Тюлинның кем икәненә 1905 ел шаһит. Ә Обломовның кем икәнен граф Лев Николаевич Толстойдан, А.Буниннан карагыз, үз даирәгезгә күз салыгыз. Ерткычларны һәм жуликларны бер кырыйда калдырыйк, алай дисәң дә... ерткыч та бит бездә гадәттән тыш милли – карагыз сез аңа, явызлыгы өстенә ул әле җирәнгеч куркак та. Ә жуликлар, гадәттәгечә, милләтсез була.

Лев Николаевичның күп ягын мин дә күрәлмас дәрәҗәгә җитә яза идем, шул җанны изә иде. Шәхесенең чамасыз, хәтта артык дәрәҗәдә купайтылуында – иләмсезлек, җир чак күтәреп торган Святогор-баһадир шаукымы бар иде. Әйе, ул бөек! Мин нык ышанам: сөйләгәннәреннән тыш, күп кенә әйтелми калган серләре аның дәшмәвендә иде. Хәтта көндәлекләрендә дә ул ачылып бетми – тын кала, ул нәрсә беркайчан да, беркемгә дә ачылмаячак та. Кайчакларда гәпләшеп утырганда, ул «нәрсә» чагылып китә, миңа һәм Л.А.Сулержицкийга укырга биреп торган ике көндәлек дәфтәрендә дә кинаяле сизелеп ала; миңа калса бу – «бөтен расланган карашны инкарь итү», тирән, аяусыз нигилизм, моның җирлеге – актык чиккә җиткән, беркем арындыра алмаган өметсезлеге һәм ялгызлыгыннан килә. Болай ук та ачык итеп моны аңа кадәр беркем дә тоя алмагандыр. Икеләнми әйтәм, еш кына ул күңел төбендә кешеләргә карата битарафлык саклый иде. Ул – шундый да биеклектә, кодрәткә ия ки, ә тегеләр аның өчен вак чебен өере, мәшәкате, ыгы-зыгылары белән көлке дә, мескен дә. Ул алардан бик ераклашкан, япан чүл уртасына җиткән дә, үзенең бар ихтыяр көчен киереп, бер ялгызы «иң мөһим хикмәтне» – үлемне күзәтә.

Гомере буе үлемнән курыкты, күрәлмады ул аны, гомере буе җан янәшәсендә аны «арзамас бүкәе» тетрәтеп торды: аңамы соң, Толстойгамы үлү? Бөтен җиһан аңа төбәлгән; Кытай, Һиндстан, Америкадан – һәр тарафтан аңа таба тере кан тамырлары сузылган, аның җаны – һәммәсендә дә, гомерлеккә! Нигә әле әлмисактан килгән канунны бозып, табигатькә үзенең бер кешесенә җисми үлемсезлек бирмәскә ди, нигә? Ул, әлбәттә, төптән уйлап эш итүчән, могҗизага ышанмаслык дәрәҗәдә акылга ия кеше, икенчедән, ул – шукланырга, сынап карарга ярата, күз күрмәгән казармага эләгер алдыннан, куркудан, чарасызлыктан дуамалланган яшь рекрут шикелле кылана иде. Хәтерлим әле, Гаспрада савыгып чykканнан соң, ул, Лев Шестовның «Ницше һәм граф Толстой өйрәтмәләрендәге яхшылык һәм явызлык хакында» дигән китабына карата А.П.Чеховның «ул китап миңа ошамады» дигәненә җавап итеп, болай дигән иде:

– Ә менә мин мавыгып укыдым. Кыландырыбрак язылган, ә барыбер кызыклы. Әгәр эчкерсезлектән килсә, әдәпсезләрне дә яратам ич мин. Менә ул: «Асыл хакыйкать кирәкми», – дигән, дөрес бит: нигә аңа хакыйкать? Барыбер – үләчәк.

Шул мәлдә, әйткән сүзенең аңлашылып бетмәвен сизенеп, өстәп куйды:

– Уйланырга өйрәнгән кеше, ни турында гына уйланмасын – ул үзенең үлеме хакында уйлый. Бөтен философлар да шундый. Үлем киләсе булгач, нинди асыл хакыйкать булырга мөмкин, ә?

Аннары ул: «Бөтенесе өчен дә уртак бердәнбер асыл хакыйкать – Аллаһны ярату», – дип, бу теманы салкын гына, арыган халәттә уртага салды. Төшке

аштан соң, террасага чыгып утыргач, теге китапны тагын кулына алды да: «Толстой, Достоевский, Ницше үз сорауларына җавап тапмыйча яши алмыйлар иде, алар өчен бөтенләй җавапсыз калуга караганда, теләсә нинди җавап табу кулайрак» дигән җирен укып көлде:

– Менә нинди кыю чәч кыркучы ул, турыдан-туры әйтә бит: мин үземне алдадым, димәк – бүтәннәрне дә. Бу бит ачыктан-ачык күренеп тора...

– Ә нишләп чәч алучы? – дип сорады Сулер.

– Болай гына, – диде ул, үзалдына уйланып. – Башка килде дә. Авылда мужиклар арасына килеп эләккән көяз, затлы Мәскәү парикмахеры искә төште дә. Хәрәкәтләре купшы, нәзакәтле, кыланып бии, бөтенесенә өстән генә җирәнеп карый.

Бу сөйләшүне сүзгә-сүз китерәм, мин аны, үземне мавыктырган күпләре кебек үк, кәгазьгә төшергән идем. Мин дә, Сулержицкий да еш кына язып барган идек, әмма Сулер, миңа килешли, Арзамас юлында язмаларын югалткан булып чыкты. Бу яктан ул – таркау кеше иде, Лев Николаевичны хатын-кызларча ярата үзе, ә мөнәсәбәте ничектер сәер, гүя – аңа өстән, вәкарь белән карый. Мин дә үземнең язып барган кәгазьләремне каядыр тыкканмын, таба гына алмыйм, Россиядә кемгәдер биреп калдырганмын ахрысы.

Мин Толстойны бик игътибар белән күзәтә идем, чөнки мин тере, асыл дингә табынучыны гел эзләдем, эзлим һәм гомер соңынача эзләячәкмен. Бервакыт А.П.Чехов, безнең культурасызлык хакында зарланып торды:

– Әнә Гётеның һәр сүзен язып барганнар, ә Толстойның фикерләре һавада эреп югала. Соңыннан, аңга килеп, тотыначаклар истәлек язарга – алдашачаклар бит, – дигән иде.

Аннары Шестов мәсьәләсендә Лев Николаевич болай диде:

– «Куркыныч өрәкләргә карап яшәргә ярамый бит инде», дигән. Каян белә ул ярый-ярамыйны? Әгәр ул белсә, өрәкләрне үз күзе белән күргән булса, пүчтәкне язмас, гомере буе җитди гамәл кылган Будда кебек, бүтән нәрсәгә тотыныр иде.

Шестовның яһүд икәнен искәрткәч:

– Булмас, – дип, ышанычсыз гына әйтеп куйды Лев Николаевич. – Юк, ул яһүдкә охшамаган; дин тотмаган яһүд булмый, хет берне табып әйтегез ...юк.

Кайчакта шулай тоела: бу карт сихерче үлем белән уйный бит, үчекли аны, ничек тә хәйләләмәкче була: мин синнән курыкмыйм, мин сине яратам, мин сине көтәм. Ә үзе җете күзләрен кысып күзәтә: «Нинди микән син? Синең артыңда, тегендәрәк ни бар? Син мине тулаем юк итәсеңме, әллә инде ни дә булса яшәп калачакмы?»

Аның: «Миңа әйбәт, миңа коточкыч әйбәт, миңа искиткеч әйбәт», дигәне сәер тойгылар уята. Шунда ук өстәп куя: «Газап чигәргә иде». Интегәсе килүе – монысы дөрес; секунд та икеләнмичә әйтәм, ул, әле авыру хәлендә дә төрмәгә эләксә яисә сөргенгә җибәрсәләр, чын күңеленнән куанып, газап таҗын кияр иде. Бәлки, газап чигү аныңча үлемне күпмедер дәрәҗәдә аклау, аңлаешлы итү, кабул кылуны җиңеләйтүдер. Әмма аңа беркайда да рәхәт түгел иде, ышанып әйтәм, беркайчан да, беркайда да: «акыллы китапларга чумганда да», «ат иярендә дә», «хатын-кыз күкрәгендә дә» ул «җир оҗмахының» ләззәтен төбенәчә кичерә алмады, чөнки ул аек акылы өстенлек иткән, тормышны, адәми затларны үтәли күрә белгән кеше иде. Бервакыт болай диде:

– Габдрахман хәлифә бу тормышта бәхетле ундүрт көн кичергән, минеке

алай ук түгел бугай. Чөнки мин беркайчан да үзем өчен, күңелем өчен дип яшәмәдем, яши дә белмәдем; кешеләр өчен, тыштан гына яшәдем.

А.П.Чехов аңардан чыгып киткәндә миңа әйтте: «Мин аның бәхетсез булуына ышанмыйм», – диде. Ә мин ышанам. Әмма аның «тыштан гына» дию дөрес түгел, әлбәттә, ул кешеләргә, ярлыларга үзеннән артканны бирә барды; аларны укырга «мәҗбүр итү», бергә күңел ачу, яшелчә, җиләк-җимеш кенә ашап тору, мужикны ярату, үзенең, ягъни Лев Толстойның дини фараз-аңгәмәләренең гөнаһсызлыгына ышану – аңа ошый иде. Нәрсәдер сонарга кирәк, йә канәгатьләнеп, йә шөгыль табып китсеннәр, югалсыннар гына! Күнегелгән газаплы, ә кайчакта уңайлы тоелган ялгызлыгында «төп сорау» бимазалаган тома упкын каршында калдырсыннар гына үзен.

Русның бөтен вәгазьчеләре дә – Аввакумнан һәм, бәлки, Тихон Задонскийдан калганнары – салкын кешеләр, чөнки алар җанга тәэсир итүчән дини өйрәтмәләргә ия түгелләр иде. Мин үземнең «Тормыш төбендә» дигән пьесамда Луканы нәкъ шундый карт итеп сурәтләдем дә: аны кешеләр түгел, ә «барыннан да бигрәк, нинди булса да җавап табу» кызыксындыра. Ирексездән кешеләр белән каршылыкка килгәндә, ул аларны үзенә комачау итмәсен өчен генә юаткан була. Мондый бәндәләрнең бөтен акыллы фикере, вәгазьләре эчкә яшерелгән, чиркану аша бирелгән сәдака кебек, вәгазь-өйрәтмәләре исә фәкыйрь сүзләргә төрелгән, ялварулы иде: «Дүрт ягың кыйбла!» Аллаһны вә якыннарыгызны яратыгыз, ә дүрт ягыгыз – кыйбла! Аллаһны каһәрләгез, ерактагыны яратыгыз һәм – дүрт ягыгыз кыйбла! Калдырыгыз мине, мин дә бит үлемгә дучар ителгән кеше!»

Нишлисең, бу шулай һәм озакка. Бүтәнчә булмый һәм булачак та түгел, чөнки кешеләр кавеме җәфалардан арып тинтерәгән, бер-берсеннән коточкыч аерылган, бөтенесе дә җан җелеген суырып торган ялгызлык белән тышауланган. Әгәр дә Лев Николаевич чиркәү белән килешүгә барса, мине әз генә дә гаҗәпләндермәс иде. Бу очракта аның үз мантыйгы: бөтен кешеләр дә чүп, хәтта епископ булса да. Ә чынлыкта, туры мәгънәдә килешү барып чыкмас та иде, аның өчен бу акт: «Үземне күрәлмаучыларны ярлыкыйм» дигән мантыйкый бер адым гына. Христианнарча адым, ә төбендә җиңелчә генә мыскыллы елмаю яшеренгән; моны – акыллы затның тинтәкләрдән үч алуы дип аңларга булыр иде.

Ни турында, кирәкмәгәнгә, ни язам соң әле мин? Җанымда эт улый, ниндидер кайгы киләсе шәйләнә. Менә газеталар бәйләме килде, бар да ачык хәзер: сезнең анда «легендалар тудыра» башлаганнар – торган, яшәгән, ди, ялкаулар вә эш сөймәүчеләр, ә ирешкәннәре – изгелек иясен табу. Уйлап кына карагыз, өмете өзелгәннәренең башы иелгән, күпләрнең күңеле – буш, яхшыларның күңеле кайгы белән тулган хәзерге халәтебездә ил өчен бу бит бик зарарлы.

Ач-ялангачлар легендага тартыла. Шуның белән – изелүен, вөҗдан газабын басарга тырыша. Менә шушы теләкне канәгатьләндерергә тырышачаклар инде хәзер, кирәкми иде «житие блаженного и святого», югыйсә ул үзенең кеше булуы белән бөек һәм изге иде, кеше буларак ул чиктән тыш әрнүле матур иде, кешелек кешесе. Мин бу очракта үз-үземә каршы да киләм, әмма анысы мөһим түгел. Аның Аллаһны эзләп табарга талпынуы үзе өчен түгел, ә кешеләр өчен иде, чөнки кешене ул үзе сайлаган тыныч чүлдә калдырып киткән иде. Христос кальбендәге каршылыкларны оныттырыр өчен, аның рәвешен гадиләштереп, сугышчанлык башлангычын йомшартып, ул безгә Инҗил бирде. «Күктән

юллаучы ихтыярына» күндәм булырга чакырды. Һичшиксез, Толстой Инҗиле кабул итәргә җиңелрәк, чөнки рус халкының сырхавына тәңгәл килә. Ни дә булса бирергә кирәк иде бит инде бу халыкка, «төп нәрсәдән» дикъкатьне алып, күпме зарланырга, җирне тетрәтеп, күпме ыңгырашырга мөмкин. Ә «Сугыш һәм дөнья» һәм тагын шул исәптән, башкалары – шыксыз рус җирендәге кайгы-өметсезлекне тынычландыра, юата алмый иде.

«Сугыш һәм дөнья»ны ул үзе: «ялган тыйнаклыкка бирелмичә» – «Илиада» дип атаган. М.И.Чайковский «Балачак», «Үсмерчак» хакында да үз авызыннан шундый бәя ишеткән.

Әле генә Неапольдан журналистлар килеп китте, берсе Римнан ук кубарылган. Миннән «Толстойның качуы» турында фикер ишетәселәре килә, «качу» дип туп-туры әйтәләр бит әле. Сөйләшәсем килмәде. Аңлыйсыздыр, әлбәттә, җаным хәвефле ярсыган мәл, минем Толстойны изге итеп күрәсем килми; шулай гөнаһлардан хали булмыйча калып, үтәли гөнаһка манчылган бу дөньяда йөрәккә якын мисалда калсын. Пушкин һәм ул – безнең өчен алардан да бөек һәм кадерле беркем дә юк...

Лев Толстой үлде.

Телеграмма килде, анда артык гади итеп әйтелгән: «үлде».

Бу хәбәр йөрәккә бәрде, ачынулы сагыштан үксеп еладым, менә хәзер, ярымаңсыз бер халәттә, аны ничек белгән-күргәнемне хәтердән барлап, җанны авырттырып, аның турында сөйлисе килә. Табутта ятуын күз алдыма китерәм: инеш төбендә шомарган таштай ятадыр кебек, чал сакалы куелыгына – күпләр өчен ят булган, алдандыра торган елмаюы яшеренгәндер кебек. Каторга мәктәбен үткән куллары, ниһаять, тынычланып, кушырып куелгандыр. Бөтенесен дә үтәли күрә торган күзләрен хәтерлим, һавадан укмаштырып, һәрчак нидер әвәләгән шикелле хәрәкәтчән бармаклары, фикерләү рәвеше, шаяртулары, мужиклардан йоккан хикмәтле сүзләре, тонык тавышы. Күзаллап карыйм да... биниһая олы тормыш мәйданын колачлаган бу зат – үзе – акыл иясе, үзе – дәһшәтле.

Бервакыт мин аны шундый бер мәлендә күрдем, андый халәттә күрү аны, бәлки, кемгә дә насыйп булмагандыр. Гаспрада ул яшәгән җиргә барырга дип чыктым да Юсуповлар биләмәсе турыннан, диңгезгә терәлгән яр астыннан бара идем, ташлар арасыннан аның кечерәеп калган курач гәүдәсен искәреп алдым; таушалганрак төссез җилән, ямьшек эшләпә кигән. Яңагын учына сөяп, сакалының көмешсу бөртекләрен бармак арасында бөтерә-бөтерә еракка, диңгез киңлегенә төбәлгән, аяк очына тәгәрәп килгән карусыз яшькелт дулкыннар, куштанланып, карт күрәзәчегә үзләре хакында нидер сөйлидер шикелле. Болытлы да, кояшлы да көн иде бу. Кабарынкы ташларны болыт күләгәләре ара-тирә сыйпап уза, тагын кояш ялтырап чыга, шул ташлар белән бергә картның гәүдәсе дә бер караңгылана, бер яктыра. Бер-берсенә әүмәлгән зур-зур ташлар – чатнаган җыерчыклы, кичәге штормнан соң, исе аңкып торган суүсемнәр белән капланган. Бу мизгелдә Толстой үзе дә җан иңдерелгән борынгы таш кебек тоелды; тереклекнең әүвәлен, ни өчен яшәвен, җир йөзендәге үсемлекләрнең, дәрья суларының, кеше кавеменең, бөтен җиһанның – ташлардан алып кояшкача – кайчан, ничек бетәчәген дә ул гына беләдер кебек. Бу диңгез дә – аның күңел дулкыныннан, тирә-юньдәге бар хәят – аның ымыннан, аның кодрәтеннән яратылган. Әнә ул, бер хәрәкәтсез халәттә, уйга талган. Гүя, аның гәүдәсе аша үтеп, тамырлары – җир караңгылыгына, ә ябалдашы күк гөмбәзенә үрләгән ниндидер сихер, тылсым нурын күргәндәй

булдым. Ул – бер ноктаи назарга төбәлгән дә ихтыяр көче белән дулкыннарны әле үзенә тарта, әле чигендерә; болытларны, күләгәләрен ияртеп, бер җыя, бер тарата; ташларны, кубарып, йокысыннан уята. Кинәт мин шашынулы бу мизгелдә шуны тойдым – мондый могҗизаның да булуы мөмкин бит! – менә хәзер бөтен буена аягүрә басар да, кулын җилпер дә... диңгез дулкыннары тораташ калыр, ташлар калтырый-калтырый кычкырырга тотыныр, бөтен хәят кайнап хәрәкәткә килер, төрле тавышка үзе турында, аның турында, аңа каршы сөйли башлар. Ул мизгелдә мин ниләр тойганымны сүзләр белән аңлатып бирә алмыйм, күңелдәге тантаналы да, хәвефле дә хисләр ачышы бәхетле уйга килеп төенләште:

«Мондый кеше барда мин бу җирдә ятим түгел!»

Ул чакта мин, аның уйларын бүлдерәсем килмичә, чуер ташларны чыкырдатмыйм дип, сак кына атлап, кире киттем.

Менә хәзер инде үземне тома ятим итеп тоям, язам да елыйм, гомеремдә дә болай ук кайгыдан сыгылып үкси-үкси, ачы итеп елаганым юк иде. Әйтә алмыйм: яраттыммы мин аны, хәер, аңа карата булган ярату яисә күралмау хисе – мөһиммени?! Ул һәрвакыт минем күңелемдә олы, фантастик дулкынланулар кузгата иде; хәтта ул уяткан кабул ителмәслек дошмани хисләр дә төшенкелеккә китерми, ә, ниндидер шартлау уятып, күңел офыгын киңәйтеп, сизгерләтә генә иде. Кадерле мизгелләр: менә ул, аяк астындагы тигезсезлекләрне тигезләнергә мәҗбүр иткән шикелле, табанын ышкытып атлап килә, искәрми дә каласың, йә ишектән, йә берәр почмактан пәйда була да җирдән нык басып йөрергә күнеккән аякларын вак-вак атлатып килә, кулының баш бармакларын билбавына кыстырып, бер секундка гына туктала, үткен карашын йөгертеп, эчтән барысын да аңлап ала:

– Исәнмесез!

Мин һәрвакыт бу сүзнең мәгънәсен болай шәрехли идем: «Исәнмесез! – миңа – канәгатьлек, ә сезгә аннан әллә ни йокмас, шулай да – исәнмесез!»

Гәүдәгә кечкенә үзе, әмма яныбызга килеп басуга, бар да аңардан кечерәк булып кала. Сакалы мужикларныкыча тупас, әмма куллары гаҗәеп, киеме гади, аның менә шушындый тышкы кыяфәт-рәвешеннән күпләр алдана, россиялеләрнең, беркатлыланып, эчкә төртеп сөйләшергә җиткән тәкәллефсезлегенә (аминокошонлык) еш кына үземә шаһит булырга туры килде. «Әх, туганкаебыз безнең. Менә нинди икәнсең бит! Ниһаять, туган җиребезнең бөек улын күрү бәхетенә ирештем бит! Мәңге яшә, табынуымны кабул кыл!»

Бусы – гадие, күңелдән чыкканы – Мәскәү русыныкы, менә тагын «иректе уйлаучы» руcныкы: «Лев Николаевич! Сезнең дини-фәлсәфи карашларыгыз белән килешмәгән, әмма бөек художник булуыгызны таныган хәлдә...»

Кинәт, шул мәлдә, мужик сакалы астыннан, демократик, таушалган кафтан эченнән чын рус барины, менә дигән аристократ калкып чыга, – бу мәлдә беркатлылар, укымышлылар һәм башка бүтәннәрнең түзеп булмаслык салкын бәрүдән борыннары зәңгәрләнә. Аксөяк нәселле бу затның янәшәсендә була алу күңелгә хуш килә, аның күркәмлеген, кул хәрәкәтләренең нәфислеген, вәкарь белән тотнаклы сөйләшүен күрү, үтергеч сүзләрне ыспай гына атып тидерүен ишетә алу – үзе бер хозур иде. Холоплар өчен күпме кирәк булса, баринлык аңарда шулкадәр иде. Әгәр алар Толстойда баринлыкны кузгаталар икән, ул үз иркендә җиңел генә хасил була да шундый итеп сыта башлый, тегеләргә, куырылып килеп, чыелдарга гына кала.

Ясная Полянадан бервакыт мәскәүле – беркатлы рус белән бергә кайтырга туры килде, ул бик озак аңга килә алмыйча азапланды, кызганыч елмаеп, каушавын тыя алмыйча:

– Ну и ну – мунча кертте. Коры тота... Фу!

Үкенгән тавыш белән ярып салды:

– Мин аны чынлап та анархист дип уйлаган идем. Бөтенесе туглый – анархист та, анархист, ышандым инде...

Бу кеше зур корсаклы, чи ит төсендәге чырайлы бай фабрикант иде – Толстойның анархист булуы аңа нигә кирәк икән? Рус күңеленең тагын бер «тирән сере»...

Әгәр ошарга тели икән, Лев Николаевич моны чибәр, акыллы хатын-кыздан өлгеррәк булдыра ала. Менә аның тирәсендә төрле катлау кешеләре утыра: олуг кенәз Николай Михайлович, маляр Илья, Ялтадан килгән социал-демократ, штундист Пацук, ниндидер музыкант, немец, графиня Клейнмихельнең эш башкаручысы, шагыйрь Булгаков – болар бар да аңа бертөсле яратып карыйлар. Ул Лао-цзы фәнен аңлатып утыра, миңа калса, ул гадәттән тыш кеше – оркестр, кайсыдыр ки төрле коралларда – җиз торбада, барабанда, гармунда, флейтада берочтан уйный белә.

Мин дә аңа башкалар кебек үк карадым. Тагын бер тапкыр гына, дисәм... бүтән беркайчан да күрә алмаячакмын инде.

* * *

Журналистлар җыелды, «Толстойның үлемен инкарь итеп», Римга телеграмма сукканнар, имеш. Ыгы-зыгы килделәр, Россиягә теләктәшлек белдереп, сүз боткасы ясадылар. Рус газеталары икеләнергә юл калдырмаган шул.

* * *

Каты авырып яткан чагында да аны жәлләп, ялганга бару мөмкин түгел иде. Андый кешене кызгану – мәнсезлек. Андыйларны сакларга, иркәләргә кирәк, таушалган, җансыз сүзләр тузанына коендырасы түгел.

Сорап куя иде:

– Сезгә ошамыймдыр мин?

Әйтергә иде дә: «Әйе, ошамыйсыз», – дип.

– Яратмыйсызмы мине?

– «Әйе, бүген мин сезне яратмыйм».

Сорау куюы аяусыз иде, ә җавап биргәндә – акыл иясенә хас булганча, тотнаклы үзе.

* * *

Тургеневның үткәне турында шулкадәр матур сөйләде. Яратып көлеп, мәзәкләр китереп, Фетны искә алды. Некрасов хакындагы сүзләре салкын, мыскыллы иде. Бөтен язучыларны да ул, гүя, үз балалары итеп тоя, ул – ата кеше, бөтен җитешсезлекләрен күреп тора, мәгез, ди – начар якларын яхшы якларыннан алгарак куеп тасвирлый. Кемнеңдер яман ягын искә алып сөйли башласа, аны тыңлавы уңайсыз иде, зәһәр елмаюыннан күзләребез түбән төшә, берни дә хәтергә эләгеп калмый.

«Г.И.Успенский тула телендә язды, аның бернинди дә сәләте юк!» – дип, ул бервакыт, кызып, үзенекен исбатларга тырышты. Күп тә үтми Успенский хакында (мин дә шунда бит) А.П.Чеховка болай диде:

– Менә язучы ичмасам! Ихласлыгы белән ул Достоевскийны хәтерләтә, тик Достоевский сәясәткә бирелә, ә бу – гади, эчкерсез. Әгәр ул Аллаһка ышанучы булса, аны кайсы да булса бер сектант эзләп табар иде.

– Сез бит Тулага кирәк язучы гына, сәләте юк, дигән идегез?

Йөнтәс кашлары астына күзләрен яшерде дә:

– Ул начар язды. Нинди тел инде ул? Сүзләргә караганда тыныш билгеләре күбрәк. Талант ул – ярату. Кем ярата белә, шул талантлы. Гашыйкларга карагыз сез – һәммәсе талантлы!

Достоевский турында ул теләр-теләмәс кенә, читләтеп-уратып, үз-үзен көчләп әйтә.

– Аңа Конфуций яисә буддачылар тәгълиматын өйрәнергә иде, тынычланып калган булыр иде. Бу – һәммәбез дә белергә тиешле төп нәрсә. Ул табигате белән дуамал иде. Ачуы килгәндә, маңгае күбеп чыга, җитмәсә, колаклары селкенә. Күпне тоя, ә уйлары хөрти, кемнәр әле, фурьеристлардан, Буташевич, тагын шуның ишеләрдән фикерләргә өйрәнде. Аннары гомере буена аларны сөймәде. Канында аның нindидер яһүдилек бар иде. Шикчел, үз-үзен яратучан, авыр холыклы, бәхетсез кеше. Шунысы сәер: аны күп укыйлар, нишләп алай – һич аңлый алмыйм! Авыр бит укырга һәм файдага түгел, аның ул Идиоты, Үсмерләре, Раскольниковлары – бөтенесе дә тормышта булалмый, гамәлдә бар да гади бит югыйсә, аңлашылып тора. Ә менә Лесковны зерә укымыйлар, чын әдип, сез укыдыгызмы аны?

– Әйе. Бик яратып. Бигрәк тә – теле шәп.

– Телне ул сүз белән фокуслар ясый алырлык дәрәҗәдә гаҗәеп белә. Сәер, нигә дип аны яратасыз, сез ничектер башка... рус түгел, сезнең уй сөрешегездә дә руслык сизелми – ярый инде, болай әйтеп сезне рәнҗетмәдемме? Мин – карт кеше, хәзерге көн әдәбиятын аңлап та бетермим, әмма шуны тоям: русныкы түгел. Әллә нинди мәзәк шигырьләр язалар хәзер – кемгә арналган, кемгә хаҗәт. Шигырьгә Пушкин, Тютчев, Шеншиннан өйрәнергә кирәк! Менә – сез, – дип, ул Чеховка мөрәҗәгатъ итте, – сез – чын рус! Әйе, бөтен вөҗүдегез белән рус.

Ягымлы елмаеп, иңеннән кочып алган иде, Антон Павлович, кыенсынудан каушап, калын тавыш белән үзенең дачасы, татарлар турында сөйләнә башлады.

Чеховны ул һәрчак яратты. Бер чакны Антон Павлович Александра Львовна белән парк юлыннан бара, Толстой ул вакытта савыгып җитмәгән иде әле, террасада кәнәфигә чумып утырган җиреннән тегеләр артыннан сузыла төшеп карады да салмак тавыш белән:

– Әх, нинди ягымлы, искиткеч кеше: тыйнак үзе, сабыр, барышнялар кебек! Атлап йөреше дә шундый. Гаҗәеп кеше.

Кичкырын, эңгер-меңгердә кашларын хәрәкәтләндереп, күзләрен кысыбрак «Сергий атакай» дигән әсәреннән бер күренешнең вариантын укыды. Анда – хатын-кызның бер дәрвиш янына күңеленаздырырга ниятләп баруы хакында сурәтләнгән иде. Азагынача укып чыкты да, башын артка ташлап, күзләрен йомды һәм ап-ачык итеп:

– Шәп язган бит, картлач, шәп! – диде.

Шулкадәрле дә гаҗәеп-табигый килеп чыкты бу, матурлыктан соклануы шундый эчкерсез иде – мин моны күреп таң калуымны мәңге онытмам, сүзләр белән сурәтли дә алмам, бу хисне тояр өчен алагаем көч кирәк иде. Хәтта йөрәгем туктап куйды, аннары инде бөтен тирә-юньне яңартып, тере сафлык сирпелде.

Бер караганда, аның сөйләме дөрес кысаларга буйсынмый да кебек, бер

үк сүзләрне кайта-кайта кабатлавы, авыл гадилегеннән чумырып алган бай әйләнмәләре белән үзенчәлекле тел куәсен, аңлатып булмый торган матур агышын бәһаләр өчен, аның сөйләп торуын үзеңә тыңларга-күрергә кирәк. Сүзләренең куәте көйле тавышында гына да, йөз сызыкларының хәрәкәтләнеп торуында гына да түгел, ә күзләренең чаткыланып уйнавында – мондый да оста теллелекне мин кайчан да булса күргәнмендер дип уйламыйм. Толстойның пар күзеннән мең күз карый иде.

Сулер, Чехов, Сергей Львович, тагын кемдер паркта хатын-кызлар хакында гәпләшеп утырабыз. Толстой бер сүз әйтмичә озак кына утырды да кинәт әйтеп салды:

– Бер аягым белән кабер якасына баскач кына, мин хатын-кыз хакында бөтен дөреслекне әйтәчәкмен. Әйтәм дә... табутка сикерәм, капкачын ябам да – аннары тотып карагыз мине! – Күз карашы шундый мут-шөбһәле булып кабынды ки, һәммәбез дә бер мәлгә тынып калдык.

Минем уемча, аңарда – Васька Буслаевның кыю, сынаучан шуклыгы, үҗәт-үзсүзле протопоп Аввакум җанының бер өлеше чагыла, ә каядыр – өстәме, кырыйдамы чаадаевча скептиклык посып тора.

Менә ул – бөтенесенә чит-ят, гаммави бер дөреслекне табарга адарынып, уйлар чүлен аркылыга-буйга гизеп чыккан, әмма үзе өчен таба алмаган карт тылсымчы булып күз алдымда тора. Карыйм да мин аңа – югалту кайгысы шулкадәр зур булса да, күрдем бит мин аны, күрдем, дигән бер горурлык хисе әрнүле кайгыны юатып тора.

«Толстойчылар» арасында Л.Н.ны күрү сәер иде: мәһабәт манара калкып тора, гөмбәз астыннан бөтен дөньяга туктаусыз чаң кагалар, ә тирә-юньдә сагаеп кына әнчек этләр йөгерешә, чаң авазына кушылып улашалар, кайсыбыз шәбрәк улады, дип бер-берсен күзәтәләр. Миңа калса, бу бәндәләр графиня Панинаның биниһая зур йортына, затлы сараена да икейөзлелек, куркаклык, вак сәүдәгәрлек кәсафаты сеңдереп, мирас бүлешүне көтәләр. «Толстойчы»ларда Россиянең караңгы почмакларына кадәр үтеп керә торган мөсафирлар, дәрвишләр белән уртаклык бар, алар бит үзләре белән эт сөяге йөртеп, шуны борынгы изгеләр сөяге дип тәкъдир итәләр; «мисыр караңгылыгы»н, Гайсә анасының «күз яше»н сатып йөриләр. Хәтерлим әле, шундый апостолларның берсе Ясная Полянада чакта, тавыкларны үпкәләтмим дип, йомырка ашамады, ә кайтканда Тула станциясендә итне, умырып, тыгынып куйды:

– Картлач арттыра!

Алар барсы да зарланырга, үбешергә ярата, һәммәсенең дә кулы тирләгән, күз карашы ялган булыр. Гамәлдә исә җирдәге тормышка кирәк-ярагын үз файдаларына бик шома хәл итәләр.

Лев Николаевич, әлбәттә, «толстойчылар»ның кем булуын, асыл бәһасен аңлый, ул хисләнеп яраткан, һәрчак яшьләрчә кайнарланып мактаган Сулержицкий да моны белә иде. Ясная Полянада кемдер Толстой вәгазьләрен кабул иткәч, тормышым шундый матурланды, җаным чистарды дип, сулышына кабып сөйләде. Шул мәлдә Лев Николаевич, миңа таба елышып:

– Алдый бит, шельма, минем күңелне күрәм дип алдаша инде ул.

Күпләр, чынлап та, аның күңелен күрергә тырыша иде, әмма моны табигый, акыллы итеп башкаручыларны мин хәтерләмим. Ул үзе яраткан темалардан: бөтен нәрсәне гафу итү, янәшәңдәгене ярату, Инҗил һәм Будда диннәре хакында минем белән сүз кузгатмый иде. «Бу атка ризык түгеллеген» бик тиз аңлады күрәсең. Монысы миңа ихластан ошады.

Теләгән чагында ул үзенә аерым бер төрле күркәм, түбәнчелекле була, сизгер, мөгамәләсе йомшак, сүз сөреше, һичшиксез, гади, нәфис булыр, ә кайчакларда аны тыңлавы шулкадәр авыр, күңелне изә. Миңа аның хатын-кызлар хакындагы акыл сатулары ошамый иде, артык «гади, халыкчан» булып китә, сүзләрендә ясалмалык сизелә, фәкать үз шәхесенә караганда да ачылып бетми, нидер яшереп калдыра. Гүя, аны кайчан да булса бер мыскыл иткәннәр, шуны ул һич тә оныта да, гафу итә дә алмый. Хамовникидагы өендә беренче танышкан кичтә, ул мине кабинетына алып кереп, каршына утыртты да минем «Варенька Олесева», «Егерме алты һәм берәү» дигән әсәрләрем турында сөйли башлады. Мин аның тоныннан чүгеп калдым, каушадым – шулкадәр шәрәләндереп, әче итеп сөйли, әйбәт кызга оялчанлык хас түгел, дип исбатларга тырыша.

– Унбише тулган сәламәт кызыкай үзен кочуларын, капшауларын тели. Аңы-акылы белән әлегә аңлашылмаган, әлегә татымаган билгесезлектән курка билгеле – менә шуны гыйффәтлелек, оялчанлык дип атыйлар. Ә тәне сизә, акылга каршы килеп, билгесезлек чиген бәреп чыгарга хокук даулый. Ә сезнең ул Варенька Олесева сәламәт кыз итеп сурәтләнгән югыйсә, ә тойгылары – арык, бу дөрес түгел!

Аннары ул «Егерме алты һәм берәү»дәге кызга күчте. Бер-бер артлы «әшәке» сүзләрне иркен куллануы миңа әдәпсезлек булып тоелды, бераз үпкәләтте дә шикелле. Соңыннан аңладым мин, «тибелгән» сүзләрне ул төп-төгәл, үткен мәгънә бирү өчен файдаланган икән, ул чакта аны тыңлау бер дә күңелгә хуш килмәгән иде. Мин аңа каршы чыкмадым: капылт кына ул йомшарды, ягымлыланып, минем тормыш-көнкүрешем, укуым, нинди китаплар яратуым турында сораша башлады.

– Сезне бик укымышлы дип әйтәләр – дөресме шул? Нәрсә, Короленко музыкант тамыни?

– Юк шикелле. Белмим.

– Белмисез? Сезгә аның хикәяләре ошыймы?

– Бик тә.

– Контрастлыктан бу. Ул – лирик, ә сездә ул юк. Вельтманны укыганыгыз бармы?

– Әйе.

– Яхшы язучы, дөрес бит, өлгер, төгәл, купайтмый. Кай урыннарында Гогольдан көчлерәк. Ул Бальзакны яхшы белә. Гоголь исә Марлинскийга ияргән.

– Гоголь, бәлки, Гофман, Стерн йогынтысына бирелгәндер, Диккенсны да читкә тибәрмәгән, – дигән идем, күзгә туры карап, сорау бирде:

– Сез бу хакта каян да булса укыдыгызмы? Юк? Хаклы түгелсез, Гогольнең Диккенсны белүенә шикләнәм. Ә сез чынлап та күп укыдыгызмы? Карагыз аны, зыянга бу! Кольцов шуның белән үзен үтерде.

Саубуллашканда ул, кочып, биттән үбеп, болай диде:

– Сез – чын мужик! Язучылар арасында кыен булыр сезгә, әмма өркеп калмагыз, ничек тоясыз – шулай сөйләгез, тупас чыкса да – бара ул! Акыллылар аңлар.

Бу тәүге күрешү миндә каршылыклы уйлар тудырды. Толстойны күрүемә шат, горур идем, әмма аның әңгәмәсе ниндидер имтихан кебек тоелды, гүя, мин – «Казаклар», «Холстомер», «Сугыш...»ны язган әдипне түгел, ә минем эргәмә төшеп, ниндидер «халык стилендә», урам, мәйдан телендә сөйләшүне

кирәк санаган баринны күрдем. Күз алдыма китереп, күпмеләр яшәткән кадерле сурәт бүген йөзтүбән аугандай булды.

Икенче тапкыр Ясная Полянада күрештек. Көзге төмсә көн иде. Вак яңгыр сибәли, ул, авыр драп пәлтә, биек кунычлы, калын табанлы күн итекләр киеп, каен урманына истирәхәт кылырга алып китте. Күлләвекләр аша яшьләрчә җитезлек белән сикереп чыга, ботакларны сыгып, тамчылар тәлгәшен башына коя һәм шагыйрь Шеншинның шушы чаукалыкта Шопенгауэрны үзенә аңлатуын мавыктыргыч итеп сөйли – каеннарның дымлы, атлас кәүсәсен, кулларын йомшак кына тигезеп, сыйпап ала.

– Күптән түгел генә кайдадыр шигырь юллары укыдым:

Гөмбәләр бетте, чокырларда
Исе калды гөмбә дымының.

Бик шәп, бик дөрес!

Кинәт, әллә каян гына сикереп чыгып, аяк астына куян атылды, Лев Николаевич тайпылып калды, бөтен гәүдәсе җыелып килде, ә йөзендә алсу төс кабынды, күпне күргән җәнлек аулаучы сыман «һайт!» дип кычкырып җибәрде. Аннары, миңа карап, рәхәт бер елмайды, акыллы, кешечә, гади итеп көлеп куйды.

Икенче вакыт шул ук паркта ул, бик бирелеп, күктәге тилгәнне күзәтә башлады. Тилгән мал утары өстендә тирбәлә, бер әйләнеш ясый да тагын тулгана, канатларын сизелер-сизелмәс кенә тирбәтә, тәвәккәлләргә икеләнә: томырылыргамы аска, корбанына, әллә иртәрәкме? Лев Николаевич бөтен гәүдәсенә тартылды, учын күз өстенә куеп, дулкынланып пышылдады:

– Безнең тавыкларга турылый, явыз. Менә хәзер, менә... менә... их, курка шул! Анда кучер йөри ахрысы, кучерны чакырырга кирәк.

Чакырды бит. Ул кычкыруга, тилгән, сискәнеп, өскә атылды да, кырыйга тайпылып, юкка чыкты. Лев Николаевич, тирән сулыш алып, үз-үзен шелтәләгәндәй:

– Кычкырасы калмаган, болай да качасы иде, – диде.

Бервакыт аңа, Тифлис турында сөйләгән уңайдан, Берви Флеровский хакында искә төшереп алдым.

– Аны белә идегезмени? – дип, Лев Николаевич кызыксынып сорады. – Сөйләгез әле, нindirәк кеше?

Мин Флеровскийны «озын гәүдәле, мул сакаллы, ябык, зур күзле...» дип сөйләп киттем. Озын итәкле хитон киеп, кызыл шәрабта пешкән дөге төенчеген билбавына кыстырып, бинһая зур, киндер зонтик белән коралланып, ул минем белән Кавказ артында тау сукмаклары буйлап сәяхәткә чыкты. Бервакыт тар сукмакта буйвол белән кара-каршы очрашкач, чигенергә дигән карарга килдек. Гаярь җәнлеккә ачык зонтик белән кизәнә-кизәнә, артка чигенә торгач, чак кына упкынга убылмый калдык... Кинәт, искәрәм, Толстойның күз төпләре яшьләнеп чыкты, мин, аптырап, сүземнән туктап калдым.

– Болай гына, сөйләгез, сөйләгез! Яхшы кеше турында тыңлау куанычыннан бу. Нинди кызык кеше, ә! Мин аны шулай үзенә бертөрле итеп күзаллый идем. Радикаль язучылар арасында ул – иң өлгергәне, иң акыллысы. Аның «Азбука»сында безнең цивилизациянең вәхшилеккә корылганы, ә культураның күндәм кабиләләр эше, ягъни, көчсезләр эше икәне, яшәү өчен көрәш дигән нәрсә – явызлык кылуны аклар өчен ялган уйдырма икәне әтрафлы исбатлап

бирелә. Сез, әлбәттә, моның белән килешмисез? Ә менә Доде – килешә, хәтерлисездер, аның Поль Астьесы нинди бит?

– Европа тарихындагы норманнар ролен Флеровский теориясе белән ничек килештерергә?

– Норманнар ул – бүтән!

Әгәр ул җавап эзлисе килмәсә, һәрчак «ул – бүтән» дип нокта куя иде.

Миңа шулай тоела (ялгышмыйм дип уйлыйм): Лев Николаевич әдәбият турында гәп куертырга бик яратмый, әмма әдәбиятчыларның шәхесе хакында аеруча теләп кызыксына. «Аны беләсезме? Нindirәк ул? Кайда туган?» – кебек сорауларын миңа бик еш ишетергә туры килде. Һәрчакта диярлек аның фикри хөкеме кешене үзгә бер яктан ача иде.

В.Г.Короленко хакында уйланып ул:

– Великоросс түгел, шуңа күрә безнең яшәү рәвешен үзебезгә караганда гаделрәк, тирәнрәк күрергә тиеш, – диде.

Үзенең яратканы, сөеклесе – Чехов турында:

– Аңа медицина комачаулый, табиб булмаса, тагы да шәбрәк язар иде, – ди.

Яшь каләм тибрәтүче кемдер турында:

– Инглиз булып кылана, мәскәүленең кулыннан килә димени?

Бервакыт миңа әйтә:

– Сез – уйдырма язасыз. Сезнең ул Кувалдаларыгыз – уйлап чыгарылган.

– Кувалда тормышта бар, исән кеше.

– Кайда күрдегез аны, сөйләгез әле.

Казанның җәмәгать судьясы Колонтаевның камерасында булган күренеш аңа хәтәр кызык тоелды, менә шунда инде мин, Кувалда исемен биреп, әсәремә керткән адәмне күрдем.

– Аксөяк! – диде ул, күз яшьләрен сөртә-сөртә көлеп. – Әйе, әйе, аксөяк! Ә нинди сөйкемле, кызык кеше! Сезнең язганыгызга караганда, сөйләвегез әйбәтрәк. Юк, сез – романтик, уйлап чыгарып язасыз, инкарь итмәгез.

«Бөтен язучылар да, үзе күрергә теләгәнчә, тормыш хәлләрен баетып сурәтләргә тырыша. Мин актив кешеләрне яратам, андыйлар тормыштагы явызлыкка каршы төрле алым, хәтта көч тә кулланырга сәләтле була», – дигәнемә каршы Лев Николаевич кабынып китте:

– Көч куллану – иң зур яманлык! – дип, кулымнан тотты. – Ничек кенә чыгарсыз икән сез бу каршылыклы чытырманлыктан, ә, уйдырмачы? Сезгә, әнә, «Минем юлдаш» – анда уйдырма юк, шунысы әйбәт, уйлап чыгарып язылмаган. Үзегездән чыгарып язганда инде – рыцарьлар туа, Амадис, Зигфрид кебекләр...

Кешесыманнар, котылгысыз «юлдашлар» белән тыгыз даирәдә яшәргә мәҗбүрбез икән, димәк, бөтенесе дә тотрыксыз җирлектә, дошмани хәяттә төзеләчәк. Бу фикеремнән соң ул, елмаеп, терсәге белән йомшак кына этеп, болай диде:

– Моннан бик тә хәтәр, куркыныч нәтиҗә чыгарып була. Сез – икеләнүче социалист. Сез – романтик, ә романтиклар монархист булырга тиеш, алар гомергә шундый булды да.

– Ә Гюго?

– Ул – башка... Яратмыйм шул лыгырдыкны.

Еш кына ул минем нәрсәләр укуымны сораша, һәрчак мине, үз зәвыгыннан чыгып, китап сайлый белмәүдә шелтәли.

– Гиббон – Костомаровтан кайтышрак, Момсенны укырга кирәк, туйдыра, ләкин саллы яза.

Иң беренче укыган китабым «Бертуган Земганнолар» икәнен белгәч, ачуы килде:

– Менә бит – ахмак роман. Сезне шул бозган да. Французларда өч язучы бар: Стендаль, Бальзак, Флобер, тагын Мопассанны әйтергә була. Безнең Чехов аннан өстенрәк. Ә Гонкурлар – үзләре үк клоуннар, җитди булып кыланалар гына. Тормышны китаплардан өйрәнеп алганнар да – ә ул китапларны алар кебек үк уйдырма осталары язган бит – җитди эш башкарырбыз дип уйлыйлар, ә моның кемгә хаҗәте бар.

Мин әлеге бәя беләң килешмәдем, бу аңа ошамады, Лев Николаевич каршылыклы фикерләрне авыр кичерә, кайчакта аның уй йөртүе сәер бер каприз булып тоела иде миңа.

– Токымның бозылуы – юк нәрсә, – диде ул. – Моны италияле Ломброзо уйлап чыгарган, яһүд Нордау, аңа ияреп, попугай кебек кабатлый. Италия – шарлатаннар, авантюристлар иле. Андый илдә генә Аретино, Казанова, Калиостро кебекләр туа ала.

– Ә Гарибальди?

– Ул – сәясәт, ул – башка!..

Россиядәге сәүдәгәр гаиләләре тарихыннан китерелгән төрле мисалларга карата ул:

– Бу дөрес түгел, моны акыл сата торган китапларда гына язалар, – диде.

Мин аңа үзем күреп белгән өч буын сәүдәгәрләрнең тарихын сөйләдем, бу тарихта – үзгәрә барган нәсел-токым канунының котылгысыз гамәлгә ашуы ачыла иде; тыңлап бетергәч, ул, дулкынланып, җиңемнән тартты:

– Менә монда – дөреслек бар! Тулада шундый ике гаиләне үзем дә күреп беләм. Бу турыда язарга кирәк! Кыска итеп зур роман язарга, аңлыйсызмы? Кичектермичә!

Күзләре әсәренеп җемелдәде.

– Рыцарь булып күренәчәкләр бит, Лев Николаевич.

– Ташлагыз! Бу бик җитди. Кара син, теге... монахлыкка китеп, бөтен гаиләсе өчен догага бирелгәне – гаҗәп бит! Бу – чынбарлык: сез гөнаһланыгыз, ә мин сезнең гөнаһларны ярлыкарга барам... Икенчесе тагын – гел күңелсезлектә, мал туплаучы – төзүче – бу да чынбарлык. Эчеп алдымы – ерткычка, азгынга әверелә, ә үзе – бөтенесен ярата, үзе – көтмәгәндә җан кыя... әх, бу бит шәп! Менә моны язарга иде, караклар, сәләмәләр арасыннан герой эзләргә кирәкми! Геройлар – ялган, уйлап табылган; бар гади кешеләр, кешеләр – бары шул гына.

Еш кына ул минем хикәяләрдәге артык купайтылган урыннарны күрсәтә иде. Бервакыт, «Үле җаннар»ның икенче кисәген искә төшереп, кәефле елмайды да:

– Без барыбыз да – коточкыч уйдырма язучылар. Мин дә шулай, сурәтләгән кешең капылт кына кызганыч булып китә дә, аңа уңай сыйфатлар өстәп куясың, ә икенчесеннән – киметәсең, янәшәсендәгеләргә корымы йокмасын өчен, – диде.

Шунда ук, баш бирмәс хаким сыман, кырыс тонга күчте:

– Шуңа күрә әйтәм дә: сәнгать ул – ялган, чама белмичә алдашу, ә бу – кешеләр өчен зарарлы. Чынбарлыктагы тормышны язмыйсың, ә тормышны үзең уйлаганча язасың бит. Кызыкмы, кирәкме ул: әнә теге манараны, диңгезне, әнә теге татарны нинди итеп күрүем кемгә файда бирә?

Көйсезләнү галәмәтеме, кайчакларда аның уй-фикерләре юри почмак-

ландырылган кебек тоела, еш кына нәкъ менә шул аяусыз туры бәреп әйтүе белән әңгәмәдәшен шаккатыра, йөзтүбән аудара иде ул.

Үзе сөйләгән хикәяте хәтердә:

– Май азагы иде, Киев юлыннан барам шулай. Җир кинәнә, оҗмах инде: күк аяз, кошлар сайрый, бал кортлары безелдәшә, кояш йомшак нурларын коя, тирә-юнем – бәйрәмчә, кешечә, искиткеч хозурлык. Елыйсы килгән бу рәхәтлектә мин үземне бал корты итеп хисләндем, дөньяның бөтен гүзәл чәчәкләре – минем карамакта, Аллаһны да җанга якын итеп тойдым. Кинәт күрәм: юл читендә, куаклар арасында ике мөсафир ята, берсе – ир-ат, икенчесе – хатын-кыз. Бер-берсен сыйпашкан булалар, икесе дә төссез, җыерчыклы, пычракка буялып беткәннәр, бөҗәкләр кебек укмашып, үзара мырлашып, нидер мыгырданалар, ә кояш – шәрә, зәңгәрләнгән аякларын, арык, коргаксыган гәүдәләрен рәхимсез яктырта. Шул мәлдә җаным кысылып куйды: йә Ходa, синме – матурлык тудыручы: ничек сиңа оят түгел? Бик авыр иде миңа ул мәлдә...

Менә бит ничек килеп чыга: моны диндарлар шайтан котыртуыннан, дигәннәр. Табигать, аяусыз һәм артык мыскыллап, кешене менә ничек рәнҗетә: көчен суырып ала, ә теләкне калдыра. Бусы – бөтен тереклек ияләренә дә хас, ә менә тән-бәдәнгә кагылышлы бу – коточкыч сыналу ояты – фәкать адәми затка гына бирелгән. Без ул газапны котылгысыз җәза итеп вөҗүдебездә йөртәбез – ә нинди гөнаһ өчен?..

Әлеге фикерләрне әйткәндә, күзләренең сәер ялтыравында сабый зары да, кырыс таләпчәнлек тә чагылып алды. Иреннәре калтырап, мыек төкләре тырпайды. Сүзен бетергәч, ул, кесәсеннән кулъяулык чыгарып, бернинди тир чыкмаган йөзен сөртте. Аннары, мужикларныкыча көчле кулының бармакларын кәкрәйтеп, сакалын тарап алды, тынычланып, сүзен янә кабатлады:

– Йә, нинди гөнаһ өчен?!

Беркөнне түбәнге юлдан Ай-Тодорга барырга дип чыктык. Үсмер егет шикелле җиңел атлый, сүз сөрешендә ниндидер тынычсызлану сизелә:

– Тән-бәдән рухның эте кебек күндәм булырга тиеш, кая юллый аны рух, шунда йөгерә, ә без ничек яшибез? Бәргәләнә, дуамаллана тән, ә рух мәхлукларча, кызганыч булып, аңа тагылып йөри.

Ул, йөрәк турын каты итеп ышкып, кашларын күтәрде, хәтерен барлап, сүзен дәвам итте:

– Көзен Мәскәүдә, Сухарев янәшәсендәге тын бер тыкрыкта мин исерек хатынны күрдем: канау кырыенда ята, ихата ягыннан юл ясап чыккан шакшы су аның арт чүмечен, аркасын чылатып ага; ята шул салкын болганчыкта, нидер мыгырдана, күтәрелмәкче була да – тагын лач шул пычракка, калкына гына алмый.

Сүзеннән бүленеп, ул бөтен тәненә калтырап куйды, күзләрен кысып, башын селкеп торды да тын гына:

– Утырыйк әле шушында... Иң әшәкесе, иң җирәнгече – исерек хатын-кыз. Шул чакта аңа ярдәм кулын сузасым килә – чирканам; бөтен гәүдәсенә сыек,ябышкак лайла сыланган, кагылдыңмы – ай буена да кулыңны юып бетерә алмассың – коточкыч! Янәшәдәге эскәмиядә салам чәчле, соры күзле малай утыра, яңаклары буйлап күз яше ага, борынын тарта-тарта, өметсез-арган тавыш белән кабатлый:

– Ә-ни-и-и... әни-кәе-е-м-м. Тор инде, әни-и-и.

Әнисе кулларына таянмакчы, үзалдына мырылдап куя, башын күтәрмәкче була да, арты белән тагын, шап итеп, лайлага төшә.

Лев Николаевич, сүздән калып, бераз тын гына утырды, як-ягына карап алды, тынычсызланып, пышылдап диярлек кабатлады:

– Әйе, әйе – имәнгеч! Сез исерек хатын-кызларны күп күрдегезме? Күпмени – их, йә Хода! Сез бу хакта яза күрмәгез, кирәкми!

– Нигә?

Күземә туп-туры текәлеп елмайды да, кабатлап:

– Нигәме? – диде. Аннары уй-гаме аша сүзләрне әкрен генә тартып чыгарды:

– Белмим. Болай гына әйтүем... Шакшылык турында язарга оят бит. Ә нигә язмаска соң әле? Юк, барысын да язарга кирәк, барысы турында да...

Күзләреннән бәреп чыккан яшьләрен сәер елмаеп сөртте дә кулъяулыгына карады, ә яшьләре битендәге җыерчыклар арасыннан ага да ага.

– Җылыйм, – диде ул. – Мин – карт инде, нинди дә булса гадәттән тыш хәлне искә төшерсәм, йөрәктә дулкын куба, – дип, терсәге белән йомшак кына төртеп куйды. – Менә сез дә, кайчан да булса, гомер соңына килеп җитәрсез, бөтенесе дә ничек булган, шулай торып каласын белгәч, сез дә җылап алырсыз, миннән дә арттырыбрак, хатын-кызлар әйтмешли, «чишмәлерәк» итеп... Ә язарга кирәк, барысы турында да, югыйсә теге... салам чәчле малай үпкәләр бит: дөрес түгел, бөтенесе дә әйтелмәгән, дип, өнәмәвен белдерер. Дөреслек ягына ул таләпчән!

Шулай дип ул кагынып алды да, шәфкатьле тавыш белән:

– Әйдә, сөйләгез әле ни дә булса, сез мавыктыргыч сөйли беләсез бит. Малайчак турында, үзегез турында. Сезнең кайчандыр малай булуыгызга һич ышанасы килми. Нindидер сәерлек бар сездә. Әйтерсең лә балигъ булып тугансыз. Ә фикер сөрешегездән күпвакыт самимилек, сабыйлык бәреп чыга югыйсә, тормышны хәйран беләсез; тагын да күбрәге кирәкми. Әйдә, сөйлә әле...

Җайлап кына нарат төбенә чүмәште, шәрәләнеп калган агач тамырларын, коелган дымык ылыс бөртекләрен сыйпап, шулар арасында кайнашкан кырмыскаларны күзәтә башлады.

Төньяк кешесе, гадәттә, көньякның купшы табигатенә, масаеп үскән һәртөрле агачларына, тетрәп торган җиләк-җимешләренә, үсемлек-гөлләрнең мактанчык көязлегенә ияләнеп бетә алмый, Лев Толстой исә (исеме үк эчке кодрәтен тантана итеп тора) – җир тирәнлегеннән чыккан, бирчәйгән нык тамырлар белән чолганып төенләнгән бәләкәй кеше – әйткәнемчә, мактанулы Кырым табигатенә урынлы да, урынлы түгел дә кебек иде. Бик кадими кеше, гүя бөтен өязнең хуҗасы – хуҗа һәм бар итүче – йөз ел каядыр китеп торганнан соң, менә кайтып төшкән дә кайчандыр үзе бар иткән биләмәләрен тамаша кылып утыра, күп нәрсә онытылган инде, күп нәрсә аның өчен яңа, бөтенесе дә ничек кирәк – шулай яки шулай ук та түгел, асылына төшенергә кирәк: нәрсә шулай түгел, ни өчен...

Юллар, сукмаклар буйлап ул, бу җирнең иҗтиһатлы белгече кебек нык басып, ашкынып атлый, аның күз уңыннан бер генә таш та, бер генә фикер дә яшеренеп кала алмый; күзәтә, үлчи, капшый, чагыштыра. Һәм ул ярсулы уйларыннан яралган тере бөртекләрне үз хәятына сибеп бара.

Сулерга әйтә бервакыт:

– Син, Лёвушка, берни укымыйсың, әйбәт түгел. Үз-үзеңә чамадан тыш ышанасың. Әнә Горький бик күп укый – бу да әйбәт түгел, монысы инде үз-үзеңә ышанмаудан. Менә мин күп язам – бу да әйбәт түгел, монысы – картлыкның үз-үзен яратуыннан, бөтенесе дә минемчә уйларга тиеш дигәннән

килә. Әлбәттә, мин, үземә калса, матур уйлыйм, ә Горькийга алай ук тоелмый, ә син берни дә уйламыйсың, авыз ачып торасың, нәрсәгә әләгергә дип күзәткән буласың. Аннары бөтенләй кирәксезгә барып ябышасың – ничә тапкыр шулай булды инде. Ябышып торасың да, үзеннән-үзе куба башласа, тотынып калырга теләмисең. Чеховның «Душечка» дигән гаҗәеп хикәясе бар. Син андагы хатын-кызга охшагансың.

– Кай ягым белән? – дип көлде Сулер.

– Яратуын яратасың, ә сайлана белмисең, аннары юкка каласың.

– Гел шулаймы?

– Гел? – дип кабатлады Лев Николаевич. – Юк, гел түгел.

Көтмәгәндә миңа, таш аткан кебек, сорау бирде:

– Сез нишләп Аллаһка ышанмыйсыз?

– Ышаныч юк, Лев Николаевич.

– Алдашасыз. Сез – табигатегез белән ышанучан кеше, Аллаһсыз ярамый сезгә. Озак та үтми моны тоячаксыз. Дингә ышанмавыгыз үҗәтлектән, кинә саклаудан: имеш, дөнья сез теләгәнчә яратылмаган. Дин тотмавыгыз оялчанлыктан да килә, яшь-җилкенчәккә хас бу: хатын-кызга илаһи итеп карыйлар, ә шуны танырга теләмиләр, аңламас дип куркалар, дөресе – кыюлыклары җитми. Дингә бирелү, мәхәббәт кебек үк, батырлык, кыюлык сорый. Инанам, дип, үз-үзеңә тәкрарларга кирәк – барысы да әйбәт булыр, ихтыярыгыз теләгәне алга килер, үзеннән-үзе аңлашылыр һәм үз артыннан ияртер. Сез күпләрне яратасыз, ә инану ул – куәтле ярату, тагын да куәтлерәк яратырга кирәк, шул чакта ярату – инануга әверелә. Мәхәббәтең төшкән хатын-кыз – дөньяда иң күркәме булып тоела, һичшиксез, һәркем иң матурны яратам, дип уйлый, менә шул инде – инану була. Ышанудан хали кеше ярата алмый. Бүген – берәүгә, бер елдан – икенчегә гыйшкын белдерә. Мондыйларның күңеле – сукбай, яшәү рәвеше – кысыр, бу – әйбәт түгел. Сез – тумыштан динле кеше, юкка үзегезне сындырмагыз. Менә сез матурлык, дисез. Ә нәрсә соң ул матурлык? Иң бөеге, иң мөкәммәле – бердәнбер Аллаһ...

Элек ул беркайчан да диярлек мондый темага минем белән сүз бәйләми иде, бу мәлдә үзен эре-мөһим тотуы, көтелмәгәнлек мине сытты, әйләндереп каплады. Мин дәшмәдем. Ул, диванга аякларын бөкләп утырып, сакал куелыгыннан тантаналы елмаю сирпетеп, бармак янады:

– Моңардан дәшми калалмыйсыз! Юк!

Ходай барлыгына ышанмаган мин, нишләптер, аңа бик тә сагаеп, бераз куркынып карыйм да уйлыйм: «Бу кеше – илаһи!»

**Марсель ГАЛИЕВ** *тәрҗемәсе.*



*Алинә Хисамиева – 1986 елда Азнакай шәһәрендә туган. Азнакай татар-төрек гимназиясен, Әлмәт дәүләт нефть институтын, Казан дәүләт технология университетының аспирантурасын тәмамлый. Бүгенге көндә «Азнакайнефть» идарәсендә икътисадчы булып эшли. Шигырьләре «Балаларга бүләккә», «Яшь дулкын», «Илһам чишмәләре» китапларында; «Сабантуй», «Тормыш кыры», «Мәйдан», «Маяк» газета-журналларында, 2007 елда «Кызлар күңеле» китабында басылган. Институтта уку дәверендә С.Сөләйманова исемендәге әдәби стипендиягә лаек була.*

# КАЙТАВАЗ КАБАТЛЫЙ ҮТКӘННӘН

## Эзлим

Кышкы төннән күзләреңне эзлим.
Һич булмаса ялгыз эзеңне!
Синең сукмак. Таныйм. Парлы!
Үзгәрткәнсең ахры үзеңне!

Үзгәрмәсәң, тигез эзләр салып,
Бер сулышта үтмәс идең лә.
Һич булмаса, аунап елар урын
Миндәгечә! Калыр иде лә!

Йокы алмаган төне, ае, елы
Иярерләр иде артыңнан...
Мин генәме соң сөюләрне
Йөрәгендә мең кат яндырган?!

Юк, көнләшмим. Хәйран калам!
Борылып карамавың үткәнгә...
Зәңгәр кыңгыраулар чың-чың килде,
Мин сөюдән качып киткәндә.

Шуннан бирле зәңгәр кыңгыраудан
Гөлләмәләр җыймыйм үземә.
Сары такыялар үрәм хәзер –
Тәңгәл килә бигрәк йөземә.

Кышкы төннән күзләреңне эзлим.
Һич булмаса ялгыз эзеңне!
Табып эзләреңә әйтим мәллә
Соңга калган сөю сүземне.

## Әтисез

Күңелгә канатлар иңдереп
Югалдың!
Мин нәни.
Үкседем!
Җилләргә уралып, куркудан –
Ни оча – ни йөри белмәдем!

Әтисез! Караңгы бар галәм.
Кояшны балачак күрмәде.
Өй тулы шәмнәрем югыйсә,
Янмады, яктылык элмәде.

Сәерлек!
Йотлыгып, дөньяның
Битараф һавасын иснәвем!
Үкенеч!
Шатлыктан чын итеп,
Чыр итеп, көлә дә белмәвем!

Сәерлек!
Ышанып ир-затка,
Мәхәббәт утында көюем.
Рәнҗетеп кимсенгән күңелнең
Һаман да яшәүне сөюе.

Канундыр! Яз килеп эреткәч,
Ышыксыз пыяла чатнавы.
Чатнадым!
Ярылдым! Йөрәктә
Һаман да пыяла вaклары...

Күп еллар әтисез.
Ни гаҗәп!
Җаныма бер дәва тапмавым.
Бер сүздән мөлдерәп бүген дә
Ялгызым күпме кар таптадым.

## Яраклаштым

Яраклаштым инде табигатькә,
Карсыз кышка. Салкын җәенә.
Кешеләрнең чыбыркыдан усал,
Яралардай зәһәр теленә.

Яраклаштым инде дөньясына,
Төннәр буе йолдыз күзләмим.
Дус-туганнан терәк табыйм, диеп,
Кар астыннан гөлләр эзләмим...

Ияләштем инде җил-давылның
Көтмәгәндә ишек кагуына.
Язмыш камчы булып кыйнаганда,
Парлы килеш ялгыз калуыма...

Ияләштем инде. Яраклаштым.
Юктыр, дидем, башка чарасы.
Сулышымны гына кыса никтер
Әллә күлмәк, әллә дөньясы!

* * *

Мең тамчы яңгырны кабаттан
Җир йоткан, сусавы өткәннән.
«Мин синең сөюең булалмам!»
Кайтаваз кабатлый үткәннән.

Мин синең тормышка кызыкмыйм,
Үз дөньям! Үз һавам! Үз исле!
Һич юкка хисләрем түгелгән,
Яңгырга ияргән  кар төсле.

Мин көтмәм юлларың чатында
Адашкач, эзләмәс күзләрем.
Чакырмам чуалгач хисләрем,
Туктат, дип, дөньямның күчәрен!

Өшемәм ялгызым кышларда,
Иңнәрдән алмамын шәлемне.
Мин калам мәңгегә бу кышта –
Яңгырлы! Сөюле! Аһәңле!

## Ят килеш

Көн тумый, таң атмый һич бүген.
Тукталган вакыт та... Төн, имеш.
Тугайлар иңлибез... Төш икән,
Мин сиңа, син миңа ят килеш...

Ят, имеш... Күкләргә аш та син сөюдән!
Ай тикле ай кабыз чырасыз.
Кояшны учыңа сыйдыр да
Кал, имеш, бер йотым җылысыз!

Ят, имеш... Үзеңнең сулышны
Суларга ымсынып торганда...
Һаваны бүләк ит! Юк! Күкне!
Ул гел яшь! Мәхәббәт сулса да!

Төш икән! Януым, көюем
Син, диеп, өзелгән  мең төнем.
Үзәкнең һәр кылын кискәләп
Таң атты. Күземнең соң көне.

## Ерак киттем

Ерак киттем, ахры, үз-үземнән –
Ап-ак карда килә ауныйсым!
Күккә  куеп нәни учларымны,
Аклыгын карларның аулыйсым.

Ерак киттем, ахры, үз эшемнән –
Күзге җилләр талкый җанымны.
Шигъри тәлгәшләрне тезгән чакта,
«Сан дөньясы» били хушымны...

Ерак киттем, ахры, кешеләрдән –
Җылылыкка сусап таң калам!
Сөйләшәм дә төнге тынлык белән,
Йөрәгемә талгын моң салам.

Ерак киттем, ахры, үз-үземнән –
Кайтыр юлым эзләп йөрим менә...
Язмыш кына риза түгел бер дә,
Карлы яңгыр булып миннән көлә!


## Әни

Йөзләреңә яшьлек төсен ягып,
Яшәртәсем килә сине, әни!
Канатланып очыйк әле бергә,
Яшьлек тугайларың ятмыни!

Рәнҗүләрең тулы йөрәгеңне,
Төзәлсен, дип бәйлим, түз, әни!
Синең янда шундый җылы миңа –
Боз салкыны эри, күр, әни!

Галәмдә юк, бәгырьдәге җырны
Көйлик  әле бергә, суз, әни!
Күңел дәрьясыннан бәреп чыгар
Үксетердәй моңым әзмени?!

Челтәрләнеп беткән күңелеңә
Яңа пәрдә элдем, күр, әни!
Үзәгеңә үткән сызлануың,
Синең яраң миндә юкмыни?
Синең язмыш миңа ятмыни?!



Ринат
Мөхәммәдиев

# АЯЗУЧАН БОЛЫТЛЫ ҺАВА...

хикәя

Мәскәү шәһәрендә, Халыкара язучылар берлегендә, Сергей Михалковның урынбасары булып эшләп йөргән көннәрем. Эш урыныбыз – «Война и мир» романындагы Наташа Ростованың беренче балы узган тарихи бина. Аның аскы катында ресторан. Төшке ашны, рәис белән кара-каршы утырып, без шунда ашый торган идек.

– Ринат, сиңа бер үтенеч бар бит әле бүген, – дип мөрәҗәгать итте ул көннәрнең берендә.

– Тыңлыйм. Тыңламый хәлем юк, Сергей Владимирович...

– Бүген, сәгать дүрткә, Журналистлар йортына чакыру бар. Анда дөньяның төрле почмакларыннан җыелган рус теле һәм әдәбияты укытучылары белән очрашу була. Вәгъдә биргән идем, әмма бара алмыйм. Бармавымның сәбәбе бик җитди – бер чибәр кыз белән күрешү җае чыкты. Коткарсаң син генә коткарасың, – диде аксакал, уенын-чынын бергә кушып.

– Сәбәп чынлап та бик җитди икән шул, – дидем. – Әмма бу очракта, Сергей Владимирович, мин бит сезне алыштыра алмам. Аларга мин түгел, танылган шагыйрь Михалков кирәк. Өстәвенә тагы, рус теле белгечләре, дисез... Фамилиямне ишеткәч үк качып бетмәсләрме?!. Бәлки, миңа, сезнең урынбасар буларак, теге чибәр кыз янына барырга кирәктер?..

Шаяруны аңлый һәм шаярганны ярата да торган иде аксакал. Бу очракта да рәхәтләнеп көлеп алды.

– Хәйләкәр дә соң үзең. Син татар түгелдерсең бит? – дип куйды соң чиктә.

Берни эшләр хәл юк, ризалашырга туры килде. Беренче мәртәбә генә түгел ич, кайбер көннәрдә җидешәр-сигезәр урынга чакыру китерәләр иде аңа. Бу кичне дә җаваплы очрашулары барлыгын беләм. Тугызынчы дистәсенең икенче яртысын барларга керешкән шагыйрь, бик теләсә дә, кырыкка ярыла алмый бит инде.

Кушылган җиргә кичекмичә бардым. Мин киләсен хәбәр итеп куйганнар иде, ихтирам белән каршы алдылар, чәй эчерттеләр һәм президиумга утырттылар. Иҗат берлеге һәм язучылар исеменнән сәламләп чыгыш ясарга да туры килде. Дөньяның төрле почмакларыннан җыелган рус теле һәм әдәбияты

---

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ (1948) *– язучы һәм җәмәгать эшлеклесе; «Кенәри читлек кошы», «Сират күпере», «Утлы таба өстендә» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, Төркиянең әдәбият һәм мәдәният өлкәсендәге халыкара әдәби премиясе лауреаты. Россия Федерациясе һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Мәскәүдә яши.*

белгечләренең ихлас чыгышларын тыңлау чын-чынлап онытылмаслык тәэсир ясады үземә. Кайда гына укытмыйлар икән дә кайда гына өйрәнмиләр икән рус телен һәм әдәбиятын – Японмядә, Кытайда, Австралияда, Африка һәм Көньяк Америка илләрендә... Хәтта, күпме яшәп, күпме дөнья гизеп тә, исемнәре шул көнгәчә колакка чалынмаган утраулардан килгән вәкилләр чыгыш ясады. Һәрхәлдә, ник барганыма үкенеп утырырга туры килмәде, үзем өчен бик файдалы һәм гыйбрәтле яңалыклар алып киттем бу очрашудан.

Өйгә шактый ук соңарып кайтырга туры килде. Чәй өстәле артына утырдым һәм, ияләнгән гадәт буенча, телевизорны кабыздым. Анда-монда баскаларга керешсәм, ни күрим – Мәскәү шәһәре каналларының берсендә шул кичәдә чыгыш ясаган бертөркем галим-голамә түгәрәк өстәл артында әңгәмә корып утыра. Исемнәре хәтердә калмаган булса да, таныш йөзләр, таныш сүзләр игътибарымны җәлеп итте...

Әйе, мин әйтәм, бу япон кызының үзенчәлекле акцентына һәм, әлбәттә, мөлаем йөзенә беренче күрүгә үк игътибар юнәлткән идем. Ә менә теге ир егет Бразилиядән иде кебек, Есенин шигырьләрен яттан сөйләп сокландырган иде ул... Ә монысы – иллене узып барган, карап торышка әллә ни чибәрлеге булмаса да, мөлаемлыгы белән үзенә тартып торган кара тәнле ханым, Кубадан. Тәнәфес вакытында аның белән хәтта берничә авыз сүз дә алыштык кебек әле. Минем Язучылар берлегеннән икәнемне белгәчтер инде, яныма килеп, үзе сәлам бирде. Исемен дә әйтте әйтүен, әмма хәтердә калмаган. Яшьлек елларында шигырьләр дә язган икән. Хәзер Гавана университетында рус теле һәм әдәбияты укыта. Бик иркенләп фикер алышырга иде кебек исәбе. Минем кайда һәм кем булып эшләвем, нинди әсәрләрем булуы хакында да кызыксыну белдергән иде... Әмма, җавап бирергә өлгердемме-юкмы, күренекле рус язучысы, күптәнге дустым Александр Арцыбашев килеп кочаклап алмасынмы үземне шул мизгелдә. Билгеле инде, әңгәмә шунда өзелде, әллә ул ханым үзе китеп барды, әллә, хәл-әхвәлләр белешә торгач, без читкә тайпылганбыз, ачык кына әйтә дә алмыйм хәзер.

Чү, тапшыруны алып баручы кунакларга кызыклы гына сорау белән мөрәҗәгать итте түгелме:

– Хөрмәтле ханымнар һәм әфәнделәр, рус әдәбияты белән кызыксынып китүегезнең тарихы нидән башланды, шул хакта безгә дә кыскача сөйли алмассызмы?

– Лев Толстой романнарыннан башланды, – диде берәве.

Икенчесен яшьлек елларыннан ук Достоевский әсәрләре таң калдырган. Пушкин, Лермонтов һәм Есенин исемнәрен дә кат-кат кабатладылар...

Чират Гавана университеты профессорына җитте. Ә ул, ни сәбәпледер, үз уйларына бирелепме, икеләнә калды бер мәлгә.

– Ә сез, Донья Алеида, ни диярсез? Нигә дәшми утырасыз... Сезнең рус әдәбиятына килү юлыгыз кем иҗатыннан башланды?

– Унҗиде яшемдә мин бер рус егетенә гашыйк булган идем, – диде ул, гел көтмәгәндә. Һәм шул урында, еракта калган хатирәләрен барлауданмы, бераз югалып калды.

«Ах» та «ух» иттеләр өстәл артында утыручы коллегалары, аларга бу бик тә кызыклы тоелды. Кайсы берәүләре елмаеп һәм көлеп тә җибәрделәр кебек. Алып баручы шундук элеп алды:

– Кызык, бик тә кызык, – диде ул. – Шул мәхәббәтегез хакында безгә дә сөйләп китмәссезме...

– Сөйләрлек берни булмады, – диде ханым, тирән сулыш алып. – Ул егет

испанча бер сүз белми иде, мин – русча... Аңлаша алмадык. Ул китте һәм эзсез югалды. Ә мин үземә, һичшиксез, рус телен өйрәнәчәкмен, дип, сүз бирдем шуннан соң. Һич кенә дә рус теле яисә әдәбияты белгече булу түгел иде хыялымда. Математик булырга җыена идем мин.

– Менә бит нинди тарих, ничек кызык килеп чыга, – дип, тагы да җанлана төште тапшыруны алып баручы. – Ә ул егетне бүтән күрмәдегезме? Эзләмәдегезме?!.

– Сез ни сөйлисез, Куба кайда да, Россия кайда... Нинди эзләү, нинди табу, дисез. Минем менә гомеремдә беренче мәртәбә чит илгә чыгуым, яшьлек хыялым тормышка ашты – Мәскәүгә килдем.

– Донья Алеида, сез бүген Россиянең башкаласы Мәскәү шәһәрендә. Әйтегез әле, ул егетне эзләргә һәм эзләп табарга теләр идегезме?

– Ул заманнан бик күп вакыт узды, – диде ханым, беркадәр уңайсызланып. Чигәсенә төшеп торган чал чәчләрен ипле генә артка таба сыпырып куйды. – Күрәсез, миңа да унҗиде яшь түгел. Аның да егет чаклары узган булса кирәк...

– Ә шулай да? – дип, төпченүен дәвам итте алып баручы.

– Мин аны эзләп килмәдем, – диде ханым, катгый рәвештә. Һәм әллә нидән генә, ерак яшьлектә калган хисләрен искә төшерепме, шул мизгелдә күз читләрендә мөлдерәп пәйда булган яшь тамчыларын яулык чите белән сөртеп куйды. – Әмма, гел уйламаган-көтмәгәндә, мин аны очраттым бит.

– Очраттыгыз?! – дип, гаҗәпләнүдән үзалдына сузып куйды алып баручы.

Бу сүзләрне ишеткәч, як-ягында утыручылар да, ышанырга-ышанмаска белми, ачкан авызларын йомарга онытып, бер мәлгә хәйран калып тордылар.

– Таныдыгызмы?.. – диде араларыннан берәү.

– Мин таныдым.

– Ә ул?

– Ә ул мине танымады...

– Менә-менә, ир-атлар шундый инде... Алардан башканы көтеп тә булмый, – дип күтәреп алды янәшәдә утырган берничә хатын-кыз. Ир-атка карата мөнәсәбәт шул кадәрле дә бердәм булыр икән. Дөньяның төрле почмакларыннан җыелган укымышлы кешеләр бит без югыйсә.

Шушы минутта бу программаны карап утырган мәскәүлеләрнең дә бик күбесе килешкәндер дип уйлыйм мондый фикер белән. Мин дә баш кагып утырдым кебек әле.

Алып баручы дилбегәне кулыннан ычкындырырга теләми иде, әлбәттә, әмма сүзне капылт кына читкә борып җибәрүе дә уңайсыз. Бу тарихны йомгаклау максатыннан булса кирәк, ул тагы, кара тәнле, әмма искиткеч мөлаем һәм якты карашлы әлеге профессорга мөрәҗәгать итте:

– Сеньора Алеида, бәлки, ул егет... Хәер, бүген инде ул, әлбәттә, егет булмас, әфәнде, диик, сезне хәзер телеэкраннан күрә торгандыр дип гөманласак, аңа бүген ни дип әйтер идегез?

Ике уйлап тормады ханым, шундук җавабын да тапты:

– Яратам, – дияр идем. Һаман яратам... Һәм тагы шуны әйтим: мин хәзер дә, әледән-әле, үзем туып-үскән Варадерога кайтам. Океан читендәге кайнар ком өстеннән атлап, ялгызым гына йөргәндә, еракта калган яшьлегемне һәм әлеге россияле сеньорны очратырмын кебек тоела. Инде менә исемегезне һәм фамилиягезне дә белдем хәзер, әмма әйтмим, сезне уңайсыз хәлгә куярга теләмим. Шуны гына әйтәм: күрәсез ич, мин вәгъдәмдә тордым – рус телен өйрәндем. Ә сез...

Телевизорымны икенче каналга күчердем шунда, футбол карарга керештем. Күчерүен күчердем, ә теге шактый ук калыная төшкән кара тәнле ханым һич кенә дә күз алдымнан китми. Аның күз читләреннән мөлдерәп саркылып чыккан кайнар яшь бөртекләре гүя минем яңагымнан йөгерешәләр. Эчкерсез һәм ихлас сүзләрен онытырлыкмы: «Варадеро... океан читендәге кайнар ком... Мин өйрәндем, ә сез...»

«Варадеро» дигән сүзе айнытып җибәрде үземне. Кубада, Варадерода минем дә булганым һәм ял иткәнем бар иде бит. Сиксәненче еллар башында Татарстан профсоюзлары өлкә комитеты мине Азатлык утравына ялга баручы туристлар төркеменең җитәкчесе итеп юллаган иде. Яхшы хәтерлим, миңа, җитәкче буларак, унҗиде доллар акча да алыштырганнар иде әле. Ә туристларга, ялгышмасам, уникешәр доллар. Хәер, алар югалып кала торганнардан түгел, барысы да сәүдә оешмаларында эшләүчеләр, кем әйтмешли, «завмагазин» да «завсклад» – ул елларда һәркемгә кирәге чыга торган кешеләр. Эшләүләрен белмим, көн дә бәйрәм, көн дә туй дигәндәй, ял итеп тә күрсәтте соң үзләре.

Яшь ягыннан гына түгел, тормышны аңлаулары белән дә алар миннән күпкә тәҗрибәлерәк булгандыр. Минем исә бу – беренче мәртәбә чит илгә чыгуым. Шуның өстенә төркемдәге һәр кеше өчен җаваплылык та йөкләнгән бит әле үземә. Юлга чыгар алдыннан нинди генә оешмаларга чакырмадылар да нинди генә кисәтү һәм таләп өймәделәр җилкәмә... Тегесе дә ярамый, монысы да ярамый. Завмагазин һәм завскладлар исә, шагыйрь әйтмешли, «ярамыйга карамый». Океан читендә зур бер төркем булып җыелалар да, үзләре белән алып килгән затлы эчемлекләрне капкалый-капкалый, карта уйнарга керешәләр, дөньяларын онытып ял итәләр. Телләрендә акча да мал, мал да акча. Ә миңа, акчасыз яшәргә күнеккән яшь татар язучысына, бу сүзләр ят. Малсыз һәм акчасыз гына коммунизм төзү хыялы белән яши идек бит...

Мин дә ял итәргә килдем, әлбәттә. Әмма алар арасында күңелсез, үземә урын таба алмыйм. Юк сәбәпне бар итеп, бер читкәрәк тайпылам да, кайнар ком өстенә сузылып ятып, Хемингуэй әсәрләрен укырга керешәм. Рус телендәге ул китапны Гаванада китап кибетеннән тапкан идем. Язучының әсәрләрен үзе яшәгән, үзе иҗат иткән төбәктә уку аеруча тәэсирле икән ул. Кояш нурлары тәнне яндыра башлаганны сизсәм, барып су керәм, океанның җылы дулкыннарында тирбәләм, туйганчы йөзәм. Гыйнвар уртасында шундый рәхәтлек кичерермен дип кем уйлаган... Без юлга чыкканда, Казанда утыз тирәсе суык калган иде, ә монда шул кадәрле үк эсселек. Җирле халык су тирәсендә әллә ни күренми, «нигә?» диеп сорау бирсәң: «кыш ич, суык», дип җавап кайтаралар. Безгә бу көлке, әлбәттә.

Көннәрдән бер көн, шул рәвешле, ялгызым гына комда кызынып китап укып ятам. Сәүдәгәрләрем шау-гөр килеп ял итә: берөзлексез анекдот сөйлиләр, шаркылдашып көлешеп алалар, акчага карта уйныйлар, тарталар, ара-тирә шешә һәм стаканнары шалтырап куя.

Берара башым калкытып карасам, ни күрим, безнең төркемдәге ир-атларның берсе, чалыш-молыш атлап, читтә ялгызы гына китап укып яткан кара тәнле бер яшь кыз янына китеп барды. Кызның баш очына ук барып чүгәләде бу. Эчеп алгач, безнекеләрнең батырлыгын беләсез, тегеңәргә кулын да сузгаларга кереште. Ә кыз моның белән сөйләшергә теләми, китабына текәлгән, авыр сүз әйтергә тартына, итагатьле генә аны читкә тибәрә. Бәйләнчек черки сыман шактый гына азаплады бу теге кызны. Бәлки, миңа яннарына барып, чит ил кешесенә болай бәйләнү ярамаганлыкны якташыма аңлату, кисәтү дә

кирәк булгандыр. Әмма, сабырлыгым җыеп түздем, тавыш-гауга чыгарудан уңайсызландым.

Ниһаять, кызның түземлеге тәмам бетте, яткан урыныннан капылт кына торды да, китаплары һәм аяк киемен ике кулына алып, яр буеннан ипле генә безгә таба китте. Су читләтеп минем турдан узып бара. Талгын дулкыннар әледән-әле аның аяк йөзләрен үбеп-үбеп ала. Күрмәгәнгә сабышам, әлбәттә, әмма күзәтәм... Күз төшкәч, күзәтми мөмкин дә түгел. Талчыбыктай зифа һәм сылу да икән соң үзе, гүя, ул атламый, ә йөзеп бара. Ул утлы күмер сыман янган күзләр, төз муен, кояш нурларында көмеш сыман елык-елык килеп иңбашына сузылып төшкән чем-кара чәчләре дисеңме. Шул талчыбыкның шома тәнендә шактый ук бүртеп чыккан пар бөреләр... Алга таба дәвам итим, дисәм, сүз җитми, сүз... Ул зифалык һәм аның хәрәкәтләрен тулырак тасвирлар өчен, рәссам яисә музыкант булып туарга кирәк булган. Бары монда, җылы океан эчендә урнашкан шушы җәннәткә тиң утрауда гына туып үсәргә мөмкин андый да зәвыклы һәм нәзакәтле табигать баласы.

Кыз, бераз ары китеп, үзенә яңа урын тапты. Сүзсез музыка сыман, ипле генә салмак хәрәкәт белән, ком өстенә сузылып ятты. Һәм тагы китапларына капланды. Әле берсен алып укый, әле икенчесеннән ниләрдер карап ала. Юк, бу һич кенә дә укыганга сабышу түгел, чын-чынлап нидер өйрәнә, вакытның кадерен белеп, имтиханга әзерләнә, дигән нәтиҗә ясадым үзалдыма.

Ул да түгел, теге бәйләнчек ир-ат яңадан хәрәкәткә килде, әнә, үзалдына сызгырына-сызгырына, океан читләп минем турыдан узып бара.

– Наил абый, – дидем үзенә, берни күрмәгән һәм аңламаганга сабышып. – Кай якларга китеп барышың?..

– Су кызын эзләп баруым әле менә...

– Наил абый, дим, бәйләнмә инде шул балага, имтиханга хәзерләнә торгандыр, күрәсең, сөйләшәсе дә килми ич.

– Энем, мин үзем беләм, – дип, эре генә кул селтәде дә ул миңа, юлын дәвам итте.

– Ярар алайса, үзең беләсеңдер, – дидем дә, ул тарафка башка карамаска ният итеп, борылып яттым. Ә шулай да ара-тирә Наил абыйның кыз янында русчалы-татарчалы ниләрдер мыгырданганы барыбер колакка чалынып торды. Торып үзен шелтәләсәм, көн кебек ачык, тавыш чыгарачак. Түздем...

Бераздан, шул тарафка күз төшерсәм, ни күрим, теге кыз тагы торып баскан. Бәйләнүчедән ничек котылырга икән дип булса кирәк, бертын як-ягына карап торды. Һәм, китапларын кочаклап, миңа таба атларга кереште. Әйе, туп-туры миңа төбәп килә. Сизеп торам: «Бу сәрхушне туктатыгыз, бәйләнмәсен миңа, туктатмасагыз, тавыш чыгарачакмын», – дип әйтәчәк инде бу. Шул гына җитмәгән!

Мин яткан урынга, күп булса, метр ярым ара калгач, ниһаять, ул туктады. Күңелдә шом, ни әйтер дип көтәм. Ә ул шундый мөлаем итеп елмаеп җибәрмәсенме, тулышкан иреннәре артында ап-ак тешләр балкып җемелдәде.

– Буенос диас, – диде иң элек, һәм тагы миңа аңлашылмаган ниндидер ягымлы да, йомшак та испан сүзләре тезеп китте.

«Хәерле көн» дигәнен аңладым, әмма башкаларын юк. Көлке чыккандыр бәлки, шундый алиһә каршыңда басып торганда, җавапсыз калып булмый бит инде.

– Буенос, буенос, – дигәнмен, алдын-артын уйлап тормастан.

Ул тагы нидер аңлатты. Һични аңламасам да, мин баш кактым. Яр читеннән, берни булмагандай, үзалдына сызгырынып кайтып килүче Наил абзыйга да ишарәләде кебек.

Мин тагы «буенос-буенос», дидем. Башкача ни диим соң, испан телен белмим ич. Шуның өстенә бит әле, кызыбызның теле телгә йокмый, автоматтан аткандай тиз сөйләшә. Көтелмәгән бу очрашудан юлда өйрәнеп килгән җидесигез сүзем дә кинәт онытылган, хәтергә килми тинтерәттеләр.

Кызның, үзе яшь кенә булса да, тапкырлыгы һәм кыюлыгына исең-акылың китмәле. Рөхсәт биргәнмен, күрәсең, шул үзе басып торган җирендә ком өстенә сөлге җәеп, аның бер башына китапларын тезеп куймасынмы! Һәм ипле генә, талгын җилдә сыгылган тал чыбыгыдай бөгелеп, үзе дә сузылып ятты шунда. Текәлеп карамаска тырышсам да, аның шомырт сыман чем-кара зур күзләрендә чагылып киткән якты балкыш һәм беләзеккә сыяр сыман тоелган бер йомарлам майдай нечкә биле хәтердә уелып калган.

Миңа таба серле генә елмаеп, тагы берничә авыз сүз әйтте дә китапларына текәлде ул.

– Пурфавор, – дигәне, «рәхмәт» булды кебек, башка сүзләрен һич кенә аңламадым.

Хәерлегә булсын. Наил абый да ул-бу сүз әйтми генә узып китте, килеп бәйләнеп йөрмәде, тавыш-фәлән чыгармады. Дус-ишләре янына кайткачтын, шау-шу килеп көлешеп алдылар алуын, әмма ул кадәресендә минем эшем юк. Күреп торам, кызыбызның да эч пошканнан эзләнеп йөрүе түгел, укырга дип килгән. Китапларына ничек килеп капланса, шул рәвешле тырышып укуын, өйрәнүен дәвам итә, әнә. Аның өчен янәшәсендә чит бер кеше әллә бар, әллә юк инде хәзер. Мин дә, башта беркадәр тынычсызланып алсам да, мавыгып, Хемингуэйны укуымны дәвам иттем...

– Командир, син төшке ашка кайтып тормыйсыңдыр инде, – дигән тавыш ишетелде бераздан.

Бу – Наил абыйның мине кайгыртуы икән. Сәүдәгәрләр, су буеннан тезелешеп ихатага кайтып килгән казлар кебек, бер-бер артлы кунакханәгә таба юл тотты. Миңа да вакыт. Инде байтактан ничек торып китү һәм, торып киткәндә, күршемдә генә имтиханга әзерләнеп яткан чем-кара су кызына ни дип дәшү хакында уйланып ятуым.

Ул да минем китәргә җыенуымны аңлап, башын күтәрә төшеп, үземә ым какты, янә бер елмаюын бүләк итте. Рәхмәт белдерүе иде булса кирәк, коткардым ич.

– Адиос, – дидем. – Аста луэго, – дип өстәдем әле тагы. Бар белгәннәремне әйтеп бетердем. «Сау булыгыз»ы да җиткән иде югыйсә, «хәзергә, күрешкәнгә кадәр»е нигә кирәк булгандыр...

Көндезге аштан соң, Эрнест Хемингуэй яшәгән һәм иҗат иткән утарга сәяхәт кылдык. Әле дә онытасым юк, бу минем өчен аеруча мөһим һәм күптән көтеп алынган гизү иде. Шунысын да онытмыйк: ул елларда СССРда аңардан да популяррак чит ил язучысы булмагандыр...

Ә санаулы көннәр бер-бер артлы уза торды. Көн буе кайнар комда ауныйбыз һәм су керәбез. Җир читендәге бу ерак утрауга да шуның өчен дип килгәнбез бит инде.

Ниһаять, кайтып китәр көнебез җитте дигәндә, көтмәгәндә, океан читендә теге сылу кыз тагы күренмәсенме!.. Инде онытылган иде дип әйтеп булмый, әлбәттә, су буена төшкән саен, аның юклыгын мин һәркөн сизә, тоя торган

идем. Әмма бу дөньяда азмы кеше шул рәвешле игътибарны җәлеп итә дә соңыннан эзсез югала, онытыла. Гаҗәпләнер сәбәп яисә урын юк.

Кызның барлыкка килүен мин түгел, бу юлы да Наил абый күргән булып чыкты. Бөтен яр читен яңгыратып, бу хакта ул миңа хәбәр салды:

– Командир, күзеңне ачып кара, кояш чыкты, кояш...

Хәбәре матур булса да, чагыштыруы ул кадәрле уңышлы чыкмагандыр. Кояш монда бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр, дип уйлап куйдым үзалдыма.

Океан иксез-чиксез, алтын түшәк булып җәелгән кайнар ком бер офыктан икенче офыкка кадәр сузылган. Һәр тараф буш, җирле халыкның эзе дә юк су читендә. Туристлар, күп булса, ике-өч урында төркем-төркем булып кайнаша. Ә кыз, гүя, аңарга башка урын беткән, китапларын кочаклап, тагы безнең тарафка атлап килә. Инде узып китә, дисәм, туп-туры мин яткан урынга килеп туктамасынмы!.. Исәнләште һәм рөхсәт сорады, мин баш кактым. Тамга салып киткән диярсең, ул тагы үзенең теге көнге урынына килеп урнашты.

Бер күзем – китапта, икенчесе өлгереп килгән әлеге кара җимешне күзли. Кем белә, бәлки, өлгереп үк җиткәндер дә... Әмма безгә моны аңлау сәләте бирелмәгән. Ялгышмасам, Кубага килгәнче, кара тәнле кешеләрне мин киноларда гына күреп белә идем. Ә менә шул кадәрле дә нәфис һәм матурлары була торгандыр дип, башыма да китерә алмый идем. Табигать нинди генә гүзәлләрне тудырмый бит, ә?.. Һичбер рәссам, һичбер скульпторның төшенә дә кереп карамаган нечкә нәзакәтлелек бар ич моңарда.

Качып кына үзен күзәтүемне күрдеме, ул елмаеп куйды. Җәйге таңда күзләрне чагылдырып балкыган кояш нурларыдай өтеп алды аның шул елмаюы һәм серле карашы. Кулындагы китап эченә кыстырылган кәгазь кисәгеннән укып, рус телендә сүз башлады:

– Сезгә зур рәхмәт, товваричь, – диде ул, соңгы сүзне шактый зур кыенлык белән әйтеп. – Мин имтиханымны «бишле»гә тапшырдым.

– Котлыйм, – дидем, – әмма минем ни катышым бар сезнең «бишле»гә?..

Рус телендә яңгыраган сүзләргә русча җавап бирдем. Ә ул берни аңламады. Тора-бара йөзеннән мөлаемлек качты, борчуга сабышты кыз. Мин әйткән сүзләрне бик тә, бик тә аңлыйсы килә иде бит. Кабалана төшеп, кулындагы калын бер китапны актарырга кереште. Ул испанча-русча сүзлек икән. Әмма русча-испанчасы юк. Димәк, эзләп азаплану файдасыз булып чыга. Миңа да сузып карады китабын. Ә мин нишлим, испанчаны белмим, кәҗә игъланга караган сыман карап тордым-тордым да кире үзенә суздым китабын.

– Сез хорошши товваричь, – диде тагын, теге кәгазь кисәгенә күз төшереп алгач.

Бу минем шул кадәрле дә рәсми «товарищ» сүзен, үземә мөнәсәбәттә, хатын-кыз затыннан беренче тапкыр ишетүем булгандыр.

– Рәхмәт, – дими, ни диим?! Монысын аңлады һәм үзенең аңлавына куанганын күрсәгез икән сез аның. Хәтта шатлыгыннан кулын чәбәкләп алды.

Кыз океан читеннән югалып торган көннәрдә имтихан биреп кенә калмаган, имтихан алырга да әзерләнгән булып чыкты. Тора-бара тәмам үзләшеп китеп, кулындагы дәфтәр битенә карый-карый, сорау арты сорау яудырырга керешмәсенме бу.

«СССРда яшәү ничек?» дигән соравына баш бармакны күтәреп җавап бирдем. Яшемне сорады. Өч мәртәбә ун бармагымны күрсәттем, тагы ике-өч бармак бөгеп вакланып тормадым.

– Кем булып эшлисең? – дигән соравына, каләм тотып язган сыман, ишарә ясап күрсәттем.

Аңламады. Озак баш ватып тормадым, кулымдагы китапны болгый-болгый, «Хемингуэй», дип кабатладым. Аңлады кебек, чөнки елмайды һәм, гаҗәпләнгән атлы булып, башын чайкап куйды...

Минем дә сорауларым булгандыр ул, бәлки. Ләкин ничек сорыйм? Аның русчасы юк. Хәтта үземнең кем булуымны аңлатырга теләп, «татар», диеп күпме кабатласам да, аңлау тапмадым, ишеткән-белгән сүзе булып чыкмады. Французча белсә, вата-сындыра булса да аңлашырга тырышыр идем дә бит. Белми...

Хәер, аңлашылмаса аңлашылмас, аның карашын тою, тавышын ишетү һәм аның белән кара-каршы утыру, аңа дәшми генә булса да карап тору да җанга рәхәт булгандыр шул санаулы гына минутларда. Бераздан тагы Наил абыйның тавышы ишетелде.

– Командир, төшке аш вакыты җитте...

Мин сискәнеп куйдым. Юк, куркудан түгел, Наил абый белән чын дуслар булып киткән идек инде. Бу юлы да аның тавышы дустанә һәм кайгыртучан яңгырады. Инде эчүне дә ташладылар. Хәер, алып килгән эчемлекләре бетте кебек.

Юлдашларымның кузгалуын күреп, кыз минем дә китәргә җыенуымны аңлады булса кирәк. Яткан урыныннан җәт кенә торып утырды ул һәм күзләрен мөлдерәтеп карап куйды. Гадәттә, төшке аштан соң, безнең бер-бер сәяхәт планлаштырылган була, кыз да моны чамалый иде булса кирәк. Төштән соң үзебезне эчемлекләр, ягъни ром ясый торган заводка алып барырга тиешләр иде ул көнне. Көтеп алынган сәяхәт...

– Аста маньяна, – диде ул. Бу «иртәгәсе көнгә кадәр», дип хушлашуны аңлата. Мин белгән җиде-сигез сүзнең берсе шушы.

Килешеп баш каксам, ялган булыр иде. Чөнки иртәгә иртүк без кайту юлына чыгачакбыз. Варадеродан Гаванага автобус белән, аннан – самолёт. Кызга шуны ничек аңлатырга икән соң? Торып баскан җиремдә катып калдым, тиешле сүз таба алмадым. Һәм, тәвәккәлләп, кулымны һавага күтәрелүче самолётка охшатып, тиз генә югарыга чөйдем, «ву-у...» дигән аваз да чыгардым әле тагы.

Минем «сабыйлыгым»ны күреп булса кирәк, ул көлемсерәгәндәй итте башта. Әмма, бу хәбәр көтелмәгән булдымы, шундук нык кына кәефе дә кырылды кебек. Кызыбызның күзләренә әллә томан, әллә моң төшкәндәй булды. Тәмам югалып калды ул, иреннәре калтыранды, сораулы карашы әле кулындагы сүзлеккә, әле миңа төбәлделәр. Сүзлектән, кабаланып, нидер эзләргә кереште ул, тик әйтер сүзен тапмады. Мин кул болгадым һәм борылып китеп бардым. Нишлим, тагы ни кыла ала идем соң мин?.. Ул артымнан нидер әйтеп калды кебек. Мин тагы, борыла төшеп, кул болгадым. Ул да кулын югары күтәрде һәм тагы теге сүзен кабатлады... Тукта, ни диде соң? Мин һич кенә дә аңлый алмый азапланган ул сүз кызның исеме булган түгелме... Әйе, «Алеида», диде кебек ич. Алеида...

Футбол матчын тиз генә өзеп, кабалана төшеп, мин яңадан Мәскәү каналын ачтым. Әмма, ни кызганыч, «түгәрәк өстәл» инде тәмамланган. Кунаклар таралган... Диктор иртәгә буласы һава торышы турындагы хәбәрен йомгакларга җыена. «Аязучан болытлы һава, кыска вакытлы яңгырлар...» булачак икән иртәгесен.

Менә сиңа мә, «аязучан болытлы һава...», дип, кат-кат кабатладым кебек үзалдыма. Тагы ни диим соң?!.



Зөлфәт
Хәким

# ТӘРӘЗӘДӘ ҺАМАН УТ ЯНА

БЕР ПӘРДӘЛЕ ДРАМА

**Катнашалар:**
Ле н и з а
Х а ф и з
Ф и л ү с ә
Т и м у р
Х ә н и я
З ә р и м ә

**I**

*Төн. Х а ф и з белән Ф и л ү с ә караватта яталар. Җиһазлар урнаштырылмаган.*

Ф и л ү с ә . Хафиз!

Х а ф и з . М-м-м...

Ф и л ү с ә . Йоклыйсыңмы?

Х а ф и з . Юк.

Ф и л ү с ә . Фатир алдык алуын, әмма районы ошамый.

Х а ф и з . Нәрсәсе ошамый? Кибетләр якын. Йорт яныннан йөк машиналары йөрми.

Ф и л ү с ә . Шомлы урын бу... Аңлата алмыйм.

Х а ф и з *(хатынын кочаклап)*. Шикчелем минем! Күңелеңдәге шомнарның сәбәбен һәрвакыт үзеңнән эзлә.

Ф и л ү с ә . Фатирга аласы әйберләр күп, машинага акча калмаячак.

Х а ф и з . Барысын да берьюлы алып булмый инде. Түз, сабыр ит.

Ф и л ү с ә . Туганнардан, таныш-белешләрдән яхшы түгел.

Х а ф и з . Фатирны үзем эшләп алмавым үземне дә борчый. Мин, ир-егет буларак, фатирны үзем алырга тиеш идем. Шунысы оят.

Ф и л ү с ә . Ояты юк инде аның. Бер миллионны синең әти-әниең бирде бит.

Х а ф и з . Ә икенче миллионны синекеләрдән алдык.

Ф и л ү с ә . Үзләре шулай киңәшләштеләр, анысы өчен борчылма.

---

Зөлфәт ХӘКИМ (1960) – *драматург, прозаик. Дистәдән артык китап, иллегә якын пьеса һәм күпсанлы җырлар авторы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Х а ф и з . Мин үземне бурычлы итеп тоярга яратмыйм.

Ф и л ү с ә . Бурычка дип әйтүче булмады бит сиңа.

Х а ф и з . Әйтмәсәләр дә, бурыч инде ул.

Ф и л ү с ә . Бөтен нәрсә кыйммәт, алга таба нишләрбез, шуны уйларга кирәк хәзер.

Х а ф и з . Минем сиңа бер үтенечем бар – зинһар, ашыктырма, теге кирәк, бу кирәк, тегеләй итик, болай итик, моны алыйк, тегене алыйк, дип кыбырсыма. Барысы да берьюлы килми. Эшләрбез, кирәк нәрсәләр тора-бара булыр. Ашыктырма. Шул чагында, бәлки, үземне бурычлы дип хис итмәм.

Ф и л ү с ә . Ярар, ярар. *(Хафизга елыша. Кочаклашалар.)*

Х а ф и з . Бәбиебез булгач, агачтан матур иттереп ясли-карават ясармын.

Ф и л ү с ә . Бу фатирда тора башлаганыбызга бер атна булды. Каршы йортның дүртенче катындагы бер фатирда көне-төне ут яна, игътибар итмәдеңме?

Х а ф и з . Кеше тәрәзәсендәге утта хәбәрем юк әле. Болай да баш каткан. Мин университет тәмамладым, физика-математика укытырмын дип хыялланып йөргән кеше, бөтенләй башка сукмактан китеп бардым.

Ф и л ү с ә . Сиңа укытучы булып эшләмә диюче булмады, үз теләгең белән бу эшеңә тотындың.

Х а ф и з . Акча кирәк, дисең бит.

Ф и л ү с ә . Нишлисең инде. Мин дә бит, акушерка башым белән, торговляда эшлим. Заманасы шундый булгач. *(Торып су эчә.)* Эчәсең килмиме?

Х а ф и з . Юк.

Ф и л ү с ә *(тәрәзәдән карап)*. Теге тәрәзәдә һаман ут яна.

Х а ф и з . Йокылары килмидер. Без дә менә төн кошлары кебек йокламыйбыз бит.

Ф и л ү с ә . Нишләп көндез дә ут яна икән соң анда?

Х а ф и з *(торып, тәрәзә янына килә)*. Димәк, фатирлары караңгы, көн яктысы төшмидер. *(Филүсәне күтәреп караватка алып китә.)*

*Караңгылык. Сәхнә яктыра. Хафиз белән Филүсә торалар. Филүсә ашык-пошык чәй әзерли.*

Ф и л ү с ә . Тизрәк кухняны рәткә китерергә кирәк.

Х а ф и з . Җитешербез әле.

Ф и л ү с ә . Бер атна торабыз инде монда, ванна бүлмәсенә кирәклек түгел.

Х а ф и з . Әкренләп тәртипкә кертербез әле.

Ф и л ү с ә *(тиз генә чәен эчеп)*. Соңга калам бугай инде. *(Кабаланып эшкә җыена.)* Синең бүгенгә заказың бармы?

Х а ф и з . Бер коттеджда шалтыратырга тиешләр – нарат рейкалар белән эчтән тышларга кирәк, диделәр.

Ф и л ү с ә . Күпме түлиләр?

Х а ф и з . Бәясен сөйләшмәдек әле.

Ф и л ү с ә . Син гел шулай – бәясен сорарга ашыкмыйсың...

Х а ф и з . Ярар инде, иртүк акча турында сөйләшмә.

Ф и л ү с ә *(тәрәзәдән карап)*. Яңгыр яумый бугай. Зонтик алмыйм. Теге тәрәзәдә һаман ут яна. Киттем мин. *(Хафизны кочаклап үбә.)* Пока! *(Чыгып китә.)*

Х а ф и з *(тәрәзәдән карап)*. Чынлап та, сәгать инде унынчы, ә утлары һаман яна. Берәр фаҗига булмады микән анда? Авыру кеше торалмыйча ята микән? Берәрсе үлгәнме?..

## II

*Лениза фатиры. Фатирның залы остаханәгә әйләнгән – картиналар, краскалар, кәгазьләр, рамкалар. Лениза картина ясый. Ишек кыңгыравы зеңгелде. Л е н и з а барып ишекне ача.*

Х а ф и з . Исәнмесез.

Л е н и з а . Исәнмесез.

Хафиз. Гафу итегез, сез белмисезме, бу йортта фатир сдавать итүче юк микән? Бәлки күршеләрегезнең нияте бардыр...

Лениза. Сез һәр фатирга шакып сорап йөрисезме, әллә миннән генә сорыйсы иттегезме?

Хафиз. Юк. Мин... Һәр фатирга... Күбесе эштә хәзер...

Лениза. Нишләп домофоннан гына сорамыйсыз, алай җайлырак бит?

Хафиз. Сез миннән шикләндегез, ахрысы. Мин карак түгел.

Лениза. Дөресен әйтегез, сезгә нәрсә кирәк?

Хафиз. Фатир снимать итәргә йөрим.

Лениза. Алдыйсыз.

Хафиз. Ярар, дөресен әйтәм. Мин каршы йортта яшим. Бер атна элек урнаштык. Фатирыгызда көндез дә, төнлә дә ут яна. Атна буе ут сүнмәгәнгә игътибар иттек. Әллә ниләр уйлап бетердем. Урын өстендә авыру кеше ятадыр, караучысы юктыр дип тә уйладым... Гафу итегез, кеше үлгәндер дә, туганнары, якыннары юктыр дип тә уйладым... Озакка киткәннәрдер, утны сүндерергә онытканнардыр дигән фикер дә килде. Күршеләренә әйтеп, хуҗаларга шалтыратырга кушармын, дидем – счётчик чутлый бит, түләргә күп туры киләчәк, мәйтәм...

Лениза. Кызык – ике ел инде ут өзлексез яна, моңарчы беркемнең дә кызыксынганы булмады, сез – беренче кеше. Димәк, фатирымда ут сүнмәү сезне пошамаганга калдырды. Җаныгыз тынычлансын өчен, фатирымны кереп күрегез алайса.

Хафиз. Ә сез миннән курыкмыйсызмы?

Лениза. Самомнение зур икән économiquesездә.

Хафиз *(фатир эченә узып)*. Сез рәссаммы?

Лениза *(көлеп)*. Каян белдегез?

Хафиз. Үзегез ясыйсызмы?

Лениза. Минем өчен күршеләр кереп ясамаслар бит инде.

Хафиз *(картиналарны карап)*. Ай-яй, хәтәр сурәтләр... Менә сиңа мә! Сез бит тәүлек әйләнә өзлексез картиналар ясамыйсыздыр – ял итәсездер, йоклыйсыздыр, нишләп бер дә утыгыз сүнми?

Лениза. Картиналар өчен шулай кирәк.

Хафиз. Ничек инде?

Лениза. Сез аны аңламаячаксыз.

Хафиз. Гаиләгез бардыр?

Лениза. Гаиләм бик зур – җиде миллиард кеше яши планета дигән участогымда.

Хафиз. Үзегез генә яшисезме?

Лениза. Бу дөньяда берүзең генә яшәү мөмкин түгел. Менә бит әле, хәтта каршы йорттан утыгыз сүнми дип килеп керәләр.

Хафиз. Башта хатыным игътибар итте сезнең тәрәзәгә.

Лениза. Димәк, хатынызны тынычландырыр өчен монда кереп иснәнергә булдыгыз?

Хафиз. Мин инде сезгә әйттем ниләр уйлап бетергәнемне.

Лениза. Күрәсез, куркырлык бернәрсә дә юк. Киресенчә, бу дөньяда ут янмаса куркынычрак. Үзегез кем булып эшлисез?

Хафиз. Мин агач эшләре белән шөгыльләнәм – ишекләр, рамнар куям, күбрәк шәһәр читедәге агач йортлардан заказлар алам. Столяр дип атала иде элек ул эш, хәзер башкачарак. *(Картиналарга сокланып карый.)* Искиткеч! Кем уйлаган, каршы йорттагы бер фатирда шушындый иҗат кайныйдыр дип.

Лениза. Һәрбер тәрәзәдә сер бар. Әллә кайсы фатирларда әллә кемнәр әллә ниләр эшләп ятадыр, кешеләр бу турыда уйламыйлар гына. Сезнең исемегез ничек?

Хафиз. Хафиз.

*Хәния керә. Кулында пакет.*

Хәния *(ишек катыннан)*. Лениза, кызым, бу мин, Хәния апаң. Исәнмесез.

Хафиз. Исәнмесез.

Лениза. Бүген иртәрәк килдең, Хәния апа.

Хәния. Мин базарда син ярата торган табан балыгы алдым, бүген төнлә тотылган, тизрәк шуны сиңа пешереп ашатыйм, дидем.

Лениза. Бик әйбәт, ләкин теге көндәге шикелле нык тозлама, яме.

Хәния. Ярар, ярар.

Лениза. Башта безгә кофе ясап китер әле.

Хәния. Хәзер.

*Тимур керә. Хафизга шикләнеп карап тора.*

Тимур. Хәерле көн!

Лениза. Сәлам.

Хәния *(кофе китереп)*. Исәнме, Тимур!

Тимур. Исәнме, Хәния апа.

Хәния. Кофе эчәсеңме?

Тимур. Эчәм.

Лениза. Мин Германиягә бармыйм. *(Кофе йотып куя.)*

Тимур. Нишләп?

Лениза. Барасым килми.

Тимур. Күргәзмәңне шундый шәп иттереп оештырдык. Исмәгыйль үзе сине көтә. Немесләрнең сине бик күрәсе килә.

Лениза. Авырып тора, диярсез.

Тимур. Анда синең баруың бик кирәк. Шуннан, бәлки, турыдан-туры Англиягә дә юл тотарбыз. Лондоннан Маккейн көнаралаш шалтыратып тора.

Лениза. Тимур, бармыйм дигәч бармыйм инде. Башка вакытта барырмын әле.

Тимур. Гафу итегез, мин сезне белмим.

Лениза. Таныш бул – Хафиз, әнә теге каршы йортта яши.

Тимур. Ә бу йортта нишли?

Лениза. Миңа свежий балык тотып алып кайткан.

Тимур. Сез күптән танышлармы соң?

Лениза. Балалар бакчасына бергә йөргән идек. Нишләп кофе эчмисез?

Хафиз *(каушап)*. Ни... кайнар.

Хәния *(Тимурга кофе алып килә)*. Лениза, балыкны парда пешеримме?

Лениза. Үзеңә кара. Тозын гына чамалап сип.

Тимур. Рамкаларга заказлар бирергә кирәк, бүген җитешермен микән?

Лениза. Рамкаларны онытмассың син, ә менә стеллажны һаман корып куярга кеше алып килмисең.

Тимур. Иртәгә кичкә таба кеше җибәрермен. *(Стена буендагы такталарга карый.)* Тәк, дрель кирәк булачак. Иртәгә, иртәгә. Хафиз нинди профессия кешесе?

Лениза. Умартачы. *(Хафиз көлеп куя.)*

Тимур. Син, гадәттәгечә, телеңә ни килә, шулай алдыйсың инде.

Лениза. Сиңа нигә аның кем булуы, кайда эшләве?

Тимур. Аның үзенең теле юкмыни?

Лениза. Кергәндә бар иде.

Хафиз. Мин фатирлар ремонтлауда катнашам, агач эшләрен башкарам.

Лениза *(Тимурга текәлеп)*. Алып килдеңме?

Тимур. Әлбәттә. *(Чынаягын өстәлгә куя.)* Һәрвакыт вакытында алып киләм бит. *(Хафизга шикләнеп карый.)*

Хафиз. Ярый, мин китим. Рәхмәт, кофе бик тәмле булды.

Лениза. Хатыныгыз тыныч йокласын. Сау булыгыз.

Хафиз. Сау булыгыз. *(Чыгып китә.)*

Тимур. Кем бу?

Лениза. Горгаздан техобслуживание ясарга килгән. Газ утечкасы юк микән дип тикшерде.

Тимур. Күптән түгел генә тикшергәннәр иде бит.

Лениза. Тагын тикшерергә булганнар.

Т и м у р . Шикле, бик шикле. Зерә чыгарып җибәрдем мин аны. Кем икәнен, ник килгәнен әйттерергә иде.

Л е н и з а . Акчаны доллар белән алып килдеңме?

Т и м у р . Юк, үзебезнең акча белән.

Л е н и з а . Әнә шунда куй. *(Тимур акчаны шкаф тартмасына тыгып куя.)*

Т и м у р *(кухня ягына кычкырып).* Хәния апа! Германиядән сиңа нәрсә алып кайтыйм?

Х ә н и я *(кухнядан кычкырып).* Картайтмый торган дару булмасмы.

### III

*Лениза фатиры. Л е н и з а рәсем ясый. Инструментлар күтәреп Х а ф и з керә.*

Х а ф и з . Исәнмесез.

Л е н и з а . Исәнмесез.

Х а ф и з . Стеллажыгызны корып куярга дип килдем.

Л е н и з а *(гаҗәпләнеп).* Кызык...

*Хафиз стеллажны корырга тотына. Лениза карап утыра.*

Х а ф и з . Тимур кем ул?

Л е н и з а . Чекотилоның оныгы.

Х а ф и з . Кемнең?

Л е н и з а . Чекотилоны ишеткәнең юкмыни? 52 кешене үтергән маньяк.

Х а ф и з . Шаярасыз... Сез бер сорауга да дөресен әйтмисез, ахрысы.

Л е н и з а . Мин сорауларны яратмыйм. Һәрбер сорауда агрессия бар, һәрбер сорау синең территорияңә керүгә тиң.

Х а ф и з . Бер сорауга да җитди җавап бирмисезме?

Л е н и з а . Менә хәзер дә сорау бирәсең.

Х а ф и з . Димәк, фатирыгызда ут сүнмәүнең сәбәбе дә ялган. Картиналарга электр уты кирәк микәнни?..

Л е н и з а *(кырысланып).* Син бүген монда ник килдең?

Х а ф и з *(эшеннән туктап).* Сине күрәсем килде. Ышанмыйсыңмы?

Л е н и з а . Ышанам. Син пыяла кебек – үтә күренмәле.

Х а ф и з . Яхшымы ул, начармы?

Л е н и з а . Синең белән файдаланучылар өчен бик уңай, ә синең үзең өчен киләчәк тормышта комачаулый торган сыйфат.

Х а ф и з . Серле кеше син, Лениза. Сәнгать кешеләренең шундый булганын ишетеп беләм, әмма синең кебек кешене беренче тапкыр күрәм.

Л е н и з а . Һәрбер җан иясендә акыл белән тотып булмый торган сер ята.

Х а ф и з . Матур кеше син.

Л е н и з а . Бәлки, картиналарым фонында шулай күренәмдер.

Х а ф и з . Юк. *(Ленизага текәлеп карап тора.)* Миндә бер сәер теләк туды – синең күзләреңнең тирәнлегенә чумасым килә.

Л е н и з а *(көлемсерәп).* Батып үлүдән курыкмыйсыңмы?

Х а ф и з . Бу упкында батып үләргә дә риза.

Л е н и з а . Бата башлагач, кеше котылыр өчен тотынырга салам сабагы эзли.

Х а ф и з . Нишләп Германиягә барырга теләмисең?

Л е н и з а . Икенче Бөтендөнья сугышыннан калган противопехотная минага басармын дип куркам. Мин бит сиңа әйттем инде: миңа сораулар бирүдән мәгънә юк. Әнә, картиналарымны кара, анда барлык сорауларга җаваплар бар.

Х а ф и з . Картиналарны аңлап җиткерү мөмкин түгел, анда ничек җавап табасың.

Л е н и з а . Сәнгатне аңларга түгел, тоярга кирәк. *(Стенага сөялгән берничә картина арасыннан берсен алып почмакка илтеп куя, өстенә җәймә каплый.)*

Х а ф и з *(картинага ымлап)*. Бу кем сурәте?

Л е н и з а . Хәния апаның улы – Рәкыйп – авариядә һәлак булды.

Х а ф и з . Хәния апа синең туганыңмы?

Л е н и з а *(ачулы тавыш белән)*. Эшең өчен күпме түлим?

Х а ф и з . Кирәкми. Шуның өчен монда тагын керергә рөхсәт ит. Бәлки, тагын берәр эш эшләргә кирәк булыр, теләсә кайсы вакытта чакыр. Телефон номерыңны миңа бирмисеңме?

Л е н и з а . Бирмим.

Х а ф и з *(кесәсеннән кәгазь белән каләм алып)*. Алай-болай кирәгем чыкса, шалтыратыгыз. *(Телефон номерын язып өстәлгә куя.)*

*З ә р и м ә керә.*

З ә р и м ә *(елмаеп)*. Хәерле көн.

Л е н и з а . Исәнме, Зәримә.

З ә р и м ә . Тимур монда түгелмени? Ул бит стеллажыңны корырга җыенган иде, эшчеләрем заняты, үзем корам, дигән иде.

Х а ф и з . Менә, Хафиз корып бирде инде.

З ә р и м ә . Хафиз безгә кем була инде?

Л е н и з а . Күрше йортта яши.

З ә р и м ә . Бик якын кеше икән. *(Көләләр.)*

Л е н и з а *(стеллажга карап)*. Рәхмәт сиңа, Хафиз. Оста куллы кеше икәнсең.

Х а ф и з . Ярый, сау булып торыгыз. *(Чыгып китә.)*

З ә р и м ә *(сумкасыннан дарулар алып)*. Менә бу даруны йоклар алдыннан эчәрсең. Боларын беләсең инде, күптән кабул итәсең. Баш авыртуың беттеме инде?

Л е н и з а . Баш авыртмый, кулаяклар торымнан-торымга сызлый.

З ә р и м ә . Үтәчәк анысы да. Менә бу препаратны кабул ит.

Л е н и з а . Рәхмәт.

З ә р и м ә . Иң авыр чорың үтте инде. Организм нык булып чыкты синең. Кан басымың нормада.

Л е н и з а . Шунысы сәер: элекке халәтемә никтер кайтасым килми. Туганда ук авария аша туганмындыр шикелле.

З ә р и м ә . Димәк, бүгенге көнеңнән канәгатьсең.

## IV

*Ф и л ү с ә фатирда әйберләр, җиһазлар урнаштыру белән мәшгуль. Форточканы ачкач, тәрәзәдән карап тора. Күңеле шөбһәләнә, әкрен генә барып диванга утыра. Х а ф и з керә.*

Х а ф и з . Син кайттыңмыни инде?

Ф и л ү с ә . Иртәрәк җибәрегез дип сорадым. Кайчан урнаштырып бетерәбез инде әйберләрне?

Х а ф и з . Әкренләп урнаштырырбыз әле.

Ф и л ү с ә . Шифоньерны корып бир тизрәк. Ичмаса кием-салымны элеп куярмын. *(Тәрәзәдән карый.)* Яп-якты көн, теге фатирда барыбер ут яна.

Х а ф и з . Ник аптырыйсың инде аңа? *(Тәрәзәдән карап тора.)*

Ф и л ү с ә . Бүген теге заказ буенча бардыңмы соң?

Х а ф и з . Нинди заказ буенча?

Ф и л ү с ә . Рейкалар кадакларга барам, дигән идең.

Х а ф и з . Иртәгәгә сөйләштек.

Ф и л ү с ә . Бүген менә бу каршы йортта эшләдеңме әллә?

Х а ф и з . Ник алай сорыйсың?

Ф и л ү с ә . Син бит хәзер шул йортның ишегалдыннан чыктың – тәрәзәдән күрдем.

Х а ф и з *(кәефсезләнеп)*. Әйе, каршы йортта булдым. Стенага стеллажлар беркетергә чакырдылар.

Ф и л ү с ә . Нәрсә булды сиңа?

Х а ф и з . Әллә тагы.

Ф и л ү с ә . Син Казанга ияләшә алмый җәфаланасың инде.

Х а ф и з . Чаллыда иркенрәк иде шул. Казанның ыгы-зыгысы сиңа табигый, ә мин – провинция кешесе.

Ф и л ү с ә . Анда, атаң-анаң янында, сиңа кулайрак, шуңа кире кайтасың киләдер. Әйдә, рәткә китерик инде фатирны.

Х а ф и з *(кискен итеп)*. Филүсә, ашыктырма! Гел куалап, этеп, төртеп торасың! Алай кирәкми!

Ф и л ү с ә . Ичмаса машинабыз да юк. Тегендә-монда кирәк-яракка йөрергә. Кешеләрдән оят.

Х а ф и з . Булыр әле барысы да. Мин бит әллә ничәгә ярыла алмыйм.

Ф и л ү с ә *(Хафизны арттан кочаклап)*. Мин кайчан бәбигә узармын икән?..

Х а ф и з . Белмим.

Ф и л ү с ә . Стеллаж өчен күпме түләделәр?

Х а ф и з . Анда тагын эш бар әле. Соңрак барысын бергә түләячәкләр.

Ф и л ү с ә . Күпме?

Х а ф и з . Белмим.

Ф и л ү с ә . Син гел шулай. *(Тәрәзә янына бара.)* Теге фатирда һаман ут яна.

Х а ф и з . Мин ул фатирга кереп чыктым. Син гел игътибар иткәч, кызыксынырга булдым.

Ф и л ү с ә *(сагаеп)*. Йә, нәрсә анда?.. Кемнәр яши?

Х а ф и з . Бернинди криминал-мазар юк. Ул фатирда рәссам кыз яши. Өч бүлмәле фатиры бер зур остаханәгә әйләнгән.

Ф и л ү с ә . Үзе генә яшиме?

Х а ф и з . Үзе генә.

Ф и л ү с ә . Утын ник сүндерми?

Х а ф и з . Картиналарга шулай кирәк.

Ф и л ү с ә . Нәрсә дип кердең соң син анда? Нишләп утыгыз сүнми, дип сорадыңмы?

Х а ф и з . Әйе. Филүсә, артык күп сораулар белән бимазалыйсың.

Ф и л ү с ә *(якын килеп)*. Нишләдең син бу көннәрдә? Мондый түгел идең син.

Х а ф и з . Кеше үзгәрә инде ул. Һәр кеше гел бер шаблоннар буенча яшәргә тиеш дип уйлыйсың син. Дөньяны бер төсләрдә генә күрәсең бугай.

Ф и л ү с ә *(корыланып)*. Әллә рәссам кыз янына кергәч, башка төсләр абайладыңмы?

Х а ф и з . Анда чынлап та башкалар күрмәгән төсләр күп. Сәнгать – сәнгать инде ул. Чынбарлык белән янәшә башка төрле, яңа дөнья тудыручы кеше бәхетле буладыр.

Ф и л ү с ә . Нинди яңа дөнья тудыра алалар соң алар?

Х а ф и з . Бу дөньяга караганда кешелеклерәк, игелеклерәк.

Ф и л ү с ә . Сәнгатьне тормышта үзенә урын таба алмаучылар ярата. *(Әйберләр урнаштырырга тотына.)*

## V

*Лениза фатиры. Т и м у р , аз-аз кабып, виски эчеп утыра. Ишек кыңгыравы зеңгелди. Тимур ишекне ача, бусагада Хафиз пәйда була.*

Х а ф и з . Хәерле көн.

Т и м у р . Хәерле көн.

Х а ф и з . Мин отвёрткамны онытып калдырганмын.

Т и м у р . Уз әйдә.

Х а ф и з *(түргә узып)*. Ленизa өйдә түгелмени?

Т и м у р . Хәния апага күзлек алырга киттеләр.

Х а ф и з *(идәннән отвёртканы алып)*. Менә ул.

Т и м у р . Стеллажны оста корып куйгансың. Виски эчәсеңме?

Х а ф и з . Бераз мөмкин. *(От-*

*вёртканы курткасының түш кесәсенә тыгып куя.)*

Т и м у р *(виски салып)*. Утыр. *(Эчәләр.)*

Х а ф и з . Хәния апа Ленизаның кеме ул?

Т и м у р . Кеме дип әйтим. Өен җыештыручы, ашарына пешерүче.

Х а ф и з . Улы авариядә һәлак булган икән.

Т и м у р . Әйе, Рәкыйп харап булды. Ленизаның егете иде ул. Лениза исән калды, ә Рәкыйп... Шулай язгандыр инде... *(Стаканнарга виски сала.)*

Х а ф и з *(як-ягына карап)*. Монда кергәч, мин башка дөньяга эләккән кебек булам.

Т и м у р . Сиңа ничә яшь?

Х а ф и з . Бер айдан егерме биш тула.

Т и м у р . Хатыныңа?

Х а ф и з . Апрельдә егерме өч тулды.

Т и м у р . Һи, бигрәк яшьләр әле сез. Балагыз бармы соң әле?

Х а ф и з . Әлегә юк. Тырышабыз, кем әйтмешли.

Т и м у р . Булыр, булыр. Күптән өйләнештегезме соң?

Х а ф и з . Ел ярым булды инде. Башта Чаллыда яшәдек, минем әтиәни белән... Хатыным Казан кызы, монда килергә күндерде. Әтиәниләре дә монда... *(Авыр сулап куя.)* Авыр... Казан тормышына күнегә алмыйм. Акча юк... Филүсә белән дә мөнәсәбәтләр әллә нинди. Өйләнешкәнче әйбәт иде... Тормышның мәгънәсе нәрсәдә икәнне аңламыйм.

Т и м у р . Ничего, балагыз тугач, мәгънәсе табылыр. *(Виски йотып куя.)* Хезмәт хакы күпме аласың?

Х а ф и з . Аз чыга инде. Айга егерме мең тирәсе.

Т и м у р . Минем сиңа бер тәкъдимем бар. Миңа эшкә кер.

Х а ф и з . Нинди эшкә, кем булып?

Т и м у р . Ленизаның картиналарына рамкалар ясаучы кирәк. Син булдыра ала торган эш дип уйлыйм.

Х а ф и з *(җанланып)*. Чын әйтәсезме? Бик шатланып керәм!

Т и м у р . Дөрес, рамкалар ясау эшеңнең бер өлеше генә булачак. Минем фирмада грузчик эше күбрәк. Тегендә-монда әйбер ташырга да кирәк булачак.

Х а ф и з . Риза мин, риза. Тик... Лениза нәрсә әйтер бит.

Т и м у р . Лениза үзе синең белән сөйләшергә кушты. Синең телефоныңны бирде, бүген кичкә таба сиңа шалтыратырга җыенган идем.

Х а ф и з . Чынлапмы?!

Т и м у р . Нишләп хезмәт хакы күпме булыр дип сорамыйсың?..

Х а ф и з *(канатланып)*. Күпме булса да риза мин! Мондый картиналарга рамкалар ясау үзе бәхет бит әле ул...

Т и м у р . Маладис икәнсең. *(Елмая.)* Утыз мең кулга алачаксың.

Х а ф и з . Рәхмәт.

Т и м у р . Безнең мастерской шәһәр читендә. Рамкаларны үз фатирыңда да ясый аласың инде, анда барып йөргәнче. Ә башка эшләрне башкарырга алдан хәбәр итә торган булырмын.

Х а ф и з . Фатирымда әле әйберләр, җиһазлар урнаштырылмаган. Берничә көн вакыт кирәк.

Т и м у р . Ярар. *(Картиналарга ишарәләп.)* Боларына, Лениза рөхсәт итсә, монда ясый торырсың.

Х а ф и з *(шатлыктан сикереп тора)*. Рәхмәт! *(Утырып, стакандагы вискины эчеп бетерә.)*

*Сәхнә караңгылана. Сәхнә яктырганда, Х а ф и з рамкалар ясый. Х ә н и я коелган чүпне соскыга җыеп йөри.*

Х ә н и я . Ленизага рәхмәт яусын инде. Ул булмаса нишләр идем. Үз анасы кебек күрә мине.

Х а ф и з . Әти-әнисе кайда соң аның?

Х ә н и я . Аның әтисе җилле кеше, аерылып башка хатынга өйләнде дә, Сочида яшәп яталар. Әнисе, Мәскәүдәге банк хезмәткәренә чыгып, башкалага китте. Лениза берсе белән дә аралашмый.

Х а ф и з . Ленизаа нишләп кияүгә чыкмый?

Х ә н и я . Чыгар әле. *(Кәефе кырыла.)* Улым Рәкыйп белән өйләнешергә җыеналар иде алар. Менә бит нәрсә килеп чыкты.

Х а ф и з . Гафу ит, Хәния апа, мин белмәдем.

Х ә н и я *(авыр сулап)*. Алар бит икесе бергә эләктеләр авариягә. Ленизаа реанимацияләрдә ятты, исән калды, улым исән калырлык түгел иде шул. Ленизаа миңа үз кызым шикелле. Минем бүтән беркемем дә юк. Ирем илле ике яшендә вафат булды, бердәнбер улымнан да мәхрүм калдым. Син эшлә, эшлә. *(Пауза.)*

*Л е н и з а кайтып керә.*

Л е н и з а . Эш барамы?

Х а ф и з . Бара.

Х ә н и я . Курчак кебек булгансың, кызым.

Х а ф и з . Парикмахерым шәп минем.

Х ә н и я . Нәрсә пешерим?

Л е н и з а . Әлегә чәй куй әле.

Х ә н и я *(кызны аркасыннан сөеп)*. Рәхмәт сиңа бүләкләрең өчен, балакаем.

Л е н и з а . Туган көнеңә шундый бүләкләр дә алмаммыни инде?!

Х ә н и я . Инде миңа тоткан расходларың...

Л е н и з а . Әй ярар инде, Хәния апа. Чит кеше сыман сөйләшмә. *(Хәния китә.)* Хәния апа юкка да куана – бәхетле кеше!

Х а ф и з . Мин дә үземне бәхетле кеше дип саный башладым.

Л е н и з а . Нәрсә, хатының балага уздымы әллә?

Х а ф и з . Юк. Сезгә эшкә урнашуым бәхет түгелмени...

Л е н и з а . Бик куанма әле – Тимур каты җитәкче. Беләсең килсә, Тимур минем дә нәчәлнигем. Ул сине каты җигәчәк әле – әзер тор. Авыр булса, китәрсең.

Х а ф и з . Юк. Ленизаа, китмим. *(Текәлеп карап тора.)* Мин һаман ышанып җитә алмыйм әле.

Л е н и з а . Йә, йә, син дә Хәния апа кебек юк кына нәрсәгә дә куанасың икән. *(Елмая.)* Син ясаган рамкалар миңа ошый. Тимур да мактый.

Х а ф и з . Һи, рамка нәрсә ул. Менә син ясаган картиналар чыннан да искиткеч.

Л е н и з а . Бер акыл иясе: «Картинаның мәгънәсе аның рамкасында», – дигән.

Х а ф и з . Шаярып әйткәндер ул.

Л е н и з а . Сәнгать ул – һәрвакыт чикләнү, дип әйтергә теләгән ул. Чиге булган нәрсә генә матурлыкка ия. Чикләнгән формасы булмаса, бернәрсә дә матурлыкка ия булалмый. Чикле форманы карап сокланырга исә дистанция кирәк. Күзеңә төртелеп торган нәрсәнең дә гүзәллеген абайлау мөмкин түгел.

Х а ф и з *(ихластан сокланып)*. Бер гүзәл кызга шулкадәр күп байлык бирелгән – сәләт, акыл, чибәрлек...

Л е н и з а *(көлемсерәп)*. Күз тигезәсең инде.

Х а ф и з . Минем күзем каты түгел. Ниһаять, мин тормышымда яктылык күрдем.

Л е н и з а . Кайтып, хатыныңа шулай дип әйтә күрмә.

Х а ф и з . Өйләнешер алдыннан без озак очрашып йөрдек, яшәдек... Шуңадыр, никахлашкач, араларыбыз җылы түгелдер. Аның гел мине тарткалап-эткәләп торуы да шуннан.

Л е н и з а . Яратмыйсың син хатыныңны. Күзләреңнән күренә.

Х а ф и з *(картиналарга күз салып)*. Синең һәрбер картинаңда сер бар, аларны карап туймаслык. Ләкин мин аларда миллилек күрмим. Син

бит татар кызы. Милли сәнгатьне үстерү турында да уйларга кирәк, минемчә. Бу сүзем өчен гафу ит.

Л е н и з а . Төне буе тешең сызласа, милләт кирәк түгел, стоматолог кирәк. Кая гына барсам да, татар телендә сүз катсам, мине беркем дә аңламый. Кешегә ярдәме тимәсә, ул телнең ник кирәге бар.

Х а ф и з *(шаккатып)*. Синнән мондый сүз ишетү сәер. Туган тел турында алай әйтергә ярамый. Изге төшенчә ул.

Л е н и з а . Изге төшенчәләр кешегә өмет бирә. Ә синең туган телең нинди өмет бирә?

Х ә н и я *(сүзгә кушылып)*. Мин дә гел әйтәм инде аңа. Татар аһәңе аңкыган сурәтләр дә яса инде, мәйтәм. Бальзак әйтмешли, сәнгать – милләт киеме.

Л е н и з а . Син дә, Хәния апа, кайвакыт артык акыллыланып китәсең. Шәрә тән матуррак булырга мөмкин. Гомумән, кием алдый бит ул...

Х ә н и я . Менә сөйләш син моның белән. Ленизаның фикерен үзгәртү мөмкин түгел. Әйдәгез, чәй әзер.

Л е н и з а . Хәния апа, син ял ит инде, бер тик тормыйсың, гел аяк өсте.

Х ә н и я . Арырлык әллә ни кырмадым мин. Кибеткә барып кайтыйм әле, көнбагыш мае бетеп килә. *(Чыгып китә.)*

Л е н и з а . Син минем фикерләрдән куырылып киттең шикелле.

Х а ф и з . Юк, син нинди генә фикер әйтсәң дә, минем өчен кадерле, әһәмиятле. Син иң куркыныч сүзләрне әйтсәң дә, гүзәллегең беркая китмәс. Синең һәр фикерең белән килешергә кирәктер, мөгаен. Чөнки гади кешеләр күрмәгәнне күрәсең, башкалар аңламаганны аңлыйсың. Гомумән, дөньяның асылын аңлыйсыңдыр син.

Л е н и з а . Нииндидер сәләтең булу әле ул күп нәрсәне аңлау түгел. Гап-гади сорауларга җавап табылмый. Менә берәр кешенең портретын ясасаң, шул кадәр охшаган, дип таң калалар. Ә ул кешенең үзе белән сокланучы юк. Сурәтнең оригиналга охшаганлыгын яраталар, ә ул кешенең үзен күралмаулары ихтимал. Картинадагы агачка сокланып карыйлар, ә урамда үсеп утырган оригиналга беркемнең исе китми. Сәер бит. Нишләп алай?..

Х а ф и з . Тагын шуңа игътибар иттем: синең картиналар чынбарлыктан ерак. Алар тетрәндерә, ләкин тормышчанлык белән түгел, нииндидер башка төрле тылсым белән.

Л е н и з а . Чынбарлыкка якынайган, тормышчан сәнгать үлемгә дучар. Моны күптән аңлаганнар инде. Чәй эчәсеңме?

Х а ф и з . Юк, рәхмәт.

Л е н и з а . Алайса, син бар, кайт инде. Мин эшләп алам.

Х а ф и з *(боегып)*. Өйгә кайтасым килми.

Л е н и з а . Кайтырга кирәк. Кайвакыт яшисе дә килми, ә бит яшәргә кирәк. Хатының белән аерылышыгыз. Мәхәббәт сүнгәч, киләчәккә ничек юл тотмак кирәк. Гомерләр алда бит әле.

Х а ф и з . Фатир өчен ике миллионны аның әтисе бирде.

Л е н и з а *(шкаф тартмасыннан ике миллион акча алып)*. Мә сиңа ике миллион.

Х а ф и з *(гаҗәпләнеп торганнан соң, акчаны алып)*. Акчаны алып торам, әмма әле аерылырга ашыкмыйм.

Л е н и з а . Үзеңә кара. *(Эшкә тотына. Хафиз чыгып китә.)*

## VI

*Хафизлар фатиры. Х а ф и з картиналар өчен урын әзерли. Ф и л ү с ә карап утыра.*

Ф и л ү с ә *(зарланып)*. Өйгә берничә сәгать йокларга гына кайтып йөрдең кайчаннан бирле. Ә хәзер инде монда столярная мастерская ясыйсыңмы?

Х а ф и з . Мин бит көн саен аның фатирында булмадым. Бер офистан икенчесенә әйберләр ташыдык, маляр буларак та эшләргә туры килде. Күрәсеңме, куллардагы буяуны һаман юып бетереп булмый. Өйдә эшләү җайлырак.

*Шул вакытны фатирга Т и м у р җитәкчелегендә эшчеләр картиналар һәм инструментлар ташый башлыйлар. Ф и л ү с ә елар дәрәҗәгә җитеп утыра. Бераздан Л е н и з а керә.*

Л е н и з а . Исәнмесез. *(Фатир эченә күз сала.)* Урын җитәрлек икән монда.

Т и м у р . Хафиз, әйдә синең белән теге картинаны алып керик әле. *(Тимур белән Хафиз чыгып китәләр.)*

Ф и л ү с ә *(торып)*. Сезмени инде рәссам?

Л е н и з а *(коры гына)*. Син ничәнче мәктәптә укыдың?

Ф и л ү с ә *(аптырап)*. Сезгә нигә минем кайсы мәктәптә укуым?

Л е н и з а . Ә сиңа нигә минем кем булуым?

Ф и л ү с ә *(еламсырап)*. Болай да тормышыбызны рәтли алмый идек, шушы гына җитмәгәние.

Л е н и з а . Нишләп аның белән яшисең соң син?

Ф и л ү с ә . Нишлик соң?

Л е н и з а . Аерылыгыз.

Ф и л ү с ә . Сез бик җиңел, битараф карыйсыз ахрысы тормышка.

Л е н и з а . Бергә яшәү читен булгач, аерым-аерым яшәү хет ничек карасаң да яхшырактыр, минемчә.

*Т и м у р белән Х а ф и з зур картина күтәреп керәләр.*

Т и м у р *(як-ягына каранып)*. Инструментларың җитәрлек синең. Нәрсә кирәк – шундук шалтырат.

Х а ф и з . Ярар.

Т и м у р . Киттек. *(Тимур, Лениза, эшчеләр чыгып китәләр.)*

Ф и л ү с ә *(әкрен генә фатирда хасил булган картиналарны карап йөри).* Шомлы картиналар... Һәрберсеннән кемдер карап тора кебек... Куркам мин... *(Кинәт Хафизга борыла.)* Хәзер фатирыбызда тәүлек әйләнә ут янып торачакмы?

Х а ф и з . Әйе.

Ф и л ү с ә . Ут өчен кем түли?

Х а ф и з . Паровоз алдыннан чапма инде. Квитанция килмәде бит әле.

Ф и л ү с ә . Бәлки, син миннән туйгансыңдыр? Шуңа бу эшкә кереп, монда остаханә ясарга уйлыйсыңдыр?..

Х а ф и з *(җикереп)*. Филүсә! Җитте! Синең үзеңнән башланды бу вакыйга. Үзең каршы йорттагы утка эчең пошты, куркам, диденң. Син кыбырсымасаң, мин анда кермәгән булыр идем, анда кем яшәгәнен белмәс идем.

Ф и л ү с ә . Тормышыбызны корып җибәрәсе урынга, сәер эшкә тотынасыңмы?

Х а ф и з . Сиңа барыбер түгелмени – кайда ничек акча эшләвем?! Өйләнешкәннән бирле һәр көнең мине битәрләү белән башлана һәм мине ачулану белән тәмамлана.

Ф и л ү с ә . Өйләнәсең калмаганмы әллә?

Х а ф и з . Гел үз киреңне генә сукалама инде. Чаллыдан монда синең сүзне тыңлап күчтем, синең көйгә генә бием бит инде. Тагын ни җитми?

Ф и л ү с ә . Минем көйгә биеп, нәрсә кырдың соң әле син?

Х а ф и з *(кул селтәп)*. Булды, җитте, туйдым!

Ф и л ү с ә *(усал елмаеп)*. Миннәнме?

Х а ф и з . Филүсә!

Ф и л ү с ә . Ярый, мин әниләргә кайтып китәм. Фатирны нишләтәбез, бүләбезме?

Х а ф и з . Фатир миңа калсын. Менә сиңа ике миллион акча, әтиеңә тапшыр. *(Кесәсеннән ике миллион сум алып Филүсәгә суза.)* Расчёт.

Ф и л ү с ә *(акчаны аып).* Каян алдың бу кадәре акча?

Х а ф и з . Мин хәзер акчалы эштә эшлим. *(Филүсә чыгып китә.)*

*Т и м у р керә.*

Т и м у р . Телефонымны онытып калдырганмын. *(Өстәлдән телефонын ала.)* Нишләп сөмсерең коелган?

Хафиз. Фатирымда гел ут янып торырга тиешме?

Тимур . Ник?

Х а ф и з . Картиналарга тәүлек әйләнә электр уты кирәктер бит.

Т и м у р . Юк, картиналарга ут кирәкми.

Х а ф и з . Нишләп Лениза утын бер дә сүндерми соң?

Т и м у р . Алар егете белән авариягә эләктеләр. Егете һәлак булды, Лениза исән калды. Алар шул фатирдан чыгып киткәндә, утны сүндерергә оныткан булганнар. Моны Лениза инде бүлнистән чыгып кайткач күрә. Шуннан соң утны беркайчан да сүндерми. *(Чыгып китә.)*

**VII**

*Лениза фатиры. Л е н и з а рәсем ясый. Ишек кыңгыравы зеңгелде. Х ә н и я ишекне ача. Ф и л ү с ә керә.*

Ф и л ү с ә . Исәнмесез.

Х ә н и я . Исәнмесез.

Ф и л ү с ә . Мин Хафизның хатыны Филүсә булам. Рәссам кызны күрергә мөмкинме?

Л е н и з а *(эшеннән туктап).* Тыңлыйм сине.

Ф и л ү с ә . Хафизга син акча бирдеңме?

Л е н и з а . Тагын сорауларың бармы?

Ф и л ү с ә . Бар.

Л е н и з а . Син аларны бер кәгазьгә язып Тимурга тапшыр. Мин аларны берәр атнадан укырмын.

Ф и л ү с ә *(чәнчүле тавыш белән).* Синдә рәссамлык таланты гына түгел, кеше гаиләсен бозу осталыгы да бар икән.

Л е н и з а . Бер мин генә акылга зәгыйфь түгел икән. *(Кычкырып көлә.)*

Х ә н и я *(Филүсәгә карап).* Нәрсә булды, балам?

Л е н и з а . Фаҗига.

Х ә н и я . Нинди фаҗига?

Л е н и з а *(усалланып).* Мин Хафиздан балага уздым.

Х ә н и я *(ике кулын селтәп).* Юри әйтә, кызым, юри әйтә. Лениза! Ташла инде мондый шаяруларыңны. Татулашырсыз Хафиз белән, балакаем, татулашырсыз. Аралар бозылу була инде ул, тормыш бу, әллә ниләр килеп чыга, татулашырсыз.

Л е н и з а . Аның фаҗигасе – балага уза алмауда.

Ф и л ү с ә *(калтыранып).* Син... *(Сүзен әйтә алмый, елый башлый һәм тиз генә чыгып китә.)*

Х ә н и я . Лениза! Кайчан телеңне тыя башлыйсың инде?

Л е н и з а . Хәния апа, юри әйтә, дисең... Бәлки, мин чынлап та шул сәләмәдән балага узганмындыр.

Х ә н и я . Юкны сөйләмә. Аннары, нишләп сәләмә булсын ул. Менә дигән егет! Мин кирәк түгелме инде бүген?

Л е н и з а . Бар, кайт, Хәния апа. *(Хәния чыгып китә.)*

*З ә р и м ә керә.*

З ә р и м ә . Сәлам.

Л е н и з а . Сәлам, Зәримә. Ярый килдең әле. Бүген эшлисем килми. Рәхәтләнеп сөйләшеп утырыр бердәнбер кешем син.

З ә р и м ә . Алай диюең күңелемә бик хуш. Бүген ничек йокладың?

Л е н и з а . Рәхәтләнеп җиде сәгать йокладым.

З ә р и м ә . Әйбәт булган. Шундый шәп шәраб алып килдем.

Л е н и з а . Тимур чит илдән шәраб ташый инде ул.

З ә р и м ә . Үзе дә бик ярата бит.

Л е н и з а . Ирдән уңгансың, Зәримә, нык уңгансың.

З ә р и м ә . Аллага шөкер. Әни, бизнесменга чыкма, син бит абруйлы табибә, дип теңкәмә тигән иде, хәзер сөенеп туя алмый. Онытканчы бирим әле. Менә бу даруны аз гына депрессия башланса да эчәрсең. *(Өстәлгә бер кап дару куя. Аннары бер шешә шәраб чыгара.)*

Л е н и з а *(бокаллар алып килеп)*. Син булмасаң, беткән идем мин, Зәримә.

З ә р и м ә . Ярар инде, гел бер сүзне кабатлама. Менә художник булып китүең – могҗиза ичмаса.

Л е н и з а . Мин кайвакыт уйга калам – авариягә кадәр дә дөрес яшәмәдем, хәзер дә барыбер дөрес юлда түгелмен шикелле. Әллә гел фальш белән, алдалап яшәгәнгә шулаймы... Художникка әверелүем дә әллә ялганнарга җайлырак булсын өчен микән? Художник – ялганчы бит ул.

З ә р и м ә . Художник үзе ялганчы булса да, сәнгать дөрес нәрсә, хакыйкатькә күзне ачарга ярдәм итә.

*Ишек кыңгыравы зеңгелде.*

З ә р и м ә . Тимур килгәндер. *(Барып ишекне ача.)*

*Х а ф и з керә. Кыяфәте киеренке. Дәшмичә басып тора.*

Л е н и з а . Проблемаң бармы әллә?

Х а ф и з *(Ленизага)*. Үзең генә түгел икән.

Л е н и з а . Хафиз, безгә шешәне ачып бир әле. *(Хафиз шәраб шешәсен ачып бирә.)* Шәраб эчәсеңме?

Х а ф и з . Юк.

Л е н и з а . Алайса бар, безгә йомырка кыздырып китер. *(Икеләнеп торганнан соң, Хафиз кухняга китә.)*

З ә р и м ә *(бокалларга шәраб салып)*. Кызык кеше. Кем генә юк дөньяда. Әйдә, синең сәламәтлегең өчен. Әй, юк, сәламәтлек өчен эчәргә ярамый, синең талантың өчен. *(Эчәләр.)*

*Хафиз ике тәлинкә белән кыздырылган йомырка алып килә.*

Л е н и з а . Хафиз, синең вакытың тыгыз түгелме?

Х а ф и з . Юк. Синең белән сөйләшергә кирәк иде.

Л е н и з а . Аннары сөйләшербез. Хәзер бар, зинһар, кибеткә чыгып кер. Бер банка куертылган сөт ал. *(Хафиз ишеккә таба юнәлә.)* Акчаң бармы?

Х а ф и з . Бар. *(Чыгып китә.)*

З ә р и м ә . Сиңа язмыш елмайды, шуны акылың белән аңларга тиешсең.

Л е н и з а . Үзем генә беләм иҗатымның нәрсә икәнен. Мин фәкать белмәгән нәрсәләрне әйтергә батырчылык итәм иҗатым белән. Картиналарымны караучылар мин әйтергә теләгәнне түгел, үзләре теләгәнне күрәләр.

З ә р и м ә . Бик әйбәт, бик хуп.

Л е н и з а . Иҗаттан туйгач нишләрмен?

З ә р и м ә . Тагын тотынасыңмы? Юк белән башыңны катырма. Иртәгә ни буласы да Алла кулында. Рәссам булып китәсеңне төшеңдә дә күргәнең булмагандыр бит.

Л е н и з а . Анысы шулай.

*Х а ф и з бер банка сөт тотып керә.*

З ә р и м ә . Ярый, сөйләшегез. Мин киттем. Тимур кайтуына ашарга әзерлисе бар. *(Ленизаны битеннән үбеп чыгып китә.)*

Л е н и з а . Нәрсә, балтаң суга төшкән кыяфәттә басып торасың?

Х а ф и з . Син мине Зәримә алдында кимсетергә теләдең, ахрысы.

Л е н и з а . Сине кимсетүдән миңа ни файда? Безнең әңгәмә барыбер сиңа кызык булмас иде.

Х а ф и з . Син шундый гүзәл зат... Шул ук вакытта синдә тагын бер усал нәрсә утыра шикелле.

Л е н и з а . Мине җентекләп күзәтү сиңа нигә?

Х а ф и з . Мин сиңа гашыйк булдым.

Л е н и з а . О-о-о, харап икән эшләр. Шәраб эчәсеңме?

Х а ф и з . Эчәм. *(Утыра.)* Филүсәгә алай димәскә идең.

Л е н и з а . Нәрсә димәскә идем?

Х а ф и з . Миннән балага уздым, дигәнсең.

Л е н и з а . Тизрәк синнән китсен өчен. *(Бокалларга шәраб сала.)*

Х а ф и з *(җанланып)*. Димәк, синең дә миңа хисләрең бар?

Л е н и з а . Фәкать кызгану хисе генә. *(Шәраб йотып куялар.)*

Х а ф и з *(пауза алып)*. Өемә кайтасым килми. *(Кыюсыз гына.)* Синең белән калырга рөхсәт ит.

Л е н и з а . Ярамый.

Х а ф и з . Эшеңә комачауламам. Берәр эш куш миңа.

Л е н и з а . Бернинди эш тә юк. Бүген үзем дә ял итәм.

Х а ф и з . Мин гел сине уйлап йөрим. Кем әйтмешли, ятсам да, торсам да син күз алдымда.

Л е н и з а *(торып)*. Мин бит гарип. Минем бер аягым протез. *(Чалбар балагын күтәреп күрсәтә.)* Күрәсеңме, тезгә чаклы диярлек үз аягым түгел. Чиркандырмыймы, куркытмыймы?

Х а ф и з *(шаккатып, әмма үзен кулга алып)*. Юк, куркытмый.

Л е н и з а . Авариядән соң реанимациядә аңыма килгәндә, аягым юк иде инде. *(Урынына утыра.)*

Х а ф и з *(кызның кулын үбеп)*. Ярый әле рәссамлык талантыңны югалтмагансың.

Л е н и з а . Ә мин авариядән соң ясый башладым. Аңарчы чәчәк тә ясаганым юк иде. Уртак палатага күчкәч, кинәт рәсем ясыйсым килә башлады. Зәримә – баш врачның урынбасары – күреп шаккатты, ире Тимурга әйткән, Тимур минем промоуторыма әйләнде. Шулай итеп, рәссам булып киттем. Зәримә физик яктан аякка бастырды, ә Тимур дөньяга рәссам итеп танытты.

Х а ф и з *(кинәт җанланып)*. Лениза, буем җитмәгән үргә сузыламдыр, бәлки... Мин яратам сине! Калыйм инде бүген синең белән.

Л е н и з а *(салкын елмаеп)*. Кал.

*Музыка.*

**VIII**

*Х а ф и з үз фатирында хәлсезләнеп утыра. Х ә н и я керә – буяу банкалары салынган кәгазь кап күтәргән.*

Х ә н и я . Буяулар алып килдем. *(Буяуларны киштәгә куя.)* Хафиз, ничә көн инде боегып утырасың, башыңны калкыт инде.

Х а ф и з . Хәния апа, мин Ленизаны сагынам. Атна буе тегендә-монда эшләттеләр. Атна буе минем аны күргәнем юк.

Х ә н и я . Хафиз улым, акылыңа кил. Нык гашыйк булу ярамый. Хатының белән татулаш.

Х а ф и з . Мин Ленизадан башка яши алмыйм.

Х ә н и я . Син минем мәрхүм улым шикелле... Лениза белән харап булмагаең.

Х а ф и з . Ник алай дисең?

Х ә н и я . Күрмисеңмени аның холкын. Гомумән, ул бу дөнья кешесе түгел.

Х а ф и з . Бәлки, минем дә бу дөньяныкы буласым килмидер.

Х ә н и я . Кемдер тилергән дип, аның артыннан акылдан язмыйлар инде. *(Чыгып китә.)*

*Лениза белән Зәримә көлешә-көлешә керәләр.*

Зәримә. Мөмкинме?

Лениза. Әйдә, әйдә, уз, Зәримә, ник сорап торасың? Эшләр барамы, Хафиз?

Хафиз *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Бара.

Лениза. Акрын барганга охшаган. *(Түрдәге картинага күрсәтә.)* Зәримә, менә ул картина. Кара.

Зәримә. Искиткеч. Рәхмәт, Лениза. Тимурга әйтермен. *(Чыгып китә башлыйлар.)*

Хафиз. Лениза, тукта әле.

Лениза. Зәримә, син чыга тор. *(Зәримә чыгып китә.)* Тыңлыйм.

Хафиз *(торып)*. Лениза! Син минем белән бер минутка да калмыйча чыгып китмәкче идеңме?

Лениза. Безнең бүген барасы җирләр күп.

Хафиз *(ачынып)*. Мин сагындым сине.

Лениза *(көлемсерәп)*. Шул арадамы?

Хафиз. Без хәзер чит-ят кешеләр түгел бит инде.

Лениза. Нишләп шундый нәтиҗәгә килдең?

Хафиз. Теге төннән соң без синең белән якын кешеләр түгелмени?

Лениза. Юк, Хафиз, дистанция барыбер калды. Минем бер якын кешем дә юк. Синең хатының дөрес чамалаган – минем бердәнберем карап тора һәрбер картинамнан. Ни генә ясасам да, һәр сурәттә үзем генә күрерлек итеп мин аның күз карашын ясыйм. Башкалар аны күрми.

Хафиз. Мин яратам сине! Синең бәгырең салкынайган. Аны җылытасы гына бар.

Лениза. Берүк җылыту вазифасын үзеңә бурыч итеп ала күрмә.

Хафиз. Мин яратам сине!

Лениза *(битараф)*. Аңладым. *(Чыгып китә.)*

*Хафиз кайгыга бата. Филүсә керә.*

Филүсә *(фатир буйлап йөри)*. Ничек хәлләр?

Хафиз *(һушына килеп)*. Ярый килдең әле.

Филүсә *(чәнчүле итеп)*. Сагындың мәллә?

Хафиз. Сагындым.

Филүсә. Мин разводка бирдем. Шушы көннәрдә эти белән әйберләремне алырга киләбез.

Хафиз. Шулаймы...

Филүсә. Нишләп болай бетәштең?

Хафиз. Яшисем килми.

Филүсә. Дөнья киң, якты. Яшәргә дә яшәргә.

Хафиз. Синең яшисең киләмени?

Филүсә. Әлбәттә. Дөньядан туярлык бер сәбәп тә күрмим.

Хафиз. Нишләп кеше дөньяга килгәч, болай интегергә тиеш икән?

Филүсә. Ә, бәлки, интегер өчен туадыр кеше. Газаплардан арынган мизгелләрдә үзен бәхетле итеп тойсын өчен. *(Кайнарланып.)* Син яшәүнең караңгы, авыр якларын гына күрәсең, авырлыклардан куркасың. Монда кем гаепле? Синең бишегең өстенә иелеп: «Балакаем, тормышның рәхәт булыр, рәхәт чигеп яшәрсең», – дип вәгъдә бирүче булмагандыр бит. *(Чыгып китә.)*

*Тимур белән Зәримә керәләр һәм, Хафизга игътибар итмичә, түрдәге картинаны карыйлар.*

Тимур. Сиңа шушысы ошады инде алайса.

Зәримә. Әйе. Баш врачның юбилеена менә дигән бүләк булачак.

Тимур. Лениза ризамы соң?

Зәримә. Әйе, берсүзсез риза.

Тимур. Ул бит, бу картина Исмәгыйльгә бик ошаячак, дип сөй-

ләнгән иде. Аңа алып бармакчы иде бугай ул аны.

З ә р и м ә . Лениза миңа бирде инде аны. Исмәгыйльгә Лениза үзе бүләк булып бара инде.

Т и м у р . Килешәм. Исмәгыйльгә Лениза шәп «подарочек» була.

З ә р и м ә *(ачуланып)*. Күп телеңә салынма. Менә дигән пар булырлар әле.

Т и м у р . Хафиз, бу картинага срочно рамка кирәк. Фикерләреңне туплый тор, мин балконда тәмәке тартып керәм. *(Балконга чыгып китә.)*

Х а ф и з *(башын калкытып)*. Исмәгыйль кем ул?

З ә р и м ә *(картиналар арасында йөреп)*. Кырым татары.

Х а ф и з . Тагын кем?

З ә р и м ә . Тагын кем дип... Зур эшмәкәр, Германиядә яши. Тиздән Ленизаның ире булачак.

Х а ф и з . Ул Германиягә китәмени инде?

З ә р и м ә . Әйе.

Х а ф и з . Миңа әйтмәде.

З ә р и м ә *(Хафиз янына килеп)*. Син, психикасы чалыш кешене яратып, үзең дә харап булмагаең. Китсен ул тизрәк – синең өчен шулай яхшырак.

Х а ф и з . Аның психикасына ни булган?

З ә р и м ә . Аңламыйсыңмыни? Ул тәүлек әйләнә иҗат белән дәваланучы невротик. Шунысы аяныч: андый кеше үзе генә газапланмый, берьялгызы гына бимазаланасы килми аның...

Т и м у р *(балконнан кереп)*. Шул картинада тукталдыкмы инде?

З ә р и м ә . Әйе.

Т и м у р . Алайса киттек.

Х а ф и з . Тимур, туктале, бер минутка кал.

З ә р и м ә . Мин чыга торам. *(Чыгып китә.)*

Х а ф и з . Ленизаны Германиягә җибәрмә.

Т и м у р . Ленизаны анда Исмәгыйль көтә. Чыксын шуңа. Исмәгыйль аңа дөньяны күрсәтер, талантын гамәлгә ашырырга Европада мөмкинлекләр күбрәк.

Х а ф и з . Ә мин?

Т и м у р . Нәрсә, син?

Х а ф и з . Ленизасыз нишләрмен?

Т и м у р . Моңарчы яшәгән идең бит әле. Син үз тиңеңне эзлә.

Х а ф и з . Мин аңа тиң түгел, әйе...

Т и м у р . Менә бит, үзең дә аңлыйсың. Гәүдәңне турайт. Эшлә. *(Чыгып китә.)*

*Хафиз, шкафтан бер шешә алып, авызыннан аракы эчә. Әрле-бирле йөргәннән соң, идәндә яткан балтаны ала һәм картиналарны чапкаларга тотына. Фатирдагы бар нәрсәне вата, җимерә. Аннары, балтаны читкә томырып, караватка ята. Л е н и з а керә. Фатирдагы күренешкә аптырап карап тора.*

Л е н и з а . Нәрсә булды монда?

Х а ф и з *(сыктанып)*. Син мине таптадың, бетердең, бәгыремә төкердең.

Л е н и з а *(усал итеп)*. Минем сиңа бернинди бурычым юк иде бит.

Х а ф и з . Син миндә өмет уяттың, ә үзең мине инкарь иттең.

Л е н и з а . Мин сине чакырып китермәдем. Тәрәзәмдә янган утка үзең килеп кердең.

Х а ф и з *(сикереп тора)*. Син бит мине якынайттың, гыйшык утыма утын өстәдең.

Л е н и з а . Сине мин фатирда яши торган песи яки эт урынына күрдем. Аларга минем аллергия, ә сиңа аллергиям юк.

Х а ф и з . Ник мине болай мыскыл итәсең?

Л е н и з а . Син миңа якын да, кызык та кеше түгел, Хафиз. Миңа гашыйк булуыңда мин гаепле түгел бит.

Х а ф и з *(кыҗрап)*. Таш бәгырьле кеше син.

Л е н и з а . Син – гаепне гел баш-

каларда күрүче. Андый кеше ныклы адымнар ясый алмый, тормыш авырлыклары алдында каушый торган була. Хатының, гаиләң өчен дә көрәшә алмадың. Син чиста күңелле, ләкин андый сыйфат кына бу дөньяда ярдәм италмый... *(Чыгып китә.)*

*Хафиз нишләргә белми. Тагын шешәне күтәреп аракы эчә. Т и м у р керә. Җимерелгән, ертылган, ватылган картиналарны карап йөри.*

Т и м у р . О-һо-һо... Ике миллионлык әйбер бозгансың. *(Паузадан соң.)* Белүемчә, ике миллион Ленизадан алган булгансың... Фатирың нәкъ дүрт миллион тора... Фатирыңны миңа бирәсең һәм синең белән расчёт.

Х а ф и з *(өзгәләнеп)*. Нишләп мине шушы көнгә калдырдыгыз сез?!

Т и м у р *(нәфрәтле тавыш белән)*. Син чүпрәк, хәлсез булганга кем гаепле?! *(Ватык картиналарны идәннән калкытып карый.)*

*Хафиз әкрен генә тора да такта белән Тимурның башына суга. Тимур аңын җуеп егыла. Хафиз шактый вакыт карап торганнан соң, аның кесәләрен капшый. Тимурның куен кесәсеннән пистолет ала һәм аны, әйләндергәләп караганнан соң, үзенең чалбар кесәсенә тыга. Тимурның икенче кесәсеннән ачкычлар бәйләме ала, аны да үзенең кесәсенә тыга. Барып тәрәзәдән карап тора. Шуннан соң, кызу-кызу атлап, фатирдан чыгып китә.*

## IX

*Лениза фатиры. Л е н и з а , юлга әзерләнеп, әйберләрен сумкаларга тутыра. Х а ф и з керә.*

Л е н и з а *(гаҗәпләнеп)*. Ишек ачык идемени?

Х а ф и з . Юк, бикле иде.

Л е н и з а . Ничек ачтың?

Х а ф и з . Ачкыч белән. *(Ленизага пистолет төби.)* Германиягә китмисең. Монда каласың.

Л е н и з а . Хафиз, нишләвең бу?

Х а ф и з *(корыч тавыш белән)*. Мин үтерәм сине.

Л е н и з а . Ни өчен?

Х а ф и з . Утыңны сүндерер өчен.

Л е н и з а *(ягымлы тавыш белән)*. Хафиз, йә, тынычлан әле. Кеше үтергәч, алга таба ничек яшәрсең. Ул бит инде яшәү булмаячак.

Х а ф и з . Хәзергедән дә авыр булыр микәнни?

Л е н и з а *(әкрен генә килеп)*. Син яратасыңмы мине?

Х а ф и з *(калтыранып)*. Яратам.

Л е н и з а . Яратсаң, бу әйберне бир әле миңа. *(Пистолетны Хафизның кулыннан алып өстәлгә куя.)* Утыр әле. *(Диванга утыралар. Лениза аны иңеннән сыпыра.)* Син бит тәти егет.

Х а ф и з . Минем башка чарам юк.

Л е н и з а . Кеше үтергәч авыррак булачак, Хафиз. Үземнән беләм.

Х а ф и з . Каян беләсең?

Л е н и з а . Рәкыйпне мин үтердем бит. Хәзер менә көн саен, сәгать саен шуны уйлап газап чигәм.

Х а ф и з . Ничек үтердең соң син аны?

Л е н и з а . Ул мине шундый ярата иде. Ә миңа гел нидер җитмәде, мин аның интегүен дә теләдем – көнләшергә сәбәпләр тудырдым. Аның күз алдында башкалар белән күз кыстым – аның ачуын китерер өчен генә. Ул кызып китә иде, көнләшә иде, кайгыра иде, ә мин, тиле, аның бу халәтеннән ләззәт ала идем. Авариягә эләгүебез дә минем аркада булды. Төнге клубта юри башка егетләр белән чуалган булып кыландым. Аның моңа бик каты ачуы килде. Шушы фатирга

кайттык. Мин аны тынычландырырга маташтым, хәтта гафу үтендем. Ә ул, исерек килеш, чыгып, машинаны кабызды. Мин дә аны тыярга дип машинага кереп утырдым. Ул тотты да төнге шәһәр буйлап чапты. Менә шулай, минем аркада харап булды минем бердәнберем.

Х а ф и з . Димәк, син авариягә кадәр үк каты җанлы булгансың. Синең сәерлегең, башкаларга охшамаганлыгың аңарчы да булган.

Л е н и з а . Аңлый алмыйм. Күрәсең, миндә рәссамлык яшәгән, аңа чыгарга сәбәп кирәк булган. Авария дә шуңа килеп чыккан.

Х а ф и з . Син үзеңне акларга маташасың.

Л е н и з а . Юк, акларга да тырышып карыйм, ләкин мөмкин түгел. Мин аны харап иттем.

Х а ф и з . Син кеше хисләренә, башка кеше язмышына битараф, башкаларны санга сукмыйсың, санламыйсың.

Л е н и з а . Миңа бит андый бурыч йөкләнмәгән. Кешеләрне яратмыйм мин.

Х а ф и з . Син Рәкыйпне дә яратмагансыңдыр.

Л е н и з а . Бәлки.

Х а ф и з . Мине ник якынайттың үзеңә?

Л е н и з а . Мин күрдем: тормыш авырлыгыннан качар өчен, башка дөнья эзләп килдең син миңа. Тәрәзәдәге утка хатының борчылганга түгел, ниндидер яңалык эстәгәнгә кердең син.

Х а ф и з . Тәрәзәңдәге утка этәрүче Филүсә булды.

Л е н и з а . Менә бит, тагын гаепне башка кешедән эзлисең.

Х а ф и з . Димәк, мин сиңа йорт хайваны, песи, эт сыман нәрсә урынына вакытлыча кирәк булдым?

Л е н и з а *(йөзен чытып)*. Казынма инде.

Х а ф и з *(торып)*. Ныклы адымнар ясый алмый торган кешеме мин?

Л е н и з а . Сорауларны яратмаганымны беләсең бит инде.

Х а ф и з . Төкерәм мин синең нәрсә яратуыңа, нәрсә яратмавыңа!

*Хафиз, өстәлдән пистолетны алып, чыгып китә. Подъездда аткан тавыш ишетелә. Лениза чак кына сискәнеп куя.*

## X

*Л е н и з а тәрәзәдән карап тора. Х ә н и я керә, йөзе караңгы.*

Л е н и з а . Хәния апа, чәй куй әле.

Х ә н и я *(кырыс тавыш белән)*. Үзең куй. Тагын кемнәрнең башына җитәрсең икән син?!

Л е н и з а *(ямьсез елмаеп)*. Син дә мине гаеплисеңме?

Х ә н и я *(кызып)*. Улымны харап иттең, Хафизны кул салуга җиткердең... Син Германиягә барып, әле Исмәгыйльнең башына җитәчәксең. Иблис утыра синдә, иблис!

Л е н и з а . Син бит мине күкләргә чөеп мактадың, иҗатыма сокландың, рәхмәтләр укыдың.

Х ә н и я . Мин улым белән элемтә өзелмәсен дип, моңарчы синең янда булдым. Инде сине тирәннән аңлагач, бер яхшы сүз дә әйтә алмыйм.

Л е н и з а *(тирән сулап)*. Ярар, теләсә ничек уйла. Бу фатирны сиңа калдырам.

Х ә н и я *(кычкырып)*. Кирәк түгел! Алла каргаган фатир бу!

*Т и м у р белән З ә р и м ә керәләр.*

Т и м у р . Сиңа Германиягә китүне кичектерергә туры киләчәк. Исмәгыйльгә бүген шалтыратып әйттем. Хафизның хатыны мине судка бир-

гән – Хафиздан фатирны талап алуда гаеплиләр.

Л е н и з а . Ә минем монда ни катнашым бар? Син алдың аның фатирын, мин түгел. Миңа әле ике миллионымны да кире бирүче юк.

З ә р и м ә *(җикереп)*. Җитте сиңа, Лениза! Талантың талант белән, әмма оят, намус дигән нәрсә дә булырга тиеш.

Л е н и з а . Сез үзегез миннән рәссам ясадыгыз. Мине дәваларга мин кушмадым сиңа. Сез минем аркада миллионлап акча эшләдегез. Сез үзегез миңа елыштыгыз, минем белән файдаландыгыз. Исмәгыйльнеке булгач, сез миннән колак кагачаксыз, шул сезне ныграк борчый. Ә син, Хәния апа, мине каргама, улың мине үлеп ятратканга мине гаепләмә.

Х ә н и я . Җансыз, кансыз кеше син. Ясаган рәсемнәрең дә салкын, ямьсез.

Л е н и з а . Исмәгыйль янына китүемне улыңа хыянәт дип кабул итәсең. Мин болай да инде Рәкыйпкә озак тугры булдым – һәр картинамнан ул карый, утны аның истәлеге итеп сүндермим. Ә сез, Тимур, Зәримә, хөкемнән куркасыз. Гел балда-майда йөзеп булмый шул, түли белергә дә кирәк.

З ә р и м ә *(ярсып)*. Син акылга зәгыйфь! Шуңа күрә сине бернишләтеп булмый, аңлату да мөмкин түгел. Мин булмасам, син күптән гүр иясе булыр идең. Тимур булмаса, рәссам итеп сине үз шәһәребездә дә белүче булмас иде!

Л е н и з а *(елмаеп, әмма усал итеп)*. Күземнән югалыгыз барыгыз да! *(Барысы да чыгып китәләр.)*

*Лениза җыелган әйберләренә карап тора. Ф и л ү с ә керә.*

Ф и л ү с ә . Качарга җыенасыңмы?

Л е н и з а . Кемнән кая качарга мөмкин бу дөньяда?! Синең дә мине гаеплисең киләме?

Ф и л ү с ә . Үтерәсем килә.

Л е н и з а *(көлемсерәп)*. Йә нык яраталар мине, йә үтерергә телиләр. Беркем дә миңа битараф түгел. Югыйсә беркемне чакырганым юк, беркемне якынайтканым юк. Киләләр дә минем белән бәйләнышка керәләр, аннары мин гаепле булып калам. Син мине нидә гаепләргә маташасың? Тәрәзәмдә ут янудамы? Минем янган утымда беркемнең эше булырга тиеш түгел.

Ф и л ү с ә . Яктылык бирә торган ут түгел ул.


Л е н и з а . Ул утка керергә мин беркемгә дә кушмадым.

Ф и л ү с ә . Бәлки, син үзеңнең сәнгатеңне утка тиңлисеңдер?

Л е н и з а . Ул минем шәхси эшем. Кагылмагыз минем халәтемә. Сәнгать тормыштагы фаҗигаләр өчен җаваплы түгел. Нишләп сез барыгыз да сәнгатькә битараф түгел, нигә сез аңа тартыласыз? Тәнкыйтьләр өченме?! Сүгәр өченме? Аны таптар өченме?! Минем берегезне дә чакырып китергәнем юк! *(Тирән сулап куя.)* Гаризаңны кире ал. Фатир өчен беркемне дә судка бирмә. Менә бу фатирны сиңа калдырам. Сатарсың да теләгән районнан яхшы фатир алырсың. *(Күзләрен йома.)* Су алып кил әле миңа, тәнем яна.

*Филүсә, беравык уйланып торганнан соң, әкрен генә кухняга китә. Лениза барып тәрәзәне ача һәм аска сикерә. Урам ягыннан кычкырган һәм шапылдаган тавыш ишетелә. Филүсә йөгереп килеп тәрәзәдән аска карый һәм диванга барып утыра. Беравык утырганнан соң, торып, фатирда утны сүндерә.*

*Пәрдә.*



Арпад Галгоци

# ЯЗГА ТАБА

хикәя

Караңгыланды. Казакъ далаларында караңгы искәрмәстән төшә. Сәяси тоткыннардан гыйбарәт өч йөз кешелек колонна, әлбәттә, вакытны ашыктырып, тизрәк «өйгә» кайтырга тели. Анда, артык зур булмаган «үз лагерьларында» аларны хәзер миче ягылган барак, йомшак ятак көтә. Ул гынамы, көн дәвамында арган-талчыккан тоткыннар соңгы вакытларда, махсус кибеткә кереп, ак майдан, колбасадан авыз итә ала, башка төрле тәм-томнар да шунда гына. Акчаң гына булсын! Җәйдән бирле аларга бераз эш хакы да түли башладылар. Ризык төрләндерергә шул сәмәннәр ярап тора. Югыйсә әле кайчан гына кысыр баланда да иң тәмле аш булып тоела иде.

Соңгы айларда галәмәт зур Империядә күз алдына китермәслек үзгәрешләр булып үтте, ачлык-ялангачлыктан интеккән тоткыннар язмышында да әлеге үзгәрешләрнең нәтиҗәсе күренде. Күренмәслек тә түгел – 1953 елның 5 мартында Сталин кушаматын йөрткән Иосиф Джугашвили дигән кансыз җәлладның җаны җәһәннәмгә китте. Дөмекте! Империя халкы, бу хәбәрне ишеткәч, тирән кайгыга төште, әлбәттә, шулай булмыйни – алар әлеге ерткычны кешелек дөньясының Атасы да, Остазы да дип тәмам ышанган иде инде, һәм, бердәм булып, күпсанлы корбаннар хакына тиздән бөтен инсан да бәхет кичереп яшәячәк коммунизмны көтә иде.

Ил башына надан, ләкин гаять тә хәйләкәр Хрущёв килде. Сталинның тугрылыклы аркадашлары бераздан берәм-берәм тарих сәхнәсеннән төшеп калды. Безнең өчен иң мөһиме – Сталин үлгәннән соң, сәяси тоткыннарның хәле сизелерлек җиңеләйде. 1953 елның җәендә тоткыннарны теркәп, фотога төшерә башладылар, ә ноябрьдә инде аларның кайберләрен, төркем-төркем туплап, азат та иттеләр.

Без, күкрәк киереп, иркен суладык. Ләкин барыбызга да азатлык һавасын иснәргә әле иртәрәк иде.

Безнең лагерь Караганда шәһәреннән ерак булмаган Актас дигән урында. Һәр көнне бригадаларны кирпеч лагерена эшкә алып китәләр.

Әйе, казакъ даласында караңгы искәрмәстән тиз төшә. Ләкин без аны һәрвакытта көтеп алабыз. Бу юлы, рәт-рәт тезелеп тормыйча гына, төркем-төркем булып, лагерьга ашыктык. Карлы яңгыр ява башлады. Аяз Гыйләҗев һәм мин алдан йөгерәбез. Аның белән берничә атна элек танышып, дуслашкан

идек. Баракта да ятакларыбыз янәшә. Ул сөйләргә ярата, мин исә, аның һәр сүзенә колак салып, адымымны кызулыйм.

Башка дуслары Аязны Алексей дип атаса да, мин аңа Хан Батый дигән яңа кушамат тактым. Ул – Казан университетында укыган белемле, аңлы егет, совет системасының асылына яшьтән үк төшенгән...

Күпмедер эндәшми барганнан соң, Аяз карлыккан тавышы белән минем якка кычкырды:

– Борылып кара әле, затлы банкетка ашыгучы туристларга охшап калганбыз, ә? Менә бит замана! Кайчан гына бишәр-бишәр тезелеп, кулны артка куеп, башны иеп, колоннада тынсыз гына йөри идек; бер адым читкә чыксаң да, конвой ике дә уйламый атып үтерер иде. Җүнләп яшибез генә дигәндә, сине иленә кайтарып җибәрерләр инде...

– Киресенчә дә булырга мөмкин. Сине кайтармаслармы әле өеңә. Азат иткәндә, төрле сәбәп табалар бит. Ничек булса да, мин сине Венгриядә кунакка көтәм. Тик үзең белән урыс армиясен генә ияртмә!

Бер-беребезнең аркасыннан кага-кага, рәхәтләнеп көлештек. Көтмәгәндә, ун-унбиш адым артта, кырыс тавыш яңгырады:

– Стоять!

Конвойчы сержант безгә бишәр кеше булып рәткә басарга боера иде.

Барыбыз да туктадык. Әйтерсең лә һәркем катып калган иде.

– Көтү кебек барасыз! – дип акырды сержант. – Иманыгызны укытырмын!

– Ул нәрсә, акылдан шашкан мәллә... – дип, татар дустым җилкәсен җыерды. – Сигез айга соңга калган бит болай кычкырырга!

Һәм ул, кинәт борылып, ачы тавыш белән сөрән салды:

– Кузгалмаска! Бер адым да атламаска! Ни шагу!

Без, өнсез калып, татар әмеренә буйсындык. Беркем дә урыныннан кузгалмады. Төптән юан чыккан бер конвойчы колонна алдына йөгерде, урыннарында катып калган, суыкта туңган арестантларны, шеренгага бастырып, алга кумакчы булды. Ләкин Аязның боерыгы катгый иде.

Бер урында басып торгангамы, без туңа башладык. Җилләтеп тә җибәрде. Аркан борылып, бушлатның сырган якасын күтәреп куйдык. Җил сул яктан исә иде, колоннаның уң ягындагы солдатлар нәкъ җилгә каршы басып торырга мәҗбүр. Ә дала җиле ул кышын җелегеңә төшә! Сталин үлеменә иң нык үкенүчеләр бу минутларда шулар булгандыр, мөгаен. Сержант сыны каткан рәтләр буйлап гасаби рәвештә йөрүендә булды. Ул тәмам аптыраштa иде.

– Әй син! Берия сыңары! Ишеттеңме әле, аны Лубянка подвалында стенага терәп атканнар. Дөнья үзгәрде, ә син һаман аңгыра! Бетте сезнең замана. Тәмам!

Колонна койрыгында яңгыраган бу сүзләр безнең очка да килеп иреште. Тавышын йомшартырга тырышып, сакчыларның башлыгы кичәге колларга акрын гына эндәште:

– Атларга әзерме сез? Аргансыз бит инде, кузгалыгыз.

– Лагерь нәчәлниген чакырыгыз! Ул килгәнче, бер адым да атламыйбыз! – Мин бик тиз танып алдым – бу Фомин бригадасыннан һәркемгә итагатьле поляк Левандовский! Аңа дуслары, гадәттә, Пан дип кенә эндәшә иде.

Үз кадерләрен үзләре белә башлаган тоткыннар белән каршылыкка керергә гарнизон нәчәлнигенең башына тай типмәгән. Бәхәсләшеп торырга инде соң – төн якынлаша, суык та көчәя бара. Сигез ай элек булсамы?!

Ләкин йомышчыны барыбер лагерьга йөгерттеләр. Егерме минут үттеме-

юкмы, нәчәлник килеп тә җитте. Полковник Лебедев үзе! Бер урында таптанучы туңып беткән toткыннарга ул, ачуын һич тә тышка чыгармыйча, кешечә эндәште:

– Аң булыгыз, кешеләр! Кайтыгыз! Җылынырсыз...

Күрәсең, шул сүзләр генә кирәк иде, колонна лагерьга таба кузгалды. Тик аңарчы кемдер төн караңгылыгына төбәп кычкырып өлгерде:

– Бу сержант бүтән күренмәсен!

Чыннан да, ул сержантны без башка күрмәдек. Ул гына да түгел, безне уң яктан саклаучыларның һәммәсе, битләре өшеп, хастаханәгә эләккән, дип сөйләделәр.

Икенче көнне иртән кояшның ап-ак кар өстендә уйнаган алтын нурларыннан күз чагылды.

Көннәр язга авышкан иде.

*Венгр теленнән* **Ркаил ЗӘЙДУЛЛА** *тәрҗемәсе.*

**Редакциядән**

Татар халкының олуг язучысы Аяз Гыйләҗев 1950 елның 22 мартында кулга алына. Бер ел дәвамында ул Казанның Черек күл төрмәсендә утыра, шуннан Караганда лагерена озатыла. Аяз Гыйләҗев ул елларда, күпчелек зыялылар кебек үк, совет системасына каршы оешма төзүдә, Сталинга яла ягуда гаепләнеп хөкем ителә. ГУЛАГ лагеренда алты ел утыра. Сталин үлеменнән соң аклана.

Тәкъдим ителгән әлеге хикәяне ГУЛАГ лагеренда Аяз Гыйләҗев белән бергә михнәт чиккән Арпад Галгоци әдибебезнең 90 еллыгына багышлап иҗат итте.

Венгр халкының әдәби тәрҗемәчесе белән Аяз Гыйләҗевне ул елларда нәрсә берләштерә соң? Беренчедән, алар – яшьтиләр (икесе дә 1928 елгы), икенчедән, икесе дә студентлык чорында кулга алына, өченчедән, икесе дә 58нче маддә буенча гаепләнә, дүртенчедән, кызыксыну (әдәбият, тарих, культура, чит телләр һ.б.) даирәләре уртак, бишенчедән... һәм әле тагын бик күп...

Ә кем соң ул Арпад Галгоци?

Арпад Галгоци 1928 елның 8 ноябрендә Венгриядә туа. Биредә белем ала. Инде әйтелгәнчә, студентлык елларында – 1947 елда кулга алына. Әүвәл Чиләбе, шуннан соң Караганда лагерьларында утыра. 1954 елда гына азат ителә, тик 1960 елда гына Ватанына кайту насыйп була.

Ул Будапештта заводка техник әдәбиятны тәрҗемә итүче буларак урнаша, соңрак профессиональ тәрҗемәче булып китә. XVIII гасыр – XX йөз башы рус шагыйрьләренең биш йөздән артык шигъри әсәрен тәрҗемә итә, Будапештта рус әдәбияты турында радиотапшырулар алып бара.

Арпад Галгоци – Будапештның шәрәфле гражданины; А.С.Пушкинның «Евгений Онегин» (1992), (2000), «Гений чистой красоты» (1995), «Я Вас любил» (2002), «Странная любовь» (1995) китаплары, «XVIII-XIX гасыр рус шагыйрьләре шигырьләре» (2002) җыентыгы, М.Ю.Лермонтовның «Демон» (2003), «Венгры в ГУЛАГе» (2007-2009) трилогиясе һ.б. китаплар авторы.

# «ЯШӘЛГӘНЕН ЯЗА ТОРАМ...»




Әлеге кызыклы шәхес белән якыннан танышып, тыгыз мөгамәләдә бергә-бергә әдәби сүз сәнгатебезгә хезмәт итә башлауга да биш ел була икән инде. Гомумән, иҗат кишәрлегем читәне аша хәл белеп, киңәшләрен биреп узган, катлаулы хәлләр килеп чыкканда, ярдәм итәргә әзер бер төркем мыеклы агайлар арасында ул һәм географик (күршеләр булып яшибез), һәм сәфәрдәш (95 % очрашуларга бергә йөрибез), һәм аталарча кайгыртучан (әтидән алты көнгә өлкән, мин аның улы белән яшьти), һәм фикердәш (кулъязмаларны бергә-бергә журналга әзерлибез) – әле тагын бик күп яклардан якын булып чыкты.

Сүзем – төп әдәби басмабыз – «Казан утлары» журналының проза әсәрләрен инде ничә еллар дәвамында үзе аша үткәрүче редактор, классик татар реалистик романының традицияләрен (күләм дә, сыйфат та, тел дә, иҗат агымы да...) саклап калып килүче романист, өлкәннәр һәм яшүсмерләр өчен дистә-дистә повесть-хикәяләр биргән язучы, сатирик... Камил Кәримов турында.

Язучы-әдипләрнең зур әдәби багаж төенчекләрен берәмтекләп чишә, барлый башласаң, аларның иҗади биштәр кысаларында һәркайсының үз урыны бар. Гадәтемчә, шул биштәр эченнән мин, ни өчендер, язучының тәүге әсәрен эзләргә, аның әдәбиятка нинди әзерлек белән килүен, яза башлау сәбәпләрен һәм тарихын барларга яратам.

Бу очракта да үземә шундый максат куйдым. Ниләр борчыган соң гади татар авылында салам түбәле йортта әтисез үскән, сугыштан соңгы авыр елларда михнәт чиккән егетне? Нинди хыяллар белән янган ул?

«Биштәр»гә ревизия ясаганда, һәр язучының да әлеге тәүге иҗат җимешенә юлыгып булмый. Аларның күбесенә таркаулык хас. Ә Камил Кәримовның «биштәр»ендә тәртип: үз иҗаты да, аның турында язылганнары да, башкаларның кулъязмаларына бәяләмә-рецензияләр дә, таслап-таслап, һәммәсенең дәрәҗәсен чамалап, барлап куелган. «Энекәш, хәтереңә ышанма! Теркәп куй!» – дип еш кабатларга ярата ул. Куен кесәсеннән кәгазь-каләм чыгара да, барыбызга үрнәк күрсәтеп: «Теркәп куярга кирәк», – ди, башына килгән фикерләргә сөенеп. Шул рәвешле, «теркәп куй»лар байтак җыела, блокнотлар, папкалар тула, фикерләр, деталь-символларны, җөмләләрне, инде соңрак сюжетларны каймалап, әсәрләргә әверелә...

Актара торгач, таптык без Камил Кәримовның (әле ул вакытта – Кәримов Камил) тәүге хикәясен. Моңа кадәр дә язу-сызудан читтә булмаган егетне зур әдәбиятка шушы хикәя алып килә. Аның язылу тарихы да игътибарны җәлеп итә. Язучы бу хакта болай искә ала: «Сәхнә теле» дәресе бара. Педагог – Халык артисты Асия Хәйруллина – матур сүзләрне сайлап кына, сәнгатьчә сөйләшергә өйрәтә.

– Син нәрсә язасың анда? – диде ул миңа, дәресне бүлеп.

– Хикәя күчерәм, – дим.

– Кемнекен?!


– Үземнекен.

– Бир әле монда.

Гаебемне таныргa әзер идем. Ә тәҗрибәле педагог, хикәямне алып, кычкырып укый башлады да шундук туктап калды.

– Мин аны өйгә алып кайтам әле, – диде ул. Һәм, берни булмагандай, дәресне дәвам итте.

Икенче дәрескә килгәндә, Асия апа хикәямнең соңгы битенә үзенең фикерен өстәгән иде...»



*«Хикәя үзенең эчтәлеге белән бик тыйнак, чиста, беркем тарафыннан пычратылмаган, яңа башланырга торган мәхәббәт турында.*

*Кыска гына хикәядә бик күп фикер әйтелгән. Молодец! Авыл күренеше, клуб эче, кыз, Радио апа, урам, буран, чокыр һ.б. – барысы да күз алдына килеп бара. Димәк, автор бу әйберләрне үзе бик шәп күзаллый.*

*Миңа бик ошады. Шулай ук минем укыганны тыңлаучы 17 яшьлек кызга да бик ошады. Бу – аның һәм минем фикер.*

*Имза. V-1975»*

1975 елның маенда Халык артисты Асия Хәйруллинадан фатиха алган «Мәхәббәт чокыры» матбугатта һәм без бүген тукталачак «Карурманда кара песи» *(Татар.кит.нәшр., 2015)* җыентыгында «Ниләр уйлар икән?..» исеме астында басылып чыга.

Унынчыда укучы хикәяләүче-«мин»не мәктәптә дә, өйдә әнисе дә «кызлардан куркучылар исемлегендә» йөртә. Көннәрдән бер көнне, тәүге кар төшәр алдыннан, авылга каладан артистлар килә. Әнисе улына да билет ала, тик икесенә аерым урыннардан («гадәте шулай», «янәсе, миңа ияреп йөрер чагың үткән»), ә егетнең урыны кайчандыр бергә укыган, сигездән соң киткән, күрше авыл кызы Гөлнәфидә белән туры килә.

Хикәяләүче геройның кызга соклануын автор табышлы чагыштырулар белән оста сурәтли: «борчак сыярлык кына» мәхәббәт чокырыннан «гөлләр шытып чыгар сыман». «Чыпчыклар көтүе очып киткән тавыш чыгарып», пырхылдап куйган гайбәтче Радио Мәликә дә бүлдерә алмый аның сокланулы карашын.

Ә бу вакытта «урамга күктән кар болытлары ишелеп төшкән» икән. Егет, әле моңа кадәр тәҗрибәсе булмаса да, буранлы төндә күрше авыл кызын озатырга кирәклекне рефлексив рәвештә аңлый. Кыз да елмая – ризалыгын белдерә. «Елмаю караңгы төндә дә, буран эчендә дә күренә икән!» – дип нәтиҗә ясый хикәяләүче.

Күрше авылга җитәрәк, беләгенә «усак яфрагыдай нәни кулы» белән орынып баручы Гөлнәфидә, озатучысына тотынган хәлдә, икәүләп чокырга чумалар – кызның авылдашлары «гөл савыты» казыган, кышка туфрак алганнар икән.

Шул рәвешле, кыз йөзендәге матурлык символы – мәхәббәт чокыры чып-чын Мәхәббәт чокырына әверелә: әлеге «гөл савыты» төбендә тәүге сөю хисләренең чаткысы кабына. Гөлнәфидәләр өе турысына җиткәч, кыз аның чәчләреннән кар тузанын сыпыра, «кичә генә туган каз бәбкәсе кебек йомшак», «һәр җебе шомырт чәчәгеннән эрләнгән» шарф бүләк итә. Егет үзенчә бер нәтиҗәгә килә: «Чәчләремдә сак кына кулын йөртүе бераз әниемчә дә, бераз башкачарак та иде...»

«Карурманда кара песи» китабының тагын бер бизәге – «Кышкы мәтрүшкәләр» хикәясе.

«Өебез чишмә янында ук. Элек безнең чишмә авылдан читтә булган. Әбиемә су ташырга ерак, дип, бабакаем тота да йортны чишмә янына күчереп сала. Шул

вакыттан бирле монда яшибез икән. Дөрес, авылыбыз да үсте инде. Чишмә белән без авылның үзәгендә хәзер. Әнием әйтә, әле ярый әбиең утын ташырга ерак дип зарланмаган, ди. Шаярта, билгеле, урманга кадәр өч чакрым бит әле. Яратышканнар дигәч тә инде...

Кеше егерме яшькә кадәр үсә, диләр. Ә авыл ничә яшькә кадәр үсә икән? Бабай сиксән җиде яшьтә үлгән, этиемә кырык яшь, ә авылыбыз үсә дә үсә! Ахрысы, тиздән шәһәр булыр...»

Шундый фәлсәфи уйланулар белән башланып киткән хикәянең герое да – үсмер егет. Бабасыннан калган гадәт буенча, ул чишмә буйларын көри, бозын вата, Тәнзилә исемле чибәр кызның суга килешенә сукмакка көл сибеп куя. Суга килүчеләр чатнама суыкларда аларга җылынырга кирә. Тик горур Тәнзилә хәтта 35 градуста да керми. «Менә әле дә, чиләкләрен тутырып, тәрәзә каршыбыздан үтеп китте. Өй түребездә рәшәткә юк, сукмак шундый якын, чиләкләрендәге суда үземнең йөземне дә күреп калдым, ул гына мине күрмәде», – ди хикәяләүче.

Бурасын үзе бураган, улагын үзе уйган («йорт сала белмәгән егеткә хөрмәт юк бездә») чишмәне беркөнне кар күмеп китә. Тирләп-пешеп сукмак ачучы егетнең фанер көрәге һаман Тәнзилә киләсе сукмакка каера – янәсе, яраткан кызы такырдан узсын. Тизрәк өлгерим, дия-дия, ул тәмам сусый, улактан бозлы су эчә, «чишмә бер мәлгә минем өчен генә челтерәде», дип горурланып та куя. Салкын тидереп, икенче көнне урыныннан да тора алмаган егет һаман чишмәне кайгырта, кемдер таеп егылгандыр, яшәү чыганагы булган суга килә алмаучылар да бардыр кебек аңа.

Көндез чишмәгә килүчеләр кереп хәл белә, арада Тәнзилә дә була. «Мәтрүшкә кайнатып эчерсәң...» – дип уфтанган, ярты авылны йөреп тә, әлеге сихәтле үләнне таба алмаган ананың хәлен тиз аңлый кыз – урманга барып, каравылчы Рәхмәтулла бабайдан мәтрүшкә алып кайта. Озакламый егет терелә.

Күрәбез, нәни мәхәббәтнең символы – бу очракта кышкы мәтрүшкәләр. Чын сөюнеке исә – халкыбыз тарихында борынгыдан сакланып калганы – мәхәббәт чишмәсе.

*«Балаларның төп эше – уку, белем алу. Балалар арасындагы иң катлаулы, төп проблемалар мәктәп чорында туа. Моңа кадәр гаилә атмосферасында һәм берничә дусты арасында үскән бала катлаулы мохиткә килеп керә. Укытучыга мөнәсәбәт, дуслар-иптәшләр, коллектив белән мөгамәлә һ.б. Менә шушы катлаулы мөгамәләләрне, бала җанының үтә катлаулы халәтен бирү – балалар язучысы өчен иң җаваплы өлкәдер. Песи һәм эт, яңгыр яву һәм буран улау, йокы килү һәм физзарядка ясау турында язу – чагыштырмача җиңел эш. Чөнки аларга аньк бәя биреп була, алар гомер-гомергә шулай булып килгән. Ә мәктәп тормышы көн саен үзгәреп тора, анда көн саен яңа проблемалар, яңа традицияләр туа. Соңгы елларда бүгенге мәктәп тормышыннан язылган әсәрләрнең сирәк күренүе – балалар тормышын, аларның уй-хыялларын тирәнтен белмәүдән, өйрәнмәүдән килеп чыгадыр.*

*...Камил Кәримов әсәрләре гомум фоннан камиллекләре белән аерылып тора»,*[1] – дип язган иде әле 1977 елда ук Разил Вәлиев. Язучының «Иң гүзәл җир» хикәясе – шундыйлардан. Мәктәпләрендә үсемлекләр, хайваннар турында нинди фән булса, шуларны укыткан яшь мөгаллимә Сабира Ганиевна төп герой – Гөлчирә исемле кыз күңелендә табигатькә карата ихлас мәхәббәт уяткан. Урманчы булырга хыялланган Гөлчирә, укытучы апаларының экскурсиягә урманга чыгу турындагы хәбәрен ишеткәч, бик сөенә.

Үсмер кызның табигатькә гашыйк йөрәген бар тулылыгында аңлаган автор, алдагы хикәяләрендәге кебек үк, аны табышлы фикерләү сәләте белән «бүләкли». Гөлчирәнең укытучы апасына, табигатькә, туган җиренә һ.б.ларга соклану хисләрен Камил Кәримов түбәндәге җөмләләр белән бирә: «Аз сүзлеләр күп уйлаучан була»; «Агачлар тынып калган, әйтерсең, кояш-фотограф аларга тик торырга куша»; «Сәфәр йөргән кеше, авылына кайтып кергәч, олыгайганлыгын бик тиз сизә», – ди әни»; «Коелган яфраклар урынындагы тук бөреләр кул җылысыннан яфрак ярырлар төсле»; «Тынлыкка җил үтеп керде»; «Мин наратның ботаклары сынгаланган буыннарын санадым – ундүрт... Йөрәгем тагын да ныграк сыкранды, яшьтәш икән»; «Иң авыр тынлык,

[1] Вәлиев Р. Ни чәчсәң, шуны урырсың // Казан утлары. – 1977, №8. – Б.162.

мөгаен, укытучы белән укучы арасындагы тынлыктыр»; «Ниһаять, гөрләвекләр безнең авылдан кышны алып та китте» һ.б.

Укытучы белән укучы, остаз белән шәкерт арасында гына була ала торган игътибарлы-ихтирамлы мөнәсәбәтләр хикәядә психологик яссылыкта ачыла: Гөлчирә укытучы апасының туган авылына кунакка бара, яшь мөгаллимәнең табигатьне, якыннарын, туган җирен ничек яратуын күрә, аның белән бер үк халәт кичерә һәм, иң мөһиме – төгәл нәтиҗәгә килә: ул да Сабира Ганиевна кебек мөгаллимә булачак.

Шул рәвешле, заманында Разил Вәлиев язып чыккан фикер (балалар тормышын, аларның уй-хыялларын тирәннән белү, өйрәнү) Камил Кәримовның әлеге хикәясе мисалында тагын бер кат дәлилләнә.

«Хикәя – үзе бер галәм. Димәк, бу галәмнең үзәгендә кояшы балкырга тиеш. Шул кояшсыз галәм була алмый; кояшлы галәмгә тиңләшмәгәч, язганың да хикәя була алмый. ...Хикәядә тирәли йөрергә вакыт юк. Бар да төгәл-тәгаен булырга тиеш»[2] , дип язган иде хикәяләр остасы Мәгъсум Хуҗин заманында.

Әлеге «кояш» – әдәби әсәрнең фокусы турында сүз йөрткәндә, җыентык исеменә чыгарылган «Карурманда кара песи» хикәясенә тукталырбыз. Аның сюжет фокусы нәкъ менә песи образына барып тоташа.

Гомумән, песи безнең мөселман дөньясына (Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) чапаны белән һәммәбезгә мәгълүм вакыйга), Казанда гомер итүчеләргә (Әби патша фәрманы нигезендә, мәркәзебез песиләре, гаскәр-гаскәр булып, Беренче рус мәчетычкан сугышына китә) бик якын инде, һәйкәлләре дә калкып чыга. Татар халкы бу йомшаккайларга карата аеруча мәрхәмәтле. Бигрәк тә авыл җирендә, чөнки йорт-җир, каралты-кура, терлек-туар, кош-корт сагында эт торса (яшәешебезнең урам белән бәйле өлеше), йорт эче, идән асты, баз куышы, келәт, чолан кебек «төшемле» урыннар – песиләр дәүләте. Тагын шунысы бар: мәче халкы – ирекле, бәйсез. Күп очракта алар бу өстенлектән хәйләкәрләрчә файдалана да.

Алда телгә алынган хикәядә шундыйрак песи, әле җитмәсә, кара песи сурәтләнә. Әйе, русның «чёрный кот» «вәхшилеге» безнең кара песиләр язмышына соңрак үтеп керә – кара мәче белән бәйле хорафат-ышанулар, юраулар, ырым-шырымнар, мәкальәйтемнәр, аерым фольклор текстларының тарихы фәкыйрь булуы, әдәби әсәрләрдә кара песиләрнең сирәк очравы шул хакта сөйли.

Камил Кәримов үзенең кара песиен түбәндәге эпитет-чагыштырулар ярдәмендә сурәтли: «дегеткә баткан крокодил сыман»; «имән ишекне уң тәпие белән каерып ачып, теге кара песи килеп керде. Ул, педсовет утырышына чакыртылган тәртипсез укучы кебек, үз урынын алдан ук белеп, хуҗабикә белән яшь тәрбияче каршына килеп утырды»; «теге «йөз сум» акча салкын мич башында утыра». Тавык ояларында йомыркалар эчеп, авыл халкына шактый зур зыян салып йөрүче әлеге мырауҗан аркасында хуҗабикә карчык та пошаманда. Сөйгән кызына бүләк алырга йөз сум акча кирәк булган Ирис атлы егет аның өенә килеп керә, кара песине йөз сум бәрабәренә адаштырырга тәкъдим итә. Бирегә аны әлеге мәчене инде кат-кат адаштырып та нәтиҗәгә ирешә алмаган Энгель агай җибәрә.

Әлеге хикәядә автор чын сатира остасы буларак ачыла. «Карурманда кара песи»не ике катламга бүлеп өйрәнү моны ачык күрсәтә. Әсәрдә вакыйгалар ике катламда бара: «салам түбәле өй кыегына космос аша телевизор карый торган тәлинкә кагып маташкан Энгель агай» җөмләсе хикәяне ике чорга бүлә дә куя. Автор, гүя, сугыштан соңгы авыр еллардан торып бүгенге көнгә бәя бирә. Аның әсәр тукымасына чигелгән «казино», «НЛО», «домофон», «ковролин намазлык өстендә кесә телефоныннан СМС-хәбәрләр җибәрүче 87 яшьлек карчык», «колхозны раскулачивать итү еллары», «пенсияне «Экспресс-карта» ярдәмендә алу», «Интернетка компьютерын тоташтырып бирсәләр, Регина әбинең оҗмах белән элемтәгә кереп карарга да исәбе бар», «гастарбайтер», «гипермаркет» һ.б. сүз-гыйбарәләре дә, кара песине «тавыклардан грипп йоктырып, тезмәдән мәтәлеп төшкәнен күрсәм иде», «сальмонелла кыргыры», дип каргау да, кеше исемнәренең

[2] Хуҗин М.Х. Кочасы иде дөньяны: иҗат тасвирәте төсмерләре [төз. Г.Насибуллова]. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2013. – Б.360.

(Ирис, Энгель, Мирумир, Алекс, Луара, Октябринә, Римма, Регина, Клара әбиләр, Рафинад, Эльза, Ганс һ.б.) сәер заманчалаштырылуы да – һәммәсе шуңа ишарә.

Ирис кара песине беренче тапкыр – фермага илтеп, икенчесендә елга аръягына чыгарып адаштырып карый, ләкин мәче егеттән алда кайтып утыра. Инде кеше аягы басмаган карурман – Бимә кырына илткәч, үзе дә адаша. Бәхетенә, еракка китеп өлгермәгән кара песи Ирисне кара төндә авылга алып кайта. Рәхмәте чиксез егет аңа: «Яңа өй салып чыккач, бусагабыздан кертәм әле мин сине...» – дип вәгъдә дә бирә.

Шул рәвешле, әсәрнең фокус дәрәҗәсенә җиткерелгән кара песи образы үсмер егетнең тулы психологиясен ачып бирергә ярдәм итә.

Фаил Шәфигуллинның «...балалар өчен, балалар турында яхшы әсәр иҗат итү өчен, язучы күңелендә балачак тәэсирләренең бала чактагыча саф, самими булып саклануы мөһим. Балачак хатирәләрен, балачак тәэсирләрен саф килеш саклый алмаган язучы бүгенге дөньяга балалар күзе белән караудан мәхрүм, һәм, минемчә, тормыш материалы никадәр генә бай булмасын, аның балалар турында язган әсәрләре беркайчан да балаларны чын мәгънәсендә дулкынландыра алмый», – дигән сүзләре бар. «Карурманда кара песи» китабына тупланган хикәя-повестьларны укыгач, «Тимергали бабай хикәяте» дип аталган хикәясе укучылар өчен мәктәп программасына тәкъдим ителергә лаек дип табылгач, Фаил Шәфигуллин белән тулаем килешкән хәлдә, Камил Кәримов балалар, үсмерләр тормышын аңлый белә, балачак хатирәләрен, балачак тәэсирләрен бүгенгә кадәр саф килеш саклаган, төрле елларда актуаль булырдай әсәрләр иҗат иткән дигән фикергә киләбез.

Әйе, һәр авылның да карурманы юк.

Карурман тирәсендәге авылда үскән балалар инде «Игезәкләр йолдызлыгы»на *(Татар.кит.нәшр., 2016)* килеп керде. Исемнәре, портретлары, яшәү урыннары үзгәрсә дә, без ул персонажларны әллә каян таныйбыз: холыклары, сөйләшү алымнары, портретлары таныш. Язмышлары гына олыгайган, китәр юллары гына ерак: чишмә улагына Тәнзилә өчен карлы сукмак ярган хикәяләүче-«мин» су бораулаучы Фазылга әверелгән; Тәнзилә белән Әлфинә аерылгысыз тиңнәр кебек. «Кентаврлар көтүе»ндәге «мин» дә бик таныш кеше – «яшәлгәнен яза торам...» дигән автор үзе бугай. «Игезәкләр йолдызлыгы»ның Дияр карты «Тимергали бабай хикәяте»ннән күчкәндер.

Һәр герой авторның үзе белән тиңдәш һәм гел үсештә... Моның сәбәпләре тирәнгә китә. Бер чыгышында Камил Кәримов болай дигән иде: «Мин кечкенәдән «дала кошы» – йөремсәк мәзәк кебегрәк. Бүген юлда, бер атнадан өйдә; бүген сәхнәдә, иртәгә юлда; сигезәр сәгать буе өстәл янында утырып эшләргә күнекмәгән». Аны язмышлы, сюжетларга бай иҗатлы язучы итүдә әлеге факторның өлеше шактый зур.

Шулай да Камил абыйның утырып эшләргә яратмыйм, дигән фикере белән килешеп бетеп булмый. «Татар хикәяләре антологиясе»нә[3] аны чын сатира остасы буларак керткән («Бака каргышы» хикәясе) Мәгъсум Хуҗин бер истәлегендә түбәндәгечә яза: «Камил Кәримов, зарланырга яратмаучы һәм эштән йөз чөермәүче әдибебез, «Ком сәгате» романының икенче кисәген күчергән көннәрдә:

– Кул талганчы күчерәм инде, – дип әйтеп куйды. – Ярты төнне узып та кителә. Шөкер, эшләнә! Рәхәт!

Редакция хезмәтеннән кайтканнан соң, өстәл янында «йомылып» утыра бит. Үзең еш кына кабатлаганча, шул кирәк сиңа, Камил дускай!»[4]

«Эштән йөз чөермәүче әдибебез»нең иҗатын шактый тирәнтен анализлаган әдәбият галиме Рифат Сверигин да аның бу сыйфатын әсәрләр мисалында дәлилли. «Камил Кәримов үзенең әсәрләрендә соңгы елларда әдәбиятыбызның көн тәртибеннән төшерелеп онытыла башлаган игелекле хезмәт темасын яңартып җибәрә. Тормыштагы муллыкка, яшәешнең чын хозурлыгына тик тырыш хезмәт аша гына ирешеп булуын һәркайсыбыз бик яхшы аңлый. Әмма хезмәткә мөнәсәбәт чорына, вакытына күрә үзгәргәләп тә тора. Шундый заман килде – бүген бик күпләр өчен фидакяр эш, файдалы хезмәт дигәнрәк төшенчәләрнең кыйммәте, дәрәҗәсе кимеде – алдашулы базарга

[3] Кәримов К. Бака каргышы // «Татар хикәяләре антологиясе» (ХХ гасыр) [Төзүче, кереш мәкалә язучы, аңлатма һәм искәрмәләр әзерләүче М.Хуҗин]. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. – Б.524-525.

[4] Хуҗин М.Х. Кочасы иде дөньяны: иҗат тасвирәте төсмерләре [төз. Г.Насибуллова]. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2013. – Б.289-290.

корылган җәмгыятьтә «эшләп кем баеган?», «үзләренә кирәксә, әнә җүләрләр эшләсен» дигәнрәк гыйбарәләр өстенлек итә башлады», – дип яза ул «Игезәкләр йолдызлыгы» китабына кертелгән романнарга бәя биргән мәкаләсендә[5].

Чыннан да, Камил Кәримовның һәр әсәрендә диярлек хезмәткә, эш сөюче милләт героена дан җырлана. Үзе дә бернинди эштән куркып-чирканып тормаган, җитмеш төрле эшне (механик та, машина йөртүче дә, су бораулаучы да, слесарь да, балта остасы да, төзүче дә, бакчачы-агроном да, ветеринар да... – тагын әллә кемнәр ул!) чын осталарча «егып салган» әдип иҗатында башкача булырга мөмкинме соң?! Күләмле әсәрләре язылуның чишмә башында торган «Ком сәгате»ннән башлап, менә-менә каләменнән өзелеп төшәргә торган «Тургайлы болытлар»ның икенче китабы – дәвамы булачак романга (әле исемен сер итеп саклый!) кадәр шулай бу.

Язучының, Совет чоры узып, система таркалгач дөнья күргән «Ком сәгате» (2000), «Сакау күке» (2005) әсәрләрен әдәбият галиме Дания Заһидуллина социалистик реализм принцибыннан баш тарту файдасына язылган неореалистик романнар жанрында өйрәнде һәм болай дип билгеләп үтте: «Татар прозасының классик реализм кысаларына «кайтуы» кешенең, милли характер буларак, бик күп уңай башлангычларын ачып бирергә мөмкинлек тудырды»[6].

Быел Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителә торган «Игезәкләр йолдызлыгы» китабына кертелгән «Ком сәгате» романы әнә шулай Мәгъсум абый Хуҗин күз алдында иҗат ителсә, «Тургайлы болытлар» романы (инде, түземсезләнеп, әсәрнең икенче китабын көтәбез) язылуның шаһитләре без булдык.

Гомумән, җыеп әйткәндә, Камил Кәримовның иҗатын югарылыкка күтәргән әдәби кыйммәтләрен без түбәндәгедә күрәбез:

– сюжет камиллеге һәм эзлеклелеге;

– актуаль проблематика һәм тематика;

– гади халык катламы вәкилләрен характер һәм тип дәрәҗәсендә уңышлы ачу;

– төп геройны төрле ситуацияләрдә (драматик, драматик-маҗаралы, көлкеле, фаҗигале һ.б.) сынап, һәрьяктан сыйфатлап бирү;

– фәлсәфи нигезнең тирән катламлылыгы;

– традицион, классик әдәбият үрнәкләреннән килгән реаль алым-чараларга тугры калу;

– пейзаж, портрет тудыру осталыгы;

– татар теленең байлыгын күрсәткән тел-сурәтләү чаралары муллыгы;


– фольклор традицияләренең дәвамы буларак, афористик табышлар, каламбур, рифмалашкан җөмләләр алымына оста мөрәҗәгать итү һ.б.

Әйе, шәп язучы булыр өчен, болар гына җитә микән?! Авторның үз биографиясе дә кызыклы, гыйбрәтле, бай булырга тиеш. Ул тикмәгә генә: «Яшәлгәнен язып барам... Язасыларын яши торам...» – димәгәндер. «Игезәкләр йолдызлыгы» һәм «Карурманда кара песи» кебек саллы, әдәбиятыбыз үсешенә зур өлеш керткән, аның тарихында калачак тагын бик күп китаплар көтәбез без аннан. Ә бу икесе, чыннан да, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек.

**Рамил ХАННАНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты*

[5] Свеpигин Р. Тургайларның туган ягы // Кәримов К.Ә. Игезәкләр йолдызлыгы: романнар. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2016. – Б.613.

[6] Загидуллина Д.Ф. Современная татарская проза (1986-2016 гг.): основные тенденции историко-литературного процесса. – Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. – Б.17.



Рәфикъ
Юныс

# ҖИТӘРБЕЗ ИҢ ЕРАК ЧОРЛАРГА

## Үлми телләр

Үле телләр... Кем үтергән?
Нинди сугыш коралы?
Бәлки инде безнең тел дә
Төзәлмәслек яралы?!

Үлми телләр. Яши алар
Сүзлекләргә сарылып.
Яши кабер ташларында,
Үткәннәрне сагынып.

Җилпенергә әзер килеш
Көтәләр сүз-канатлар.
Берәр галим, исе китеп,
Ул сүзләрне кабатлар...

Телләр үлми. Үлә бары
Телен җуйган халыклар.
1982

Рәфикъ ЮНЫС (1943) – *шагыйрь, публицист; «Син һәм мин», «Татарстан референдумы», «Татар гаме» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Г.Исхакый исемендәге премия лауреаты. Казанда яши.*

## Берләшик![1]

(ҖЫР)

Җитмәде безгә һич бердәмлек.
Баш булды безгә гел таркаулык.
Мең җирдә мең учак пыскыды.
Мең дулкын булып без вакландык.

Кушымта:

Берләшик әле без, берләшик!
Бер халык булып бер,
Бер җан, бер тән булып,
Бер яшик әле без, бер яшик!

Җилләр тик көч-куәт өстәрләр,
Бер учак булып без дөрләсәк.
Бер киртә дә безгә чыдамас,
Дулкынтау булып без бер бәрсәк!

Кушымта.

Өмәләп яңа өй салырбыз
Синең, минем яңа ил өчен.
Без тиңсез Сабантуй ясарбыз,
Җилфердәтеп Казан сөлгесен.

Кушымта.

Җитәрбез иң ерак чорларга
Бер булып, хөр булып, зур булып.
Меңләгән йөрәктән бер теләк
Ургылсын, бер уртак җыр булып:

Берләшик әле без, берләшик!
Бер халык булып бер,
Бер җан, бер тән булып
Бер яшик әле без, бер яшик!

1990

***Редакциядән:***

*Бу айда каләмдәшебез, озак еллар журналыбызда баш мөхәррир урынбасары, бүлек мөхәррире булып эшләгән, бик күп яңа сәхифәләргә нигез салган матбугат ветераны үзенең 75 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез!*

[1] Сәйдәш Чәчәнбаев көе.




*Рәфикъ Юнысның әтисе Юныс Вәлиев – Беренче Бөтендөнья һәм 1905 елгы Рус-япон сугышында катнашкан шәхес.*



*Рәфикъның абыйсы Мәсгуткә 90 яшь тулган көннәр, фотога ул шанлы генерал Багратион булып төшкән. Үзе исә Ватан сугышында пулемётчы партизан булган. Казанда милли китапханәбездә озак еллар директор урынбасары булып эшләде.*



*Сара Садыйкова Р.Юныс һәм аның кызы Ләйсән белән (1983).*



*«Татарстан яшьләре» газетасы хезмәткәрләре Флёра Низамова, Исмәгыйль Шәрәфиев һәм Рәфикъ Юныс – «Җидегән чишмә» иҗат берләшмәсе (Түбән Кама) кунаклары (1985).*



*«Казан утлары» редакциясендә каләмдәшләр белән. Сулдан уңга: Рәфикъ Юныс, баш мөхәррир Равил Фәйзуллин, мөхәррир-язучылар Ләбиб Лерон, Камил Кәримов, Наил Ишмөхәммәтов (2012).*




*«Правда» газетасы призына 8 чакрымлы йөгерешнең республика финалы. Алгы планда – Р.Юныс (1975).*



*Хатыны Дания белән Болгарда (2012).*

*Фотосурәтләр* **Рәфикъ ЮНЫС** *архивыннан.*

# СОКЛАНАМ! ШАКЛАР КАТАМ!

## РАБИТ БАТУЛЛАГА 80 ЯШЬ

*Татарстан китап нәшриятының ел саен бастырып чыгара торган китаплары арасына балалар өчен язылган «Исемем минем Дүрткүз» дигән әсәре белән Батуллин килеп керә. Бу 1966 ел була.*

*Күп тә үтми, Батуллинның «Исемем минем Дүрткүз»енә һәм әүвәлге башка әсәрләренә халык язучысы Нурихан Фәттахның: «Яшерен-батырын түгел, Роберт Батулланың теле коры, төссез. Аның үз ритмы, үз стиле сизелми. Әлегә аның теле тәрҗемә телен хәтерләтә... Димәк, яшь язучының беренче китабы бик үк уңышлы булып чыкмаган... Автор тәнкыйтькә колак салыр һәм киләчәктә, һичшиксез, уйлабрак, тырышыбрак язар дип өметләнергә кирәк», – дигән сыманрак бәясе килеп чыга. Бу – 1967 ел.*

*Шуннан соң Батуллинның «Каникуллар дәвам итә» (1967), «Могҗизалы тамаша» (1968), «Куян баласы Наян» дигән әкиятләре (1970), «Тылсымлы Әбугалисина» (1967), «Кичер мине, әнкәй», (1973) дигән һәм тагын башка әсәрләре дөнья күрә.*

*«Батулла татар әдәбиятында бүген беркем дә шөгыльләнми торган жанрда иҗат итә. Ул балалар өчен әкиятләр яза. Баланың әдәбият белән, гомумән, китап белән танышуын әкияттән башлаганын һәм шигъри фантазиясен үстерүдә, баланың характерын тәрбияләүдә әкиятнең әһәмияте чиксез зур икәнен искә төшерсәк, Батулланың бу изге эше турында мактаудан башка берни әйтеп булмый», дип, Нурихан Фаттах инде бу автор турында башкачарак фикер йөртә (1972 ел).*

*Монда инде Нурихан Батулланың эшли торган жанры белән бергә телен дә мактый дип аңларга кирәк. Шушы урында халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең: «Талантлы әкиятче Батулланың диапазоны киң, мөмкинлеге зур, әдәбиятыбызда аңа көндәшләр юк, димәк, яз да яз гына», – дигән бәясен китерү дә бик муафыйк булыр.*

*Әлеге чорлардан башлап, чыгып килгән әсәрләре белән Батуллин инде мактала башлый. Академия театры сәхнәсендә аның «Өчәү юлга чыктык» әсәре дөнья күрә. Курчак театрында «Пәһлеваннар иле» дигән әсәре уйнала башлый. Соңгысының режиссёры да – Батуллин үзе.*

*«Батуллинның «Тылсымчы Әбугалисина» пьесасы курчак театрлары өчен язылган классик әсәрләр таләбенә тулысы белән җавап бирә», – дип язып, Сергей Образцов авторның курчак театрлары өчен тәгаенләнгән әсәрләренә тулы бәя бирә (1967).*

*Әйе, Рабит Батулла 70 китап язган язучы гына түгел, театрлар сәхнәсендә уйналган, матбугатта басылып чыккан 23 пьеса авторы гына да түгел, Коръән хәтле Коръәнне татарчага тәрҗемә итеп, аны ун басма итеп дөньяга чыгарган, аннан башка да 12 китап тәрҗемә итеп, үзебезнең иң хөрмәтле язучыларыбыз турында җыентыклар төзегән әдип тә, телевидение режиссёры да (1963-1965), режиссёр-педагог та (1969-1974), Курчак театрының баш режиссёры да, Курчак театрында баш режиссёр булып эшләгәндә (1975-1977), күп кенә язучыларыбыздан үз телебездә пьесалар (гел рус телендәге әсәрләр генә куелган чакта!) яздыруга ирешкән шәхес тә, Драма һәм комедия театрының баш режиссёры да! Ул бит әле «Тукай», «Бичаракай»*

*дигән киносценарий, Әлфия Авзаловага, Рудольф Нуриевка һәм тагын башкаларга багышланган киносценарийлар язучы да, телеэкраннарга 1200 тапкыр чыгып, «Кичке әкиятләр», «Батулла дәресләре» алып барган, тарихыбыз, мәшһүр әһелләребез турында бетмәс-төкәнмәс тапшырулар оештырган кеше дә. Барысын да уйлый-уйлый, гомерем буена аның тынгысыз эшчәнлегенә, эшләмәгән эшенең юклыгына шаклар ката-ката, барысына да ничекләр җитешүенә аптырый-аптырый, шулар хакында белергә теләп, үзенә кайбер сораулар бирмәкче булдым.*

**– Хөрмәтле дускаем, Батуллакаем, син бит әле, «Мәдәни җомга»да бергә эшләп йөргән чакларыбызда, йөрәккәйләрең чыгымчылагач Алманияләргә китеп йөргән кеше идең, юкка гына булмагандыр бит ул?**

– Юкка гына түгел иде шул: 1996 ел иде бу. Йөрәгем сулыш ала алмый башлады. Алманиядәге Һамбург шәһәренең йөрәк институты хастаханәсендә атаклы Кальмар дигән профессор йөрәгемә гамәлият ясады. Гадәттән тыш озакка сузылса да, гамәлият, Аллаһы Тәгалә кушып, уңышлы чыкты. Тәнемдә бер метр да утыз сигез сантиметр яра җөе бар. Йөрәктә – тугыз җөй. Дүрт тамырны йөрәккә аяктан күчереп куйдылар. Минем йөрәк капкачы («аортальный клапан» дип атала ул) тимердән ясалган.

Кальмар ул мадъяр кешесе иде. Нишләптер ул мине якын күрде. Мадъярлар борынгы заманда безнең яклардан күчеп киткәннәр бит, бәлки, шуңадыр, бәлки, татар булганыма күрәдер...

Моңа инде хәзер егерме бер ел булды. Унҗиде елын бик рәхәт яшәдем. Баштагы өч ел буена Кальмар куйган режимны бозмыйча тоттым. Хәзер дә, егерме ел буена, ул кушкан бер даруны, канны сыеклата торганын, көн саен эчәм.

**– Афәрин, Батуллин, тәртибеңне моннан соң да шулай бозмыйча яши күр!**

– Яшьтәшләремә караганда, пенсиягә иртәрәк чыктым инде. Үлем белән кара-каршы очрашкач, эшнең, вакытның кадерен белә башладым. Иркенрәк яшәлгән, заягарак узган вакытларның бурычын түләр вакыт җитте дип уйладым. (Ул чакта ике хикәя язганмын да шуның белән язучы булдым дип уйлаганмын...) Һәм йөрәгемне сипләткәннән соң, өстемдә торган бурычымны, уңга-сулга карамыйча, җиң сызганып, рухланып түләргә керештем. Иң күп язуым шуннан соңгы вакытка туры килә.

Телгә игътибар итә башладым. Татар мәктәбендә укыганга күрә, телебезнең нигезе эләккән инде миңа. Шулай да башта, яза башлаганда, игътибарсызрак булганмын, гәзит теле белән язсаң да, ярый дип уйлаганмын. Телгә игътибар итәргә кирәклеген әйтеп, миңа киңәш бирүче кешеләр Зоммер Гыйләҗев белән Равил Фәйзуллин булды. Рәхмәт аларга!

**– Ә ничек игътибар итәргә телгә?**

– Телне баетыр өчен, китап укырга, бигрәк тә элекке китапларны күбрәк укырга кирәк. Күбрәк уку гына түгел, кулыңа карандаш тотып уку шарт. Мин, үземә кулланырга дип, борынгы сүзләрне язып алам. Әсәргә керткәндә исә, ул сүзләрне астөшермә итеп бирмим, җөмлә агышында аңлашылырлык итеп кулланам.

**– Коръәнне тәрҗемә итү кайчан башыңа килде? Аны кайчан эшли башладың?**

– 1996 елны, Һамбургтан кайткач, Коръәнне тәрҗемә итә башладым. Режимны үземә каты куйдым: сәгать өчтә торам, тәүлегенә унбиш сәгать эшлим. Бу инде бөтенләй тәнәфессез эшләү дигән сүз түгел: берәү дә килә дә алмый, һава суларга чыгарга да ярамый, дигән сүз түгел, әлбәттә.

**– Көндәлек эшкә норма куеламы? Кат-кат язасыңмы, бер генә катмы? Кулдан язасыңмы, компьютердамы?**

– Көндәлек эшкә норма шул унбиш сәгатьтән үзе килеп чыга инде. Шома килеп чыкса – бер кат, кытыршы булса, кат-кат языла. Компьютерда язам.

**– Коръән кайчан басыла башлады?**

– Беренче басма, Аллаһының рәхмәте белән, 2000 елда чыкты. Инде унынчы басмасы дөнья күрде! Кирәксенә халык! Мин Коръәнне радиодан да тулысынча укыдым бит!

**– Афәрин, Батуллин, яшә!**

*Минем фикеремчә, Коръән сүрәләренең мәгънәсен бөтен тирәнлеге белән һәр халыкның баласы үз телендә генә аңлый ала. Коръәннең сиксән телгә тәрҗемә ителеп чыгуы шул фикерне расламыймы? Димәк, Коръәннең татарчага тәрҗемәсенә дә зур ихтыяҗ бар! Алланың изге сүзе, рухи бөеклеге, илаһилыгы ана телебездә дә гарәп телендәге кебек тәэсирле булырга тиеш...*

*Яңа, чын мәгънәсендәге тәрҗемә, төп нөсхәгә якын тәрҗемә атаклы татар язучысы Рабит Батулла тарафыннан башкарылган. Аның теле – хәзерге татар әдәби теле.*

*Коръәнне татарчага тәрҗемә итү үз телебезгә дә йогынты ясамый калмас, дини төшенчәләр генә түгел, фәлсәфи, сәяси, иҗтимагый терминнар да активлашачак, артачак һәм ана телебезнең үз стиленә кайту юллары да ачылачак дип уйлыйм. Ун меңнән артык алынма сүз һәм гыйбарәләр арасында туксан биш проценты дөньяви төшенчәләрне белдерә. Мисал өчен әйтик, «иман», «вөҗдан», «рух», «намус», «җәннәт», «фикер», «дөнья», «гафу», «гыйлем» һәм башка байтак сүзләр һәм абстракт төшенчәләр ана телебезгә Коръәннән килеп кергән, телебезне баеткан. Мәсәлән, телебездәге «Күңел күзең күрмәсә, маңгай күзең – ботак тишеге» дигән мәкаль шикелле гыйбарәләр дә Коръән теленнән кергән һәм кешенең рухи дөньясының әһәмиятен күрсәткән.*

*Рабит Батулла иҗатында тарихи әсәрләр зур урын алып тора – Тукайга, Кәбир Бәкергә, Аксак Тимергә һ.б. багышланганнары, «Сөембикә» романы, «Тузга язмаган хәлләр», «Урыннары җәннәттә булсын» дигәннәре һәм башкалар... Әлеге әсәрләр турында авторның үзе белән сөйләшеп алыйк.*

**– Рабит, халкыбыз тарихында зур урын алып торган шәхесләребездән Рудольф Нуриев турындагы әсәреңне, «Илбашы»н ничек яздың?**

– Әлеге шәхесләр турында мин язмасам, кем язар, мин язарга тиеш, – дип яздым. Бу әсәрләрне мин үзебезне, татарны күрсәтер өчен яздым. Нуриев турында... Аның турында чит илләрдә чыккан китапларны укыдым. Каләм белән. Читтәгеләр аны бию остасы итеп кенә күрсәтәләр. Ул бит безнең милләтебезнең горурлыгы. Һәм ул Америкада чыккан автобиографик китабында үзенең ниндирәк татар икәнен тәфсилләп сурәтләп язган. Һәм аның турындагы китабымда мин аны нәкъ менә милли итәргә тырыштым. Шулай итеп, «Бию җене кагылган егет» дигән роман язылды.

**– Ә Шәймиев турында күп язылды инде, димәдеңме соң?**

– Монысын бит Илфак Ибраһимов оештырды. Ул Минтимер Шәриповичка, 80 яшегезгә китап языйк, дип тәкъдим иткән, үгетләгән. Батулла яза дигәч, Илбашы риза булган. Минтимер Шәрипович бөтен язганнарны укып барды. Беренче нөсхәм бөтенләй ярамады. Калганнарын өлешләп-өлешләп, берсен дә калдырмыйча укыды. Бик эшлекле тәкъдимнәр, кирәкле төзәтүләр кертте. Менә шулай итеп эшләнде бу әдәби һәм документаль әсәр.

**– Югарыдагыларның аның хакындагы искиткеч зур бәяләмә-фикерләрен Минтимер Шәрипович үзе җыйганмы, син җыйдыңмы?**

– Аларны мин җыйдым. Актанышта, Минзәләдә, Зәйдә, Сарманда бу әсәрне тәкъдим итү чаралары булды инде, Питрәч, Буа, Арчаларда әле булачак...

**– Сезнең тормышыгыз куелган юлдан бер мизгелгә дә читкә тайпылмыйча, мультфильмнардагы шикелле тәгәрәп кенә барадыр сыман тоела миңа. Улларыгыз да шундый тәртипледер, шундый тыңлаулыдыр, бернинди мәшәкать-мазар тудырмыйлардыр сыман. Алар чыгып киткәч, сагынасыздыр, юксынасыздыр үзләрен...**

– Минем гаиләм – дәүләт. Президенты – мин. Хатын – финанс министры. Нурбәк – полицейский. Байбулат – халык.

*Дәүләт теле – ана теле, икенче тел – рус теле, ана телен белмәсә генә.*
*Президент Фәрман чыгара: бусаганы атлап керүгә – ана теле генә!*

Якын-тирәдә татар мәктәбе булмау сәбәпле, ике бала да урыс мәктәбендә укыды. Икесе дә – татарча уйлый, татарча сөйли, татарча яза. Бала чактан ук малайларның икесе дә татарга хезмәт итә башлады.

Ялта. «Сөембикә варислары» дигән фестиваль. Бөтендөнья татарларының балалары катнашында сәнгать фестивале. Шунда Байбулат, нәфис сүз остасы номинациясендә Х.Такташ шигырьләрен укып, Гран-прига лаек булды. Олы улым Нурбәк «Татар халык биюләре» номинациясендә Гран-при алды. Бүгенге көндә – профессиональ кинорежиссёр («Мәскәү кино мәктәбе»ндә укыды). Хәзер булачак мөселман киносы җыенында кинорежиссёр буларак катнаша – диплом фильмы белән. Бу фильм Ялтада, «Кинотавр»да приз алды.

Нурбәкнең балет сәнгатенә кереп китүе дә бик табигый булды, кечкенәдән тартылды. Гаиләбез белән театрларның барлык спектакльләренә йөри идек. Байбулат бию сәнгатен аеруча да яратты. Ул хәтта кеше карамыйча ташлап чыгып киткән спектакльләрне дә ахырына хәтле карап бетерә торган иде. Үзе теләп, халык биюе буенча белем алды ул. Аннары, конкурста җиңеп, Кытайга укырга китте. Шәп иттереп кытайча өйрәнеп кайтыр, дип өметләнгән идем, кытай телен белүчеләр бик кирәк бит безгә, ә ул анда кино төшерү эше буенча бик каты мавыга башлаган. Каникулга кайткач, Мәскәүдә шул эш буенча конкурста катнашкан. Хәзер әйтә инде, эти, конкурста җиңсәм, Мәскәүдә калам, җиңмәсәм, Кытайдагы укуымны дәвам иттерәм, ди. Хәерле булсын инде, алар икесе дә бик мөстәкыйль кешеләр, үзләре теләгәнчә булсын, дибез.

Әниләре йомшак булды. Укыганда «2»ле алсалар да, шелтәләмәде, «чыбык», «чыбыркы» күрмәделәр. Мәктәптә дә, училищеда да абруй казандылар. Әхлаклы булып үстеләр. Өйдән чыгып киткәндә дә, әниләре «тәртипле, итагатьле булыгыз», дип озата иде. Әлбәттә, берәр җиргә кунакка-мазарга җыенсалар, «күчтәнәч алырга онытмагыз», дип озата иде. Тәрбия шулдыр инде ул. Үзебезнең яныбыздан чыгып киткәч, балаларыбызны сагынабыз, юксынабыз, борчылабыз. Бик тынгысыз заманда яшибез, куркыныч бит. Алла үзе сакласын инде!

Нурбәк хәзер Яшьләр театрында баш балетмейстер, балаларны, яшьләрне биергә өйрәтә. Үзе дә чыгышлар ясый. Финляндиядәге Дениз Бәдретдин дигән композитор үзенең концертын оештырды, бер-ике бию биеп кит әле, дип, шул концертына Нурбәкне чакырган, биеп кайтты.

Мин аларга егерме биш яшькә хәтле тәмәке тартмыйсыз, аракы эчмисез, өйләнмисез, дигән фәрман чыгардым. Һәм алар икесе дә шул законны тоттылар.

Нурбәк өйләнде инде. Туран исемле оныгыбыз бар.

*«Җәмәгать эше өчен яну көчле Батуллада... Батулла кушканны көндәм рәвештә үтәп-башкарып утыручы түгел. Ул – янып, бирелеп, фидакарьләрчә эшләргә яратылган шәхес, бүтәннәрне үзе белән әйдәргә, аларның да йөрәкләрен үзенеке кебек яндырырга алынган кеше. Тынгысызлык, бирелгәнлек, иманлылык хас аңа. Батулла – безнең буынның бер бизәге, арабызда аның булуы – үзе бер зур куаныч», – дип язды әдип турында Халык шагыйре Равил Фәйзуллин.*


*Әлеге фикерләргә кушылып, Рабит Батуллага саулык-сәламәтлек телик!*

**Саимә ИБРАҺИМОВА**

***Редакциядән:***

*Бу айда каләмдәшебез Саимә Ибраһимова үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез!*

# МИН АЛАРГА МЕҢ-МЕҢ РӘХМӘТЛЕ!



1974 елда университетны тәмамлагач, ирем Наисны (Наис Гамбәр. – *ред.)* китап нәшриятына эшкә алдылар. Мин V курста укый идем әле. Бер үк вакытта кафедрада да эшлим. 1973 елның мартында кызыбыз Гөлназ туды. Өч айлык булгач, кинәт кенә температурасы 39 градуска күтәрелеп, хастаханәгә алып киттеләр. Бер төн эчендә дүрт балалар хастаханәсенә алып барып, бөтен җирен тикшереп, казып бетерделәр – бернинди диагноз куя алмадылар. Таң алдыннан үз кулымда вафат булды. Моннан да зуррак кайгы була микән ана өчен?! Көтеп алган беренче бала! Үлгәч кенә, үпкә авыруы булган, дип яздылар.

Тугыз айдан соң Ләйсән кызыбыз туды. Яшәргә фатирыбыз юк. Ул чакта Наис нәшриятта Рәис абый Даутов белән бер бүлмәдә утырып эшли иде. Аптырагач, Рәис абый үзләренең дачасында яшәргә рөхсәт итте. Шуннан кышка да калдык. Ә кызыбызны әти белән әни янына Яуширмәгә кайтарып куярга туры килде. Бакча өе салкын, агылмый, шуңа күрә электр плитәсен яныбызга куеп йоклыйбыз.

Беркөн шулай төн уртасында баш авыртуына чыдый алмыйча уянып киттем. Карасам, Наис һушсыз ята. Сикереп тордым да плитәне сүндердем. Ишекне ачып җибәрдем. Наисны, караваттан сөйрәп төшереп, һавага чыгарып утырттым. Мендәрләр белән терәп. Ничек көчем җиткәндер, бүген дә шаккатам. Ул көнне эшкә бара алмадык. Икебез дә эштә булмагач, килеп хәлне белделәр. Иртәгесен Рәис абый булышлыгы белән каравылчы өенә күчерделәр. Ул буш иде. Миче дә бар. Утын ягып җылытырга була. Урман – янәшәдә генә. Ремонт ясадык та шунда тора башладык. Язга чыккач, каравылчы килде, тагын түбәсез калдык. Инде нишләргә? Рәис абый белән Диләрә апа үзләренә алып кайтып киттеләр. Воровский урамындагы фатирларына. Рәис абыйның Диләрә апага булган мөнәсәбәтен шунда күреп, хәйран калып сокландым: «тәтием», дип кенә йөртте ул аны. Диләрә апа да аңа һәрвакыт җылы мөнәсәбәттә булды. Диләрә апаның пешергән ашлары, өчпочмаклары, бәлешләре телеңне йотарлык иде. Мин дә аңа булышырга тырыштым. Анда күпме яшәгәнбездер – хәтерләмим. Рәис абый безне кыйгыртып йөри-йөри, Париж Коммунасындагы бер иске йорттан ике бүлмәле фатир бирделәр. Иске йорттан фатир бирергә ярамый иде, тиздән сүтеләчәк йорт иде. Хәзер ул урында КФУның бер бинасы, элекке педагогика университеты. Шулай итеп, Рәис абый тырышлыгы белән без фатирлы булдык. Аннары кызыбыз Ләйсәнне дә алып килдек.

Рәис абый Наиска тәҗрибәле, белемле редактор булырга ярдәм итсә, мине тәрҗемәгә өйрәтте. Кыям абый Миңлебаев белән. Университетта укыганда, Кыям абый безгә тәрҗемә теориясе буенча махсус курс укыган иде. Шулай итеп, 1971 елдан мин тәрҗемә эшенә кереп киттем. Украин язучысы Иван Франконың «Бытбылдык» («Перепел») дигән хикәясе минем тәрҗемәдә беренче булып «Социалистик Татарстан» газетасында басылып чыкты. Аннан китте «Азәрбайҗан хикәяләре», «Мөхәммәд Пәйгамбәр тормышыннан хикәяләр» һ.б. әсәрләрнең тәрҗемәләре. Кыям абый белән Рәис абый мине тәрҗемә юлына кертеп җибәрделәр. Бу – бүгенге көндә минем иҗатымның бер сукмагы. Алар биргән белем ярдәмендә әле тәрҗемә буенча филология фәннәре кандидаты да булдым. Мең-мең рәхмәт аларга, урыннары җәннәттә булсын!

# ИЗГЕ ТЕЛӘКЛӘР БЕЗДӘН...

## (ОСТАЗЫМ РӘИС ДАУТОВКА ЮБИЛЕЕ УҢАЕННАН)

Моннан сиксән еллар элек
Нәүширван мулладан туып,
«Мин – голям»[1] дип аваз салган
Гаҗәеп зирәк бала.
Бүген дә ул, һичбер шиксез,
Дөньясында үтә назыйм[2]
Һәм газыйм[3] булып кала.

Гомерләрен үтеп бара,
Җыеп бәгъренә мең яра,
Эш өчен яна-көя.
Балаларын күккә чөя,
Диләрәсен өзелеп сөя,
«Тәтием», дия-дия.

Ял дигәнне белми эшли:
Хәтта өенә китешли
Ала кәгазь, каләмен.
Әйттең ни дә, әйтмәдең ни –
Соң ноктаны куймый торып,
Һич туктатмый гамәлен.

Мөхәррирлеккә – тәрҗемә,
Тәрҗемәгә гыйльми җөмлә
Ялганадыр берочтан.
Аның тәнкыйди сүзләре,
Чарланып бетеп үзләре,
Оста кисә кылычтан.

Хәләле һич тә сүндерми,
Салкын көлгә дә күмдерми
Йөрәгендәге утны.
Шуңа да ялкаулык тотмый,
Хәтта кырык эш куркытмый
Рәис абый Даутны.

Кайберәүләр көтсәләр дә,
Кайчакларда этсәләр дә,
Буйсынмый явыз котка.
Торсын дип бар да җаеннан,
Зур бәйрәме уңаеннан
Иң изге теләкләр бездән –
Наис белән икебездән –
Рәис абый Даутка!

15.03.2003

**Флёра ТАРХАНОВА**

[1] Голям – ир бала.
[2] Назыйм – төзүче, тәртипкә салучы.
[3] Газыйм – зыялы, бөек, җитди.

# «БҮРКЕМ ИКӘҮ...»

## («ПОЛЯК-ТАТАР» ӘДӘБИЯТЫ ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР)

Һенрик Сенкевич турындагы язма «Казан утлары» журналында *(2017, №12)* басылып чыкканнан соң, көтелмәгән шалтыратулар, фикер алышулар булды. Болар мине кайбер нәтиҗәләргә дә китерде. Бер яктан, укыган җәмәгатьчелектә әдипнең иҗатын татар мотивлары ягыннан тикшерү гаять кирәкле һәм актуаль дип санаганга инандым. Икенче яктан, телне югалту – әдәбиятны да югалту, Сенкевичлардан соң инде бу әдәбиятта татар мотивлары да югалмыймы, дигән сорау да куела.

Аңа җавап бирү өчен, Сенкевичлардан соң бер гасыр үткәч, Польша-Литва-Белорус татарларының иҗаты ни хәлдә, аларның талантлы каләм ияләре әсәрләрендә татар мотивлары бармы соң дигән мәсьәләгә ачыклык кертергә кирәк. Әмма бу эш шактый четерекле. Әгәр Сенкевичның әсәрләре үз вакытында ук рус теленә тәрҗемә ителгән булса, бүгенге авторларның әсәрләре белән танышу өчен, поляк телен белү сорала. XXI гасырда да үзара мәгълүмат алмашу мәсьәләсе хәл ителмәгән! Шуңа күрә язмабызның тулылыкка дәгъва итә алмавын, ул мәсьәләне көн тәртибенә кую төсендә булып, кул астындагы чыганаклар белән чикләнүебезне әйтергә кирәк.

Европа историографиясендә XX-XXI гасырларда этник татарлар тарафыннан поляк, литва, белорус, рус телләрендә иҗат ителгән әсәрләргә карата «поляк-татар» («литва-татар», «белорус-татар») әдәбияты дигән төшенчә яши. Селим Хазбиевичның шигырендә әйтелгән «Бүркем икәү...» фразасы да шуны ныгыта: *«Миндә ике мин бар: поляк һәм татар / берсе – фуражкадан, икенчесе крымка кия»* (крымка – түбәтәйгә охшаган татар баш киеме). Мондый караш безгә дә читтәге татарлар иҗатын татар дөньясы түгәрәгенә җыярга ярдәм итү юлы булып тоела.

Әлбәттә, тел мәсьәләсенә мөнәсәбәттә безнең җирлектә үзгә караш яши. «Тел бетсә – милләт бетә» дигән караш татарларны һәрвакыт йотылудан, туган телебезне җуюдан кисәтеп торган. Шул ук вакытта Бөек Литва кенәзлеге, Речь Посполитаяның уңдырышлы җирләренә Алтын Урда чорында (нигездә, XIV гасырда Бөек кенәз Витовт чакыруы буенча) килеп урнашкан татарлар инде XVI гасырда ук телләрен югалта башлаган дип санала. Аларның полякча, әмма гарәп хәрефләре белән язуы – гомумбилгеле факт. Урта гасырлардан саклана килгән китап язу һәм күчерү культуралары да шактый җентекле өйрәнелгән. Аларда хәзерге көндә гарәп графикасын файдалану традициясе инде югалган, әмма чыгыш, нәсел, гаилә һәм дин үзбилгеләнүне саклый, дигән фикер яши. Динне югалту, башка дингә күчү дә шактый киң таралган күренеш санала.

Хәзерге әдәбият диеп билгеләсәк тә, сөйләшүне 1978 елда Селим Хазбиевичның Ольштында басылып чыккан «Риваятькә тоташу» *(Selim Chazbijewicz. Wejscie w basn. Olsztyn: Pojezierze, 1978. – 63 s.)* шигырь җыентыгыннан башларга телибез. Чөнки бу тупланмада шагыйрь совет шартларында безнең җирлектә күтәрелә алмаган милли проблемаларны куя, иҗаты белән татар әдәбиятының, XX гасыр башыннан алып, Европа әдәбияты белән синхрон, янәшә үсүе хакындагы фикерне ныгыта.

Селим Хазбиевич – билгеле шәхес: Польша татарлары берлеге рәисе, Польшаның Казакъстанда һәм Кыргызстандагы илчесе, Ольштындагы Варминьск-Мазурск университетының Сәяси фәннәр институты профессоры, сәяси фәннәр докторы, шагыйрь. 1955 елда Гданьскида туа, поляк әдәбияты белгече (филолог-полонист).

Беренче шигырьләре 1973 елда вакытлы матбугат битләрендә күренә. Тупланып басылган тәүге «Риваятькә тоташу» җыентыгын шушы чорда татар мотивларын иң көчле яңгыраткан китап дип санылар.

Җыентык өч бүлектән гыйбарәт булып, аның төзелеше, бүлек исемнәре үк эчтәлегенә ишарә ясый. Беренче бүлек китап исеме белән аталган, аңа эпиграф итеп Э.Круктан «Ырудан соңгы кеше икәнлегеңне аңлау» дигән фраза куелган. Фәлсәфи яңгыраган әлеге сүзләр бу төбәктә яшәүче татар-мөселманнарның тормыш кредосы булып яңгырый. унбер шигырьнең алтысының исемнәре үк татар темасына язылганлыгын сөйли: «Робагый», «Колдын» (биредә яшәүче татарларның милли ризык исеме), «Мәчет», «Мәчет» (2), «Мәчет эчендә», «Фәс».

Беренче итеп урнаштырылган «Робагый» шигыре тарихи хәтерне югалту турында сөйли:

*Күләгәләр арасында сугыш киемнәре чыңы*
*Бу җирнең борынгы хуҗалары турында көйли.*
*Алардан тик тузан-туфрак кына калган,*
*Беркем дәшми: шаһитләр – үлгән, үлгәннәр – өнсез...*[1]

Бу җирнең борынгы хуҗалары дип ерак бабаларын хөрмәтләгән лирик геройның үкенече, сагышы – тарихи хәтерен җуйган милләткә дә, яшәешнең, гомумән, һәрнәрсәне тузан-туфракка әйләндереп, алга таба хәрәкәт итүенә дә юнәлтелгән. Милли фәлсәфә һәм гомумкешелек фәлсәфәсе шигырьдә бербөтенгә әверелә. Шул ук вакытта милләтләрнең югалуы-үзгәрүе – яшәешнең табигый законы булып та аңлашыла.

Кайбер шигырьләрдә татар мотивы төп эчтәлекне хасил итә һәм башка төрлерәк нәтиҗәләргә ишарә ясый. Әйтик, шагыйрь:

*Шулпа эчендәге*
*Бөрелгән татар колдыннары,*
*Дога кылганнан соң зиратны искә төшереп,*
*Вакыт санын башлый,*

– дип, татар ризыгының тормышны да, үлемне дә бер үремтәгә тоташтырган кыйммәт булуын ассызыклый. Вакыт – татар ризыгыннан башлана дигән фикер, кешелек гомере, милләт гомере турындагы каршылыклы уйланулар булып, укучы күңелендә дәвам иттерелә.

Исемсез шигырьдәге катлаулы кеше сурәте дини китаплардагы текстларны хәтерләтә:

*Минем тәнем,*
*Ярым ай күк бөгелеп,*
*Очларыннан бөтерелгән*
*Колдын кебек нәфис,*
*Әмма намаздан тынычланган хәлдә дә*
*Мәчеттә ул – сынмас һәм буйсынмас,*
*Догада, сөюдә, фикердә –*
*Почмаклы, үзсүзле...*

Бу шигырьдә дә кеше фәлсәфәсе милли фәлсәфә, дини фәлсәфә белән үрелеп китә.

Йә булмаса шулай ук исемсез шигырьдә иман ныклыгы турында сөйләгән лирик герой мондый сурәт тудыра: *«Бер ялгызым калсам, иманымны / яшел чалма төсле җил урый».* Мәчеттә утырып намаз уку, корбан бәйрәме, җыелып шулпа ашау, дисбе, Кәгъбәне җиде кат әйләнү кебек детальләр, *«Ярым ай булып агачка эленгән иман / Аны юа Висла дулкыннары, / Картайган бронза иман, / Хамаилләр (поляк-литва-белорус*

[1] Бу урында һәм алга таба сүзгә-сүз тәрҗемә – безнеке.

*татарларының изге китаплары. – Д.З.) тышын кыштырдатып / Ымнар кага ерак бабайларга»* кебек катлаулы образлар дини фәлсәфә буларак укыла, бер үк вакытта үзбилгеләнү юлында бәргәләнгән кешенең психологик халәтен тергезә.

Аерым бер шигырьләр – суфичылык фәлсәфәсен кабатлау – шул ук дини, милли эзләнүләр нәтиҗәсе булып аңлашыла. Мәсәлән, «Мәчет» (2) шигырендә манара исеменнән Аллаһка якынаю омтылышы сөйләнә. Мәчет манарасы Аллаһ юлына чыккан суфи хисләрен гәүдәләндерә, таныла торган суфи символлар (кыегаю, кошлар кабул итү һ.б.) шигырьне урта гасыр суфи шагыйрьләр әсәрләренә охшата.

Икенче бүлек «Маддиун-Ана» дип атала, аңа өч шигырь кергән. Сагыну-сагыш хисе белән сугарылган бу әсәрләрдә, топонимнардан кала, татарлыкны хәтерләтә торган детальләр юк. Әмма шигырьләрнең эчтәлеге лирик геройның һәм авторның татар булуына ишарә бирә. Мәсәлән, «Борынгы төш» дип исемләнгән беренче шигырь әнигә багышланган, әмма лирик геройның үкенечен, сагышын, сагынуын үзенә туплаган образ – «Мазар юлы буйлап бара торган карт хатын» сурәтендә зиратның борынгы татар сүзе белән – «мазар» дип аталуы шунда ук хисләр сәбәпчесен мөселман-татар хатынына әйләндерә. Икенче шигырь – «Липек»та милли традицияләрдән ераклашу, Европа культурасына китү турында сүз бара. Күп тапкырлар кабатлана торган «манара» сүзе әлеге югалып баручы традицияләрне мөселманлык белән тигезли.

Күләме ягыннан иң зурысы булган «Илаһи нәзариясен булдыру» бүлегенә 24 шигырь кергән. «Гали һәм унике имам хөрмәтенә поэма»да Коръәни мотивлар уйнатыла. «Диннәрне кушу турында поэма» заманның диннәрне бер тамырдан дип раслаучы концепциясенә мөнәсәбәт белдереп язылган. «Җәлаледдин Руми» шигыре суфи шагыйрь сурәтен тергезә һәм аның карашлары турында сөйли. Бу урында поляк татарларында борынгы бабалары әлеге җирләргә мәҗүси булып күченгәннәр, аннары ислам динен кабул иткәннәр дигән фикернең яшәвен дә искәртергә кирәк. Шуңа да бу әдәбиятта мәҗүсилек һәм ислам янәшә куела, һәр шагыйрьдә диярлек Алтайдан килгән мәҗүси ритуалларга мөрәҗәгать тә (шаманизм), ислам фәлсәфәсе дә чагылыш таба. Әйтерсең лә милли үзбилгеләнү дини үзбилгеләнү белән янәшә бара. Лирик герой «мин кем, кайсы ыру-милләттән» дигән сорау белән бергә «минем динем кайсы» дигән сорауны да куя. Хазбиевич җыентыгының соңгы бүлегендә дә без шушы күренеш белән очрашабыз.

Беренче шигырь җыентыгыннан соң Селим Хазбиевич тагын берничә китап чыгара: «Czarodziejski róg chłopca» (1980), «Sen od jabłek cięźki» (1981), «Krym i Wilno» (1990), «Mistyka tatarskich kresów» (1990), «Poezja Wschodu i Zachodu» (1992), «Rubai'jjat, albo czterowiersze» (1997), «Hymn do Sofii» (2005). Әлеге китапларга гомуми бәя биргән Гжегож Червинский аның әсәрләрендә Шәрык һәм Гареб синтезының үзәктә торуын, татар темасы саклануын билгели һәм төп биш мотив бар дип күрсәтә: дала; анимизм; тәңречелек белән бәйле күчеш мотивы; Илаһига якынаю һәм яшәешнең Берлеге мотивы. Галим фикеренчә, соңгы ике мотив шагыйрьнең суфичылык идеяләре белән мавыгуыннан үсеп чыга, әмма ул – суфи шагыйрь түгел. Суфичылыкның кайбер принципларына мөрәҗәгать итүе исә – тамырларны эзләү, шулар ярдәмендә милли үзбилгеләнү омтылышы белән аңлатыла.

Без дә Хазбиевичның соңрак язылган тагын берничә шигырен мисалга китерүне тиеш табабыз. Менә 2005 елны басылып чыккан «Софияга мәдхия» («Hymn do Sofii») җыентыгындагы «Сагыну» (Melancholia) шигыре:

*Мин татармын.*
*Кырыс дала җиле*
*Битләремне сөя.*
*Ә ватаным яши Вильнадагы*
*Иске мәчет рәсемендә.*
*Славян иркенлеген минем иркәм*
*Көмеш касә белән алга куя.*
*Боҗак туфрагының исе катыш*
*Шәһәрләшкән шәрык хисе кулларында.*
*Бабайларның өнен тыңлап яшим,*
*Яңгырда һәм җилдә.*

Элек-электән татар-нугайлар яшәгән Боҗак далалары исе, җил һәм яңгыр аша лирик герой бабайлар өненә тоташырга омтыла. Шушы детальләр җанның, тәннән чыгып, бабалар рухы һәм өне ярдәмендә Бөек Далага сәяхәте турында сөйләгән шигырьләрендә кабатлана. Мондый шигырьләрдә мәҗүсилек, Тәңре, Алтай, рухлар кебек детальләр кулланыла, лирик герой – борынгы кеше, аучы яки балыкчы булып аңлашыла. Еш кына, дини-суфичыл фәлсәфәдәге бакча образы (яшәеш мәгънәсендә) шагыйрьдә Дала модификациясендә кулланыла. Дала – мәңгелек белән очрашу, үз-үзеңә әйләнеп кайту урыны, җанны табу мөмкинлеге.

Шулай ук Хазбиевичның робагыйлар тупланмасына («Rubai'jjat, albo czterowiersze», 1997) кергән «Бабур-шаһ – Кабул һәм Һиндстанның падишаһы» (Babur Szach, władca Kabulu i Indii), «Суфилар шәме Нәкшбәнди яки Мәхмүд әл-Кашгари» (Światło sufich Nakszbandi czy Mahmud z Kaszgaru) һ.б. текстлары, урта гасырлар төрки-татар шигъриятенә охшатып иҗат ителгән стильләштерү үрнәкләре буларак, хәзерге татар әдәбиятындагы шушы юнәлештәге эзләнү-тәҗрибәләр белән кисешә.

Гомумән алганда, Хазбиевичның фәлсәфи тирән, шәркый уен алымнарын катлаулы табышмак дәрәҗәсенә җиткереп, эстетик алымнардан мәгънә чыгарып, модернистик тәҗрибәләр дулкынында язылган шигъри энҗеләре XX-XXI гасырлар чиге татар интеллектуаль әдәбияты белән бик тә аваздаш тоела. Әмма совет чорында, 1970-1980 елларда, Татарстанда яшәгән татар шагыйрьләре дини мотивлар, милли үзбилгеләнү турында яшерен эчтәлектә эзоп теле белән генә яза алган бер вакытта ислам фәлсәфәсен тудыруы ягыннан бу иҗат XX гасыр башы татар шигърияте эзләнүләренең, өзелмичә, Европада дәвам иттерелүе турында сөйли.

Хазбиевич иҗатында суфичылык фәлсәфәсе күп темаларның берсен тәшкил итсә, хәзерге поляк әдәбиятында аерым бер иҗатчыларда татар мотивлары – тулысы белән суфичыл поэзия үрнәкләренә охшатып стильләштерү булган авторлар да билгеле. Шундыйларның берсе – солдат поэзиясе белән поляк шигъриятенә килеп кергән, Лешек Чахоровский булып танылган Муса Чахоровский. Ул – 1953 елда туган, журналист, Мөселман дини берлегенең Югары коллегиясе әгъзасы, Польшада дүрт айга бер чыга торган «Татар күзәтүе», «Литовск татарлары» басмаларының редакторы һәм унике шигырь җыентыгы авторы да. Аның иҗатында, милли үзбилгеләнү чорын кичереп, ислам динен кабул иткәннән соң, 2006 елдан суфичылык фәлсәфәсенең төрле юнәлешләрен калкыткан әсәрләр пәйда була. Мәҗүси текстларга охшатулар, урта гасырлар төрки шигърияте жанрларын реконструцияләү, стильләштерүләр – образларның гаҗәеп тирәнлегенә, аһәң матурлыгына китерә. Бүген ул Коръәнне поляк теленә тәрҗемә итәргә керешүчеләрнең берсе буларак та билгеле.

Польшада католиклар гаиләсендә туган, нугайлардан килгән нәсел дәвамчысы Анна Кайтохова (1928-2011) – шагыйрә, прозаик, журналист иҗатында да күчмәннәр мотивы – татар мотивы булып калка. Аерым алганда, Г.Червинский шагыйрәнең «татар циклына» «Мин күчмәннәр ыруыннан» («*** Jam z rodu Nomadów...»), «Югарыдан» («Ponad»), «Таң атканда татар догалары» («Tatarskie prośby o świcie»), «Аллаһ сорар» («*** I zapyta Pan...») кебек шигырьләрне кертә һәм аларда лирик геройның суфи шәех исеменнән сөйләвен үзенчәлекле язу манерасы буларак билгели. Мондый әсәрләрдә шагыйрә тудырган дөнья сурәтендә Ул һәм Мин-лирик герой гына булып, ике арадагы әңгәмә белән чикләнү мондый аралашуны эмоциональ яктан гаять тыгызландыра, тәэсир көчен арттыра. Безнең фикеребезчә, аларны дога, Илаһига сыгыну, ялвару, рухларга мөрәҗәгать яки имләү, сихер формулаларына охшатылган икенчел текстлар дип атарга мөмкин. Мәсәлән, «Таң атканда татар догалары» шигыреннән бер өзек:

*Аһ, болытларны куучы, ашыктыручы Илаһи өермә,*
*Аһ, кош мамыгы күк җиңел болыттан яралган авырлы болыт,*
*Кипкән даланы кыз толымнары күк дымга туендыр (...)*
*Аһ, сугышта шәһид киткәннәр истәлегенә ташлар чәчелгән юл,*
*Миңа тугры бул, дус бул, ахыргы көннәремә кадәр...*

Башкарак типтагы әсәрләрне, татар мотивының урта гасырлар әдәбиятына түгел, бүгенге татар әдәбиятына якынрак вариантын без Литва һәм Белорус татар әдәбиятында күрәбез. Рус телендә иҗат итүче Адас Якубаускас – шундыйлардан. Гуманитар фәннәр докторы, Вильнюстагы Миколас Ромерис университеты доценты, Литва татарлары тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү, популярлаштыру белән шөгыльләнүче галим буларак билгеле. Аның иҗатында татар мотивлары еш очрамый, аерым бер очракларда, әйтик, «Торналарның төркемнәре очып үтте...» шигырендәге «Шәрыкка» яки «Көнчыгышка» булып ишетелгән торна тавышлары гомуми контекстта тарихи Ватан белән тәңгәлләшкән кебек, яшерен эчтәлектә тоемлана. Әмма турыдан-туры татар мотивларына нигезләнгәннәре дә юк түгел. Мәсәлән, «Селим Хазбиевичка» (1991) – шундыйлардан, мәдхия жанрында:

*Мин – Кырым ханнары оныгы,*
*Даланың әреме ачысы,*
*Литвада сугышкан батырлар –*
*Оланнар каның тавышы.*
*Башбирмәс морзалар токымы,*
*Шляхтаның кыйпылчык-такымы,*
*Грюнвальдта көрәшкә ташланган*
*Татарлар-җайдаклар торыны.*
*Алты йөз ел яшим Литвада,*
*Үз җирем, үз туган җиремдә.*
*Үз йортым – Иделем яры бу.*
*Кырымның бик ерак яры бу...*

Шигырьдә бу җирләрдә яшәүче татарлар тарихы тергезелә, шул ук вакытта лирик герой үзен һәм Татарстан, һәм Кырым белән бәйләнгән – зур татар дөньясының бер кисәге итеп сизә. Бер үк вакытта Литваның – туган җир, шулай ук ата-бабалар җире булуы ныгытыла. Татарларның батыр, көчле, башбирмәс халык икәнлеге ассызыклана.

2016 елда Белостокта Польша татарларына багышланган еллык басма – «Rocznik Tatarow Polskich» җыентыгында Адас Якубаускасның «Минем Татарстан» («Mój Tatarstanie») шигыре басылып чыга. Шигырьдә «Минем Татарстаным» риторик эндәше кабатлана, шагыйрь «Минем Казаным»ны «рухи Ватаным» дип атый.

Бу язмада телгә алынган шигырьләр, шагыйрьләр – алар олы бер мәдәни катламның бөртекләре генә. Күпсанлы басмалар, җыентыклар, китаплардан җыйнала торган бу мирас, бу мәдәният бүген әле өйрәнелмәгән, үз тикшеренүчеләрен көтә. Әмма ул, һичшиксез, гыйльми-әдәби әйләнешкә кертелергә, бәяләнергә тиеш. Бу очракта без Башкортстанда, Сахада, Үзбәкстанда, башка төбәкләрдә яшәгән, төрле телләрдә иҗат иткән, әсәрләрендә татар мотивлары ачык билгеләнә торган каләм әһелләрен дә күздә тотабыз.

Әлеге зур эштә без читтә яшәүче иҗатчыларның да, Европа галимнәренең ярдәменә дә өмет итәбез, Казандагы поляк телен өйрәтә торган мәктәпнең, бу диаспораның булышлыгы да таләп ителә, сүзгә-сүз тәрҗемә ителгән текстларны язучы-шагыйрьләребездән әдәби эшкәртү дә сорала. Әмма, беренче чиратта, әлеге олы проектны башлаучылар, оештыручылар кирәк...

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА**

* Мәкаләне әзерләгәндә, И.Воевуцкий, Г.Червинский, Г.Ситдыйков материаллары файдаланылды.

# ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ – МИЛЛИЛЕКНЕҢ БАШЫ

Халык авыз иҗатының иксез-чиксез хәзинәсен танып белми торып, шушы халыкның телен өйрәнү мөмкин түгел, дисәк, ялгышмабыз. Кешелек элек-электән өлкәннәрнең акыллы сүзләрен, төпле фикерләрен истә тотып яшәгән. Әүвәлгеләрнең тормыш тәҗрибәсе кешеләргә яшәү дәверендә төрле кыенлыклардан чыга белү юлын күрсәткән. Буыннан-буынга күчеп килгән әлеге кыйммәтләр бүгенге көндә дә зур әһәмияткә ия.

Мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, мәзәкләр, әкиятләр, риваятьләр, дастаннар, бәет-мөнәҗәтләр, лирик һәм йола җырлары, гореф-гадәтләр, милли бәйрәмнәр һ.б., шөкер, халыкта әле дә бар. Татар фольклоры әсәрләренең бер гасырдан ашкан җыелу-туплану тарихы мәгълүм. Фольклор ул һәрвакыт үсештә-үзгәрештә, кәгазьгә теркәлеп калганнары аша гына да яшь буын үзенә бик бай белем туплый ала. Тел өйрәнү мәсьәләсенә килгәндә, фольклор әсәрләре аеруча актуаль. Әдәбият, татар теле дәресләрен, тәрбия сәгатьләрен фольклор әсәрләреннән башка күз алдына китерү дә кыен. Фән-техника, компьютер, интернет заманында яшибез, күп гасырлык фольклор байлыгыбызны тормышта куллануның саега баруы беребезгә дә сер түгел. Моның шулай булуы бик кызганыч, әлбәттә. Авыз иҗатына ихтыяҗның бетүе телгә игътибарның кимүе белән тыгыз бәйле булса, киресенчә, тел байлыгы саегу сәбәпле, замана фольклорының кулланылыштан төшеп баруы проблемасы да юк түгел.

Ничек кенә булмасын, телебезне һәм фольклор байлыгыбызны саклап калу юлларын эзләү һәм табу кирәк. Халык авыз иҗатын балалар күбесенчә мәктәптә тел, әдәбият дәресләрендә өйрәнәләр. Туган телебезгә, гореф-гадәтләребезгә, гомумән, милли-мәдәни мираска әһәмият бирү, һичшиксез, гаиләдән һәм мәктәптән башлана. Шунысы бәхәссез: милли тел, мәдәни байлыгыбызны саклап калу мәсьәләсен җайга салу юлында уку-укыту системасында фольклорны куллану – гаять отышлы чараларның берсе. Фольклор әсәрләре тәрбия бирү максатыннан да, шулай ук телгә өйрәнгәндә, логик фикерләү сәләтен үстерү, сүзлек запасын баету чарасы буларак та кулланыла. Татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре төзегәндә, китап авторлары, фольклор әсәрләренең шушы хасиятен аңлап, халык иҗаты жанрларын әдәбиятның асылына төшендерү, телнең нечкәлекләрен аңлатып бирү өчен файдалана.

Укыту процессында халык авыз иҗаты балага әдәп-әхлак, туган илгә, телгә, мәдәнияткә мәхәббәт, кешеләргә ихтирам, хөрмәт хисләре тәрбияләү белән беррәттән, тел гыйлемен һәм әдәбиятны үзләштерүдә ныклы нигез ролен үти. Фольклорга тиешле игътибар күрсәтелгән дәреслек укытуның сыйфатына бермә-бер тәэсир итә.

Бүгенге көндә Татарстан мәктәпләрендә татар әдәбиятын укыту өчен дәреслекләр җитәрлек. Безне кызыксындырган мәсьәлә – дәреслек авторларының халык авыз иҗатына биргән әһәмияте. Соңгы вакытта рус мәктәпләрендә филология фәннәре кандидатлары Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов һ.б. тарафыннан 5-9 сыйныфлар өчен төзелгән «Татар әдәбияты» дәреслекләре популярлашты. Әлеге дәреслекләр төрле бәхәсләр тууга да сәбәп булды. Төп проблема – рус мәктәбе укучысы өчен дәреслекнең кыенлыгы. Бу урында халыкның үз сүзләрен – «Белмәгәнне белдер, кулына алтын йөзек элдер», дигән мәкальне куллану урынлы булыр. Безгә калса, әлеге дәреслекләр, бай материалны уңайлы һәм аңлаешлы бирү җәһәтеннән, рус телле балалар белән

эшләү өчен дә, үз телен камил белмәгән татар балалары өчен дә бик кулай, әмма уңышка ирешү өчен, төп шарт – дәреслек материалына укытучының осталыгы һәм укучының белем алырга теләге кушылган булу. Тиешле шартлар җитенкерәгән очракта, ягъни әзерлекле һәм тәҗрибәле укытучылар кулында әлеге дәреслек татар әдәбиятын укытуда алдынгы урынга лаек дигән фикеребезне җиткерәбез. Әзерлек дигәндә, монда укытучының билингваль булуы, татар телен генә түгел, рус телен дә бар нечкәлекләре белән белүе, тәрҗемә остасы булуы турында сүз бара, хәлбуки, дәреслек шуны истә тотып төзелгән дә.

Төп авторлары Мотыйгуллина Ә.Р. һәм Ханнанов Р.Г. булган «Татар әдәбияты» дәреслекләренә килсәк, татар фольклоры материаллары бишенче сыйныфтан тугызынчы сыйныфка кадәр һәр дәреслектә эзлекле урын алган. Биредә фольклор әсәрләрен генә түгел, фольклористика фәненә мөнәсәбәтле терминнарны укучыга аңлаешлы телдә аңлата бару да игътибарны үзенә җәлеп итә. «Халык авыз иҗаты», «фольклор», «халыкның сүз сәнгате» кебек төшенчәләр, укучыларның белем дәрәҗәләрен исәпкә алып, һәр сыйныфта җентекле ачыклана, жанрларга бүленеш, жанр төрләре турында мәгълүмат бирелә, схемалар аша яктыртыла, сораулар һәм биремнәр белән ныгытыла. Болардан тыш, билгеләмәләрнең татар телендә һәм дәүләт телен өйрәнүче баланың аралашу теле булган рус телендә дә бирелә баруы бик уңайлы. Жанрлар ягыннан һәр сыйныфта материалның дәреслекләргә гаять оптималь бүленгән булуын искәртми булмый. Бишенче сыйныфта әкиятләргә урын бирелә. Программада каралган 8 әкият арасында татарныкы белән башка халыкларның эпик үрнәкләре дә бирелгән булу әйбәт. Бала татар әдәбияты дәресендә, әйтик, рус әкияте белән татар телендә таныша, бу – балага тел өйрәнү җәһәтеннән файдалы, игътибарын фольклорга юнәлтү ягыннан да отышлы.

Алтынчы сыйныф дәреслеге укучыны мифлар дөньясына алып керә. Моңа кадәрге дәреслекләрдә һәм, гомумән, татар фольклористикасында мифларга аерым игътибар күрсәтелми килүне исәпкә алганда, кешеләрнең дөньяны күзаллавындагы бик борынгы карашларны чагылдырган мифларга дәреслектә бирелгән урын бик җитди яңалык буларак кабул ителә. Әдәбият дәресләрендә фольклорның әлеге төре турында да сүз алып бару укучыны чын мәгънәсендә серле дөнья белән таныштыра, милли мифларга якынайта, дөнья халыклары мифлары янәшәсендә татар мифик образларын күтәрә. Мифлар белән таныштырганнан соң, шушы ук сыйныфта халык җырларына зур игътибар бирелә. Шунысы куанычлы: дәреслек авторлары үз хезмәтләрендә фольклор фәнендәге соңгы казанышларга нигезләнәләр, татар халык җырларын иң соңгы һәм камил бүленештә тәкъдим итәләр. Җырларның йола җырлары, лирик җырлар, тарихи җырлар, уен җырлары һәм такмак-такмаза төрләре дәреслектә бирелгән схемада ап-ачык чагыла, мисаллар отышлы.

Җиденче сыйныф дәреслегендә урын алган йола фольклоры үрнәкләре этник асылыбызны балага аңлату җәһәтеннән искиткеч файдалы. Монда йола фольклорының аңлатылып кына калмыйча, шуларны чагылдырган әдәби әсәрләрдән өзекләрнең дә дәреслектә урын алуын ассызыклап китик. Халык иҗатының әдәбият белән бәйләнешен төрле яклап ачу җәһәтеннән, бу – бик оста алым. Дәреслек татар бәйрәмнәренә генә түгел, башка халык йолаларына да игътибар күрсәтә, әйтик, татарларның Нардуган, бәби туе, Покрау кебек йола-бәйрәмнәре янәшәсендә мариларның Уярня йоласы мисалга китерелә. Шушы ук сыйныфта бәетләр, мөнәҗәтләр турында да сөйләнелә, укучылар борынгы «Сак-Сок» белән танышалар.

Фольклор төшенчәсенең киңлеген раслап, сигезенче сыйныфта да дәреслек татар гына түгел, башка халыклар сүз сәнгате белән таныштыру һәм фольклор белән әдәбият бәйләнешен күрсәтү принцибын саклый, риваятьләр, легендалар, халык музыка уен коралларына, темага ярашлы әдәби әсәрләрдән өзекләргә урын бирә. Бу сыйныфта укучылар артык зур күләмле булмаган текстлар аша татарларның тарихи үткәненә сәяхәт кылалар, Казан ханлыгы чоры риваятьләре белән танышалар, «Казан кайда корылган», «Утсыз кайный торган казан», «Зөһрә кыз» кебек татар халык риваять һәм легендалары белән беррәттән, Урта гасыр Европа халыкларында таралган шундый төр әсәрләрне дә татар телендә укыйлар. Дәреслекнең шушы ук бүлекчәсе Ф.Яхинның

«Һомай кошы», Ә.Еникинең «Курай», Ф.Яруллинның «Моңлы курай» кебек әсәрләрен бирү аша фольклор һәм әдәбият арасындагы бәйләнешне ача.

Тугызынчы сыйныф дәреслеге исә халык иҗатының иң элитар жанрына – дастаннарга киң урын бирә, «Идегәй»гә, «Йосыф кыйссасы»на туктала. Әлбәттә, дастан ул – төрки эпос белән дә, борынгы Көнчыгыш әдәбияты белән дә тыгыз бәйләнеш тота торган четерекле жанр, шуңа да татар дастаннары белән таныштырганда, башка халыклар эпосы белән параллельләр уздыру кирәк. Дәреслектә бу мәсьәләгә игътибар азрак бирелгән, әмма дөнья эпосы янәшәсендә милли эпосның иң гүзәл үрнәкләре читтә калмау куандыра.

Дәреслекләрнең ахырында урнаштырылган «Теоретик сүзлекчә»дә фольклорга караган төшенчәләрнең шактый урын биләве хакында әйтеп үтми булмый, чөнки алган белемне ныгыту этабында мондый сүзлекләрнең әһәмияте биниһая. Программага нигезләнгән әлеге сүзлек, әйтик, укучыларга халыктан язып алынган әкият белән автор әкияте арасындагы аерманы таныта, фольклор белән әдәбият өчен арадаш жанрлар – әкият-поэма, әкият-пьеса, әдәби төр буларак эпос турында мәгълүмат, фольклор жанрларына билгеләмә бирә, әдәбиятта фольклоризм төшенчәсен аңлата.

Фольклор – әдәбиятның чишмә башы. Татар телен һәм әдәбиятын дәүләт теле буларак өйрәнүче рус мәктәпләре укучыларына шушы хакыйкатьне төшендерү юлында әлеге дәреслекләрнең дәрәҗәсен югары дип бәяләргә мөмкин. Һәр сыйныфта дәреслек фольклор белән ачыла, аннан татар әдәбияты ядкарьләренә киң урын бирелә. Дәреслекләр бирегә кертелгән әдәби әсәрләрдә әдипләребезнең халык иҗаты чишмәсеннән ни рәвешле файдалануларын күзаллау мөмкинлеген тормышка ашыруы белән дә кыйммәт. 2014-2016 елларда дөнья күргән, 5-9 сыйныфлар өчен икешәр кисәктән торган әлеге «Татар әдәбияты» дәреслекләре күренекле фольклор галимнәреннән кайберләрен телгә алып китүе белән үзенчәлекле. Рус мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты өйрәнүчеләр өчен белемнең мондые да һич артык түгел, киресенчә, болар бар да укучыны татар мохитенә якынайта. Бирегә татар фольклор мәктәбенә нигез салган Хәмит Ярми, аның эшен тугры дәвам иткән Фатих Урманчеев, Марсель Бакиров, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Флора Урманче, Рәшит Ягъфәров, Ленар Җамалетдинов, Айсылу Садекова, соңгы буын фольклор галимнәре Ким Миңнуллин, Лилия Мөхәммәтҗанова, Илсөяр Закирова һ.б. кебек белгечләр хакында да мәгълүмат кертү нур өстенә нур булыр иде, әлбәттә. Хәлбуки, программада урын чикләнгәнлек кайбер мөмкинлекләрне киметә.

Күзәтүебезгә нәтиҗә ясап әйтсәк, татар теленә өйрәтү процессында татар дөньясына хас гореф-гадәтләр, традицияләр, халкыбыз тарихы, фольклор белән әдәбият арасындагы күпгасырлык багланышларны колачлаган һәм ачып биргән дәреслекләрне хупламый мөмкин түгел. Мондый дәреслекләр татар телен дәүләт теле буларак укытканда (бүген аеруча да актуаль), татар фольклорын башка халыкларныкы белән параллель куя, татар фольклор әсәрләрен гомумкешелек әдәби кыйммәтләре янәшәсенә чыгара, рус мәктәбендә татар фольклорын өйрәнүнең яңа һәм нәтиҗәле юлларын ача. Баланың аңы үсү, белеме арту, чынбарлыкны танып белү тирәлеге киңәю һәм чын кеше булып тәрбияләнүе аның әдәби-мәдәни хәзинәләр катламын тирәнтен үзләштерүгә бик нык бәйле. Иң мөһим аралашу чарасы булган телне шушы телдә сөйләшүче халыкның фольклорына тыгыз бәйләп өйрәтү – һәрьяклап отышлы гамәл.

**Алёна ФӘХРЕТДИНОВА,**
*Казан шәһәре 37 нче гимназиясенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*филология фәннәре кандидаты*

# ДӘРҖИЯ АППАКОВА

*(1898-1948)*



XX йөзнең беренче яртысында татар балалар әдәбиятын үстерүгә үзенчәлекле өлеш керткән прозаик һәм драматург Дәрҗия Сәйфулла кызы Аппакова 1898 елның 2 мартында Уфа губернасының Минзәлә өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Түбән Кама районы) Байгол авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Унөч яшендә Казанга килеп, 1914-1917 елларда керәшен балалары өчен ачылган Укытучылар семинариясендә укый, берничә ел Казанда һәм туган авылында укыта. 1922 елда янә Казанга килеп, совет партия мәктәбендә һәм Казан Зур театры каршындагы театр студиясендә махсус белем алгач, берникадәр вакыт гаскәри театр труппасында артистка, аннары (1925-1928) комсомолның Татарстан өлкә комитетында инструктор һәм ВКП(б)ның Бөгелмә кантоны бүлегендә оештыручы булып эшли.

Башка бик күпләр кебек, Д.Аппакова да әдәбиятка журналистика аша килеп керә. Үткән гасырның егерменче елларында Казанда керәшен татарлары өчен чыга торган «Кызыл әләм» (соңыннан – «Киңәш» исемендә) газетасы битләрендә аның авыл тормышындагы үзгәрешләр, хатын-кызлар хәрәкәте турында күп кенә мәкаләләре, очерк характерындагы язмалары, әдәби парчалары басыла. Урта Азиягә күчеп киткәч, ул ныклап торып әдәби иҗат эшенә керешә. 1932-1940 еллар арасында Ташкентта татар, үзбәк һәм рус телләрендә балалар һәм зурлар өчен төрле милләт халыкларының үткәндәге һәм инкыйлабтан соңгы тормыш күренешләрен яктырткан «Сәнәкчеләр» (1932), «Яшь ударниклар» (1932), «Мәмәт белән Аман карт» (1934), «Хезмәт» (үзбәкчә – «Михнәт», ике кисәктән торган роман, 1934; 1935), «Кечкенә Бануның тарихы» (1937) исемле хикәя-повестьлары, балалар театры өчен «Дошман» (1939) дигән өч пәрдәле пьесасы дөнья күрә. Болардан «Кечкенә Бануның тарихы» повесте аеруча нык танyла. Октябрь инкыйлабына кадәрге татар авылы тормышын, ярлы крестьян балаларының кызганыч язмышын һәм инкыйлабтан соң аларның азат тормыш төзү юлындагы самими хыялларын романтик буяулар белән тасвирлаган бу повесть тиз арада татар, үзбәк, рус һәм инглиз телләрендә басылып чыга.

Дәрҗия Аппакованың Казан чорындагы (1943-1948) әдәби иҗат уңышлары, нигездә, драматургия һәм әкият жанры белән бәйле. Бу елларда ул «Тапкыр егет» (1943), «Шүрәле» (1944), «Бишек җыры» (1946), «Илдус» (1947) исемле пьесаларын иҗат итә. Татар фольклоры мотивларына нигезләп язылган «Тапкыр егет» әкият-пьесасы, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә кат-кат куелып, яшь тамашачыларның мәхәббәтен казана. Ул шулай ук, русчага тәрҗемә ителеп, Казанның Яшь тамашачылар театры сәхнәсендә дә уңыш белән бара.

Гомеренең соңгы елларында Д.Аппакова нәниләр өчен күп кенә әкиятләр һәм кечкенә хикәяләр иҗат итә. Аның халык авыз иҗаты әсәрләренә яки үз фантазиясенә таянып язган әкиятләре («Сөмбел», «Иске чиләк», «Гөлчәчәк белән Сандугач», «Сараның башыннан үткәннәре» һ.б.) һәм кече күләмле хикәяләре («Сөяк саплы пәке», «Йолдызкай», «Ёлка бүләге», «Шыгырдавыклы башмаклар» һ.б.) шул чор татар балалар әдәбиятында Абдулла Алиш традицияләрен уңышлы дәвам итүнең матур бер үрнәге булып торалар.

Дәрҗия Аппакова 1948 елда фаҗигале рәвештә Казанда вафат була. Ул 1935 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы иде.

# ӘНӘС КАМАЛ

*(1908-1978)*



Драматург һәм театр эшлеклесе Әнәс Камал (Әнәс Галиәсгар улы Камалетдинов) 1908 елның 20 февралендә (яна стиль белән – 5 мартта) Казан шәһәрендә татар драматургиясенең классигы Галиәсгар Камал гаиләсендә туа. Кече яшьтән үк әдәбият-сәнгать дөньясында кайнап, язучылар, артистлар белән якыннан аралашып үсә, сигез яшеннән сәхнәгә менә, «Шәрекъ клубы»нда үткәрелгән кичәләрдә катнаша башлый: хорда җырлый, шигырьләр сөйли, соңга таба спектакльләрдә эпизодик рольләрне башкара. Аның каләм тибрәтә башлавы да шушы чорга карый. 1921-1926 елларда яшүсмер егетнең халык авыз иҗаты әсәрләренә ияреп язган беренче пьесалары («Хуҗа Насретдин әфәнде», «Чегән егете белән качкан мулла кызы Хәмидә», «Җизнәкәй» һ.б.) үзешчән сәнгать түгәрәкләре тарафыннан Казанның бистә клублары сәхнәләрендә уйналып йөри, ә 1927 елда иҗат иткән «Биш меңле Гайнетдин» исемле ике пәрдәле комедиясе 1928 елда аерым китап булып басылып чыга.

Театрга, әдәбият-сәнгатькә мәхәббәт 1928 елда Ә.Камалны Казан сәнгать техникумына китерә. Техникумда укыган чорда ул берникадәр вакыт Казан эшче дәүләт театрында әдәби бүлек мөдире булып эшли һәм үзе дә бу театр репертуары өчен кече формалы сәхнә әсәрләре яза. 1931 елда, техникумның театр бүлеген тәмамлаганнан соң, Ә.Камалны Татарстанда яңа төзелгән Беренче районара колхоз-совхоз театрына эшкә җибәрәләр. 1935 елга кадәр ул шунда режиссёр, артист, художник-декоратор һәм театрның директоры булып эшли. Бер үк вакытта шул заман авыл тормышының, колхоз төзелешенең актуаль мәсьәләләрен яктырткан, уңай һәм кире күренешләрне сәхнәдә җанландырган күпсанлы эстрада әсәрләре – сатирик шигырьләр, скетчлар, водевиль, интермедия һәм «Давыл» (1930), «Ике көч» (1931) кебек күләмле пьесаларын иҗат итә.

1935 елда Беренче районара колхоз-совхоз театры нигезендә Минзәлә профессиональ колхоз-совхоз театры (хәзерге Минзәлә дәүләт театры) оешканнан соң, Ә.Камал Казанга кайта һәм 1955 елга кадәр «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә – әдәби хезмәткәр, Татарстан китап нәшриятында – редактор һәм Татарстан Язучылар берлегендә әдәби консультант вазифаларын башкара. Бу елларда драматургның иҗат активлыгы тагы да арта: «Туй» (1939), «Буран» (1943), «Сәлам хат» (1947), «Юллар» (Г.-Х.Садри белән соавторлыкта, 1950), «Март бураннары» (1955) кебек күп пәрдәле һәм берәр пәрдәле дистәләгән драма һәм комедияләре языла. Бу пьесаларның күпчелеге шул замандагы үзешчән сәнгать коллективларының репертуарына кереп, озак еллар буе сәхнәдән төшми уйналып йөри.

Ә.Камалның балалар әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре дә игътибарга лаек. Ул Татар дәүләт курчак театры өчен Г.Тукайның мәшһүр поэмасы нигезендә «Кисекбаш» (1951) исемле комедия яза, атаклы рус балалар язучысы А.Гайдарның «Школа» («Мәктәп», 1956) дигән повестен һәм башка язучыларның әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә; әтисе Г.Камал һәм башка күренекле тарихи шәхесләр турындагы тирән эчтәлекле, сәнгатьчә матур тел белән язылган хикәяләре һәм истәлекләре исә, кат-кат басылып, хаклы рәвештә укучыларның мәхәббәтен казана.

Әнәс Камал 1978 елның 18 мартында вафат була. Ул 1939 елдан СССР язучылар берлеге әгъзасы иде.

# НӘҖИП МАДЬЯРОВ

*(1928-2002)*



Шагыйрь Нәҗип Гәрәй улы Мадьяров 1928 елның 3 мартында Татарстан АССРның Арча районы Кызыл Утар авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1943 елда Кызылъяр авылындагы җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Н.Мадьяров үзенең хезмәт юлын башлый: әүвәл гади колхозчы, аннан дүрт ел буе М.Җәлил исемендәге колхоз бухгалтериясендә хисапчы булып эшли. 1950-1953 елларда Совет армиясендә хезмәт итә, демобилизацияләнеп кайткач, ул – яңадан туган колхозында бухгалтерлык эшендә. Хезмәтеннән аерылмыйча укып, 1956 елда – бухгалтерларның ел ярымлык курсларын, ә тагын бер елдан Яңа Кенәр урта мәктәбен тәмамлый. 1957 елда В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә, дүртенче курста читтән торып уку бүлегенә күчеп, 1960 елдан 1963 елның августына кадәр ул вакыттагы Кызыл Юл районында чыккан «Кызыл юл» газетасында, аннан «Коммунизмга» исемле Арча район газетасы редакциясендә авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире булып эшли.

1962 елда университетны тәмамлый һәм, бераз вакыт Кызылъяр җидееллык мәктәбендә укытучылык иткәннән соң, Татарстанның Лениногорск шәһәренә күчеп китеп, яңа ачылган телевидение студиясендә авыл хуҗалыгы тапшырулары буенча хәбәрче-корреспондент була. 1965-1980 елларда ул Балтач район газетасы «Хезмәт» редакциясендә редактор урынбасары һәм авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире вазифаларын башкара.

1980 елдан башлап Нәҗип Мадьяров Чаллы шәһәрендә яши, андагы әдәби-мәдәни мохиттә кайнап, төбәктәге өметле каләм ияләрен барлауда һәм аларны үстерүдә үзеннән лаеклы өлеш кертә.

Нәҗип Мадьяровның исеме әдәбият мәйданында узган гасырның илленче еллары ахырында күренә башлый. Беренче шигъри җыентыгы («Чык бөртекләре») 1960 елда басылып чыга. Шуннан соң ике дистәдән артык шигъри китабы дөнья күрә. Аның «Син генә уйларымда» (1963), «Уҗымнар уянганда» (1964), «Йөз төрле уй» (1976), шагыйрьнең иҗат йөзен билгели торган төп әсәрләре тупланган «Рәшәле офыкларым» (1979), «Чәчәкле тургай» (1987) кебек лирик шигырьләре тупланган җыентыкларында, юмор-сатира әсәрләрендә («Әптән Гәрәе мәзәкләре», «Көлке төенчеге», «Хикмәтле хәлләр», «Мәсәлләр» һ.б. җыентыклары) шагыйрьнең уй-фикерләре, тыйнак, ләкин эчке мәгънәгә бай самими хисләре, үзара эчкерсез мөнәсәбәтләре чагылыш таба. Юмор-сатира жанрында һәм балалар поэзиясендә дә уңышлы эшли ул. Бигрәк тә балалар өчен күп яза. Төрле елларда Казанда һәм туксанынчы еллардан башлап Чаллы шәһәренең төрле нәшриятларында дөнья күргән «Ялкын яллы кара айгыр», «Үрдәккә ни җитми?», «Ямьле кыш», «Утлы кыя», «Күбәләк», «Җәйге яңгыр», «Салават күпере», «Әби күзлеген эзли», «Кызыклы шигырьләр», «Без ничәү?», «Әкәмәт» китаплары – шулар җөмләсеннән.

Нәҗип Мадьяров – саф күңелле, олы йөрәкле, милли хисле, патриот, соңгы сулышына кадәр шигърияткә, татар дөньясына, язмышына, теленә тугрылыклы булып калган шәхес.

Әдәби иҗат өлкәсендәге нәтиҗәле хезмәтләре өчен аңа 1991 елда «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә.

Шагыйрь 2002 елның 15 апрелендә вафат була. Кабере – туган авылы Кызыл Утар зиратында.

Нәҗип Мадьяров – 1979 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

* Сәхифә «Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек» (төзүчеләре: Р.Даутов, Р.Рахмани. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2009) китабы нигезендә әзерләнде.

# ЫШАНЫЧЛЫ ИЛӘК

***

Өлкән буын Сталинны сагына, диләр. Татарлар, урыслар арасында да, теге кырыс заманнар кайтса, илдә тәртип, гаделлек булыр иде, дип көрсенүләр әледән-әле ишетелгәләп тора.

Тик өлкәннәрнең барысы да бертөсле уйлый дип раслау хата булыр иде. Күптән түгел генә автобуста барганда, ике марҗа карчыгының хатирәләр яңартуына шаһит булырга туры килде. Каршыңда утырып, гәпләшеп барган кешеләрнең сүзенә теләсәң-теләмәсәң дә игътибар итәсең. Нигездә, олырагы сөйләде, кечерәге ым кагып, җөпләп торды.

– Әти-әниемнең, өлкән туганнарымның берсенең дә кабере өстендә рәшәткә юк. «Сталин заманында рәшәткә эчендә яшәдек. Инде үлгәч тә рәшәткә эчендә ятасыбыз килми», – дип, үзләре куймаска әйтеп калдырды. Аларның ихтыярына каршы килә алмыйм инде, – дип «акланды» һәм эчен бушатты карчык.

Зиратка баргач, күршеләренә дә шулай аңлатадыр дип уйлап куйдым. Чынлап та, күпчелек кабердә чардуган куелып, берничәсендә генә булмавы сәер. Аннан килеп, адәм баласы, сәбәбен белмичә, башкаларны гаепләргә маһир. Икенчедән, зиратка мал-туар кереп йөрми ләбаса. Явыз ниятле адәмнәр килеп чыкмаса, кабер ташына кем тисен?!.

***

Андрей Морозовның «Казанские интервью» дигән китабын укып утырам. Кайберләрен укыгач, ай-һай акыллы да, зыялы да кеше икән, дип гаҗәпләнәсең. Кайберләре күптән таныш кешеләрнең яңа сыйфатларын ача. Араларында җенне чыгарганнары да очрый. Кешене ачу өчен, журналист әллә нинди сораулар бирергә, төрлечә котыртырга да мөмкин. Автор түгел, җавап бирүченең фикер сөреше, мантыйгы ачуны китерә.

Менә шуларның берсе – озак еллар Татарстан телевидениесендә диктор булып эшләгән, зәңгәр экранга әләгүе аркасында яхшы танылган агай. Җавапларында тетепме-тетә бу юньләп урысча белмәүче, татар акценты белән урысча сөйләшүче, «колакларыннан тартып үстерелгән» Татарстан чиновникларын. Әйтерсең лә урысча белү, хатасыз сөйләшү оҗмахка юллама алуга бәрабәр. Гомумән, «өлкән туганга» мөкиббән китүе, милләтен, чынбарлыкта, үзен кимсетеп бәяләве белән истә калды бу әңгәмә. Имеш, Казанда түгел, бөтен милләтләргә дә бертигез караучы, татар булганы өчен генә ташлама ясалмаучы бүтән бер шәһәрдә туып-үскәнгә, алдынгы урыс мәдәниятендә тәрбияләнгәнгә, бик бәхетле икән ул.

Йә Раббым, нинди көнгә җиттек. Каюм Насыйри үз заманында, мөселманнарга кырык нәрсә фарыз булса, Россия мөселманнарына кырык беренче фарыз – урыс телен белү, дип язып калдырган. Заман әллә ни үзгәрмәде шикелле: без бүген дә Россия мөселманнары. Әмма урыс теле татар-мөселманнар өчен кайчан беренче фарызга әйләнде соң әле?!

*Ахыры. Башы узган санда.*

***

Күренекле кешеләрнең ирешкән уңышларында хатыннарының өлеше шактый зур, тик аны без белеп, бәяләп бетермибез генә. Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Рафаил Хәкимнең өендә булып, хәләл җефетен – үзбәк кызы Мәүлидә ханымны якыннан күрсәм дә, гәпләшеп утырырга туры килмәгән иде әле.

Ташкентка Сабантуйга баручы Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты делегациясе составына Мәүлидә ханымны да керткәннәр икән. Соңрак Мирза Олугбәк паркында үткәрелгән Сабантуй мәйданында, сез татарлар бигрәк оста дипломат булып чыктыгыз әле, делегациягездә Ташкентта туып-үскән үзбәк кызы булыр дип һич уйламаган идек, дип тел шартлатты җирле хакимият вәкилләре. Ә без: киләчәктә, мондый сәфәрләр вакытында, Казандагы үзбәк милли-мәдәни мохтарияте җитәкчесен дә үзебез белән ияртеп алып барырга кирәк икән, дип мыегыбызга чорнап куйдык.

Табын янында гәпләшеп утырганда, Мәүлидә ханымның ярты гомерен Казан консерваториясендә уздыруын да, музыка белгече буларак, аны Ташкентта үтә торган сәнгать конкурс-фестивальләренә чакырып торуларын да ишеттем. Шулай да аның: «Без Рафаил белән», «Рафаил әйткән иде аны», дип еш кабатлавы миңа нык ошады. Ирен яратмаса, серләре уртак булмаса, киңәшләшеп яшәмәсә, хатын-кыз алай сөйләшмәс.

Тагын шунысы истә калды: үзбәк кызы булганга, татарчасы начарракмыр, дип, юлдашларымның күбесе аңа еш кына урысча мөрәҗәгать итә иде. Мин аңа гел татарча дәштем, татарча тулы-тәфсилле җавап алдым. Соңрак, телебез турында сүз чыккач: «Элек мин татарча сөйли башласам, үзбәк сүзләрен, гыйбарәләрен еш кыстыра идем, хәзер, киресенчә, үзбәкләр белән сөйләшкәндә, татарча сүзләрне ешрак кулланам», – дип көлемсерәп куйды ул.

***

КФУ доценты Азат Ахунов белән Чабаксардан гыйльми җыелыштан кайтып киләбез. Шунда борынгы кулъязмаларыбыз белгече Альфред Бостанов хакында сораштырасы иттем. Голландиядә докторлык диссертациясе яклап кайткан иде, Казанда бик тә эшлисе килгән иде аның. Вузларда эш таба алмагач, КФУ китапханәсенә урнаштыра аны Азат. Ул оештырган, дини мирасыбызны өйрәнүгә багышланган бер конференциядә күреп, чын галим, колачлы фикер йөртә, дип сокланып тыңлап утырган идем мин Альфредны.

– Ике атна элек кире Голландиягә китеп барды бит ул, – дип шаккатырды мине юлдашым. Чынлап та, биш мең сумлык хезмәт хакына яшәве җиңел булмагандыр милләттәшебезгә. Омски егетенә әле фатир өчен дә түләргә кирәк бит.

Мәрхүм галимебез Миркасыйм Госманов, менә шушындый егетләрне күз алдында тотып, татар тарихын ныклап өйрәнү өчен, Көнчыгыш телләрен дә, Көнбатыш телләрен дә яхшы белгән галимнәр кирәк, дигән иде. Альфред нәкъ менә шундый белгеч – гарәп, фарсы, төрек телләрен дә, инглиз, алман, француз телләрен дә белә иде, диләр...

– КФУ китапханәсендә Альберт Фәтхидән соң эшләгән кеше булмаган икән, мондагы байлыкка исең китәрлек, – дип гаҗәпләнеп сөйләгәнен, әле аның Татарстан Фәннәр академиясе каршындагы Ислами тикшеренүләр үзәгендә дә эшләп алуын берничә көн элек Россия Ислам университеты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин дә җиткерде. Аның фикеренчә, мәсьәлә алай ук гади түгел. Гомумән, Европада гуманитар юнәлештә эшләүче галимнәргә эш табуы бик авыр. Үз вакытында Михаил Кемпер да эш таба алмый йөргән иде, хәзер ул – күренекле галим; Альфред – Кемперның шәкерте, яхшы белгеч. Менә грант килеп чыкты да бер елга китеп барды, әлеге проектның вакыты беткәч нишләр? – дип аңлатты безгә вазгыятьне Рәфыйк әфәнде. Ни генә булмасын, мондый галимнәрне ничек тә үзебездә калдырасы, кызыксындыру юлларын табасы иде.

**Рәшит МИНҺАҖ**

Нәсих Таҗи

# МИН

мәсәл

Көннәрдән бер көндә,
Зат алмашлыкларын туплап бергә,
Шагыйрь саллы гына шигырь язган.
Шәп баш уйлап куясы гына калган,
Ул аны алмашлыклардан эзләгән.
Әрсез «Мин!» түзмәгән:
– Бу шигырьгә Башка
Сүз юк миннән башка, – дигән.

Син дә, ул да – миннән тора аста,
Юктыр берсенең-бер өндәве дә!
«Без»ләр безләсә дә күпме генә,
«Сез»ләре дә, «алар»ы да көлке генә –
Шулармы Баш булып өскә менә?

Юк монда миңа тиң! –
Шулай дигән дә «Мин!»
Өндәвен кадап, Баш булып утырган.
– Тәмам азды, чукынган,
Бу «мин» чыгырыннан ычкынган,
Сине, аны, безне, сезне –
Беребезне дә санламый,
Әйткәнне дә аңламый...

Алмашлыклар шулай аны сүккәннәр,
Берәм-берәм шигырь юлын сүткәннәр,
Башка шигырьгә күчеп киткәннәр.
«Мин!» калган утырып,
Өндәвенә тотынып.

Габделхак Әхмәт

# КАЙТКАН!

*Орёл шәһәрендә Явыз Иванга һәйкәл куелу уңаеннан*

ПАМФЛЕТ

Шау-гөр килә халык, нәрсә булган?!
Йөгерәләр шашып, ашкынып,
Икән, диләр, Явыз Иван кайткан,
Тимер атка, имеш, атланып.

Мин дә киттем әле күрергә дип,
Кем бүлдергән безнең гаетне
Әйе, кайткан, кылыч, тәре тотып,
Ташламаган иске гадәтне.

Кемне куркытам дип кайттың соң син?
Синсез дә күп бүген тукмаклар.
Алар синнән күпкә усалрак,
Сине алар санга сукмаслар.

Кайткан икән, нигә шаккатырга,
Тик шулай да торам уйланып.
Торсын, димен, мәңге постаментта,
Явызлыкның символы булып.



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Бары бер җөмлә

Тукай клубында язучылар җыелышы бара. (Узган гасырның 80 нче еллар ахыры.) Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева, «Идел» журналының берничә санын күтәреп, трибунага менеп бара:

– Менә, иптәшләр, күрегез, журнал тышлыгында сан саен ялангач кыз сурәте! Күрелмәгән хәл бит бу! Безнең татар кызлары беркайчан да болай чишенеп, ялангач килеш ятмаган!

Шул мәлдә арткы рәттән Батулланың калынча тавышы ишетелә:

– Алай булгач, җиде миллион татар каян чыккан соң?!

Халык дәррәү көлә. Гөлшат ханымның мул борыны кызарып чыга.

Шушы бер җөмлә тиз арада бөтен татар галәменә таралды. Хәтта чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез дә шау килде. Батулланы Финляндия, Төркия, АКШ татарлары чакырып кунак итте.

Шушы бер җөмлә – үз-үзеннән көлә, шаярта икән, димәк, халык яши! – дигән рухи канат татарны күккә чөйде. Батулла да, яңа дәрт белән, котырып яза, том арты том чыгара башлады.

Аңа һәйкәл куяр өчен, шушы бер җөмлә дә җиткән иде, югыйсә...

## Бәрәңге

Язучыларның Тукай клубында партия җыелышы бара. Президиумда Өлкә комитетыннан килгән түрәләр дә утыра. СССР Югары советына депутатлыкка Гариф Ахунов кандидатурасы күрсәтелә. Бер-берсен уздырып, әй мактыйлар үзен, әй мактыйлар – түзсен генә җитәкчебез.

Менә, трибунага кечтеки башлы, юкагир гәүдәле Җәвад Тәрҗеманов күтәрелә:

– Иптәшләр!

Аның энә күзеннән чыккандай нәзек, күкертле әче тавышы залны сискәндереп куйды:

– Җәмәгать, кемне тәкъдим итәбез без халыкка, ә! Тюремщик бит ул, утырып чыккан кеше. Депутатлыкка без кристальный чиста кешене күрсәтергә тиеш. Мин – каршы!

Трибунага Габдулла Шәрәфи чыга. Гомере буе «Азат хатын» журналында үткер хатын-кызлар арасында изелеп, бик йомшак сөйләшүгә күнеккән әдип юаш кына сүз башлый:

– Гарифны ачлык елда колхоз кырыннан ике капчык бәрәңге алып кайтканда тоталар. Үсмер егет ике капчык бәрәңге өчен утырып чыга. Күз алдына китерәсезме, җәмәгать, ике капчык бәрәңге... Ачтан үлмәс өчен... Кырык ел үткәч, шул ике капчык бәрәңгене искә төшереп утырабызмы?! Ике капчык бәрәңге өчен...

Бәрәңге... Бәрәңгегә... Бәрәңгене... Бәрәңгедән... Зал гөр килә, гүя дөбердәтеп бәрәңге тәгәрәтәләр. «Аңлашылды!» – дип, кул чабып, үтә беркатлы Габдулла Шәрәфине трибунадан чак төшерәләр.

Арткы рәттә Туфан Миңнуллин белән Батулла сөйләшеп утыра:

– Тормышта ваклыктан саклан, бассаң, улым, банк бас! – дия иде минем әти, – ди Туфан Миңнуллин.

– Да-аа, статьясы бәләкәй булган шул. «Халык дошманы»на тарттыра алмаган, – ди Батулла.

## Утыз өч һәм бер

Чордашлары арасыннан беренче булып Батулла «Жигули» маркалы машина сатып ала. Моны күргәч, Аяз Гыйләҗев көнләшүен яшерә алмаган:

– Слушай-парин, менә мин утыз өч пьеса язып, илнең җитмеш ике театрында куйдырдым, ә машина алалмадым, – дигән.

– Машина алыр өчен, Аяз ага, утыз өчне үк язарга кирәкми, «Кичер мине,әнкәй!» кебек бер пьеса язу да җитә, – дигән Батулла.

## Тибеп кал!

Беренче пьесасын куйдыргач, Батулла Мәдәният министрлыгыннан кесә тутырып гонорар алган. Кемнәрнеңдер исендә калырлык итеп сыйларга дип, язучылар оешмасына килгән. Коридорда бильярд уйнаучы бер төркем язучылар янына җитәрәк, тыгыз итеп бәйләнгән мең тәңкәлек пачканы (ул дәвердә шактый зур сумма) идәнгә ташлаган да аяк очы белән тибә-тибә килә икән. Мул акча мәсьәләсендә тәҗрибәле Туфан Миңнуллин, моны күреп алгач:

– Ярлы чакта тибеп кал, Батулла, баегач тибә алмассың! – дигән.

## Җырдан – җылауга

Минзәлә театрында Рабит Батулланың «Каерылмасын канатың» дигән спектакле бара. Премьерага бер төркем язучылар да килгән. Сәхнәдә хәлләр куера. Аерылышыр дәрәҗәгә җиткән ата-әнкә арасында кыз бәргәләнә, «Аерылмагыз, аерылмагыз...» дип инәлепләр җылый. Зал лышык-лышык җылый. Кулъяулыклар манма.

Соңыннан, спектакльне кабул итәргәме-юкмы дигән киңәшмә вакытында, Туфан Миңнуллин болай ди:

– Батулла тагын шундыйрак ике-өч җыр өстәгән булса, халыкны залдан носилка белән алып чыгарга туры киләсе иде...

## Буранны билгә урап

Батулла иртән бик шәпләп күнегүләр ясый. Билдән чишенеп ташлый. Нәселле йомран йоткан шикелле тыгыз эч мускулларын астан өскә, өстән аска, уңнан сулга, сулдан уңга йөртеп уйнатып ала. Стенага беркетелгән баскычта атына. Аннары, салкын су белән тәнен кызыштырганнан соң, табынга утыра. Өч яшьлек җылкы малының түш итеннән әнис орлыгы кушып үзе әзерләгән казыны Мәскәү күренерлек итеп юка гына турый. Шул юка кисәкләрне кара ипи телеменә бер кат тезә. Аның өстенә нәзберек киселгән лимон тәгәрмәчләрен куя. Чамалап кына тоз сибә, лимонның сусыл күзәнәкләренә мәмрәп пешкән мүк җиләкләрен батыра. Аннары иң өскә шәмәхә алабута сыман рәйхан яфракларын сала, аның өстенә Тын океаннан кайткан чекердәп торган кызыл уылдык түши – шулай итеп, бәрәкәтле авызга озатыласы бутерброд әзер була!

Чәйдән соң эш бүлмәсенә чыга. Тәрәзәне ачып куя, «Шәп, афәрин!» – дип, буранлы көнне котлый да, билдән ялангач килеш кенә утырып, компьютерын кабызып җибәрә. Ачык тәрәзәдән мыштым гына өйгә үрләгән җәяүле буран биленә сөлге булып уралганчы яза да яза Батулла.

* * *

Батулланың Чыршы авылында йорты бар. Җәйләрен ул шунда ял итә. Авылда «илһам китерүне» үзенчә әзерли ул. Язар алдыннан музыкага бирелеп ала. Балтадан «Әпипә» көен, аркылы пычкыдан «Зиләйлүк»не чыгара. Җиде төрле курайда озын көйләр сыздырып ала. Борынының бер тишеген бармагы белән каплап, «Гобой гитарасы»н чината. Аннары революциягә кадәр ясалган кыңгырауны, күрегә ямаулы тальянын ала, елап җырлый-җырлый, җырлап елый-елый уйный да тәмам арып язарга утыра.

## РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ПРЕЗИДЕНТЫН САЙЛАУ

18 март – Россия Федерациясе Президентын сайлау көне. Үзәк сайлау комиссиясендә кандидат сыйфатында сигез кеше теркәлде. Менә алар: Сергей Бабурин (РОС), Павел Грудинин (КПРФ), Владимир Жириновский (ЛДПР), Владимир Путин (үзен үзе тәкъдим итте), Ксения Собчак (Гражданлык инициативасы), Максим Сурайкин (Россия коммунистлары), Борис Титов (Роста), Григорий Явлинский (Яблоко).

## ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВ ОЧРАШТЫРА

Татарстанга Кыргызстан Республикасының «Айтматовлы һәм Айтматовсыз дөнья» кинопроекты авторлары – Чыңгыз Айтматовның улы Әскәр Айтматов, режиссёр Бакын Карагулов, төшерүче оператор Айбәк Җангазиевлар килде. Кинопроект Чыңгыз Айтматовның тууына 90 ел тулуга багышлана. Беренче көнне кунаклар Чыңгыз әкәнең әнисе ягыннан нәсел җепләре тоташкан Кукмара районында булдылар. Икенче көнне аларны Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов кабул итте.

Кыргызстаннан килгән кунаклар Татарстан Язучылар берлегендә республикабызның каләм ияләре белән очрашты. Очрашуда язучылар Разил Вәлиев, Рабит Батулла, Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Зиннур Мансуров, Вахит Имамов, Роберт Миңнуллин, Газинур Морат, Эльмира Шәрифуллина, әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов, «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары, «Мәгариф» журналының баш мөхәррире Сөмбел Таишева катнашты. Очрашуны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов алып барды.

## ҖӘЛИЛНЕҢ ТУГАН КӨНЕНДӘ

15 февраль – Муса Җәлилнең туган көнендә язучылар, сәнгать әһелләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, ветераннар, студентлар, мәктәп укучылары каһарман-шагыйрьнең Казандагы 1 Май мәйданындагы һәйкәленә чәчәкләр салды. Ул көнне ТР Милли музеенда «Моабит дәфтәрләре»нең төп нөсхәсе күрсәтелде.

## ЯҢА КИТАПЛАРНЫ ТӘКЪДИМ ИТҮ

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан 2016-2017 елларда әзерләнгән һәм нәшер ителгән фәнни-гамәли басмаларны тәкъдим итүгә багышланган чара үткәрелде. Анда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Министрлар Кабинеты, Мәгариф һәм фән, Мәдәният министрлыклары, Фәннәр академиясе, фәнни оешмалар, учреждениеләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашты. Әлеге чара кысаларында татар әдәбияты, тел гыйлеме, халык иҗаты, сәнгать, чыганак һәм рухи мирас кебек юнәлешләр буенча әзерләнгән һәм нәшер ителгән китаплар тәкъдим ителде. Җәмгысы – 70тән артык китап. Алар арасында сигез томда нәшер ителәчәк «Татар әдәбияты тарихы»ның бишенче томы (1917-1956 еллар), Татар әдәби теле тарихының икенче томы (XII гасыр – XX йөз башы), «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең өченче томы, «Габдулла Тукай. Энциклопедия» кебек саллы басмалар бар.

## «ЯРА» – ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘ

Төркиянең Истанбул шәһәрендәге «Палто» нәшриятында Аяз Гыйләҗевнең «Яра» повесте дөнья күрде. Аны төрекчәгә Фатих Кутлу тәрҗемә итте. Ул әдипнең «Өч аршын җир», «Җомга көн, кич белән...» кебек әсәрләрен тәрҗемә иткән иде инде.

## ЮБИЛЕЙЛАР

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең тууына 90 ел тулуга багышланган әдәби кичә булып узды. Шушы юбилей алдыннан Татарстан китап нәшрияты әдипнең алты томлык сайланма әсәрләрен бастырып чыгарды. Театр фойесында ТР Милли музее һәм ТР Милли китапханәсе оештырган, язучының шәхси әйберләре, кулъязмалары, китаплары куелган күргәзмәне карарга, юбиляр турында библиографик белешмә белән танышырга мөмкин иде.

Аяз Гыйләҗевнең иҗатын барлауда, мирасын саклауда аның хатыны Нәкыя ханым зур эш башкара. Кичәдә аңа Татарстан Республикасының беренче Президенты, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев

исеменнән Рәхмәт хаты тапшырылды. Аны ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин тапшырды.

Кичәдә язучылар Рабит Батулла, Ркаил Зәйдулла, галимә Миләүшә Хәбетдинова, Аяз Гыйләҗевнең уллары – тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев белән драматург Мансур Гыйләҗев һ.б. чыгыш ясады.

Әдипне искә алу кичәсендә Камал, Тинчурин театрлары, Әтнә татар дәүләт драма театры артистлары А.Гыйләҗев әсәрләре буенча куелган спектакльләрдән өзекләр күрсәттеләр. Камаллылар Аяз ага турындагы истәлек-хатирәләре белән дә уртаклашты.

***

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында татар әдәбияты классигы Фатих Хөснинең тууына 110 ел тулуга багышланган әдәби кичә булды. Ул композитор Хөснул Вәлиуллинның Фатих Хөсни сүзләренә язылган «Кошлар тынды» җыры белән башланып китте. Экранда әдипнең тормыш, иҗат юлын чагылдырган фоторәсемнәр күрсәтелде. Кичәне Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин ачып җибәрде. Әдәбият галиме Рифат Сверигин Фатих Хөснинең иҗаты турында сөйләде. Татарстанның халык артисты Равил Шәрәфиев хатирәләре белән уртаклашты. Аудиоязмада Ф.Хөснинең үз тавышын ишетү, «Җәяүле кеше сукмагы» романының язылу тарихын, татар әдәбияты классигы Ибраһим Газиның, язучының кызы Фәридә ханымның, шулай ук Г.Камал театры артистларының истәлекләрен тыңлау кичәнең матур бизәкләре булды. Татарстанның халык артистлары Хәлим Җәләй, Зөфәр Харисов, нәфис сүз остасы Розалия Зәкиева әдипнең әсәрләреннән өзекләр укыды. Г.Камал театрында Илгиз Зәйниев инцинировкасы буенча куелган «Йөзек кашы» спектакленнән өзек күрсәтелде. Шагыйрә Нәҗибә Сафина Фатих агага багышланган шигырен укыды. Әлеге чарада әдипнең якташлары – Теләче районы үзешчән сәнгать осталары да чыгыш ясады. Кичәне Татарстанның халык артисты Луара Шакирҗанова алып барды.

***

Татар әдәбияты классигы Фатих Хөснинең тууына 110 ел тулуны әдипнең туган ягы – Теләче районы Олы Мәтәскә мәктәбендә зурлап билгеләп үттеләр. Укучылар Казаннан кайткан бер төркем язучылар белән очраштылар, аларның Ф.Хөсни турындагы истәлекләрен тыңладылар.

Юбилей чаралары районның Мәдәният йортында дәвам итте. Монда үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт, язучылар Фоат Галимуллин, Әхәт Гаффар, Камил Кәримов, Рашат Низами, Марат Әмирхан, Фирүзә Җамалетдинова, Дания Гайнетдинова һәм нәфис сүз остасы Розалия Зәкиева чыгыш ясады. Кичәдә шулай ук районның һәвәскәр артистлары да катнашты. Кунакларны Теләче муниципаль районы башлыгы Илдус Зарипов каршы алды һәм аларны районнардагы яңа төзелешләр белән таныштырып йөрде.

***

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концертлар залында Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фәнис Яруллинның тууына 80 ел тулуга багышланган «Җилләрдә сыналган җилкән» дип аталган юбилей кичәсе булып узды. Залга әдипнең каләмдәшләре, укучылары, якыннары, якташлары җыелган иде. Алар алдында Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары Эльвира Камалова мәрхүмнең хатыны, озак еллар аның янәшәсендә булган якын кешесе Нурсөя Яруллинага «Фидакарь хезмәт өчен» медален тапшырды. Кичәдә ТР Дәүләт Советының мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, «Россельхознадзор»ның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе, Баулы якташлар җәмгыяте рәисе Нурислам Хәбипов, Баулы муниципаль районы башлыгы Рамил Гатиятуллин һ.б. чыгыш ясады. Миңгол Галиев, Асаф Вәлиев, Гөлнара Тимерҗанова, Рәсим Низамов, Лилия Хәйруллина, Чулпан Йосыпова Фәнис Яруллин сүзләренә язылган җырларны башкарды.

## ИСХАКЫЙНЫ ИСКӘ АЛУ

Чистай районы Наратлы Елга мәктәбендә тууына 140 ел тулу уңаеннан татар әдәбияты классигы Гаяз Исхакыйны искә алу кичәсе булды. Кичәдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, шагыйрь Газинур Морат, язучы, шагыйрә, әдәбият галимәсе Рифә Рахман катнашты һәм чыгыш ясады.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Казан утлары» журналы редакциясе филиалы бүлек мөхәррире **Юнысов Рәфикъ Юныс улы** Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: повести Р.БАТУЛЛЫ «Ниломанного гроша», А.АХМЕТГАЛИЕВОЙ «Белые ичиги»; рассказ Р.МУХАМАДИЕВА «Пасмурно, с прояснением...»; стихи Дж.СУЛЕЙМАНА, А.СУФИЯНОВА, Г.БАТТАЛОВОЙ.*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«150 лет со дня рождения М.ГОРЬКОГО»: М.ГАЛИЕВ. «Великий писатель»; М.ГОРЬКИЙ. «Лев Толстой».*
*«100-я страница»: Р.БАТУЛЛА. «Язык мой – враг мой!»*
*«Новые имена»: стихи А.ХИСАМИЕВОЙ.*
*«Драматургия»: З.ХАКИМ. «Свет в твоём окне».*
*«Литература народов мира»: рассказ А.ГАЛГОЦИ «Ни шагу!»*
*«Кандидаты на Государственную премию имени Г.Тукая»: Р.ХАННАНОВ. «Пишу то, что прожито...»*
*«75 лет Р.Юнусу»: стихи и фотографии поэта.*
*«80 лет Р.Батулле»: С.ИБРАГИМОВА. «Мои восхищения...»*
*«90 лет со дня рождения Р.ДАУТОВА»: Ф.ТАРХАНОВА. «Благодарю за всё!»*
*«Литературная критика»: Д.ЗАГИДУЛЛИНА. «Каждому по шапке...»*
*«Слово педагога»: А.ФАХРУТДИНОВА. «Фольклор – начало великого».*
*«Из записной книжки»: миниатюры Р.МИНГАЗА.*
*«Сенной базар»: басня Н.ТАЗИ; памфлет Г.АХМЕТА.*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Заинск. Водохранилище». Картина Виктора Хрулёва; деревня Нижние Лузи Заинского района. Отчий дом Рабита Батуллы. Фото Фаниля Гилязова.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: stories by R.BATULLA «Not worth a dime», A.AKHMETGALIEVA «White Ichigos»; story by R.MUKHAMADIEV «Dreary with clearing...»; poems by J.SULEYMAN, A.SUFIANOV, G.BATTALOVA.*
*«Actual criticism»: section is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*«150th anniversary of M.GORKY»: M.GALIEV. «Great writer»; M.GORKY «Leo Tolstoy».*
*«100th page»: R.BATULLA. «Loose lips sink ships!»*
*New names: poems by A.KHISAMIEVA.*
*«Drama»: drama by Z.HAKIM «Light your fire».*
*«Literature of the peoples of the world»: story by A.GALGOCI «Not a step!»*
*«Candidates for the State prize named after G.Tukay».*
*R.KHANNANOV. «I write what I have lived...»*
*«R.Yunus is 75 years old»: poems and photographs by the poet.*
*«R.Batulla is 80 years old»: S.IBRAGIMOVA. «My admiration...»*
*«90th anniversary of R.DAUTOV»: F.TARHANOVA «Thank you for everything!»*
*«Literary criticism», D.ZAGIDULLINA. «To each a hat...»*
*«Word of the teacher»: A.FAHRUTDINOVA. «Folklore is the beginning of the great».*
*«From the notebook»: miniatures by R.MINGAZ.*
*«Hay market»: fable by N.TAZI; pamphlet by G.AHMED.*
*«Pages of humor»: section is conducted by M.GALIEV.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: «Zainsk. Reservoir». Picture by Victor Khrulev; Nijniye Luzi village of Zainsk district. Father's house of Rabit Batulla. Photo by Fenil Gilyazov.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Зәй. Сусаклагыч күренеше. *Виктор Хрулёв картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Рабит Батулланың туган нигезе.
Зәй районы Түбән Олыҗы авылы. *Фәнил Гыйләҗев фотосы.*